# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

*«Мәйдан – батырлар өчен!» әдәби конкурсы:* Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА. Без барабыз, ул килмәс... *Повесть.* ....3

Айрат СУФИЯНОВ. Хак Тәгалә безне җанлы иткән... ... *Шигырьләр.* ....87

Равил САБЫР. Фәхрине үтереп ташладылар. *Роман.* ....92

Лилия ФӘТТАХОВА. Вакыт күк тарала хәятнең өннәре... *Шигырьләр.* ....132

Рафис СӘЛИМ. Агыйделнең бу ягында. *Хикәя.* ....136

Рифат СӘЛАХ. Вакыт ага... көзге яңгыр булып... *Шигырьләр.* ....139

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Якуп ӨМӘРУГЛЫ. Хикәяләр. *Төрекчәдән Зарина МОСКАУ, Карлыгач МУКАШЕВА һәм Рафис КОРБАН тәрҗемәләре.* ....143

ЮБИЛЕЙЛАР

Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Аны Мәскәү таныган *(Юныс Сафиуллинга – 75 яшь).* ....152

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Хисчән фикерле шагыйрь *(Рәшит Әхмәтҗанов иҗаты турында уйланулар).* ....157

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ЧИТ ТЕЛЛӘРДӘ

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Хикәянең дәвамы бар. ....167

Әлфинә СИБГАТУЛЛИНА. Төркиягә Казан күчтәнәче. ....168

ИДЕЛ БУЕ БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮНЕҢ 1100 ЕЛЛЫГЫ

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. XVI гасырның икенче яртысы – XYIII йөзнең уртасында Идел-Урал төбәгендә ислам дине. ....174

ХӘТЕР

Шамил СИРАҖЕТДИНОВ. Бабалар җиренә тартылу. ....182

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Бүген дә уйланып укырлык. *(Гали Хуҗиның тууына – 110 ел). Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* ....186

ПЕЧӘН БАЗАРЫ

Дамир БӘДРИЕВ. Сәяхәтче чебеннәр. *Юмористик хикәя.* ....188

«Казан утлары» архивыннан. ....172

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

КАЗАН УТЛАРЫ

*№ 10 (1200) 2022*

*БАШ МӨХӘРРИР –*

**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*

**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**

*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**

*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**

*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**

*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**

*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 28.09.2022, график буенча 28.09.2022, басылып чыгу вакыты 03.10.2022
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-2882. Тираж 7488.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.

12+

© «Казан утлары», 2022 ел

Çəçmə əsərlər
Чәчмә әсәрләр

*«Мәйдан – батырлар өчен!» әдәби конкурсы*



Айгөл
Әхмәтгалиева

# БЕЗ БАРАБЫЗ, УЛ КИЛМӘС...

ПОВЕСТЬ

*Алдагы көн агырга**
*Без барабыз, ул килмәс.*
«Идегәй» дастаныннан

«Бу юлы сыртыңа салмасаммы», диюе булды, ахры... Болай да була икән, болай да китереп сылый икән...

Борын канатына көн буе мич куенында, чуен чүлмәктә утырып, тел очына эләгүгә мәмрәп кенә китәрдәй тозлы каз итенең хуш исе килеп ягылды. Алай дисәң... Каз ите түгелдер инде ул. Әнисе капкорсаклы мичкәгә ат ите тозлап куя бит, шуны пешергәндер.

«Ехали казаки с Дона домой, обманули Галю, забрали с собой».

Мул күкрәкле Галяны карурман уртасындагы карт имәнгә чәч толымнары белән бәйләп куйганнар, аяк астына коры-сары түшәп, учак тергезергә җыеналар... Менә монда алып гәүдәңне генә түгел, керфегеңне селкетә алмыйча кадакланып ятмасаң, чукмар йодрыкларың белән бер-ике генә селтән бит инде, йә булмаса, баш аша чөеп кенә тузгыт үзләрен.

«...Не мешай мне, добру молодцу, думу думати...»

* Агыр – олылык, хөрмәт (Идегәйнең бу сүзе «алдагы көннең бәхетенә без үзебез барабыз, ул үзе килмәс» дигәнне аңлата).

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА (1973) – *язучы; М.Кашгарый исемендәге халыкара премия лауреаты. «Синең өчен яшим», «Баланнарда бал тәме», «Таллыкүлдә былбыл бар» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

Тфү, каһәр! Болай да вакыт-вакыт төпсез чокырга әйдәгән саташулы күренешләрдән, орчык урынына бөтерелгән керделе-чыктылы уйлардан ничек котылырга белмә дә, «думу думати», имеш... Тавышсыз килеш эчтән генә Пугачёв җырлары җырлап ятарлык шул хәлкәйләр. Җитмәсә, каз ите исе, диме? Ис сизгән кеше шикелле... Исеңне дә, төсеңне дә җуйдырта торган хикмәт булып чыкты әле бу. Шулай ук соңгы нокта микәнни? Әнкәсе пешергән ашлар, әткәсенең җырлары, мәрхүмнәрнең рухы, тикмәгә генә өн һәм төш булып, кырыйда бөтерелеп йөрмидер.

Ирнең хәлсезләнеп калган кулы, кершәндәй ак җәймә өстеннән шуышып, йөзенә таба күтәрелде. Каны качкан бармак битләре ияк, яңак тирәләрен сыйпап узды. «Сакал баскан». Баш миенә йөгергән, хиссез-тойгысыз гына тоелган әлеге уй бераздан, бәйләнчек чебен шикелле, өзми-куймый бөтерелергә тотынды. «Шәфкать килгәч, сурәткә чәпетергә кирәк. Сакаллы бер фото да юк ие, менә булыр. Кабер ташына шуны куярлар».

Безнең яткан җирләребез
Казан дигән башкала.
Ковид дигән чирләребез
Гөнаһлардан башлана.
Бүлнисләрдә яткач, үсте
Мөхәммәд пәйгамбәр сакалы.
Сакалы белән керсен иде
Аз булса да акылы.

Эх, кул астында берәр каләм табылса, әллә каян гына башка килеп иңгән шигырь юлларын төртеп куярга булыр иде...

– Резида! Резида!

Янәшәдәге караватт ягыннан җавап яңгырамады. Күрәсең, хатыны уколдан соң йокыга талган иде.

Менә шулай, агай-эне. Дөнья бер алдын, бер артын күрсәтә дигәннәре хак икән. Җиргә аяк терәп, күкрәк киереп йөргән буласың да беркөн килеп сыртыңа әйләнеп төшкәнеңне сизми дә каласың икән. Моңа кадәр үзеңне җиңүче санап йөрдеңме? Тамырлар буйлап аккан канның һәр күзәнәге көрәш дәрте белән сугарылып, беләкләрдә дә, йөрәктә дә көчең ташың тордымы? Ә хәзер күр... Көчнең кем кулында икәнен күрсәттеме? Кайчандыр тимерне бөккән бармаклар камырдан әвәләп куна тактасына тезеп куйган бавырсакмыни, аларның бар җегәре соңгы тамчы сутына кадәр суырылган. Шулай да ничек тә йодрыкка йомарла да кыйна үзеңне, Фәйзелхан, кыйна! Тормыш син яраткан ак-кара төсләрдәге зебра димә, шахмат тактасы ул, барысы да синең нинди адым ясавыңнан тора. Менә хәзер үз-үзеңә хисап бирергә, гафу сорыйсылардан күңелдән булса да гафу сорарга мөмкинлек бирелде – тик ятма, уйла. Гадәтең буенча турыдан ярып салып, телең белән кемнәрне рәнҗеттең? Яшьлегең, чибәрлегең, көчең бар чагында кай сылуларны гашыйк иттердең дә кемнәрне читкә тибәреп, күз яшьләре түктердең? Саваплы гамәлләрең булдымы? Уйла, уйла... Коронавирус афәте булмаса, уйланырга барыбер башка сәбәп табылыр иде. Тоташ көрәштән торган гомернең кайчан да бер чиге барлыгын бик әйбәт беләсең ләбаса. Берәрсе йолып калыр, таяныч булыр дип юанасы түгел, үз

күләгәң дә караңгыда ташлап качканны... Хәлсезлектән тәмам түнгән булса да, ярый әле башның уйлау сәләте югалмаган. Уйла, Фәйзелхан, уйла...

Палата түшәменнән идәнгә таба көмешсыман нур сузылган иде. Урамдагы декабрь суыгыннан качып, кояшның бер кыйпылчыгы бирегә керәсе иткән, ахры. Резиданы уятасы иде. Дөньяның һәр мизгеле галәмәт матур икән лә...

Гөрләвек урынына бер-берсен узып йөгерешкән уйлар агымыннан ишек төбендә ишетелгән көр тавыш арындырды.

– Карале боларны, һаман иркәләнеп яталар, ә!

Скафандрга охшаган, бөтен гәүдәсен томалаган халаттан, йөзен каплаган битлектән тагын да саллырак күренгән Шәфкать атлаган шәйгә кулындагы сумканы караватянындагы тумбочка өстенә куйды, абыйсының аяк очына үтте. Тавышка Резида да күзен ачты, сүзсез генә исәнләшеп, хәлсез керфекләрен тибрәткәндәй итте.

Энесенең тавышын ишеткәч, Фәйзелханның йөзенә рәхәт бер җылылык йөгерде. Әлегәчә баш миен бораулаган килде-китте уйлар да төтен урынына тузгып таралды.

Бу афәт башланганнан бирле кешеләрнең күпләп-күпләп урын өстенә егылуы, ис тә, тәм дә тоймыйча, сулыш алалмыйча интегеп, бүлнискә озатылуы, көн саен кемнеңдер вафат булуы турындагы хәбәрләргә колак хәтта күнегеп килә иде инде. Әлеге коточкыч хәлләр бик якында, янәшәдә генә булса да, миңа кагылмас, читләп үтәр дигән өмет уты вакыт-вакыт пыскып янса да, кайчак бик ялкынланып дөрләсә дә, ул ут бар иде. Гаҗәп, аңа сүнәр өчен күп кирәкми икән...

Больницага килеп эләккәнче, Фәйзелхан әлеге чир үзенә дә килеп ябышыр дип күзалдына да китермәгән иде. Башына тай типкән булса гына кагылыр: көрәш келәмендә ут уйнаткан мәһабәт гәүдә, алыпларны да берәм-берәм чөеп ыргыткан көрәк куллар, нинди эшкә килеп тотынса, шуны буйсындырырга, җиңәргә күнеккән корычтай холык. Әллә каян гына пәйда булган вирус дигәннәре ни йөрәге җитеп аңа якын килсен. Ялгышкан икән. Егып салды әнә. Бүлнистә берүзеңә генә күңелсез булмасын диде микән, Резиданы да аяктан екты. Көлсәң көл, еласаң ела дигәндәй, бер палатада янәшә яталар хәзер. Табибларның, шәфкать туташларының исемен түшләренә ябыштырган кәгазь кисәгеннән белеп калсаң гына: «кызыл зона»да көнозын йөз-башлары томаланган килеш йөриләр, кемнең кем икәнен күрә торган түгел. Чир башланган мәлләрдә шушында бөтенләй куна-төнә эшләгәннәр, бүтәннәргә йоктырмас өчен өйләренә дә кайтмаганнар. Палатага чебен дә очып керми дияр идең, һөнәре буенча үзе табиб булгангамы, Шәфкать җаен таба тагын, хәл белергә килеп җитә.

– Йә, ничек сез?

– Ятам... Яшәү мәгънәсе турында... уйланып.

– Берәүнең дә тапканы юк, абый. Уйлама, яшә генә син.

– Көзгең бармы? – Фәйзелханның каны качкан иреннәре арасыннан, теленнән пышылдаулы шул сүзләр тәгәрәп төште.

– Нәрсә дисең? – Энесе, ялгыш ишеткәненә нык инанган хәлдә, аңа якынрак килде. Чите кайтарылып калган җәймәне рәтләп куйды.

– Көзге дим. Көзге.

– Кызлар кебек, кесәгә көзге тыгып йөри торган гадәт юк бит, абый. – Шәфкатьнең күзләренә берчә аптыраулы, берчә сагаюлы сүзсез сорау йөгерде. Саташа дисәң, абыйсы болай үз аңында кебек. Гадәтенчә шаяртуы дисәң, монда хәлләрнең шаярып ятарлык түгеллеге көн кебек ачык. Гыжылдап тын ала, кандагы кислород күләме кимегәннән-кими. Үпкәнең моның кадәр зарарлануын белү күңелгә шом сала.

– Телефоныңа... давай... фотога чәпе. – Фәйзелхан, җитеп килгән сакалын бармаклары белән әкрен генә тарагандай итеп, шул мизгелдә үк сурәткә төшәргә җыенгандай, керфек какмый энесенә төбәлде. Аннан ике кулын күкрәгенә кушырды, сүзләрне бүлә-бүлә янә дәште. – Сакаллы... бер фото да юк... иде.

– Нишлисең аның белән? – Тәмам аптыраган Шәфкать, гаҗизләнеп, «бәлки син берәр нәрсә аңлыйсыңдыр» дигән шикелле, бу юлы җиңгәсе тарафына борылып карады. Резиданың үз хәле хәл иде, баягыча, керфек тибрәтеп кенә алды.

– Кабер ташына... шунысын куярсыз. Алай дисәң... мөселман кешесенә... фото... ярамас та...

Менә нәрсәдә икән хикмәт! Дөнья белән алыш-бирешне өзәргә әзерләнеп ятуымы? Шулай җиңел генә бирешергәме исәбе? Ә бит кешене авыру түгел, өметсезлеккә бирелү, паника харап итә, моның шулай икәнен абыйсы белми түгел ләбаса. Җан сызлавы йә көчлерәк итә, йә көлгә әйләндерә – анысын да бик яхшы беләдер. Әллә соң, үз гадәтенә тугры калып, шушы хәлендә дә шаяртырга маташуымы?

– Син, абый, тузга язмаганны уйлап ятма! – Шәфкатьнең тавышы кырысланды, ул стена буенда торган урындыкны караватянына, абыйсының аяк очына дөп итеп бастырды, ләкин утырырга ашыкмады, үз-үзен тынычландырып, палата буйлап әрле-бирле йөренеп алды. Шуннан соң гына ике тезен ике якка аерып, куллары белән шунда таянып утырды. Тавышы йомшармады. – Үләм дип ятсаң, әҗәлетдин абзаң каршы килмәс, якаңнан сөйрәр дә алып китәр, аңа ни... Яшим дип, үзең барып ябышсаң, торып чабар.

– Хәлне... күрәсең... Нишләргә соң? – Фәйзелхан, карашын яшерергә теләпме, күзләрен йомган иде. Аның керфек очларында сатлык тамчылар ялтырап күренде.

– Нишләргә, нишләргә... Кит инде, абый, син бит әллә ниткән психологларны бәреп ега торган кеше, нишләргә дигән сорауга җавап белмәскә... Көрәшәсең дә җиңәсең. Давай, исеңә төшер, иң зур җиңүең кайда булды? Алабугадамы, Казандамы, кайсы Сабантуйда, нинди ярышта? Шуларны уйла. Бу чирне дә чистага егасың син, әйтте диярсең!..

– Егарсың... Үзең егылып ятканда.

– Егылу гаеп эш түгел ул, торырга тырышырга кирәк. Вәт шул.

– Авылда... ничек анда?

– Яңалыклар юк алай. Армиядәге шикелле, йөгерәбез, агрофирма үз урынында.

– Синең соң... армиягә китүең дә... кешечә булмады.

Аллага шөкер, бу хакта телгә алып, төрттереп ятарлык булгач, абыйсының хәле өметсез түгел, димәк.

Шәфкатьнең Алабугада, милиция мәктәбе хастаханәсендә теш табибы

булып эшләгән җиреннән армиягә китеп баруы мәзәгрәк килеп чыккан иде шул. Оборона министрлыгы соравына җавап итеп, районнан 26 яшьлек, өйләнмәгән, спорт белән шөгыльләнгән берәрсен хәрби хезмәткә җибәрергә кирәк иде. Военком: «Сиңа махсус атап язылган кебек бу», – дигәч, Шәфкать тотты да үзе барырга булды. Бөтен яклап туры килә, әле койрыгы бозга катмаган; спортта төшеп калганнардан түгел – ул чакта ук милли көрәш буенча биш тапкыр район батыры булган егет! Анда да абыйсы: «Синеке кешечә булмас. Бүтәннәрне гармуннар белән озаталар, син үзең билет алып, службага киттең», – дип авыз ерган иде. Хәзер дә шуны искә төшерүе.

– Сез монда икәүләп озаклап ял итеп ятарга җыенмагыз, – диде Шәфкать, саубуллашканда, үзенең борчылуын сиздерергә теләмичә, шаяруга борып. – Авылда эш муеннан, тизрәк терелегез дә кайтыгыз.

– И энекәш... Нишләргә соң?

– Абый, нишләргә кирәген әйттем бит...

«Нишләргә? – Көрәшергә!» Шәфкатьнең бу сүзләре, ул чыгып киткәч тә, Фәйзелханның колагында байтак яңгырап торды. Бу арада авырудан тәмам хәлсезләнгән тәнен, өметсезлек белән чорналган җанын, өзелергә әзер сулышын әнә шул «нишләргә» дигән сорауга җавап эзләү генә тотып торганмы әллә? Әлегә кадәр җавап юк иде. Коронавирус – дәһшәтле дошман булып чыкты, ул яшьне дә, картны да, типсә тимер өзәрдәй спортчыны да, дан-дәрәҗәне дә, туп-тулы акча янчыгын да иләктән иләп тормый, барысын да бер тегермәндә тарттырырга әзер. Кылыч белән селтәнгәндәй селтәнеп, сине ул иң кыйммәтле нәрсәдән – күкрәк тутырып сулау мөмкинлегеннән мәхрүм итә. Үзенең күзгә күренмәс мәрхәмәтсез кулы белән үпкәңә үрелә, аны тәнеңнән, йөрәк яныннан, калак сөяге астыннан йолкып-умырып алырга теләп, үткен тырнакларын батыра, бер йотым, нибары бер йотым һава өчен моңа тиклем табынган бар байлыгыңнан, кыйблаңнан баш тартырга мәҗбүр итә. Аһ, ул бер йотым һава! Аллаһы Тәгаләнең могҗизасы, сиңа яшәү һәм уйлану, шөкер итү өчен биргән кыйммәтле бүләге! Сулыйсың – димәк, яшисең. Яшисең – димәк, тормыш хакында уйланасың. Дөнья яралтылганнан бирле кешелекне борчыган сорауларга җавап эзләп, тирә-якка төбәләсең. Күңел күзең ачылган мәлдә яшәүнең могҗиза, бүләк икәнен аңлап өлгерәсең. Дөрес яшәдеңме, әллә ялгышмы – шуны ачыкларга теләп, үтелгән юлыңа шаккатып төбәләсең.

Әллә соң бу афәт кешелекнең яңа гасырдагы гаеп-гөнаһлары өчен Аллаһы Тәгаләдән бер кисәтү булып килеп иңдеме? Булган бит, чоры-чоры белән азган кавемнәрне кайсын су бастырып, кайсын ут яңгыры, кайсын чума ише авыру җибәреп җир йөзеннән юк иткән. Хәзер дә, туктап уйланыр, иманга килер, сәҗдәгә иелер өчен мөмкинлек бирүеме әллә?

2020 елның язы шифалы ләйсән яңгыры белән түгел, телгә үк ятышсыз коронавирус белән башланды. Кешеләр дүрт стена арасына кереп бикләнде: «онлайн» дигән сүзнең асыл мәгънәсен мәктәп балалары гына түгел, тиз арада пенсионер әби-бабайлар да аңлап өлгерде. Күзгә-күз карап чөкердәшүдән мәхрүм калу булып чыкты ул. Ирек тәме җуелу булып чыкты. Урамга чыгар, урманда йөрер, шәһәр читендәге бакчаңа барыр, иркенләп һава сулар өчен рөхсәт кирәк иде. Авыру коточкыч тизлек белән тарала, бер-береңә кул биреп күрешү түгел, метр ярым арадан якынрак килеп сөйләшү дә куркынычка

әверелде. Температурасы күтәрелеп, сулыш аламыйча интегеп табиб чакыртканнар, үз аягы белән больница ишеге янына килеп җиткәннәр, вирус йоктырып вафат булганнар хакында радио-телевизорлар тәүлек әйләнәсе коточкыч саннар белән сөйләп тора. Авыз-борын битлек белән томаланды; фаҗигадән файда эзләүне гөнаһ санамаган җәмгыятьтә битлек бәяләре дә, дару бәяләре дә көнләп түгел, сәгатьләп артты; автобуска йә трамвайга, кибеткә битлексез килеп кергәннәр, штраф түләп, казнаны баетты. Бәйрәм чаралары, тамашалар, мәчеттә җыелып намаз укулар туктатылды; кунакка йөрешүләр бетте. Моңа тиклем телефонга, компьютерга табынып яшәгән кавем аһ итте: баксаң, кеше кешегә мохтаҗ икән ләбаса, дус-туган белән кара-каршы утырып чәй эчү дә олы бәхет икән бит!

Ике айдан бетә икән... җәйге кызуларда бетә икән... көзгә бетә икән... дигән өметләр акланмады. Зәхмәтле вирус, дулкын-дулкын булып, кешеләр, илләр өстенә ташлана торды. Адәм баласының тузан бөртегеннән дә зәгыйфьрәк зат икәнен раслап, гомернең вакытлыча бирелгән бүләк икәнен исбатлап, уңлы-суллы селтәнә бирде. Аллаһы Тәгаләнең бөеклегеннән коллары арасыннан бары тик гыйлем ияләре генә курка, дөреслектә, Аллаһ бөтен нәрсәгә дә кодрәтле – әлеге хакыйкатьне аңлаучылар күп түгел иде. Вирусны кайдадыр кемнәрдер махсус уйлап чыгарганмы, җир шары буйлап тараткандмы – фаразлар арасында хагы-нахагы булса да, хакыйкать бары тик берәү генә иде: Аллаһ, берәр нәрсәнең булуын теләсә, «Бул!» дип кенә әйтә һәм ул нәрсә шул ук мизгелдә бар була. Кешенең үлем вакытын да Ул гына билгели, һәм Аны беркем дә җиңә алмый. Үләм дип яткан кешене аякка бастыручы да, яшәү өчен көрәштә аңа көч бирүче дә – бары тик Ул гына.

Моны аңлау өчен кайчагында дөньялыкта да сират күперенннән узарга кирәк икән.

Егерме беренче елның соңгы аенда Фәйзелхан белән Резида да Казанга, больница палатасына килеп эләкте. Бу авыруны ничек җиңәргә белмичә, тәмам гаҗиз булган, вакыт-вакыт өметсезлек чоңгылына төшкән мәлләре менә.

Көрәшергә, дидеме Шәфкать? Иң зур җиңүең кайсы Сабан туенда булды, исеңә төшер, дидеме? Андый җиңүләрне берәм-берәм санасаң, «иң-иң» дигәнен, ай-һай, эзләп табып булыр микән соң? Салам эскертеннән энә эзләү генә булмасмы? Шулай да, шулай да...

Уйлар каймалы-каймалы иде. Алар бер-берсенә бөтенләй бәйләнмәгән дә кебек, шул ук вакытта, кисәк кенә ялганып, бер йомгак булып та тәгәрәп китәләр. Кызыкмы, кызганычмы: озын тоелган гомер юлы да, чуалган сукмакларын бергә җыеп төйнәсәң, уч төбенә сыярдай нибары бер йомгак икән.

Фәйзелханның кинәт күз аллары яктырып киткәндәй булды. Ирмен дигән ир-егетнең йөрәгендә иярләнгән ат ятар, ди, бакчы, әле шул йомгакка кагылырга да өлгермәде, тамырларда кан агышы кайнарланды, эшләнгән һәм эшләнәсе эшләр, кырыкмаса-кырык мәшәкатьләр, күктә чалкан ятып йөзгән болыт мендәрләре шикелле, тау-тау булып як-якка тезелде. Малларга печәнне җитәрлек салалар микән? Сөтләре кимеп куймасын тагын... Складта ашлык дымланып ята күрмәсен... Комбайнга дигән запчастька заказ бирергә онытмадылар микән?..

Нишләргә дигән сорауга дөрес җавап табу – җиңү дигән сүз түгелме соң? Бар авырлыкның күзенә без кебек кадалып туры карау, инде көч бетте дигән мәлдә көтелмәгән ыргылыш ясап үз-үзеңне җиңү – көрәшнең иң ләззәтле мизгеле. Тик, гафу ит, энекәш, мондый көрәш Сабантуйда булмаган лабаса. Ул чакта да... ул чакта да нәкъ шушы «нишләргә» дигән сорау кабыргасын янтайтып, янәшәгә килеп баскан иде. Ул чакта да күңеленнән үз-үзе белән көрәште Фәйзелхан. Әлеге хәлиткеч көрәш тә яшәү белән үлем арасында иде. Тик... ул чакта... үз гомере өчен түгел иде.

***

Нишләргә?

«Хуҗа бул!» диләр. «Соң, син шушы Мортныкы түгелмени? Авылыңны күрәләтә харап иткәнне карап тормакчы буласыңмы? Синең кебекләр дә көрәшмәсә, кем көрәшер? И-ии-х, җегетлә-әәр...» Әйтүе җиңел ул. Ә билеңне сындырсаң? Җиңелсәң? Ордым-бирдем генә көрәшә торганга охшамаган монда, әнә, әби-бабайларның, әти-әниләрнең җан тире тамган басу-кырлар нинди хәлəттә күзгә карап үксеп ята. Берәм-берәм егыла авыллар, бик тиз бил бирә. Гасыр буе төзелгәнне бер селтәнүдә юк итә торган заман бу: барысын сүтәләр, җимерәләр, алалар, саталар. Кем елгыр – шул, күзенә ни чалынса, эләктерергә генә тора.

Фәйзелханның тәмам башы катты. Җиде түгел, җитмеш кат уйлап та үз соравына тиз генә җавап таба алмады. Нишләргә? Түбән Камада инде эзгә салынган, көйләнгән тормышын сүтеп, кайчандыр калага алып киткән сукмаклардан кабат салага бөтенләйгә әйләнеп кайтыргамы?

Туган авылына кунакка кайткан җиреннән хуҗа булып кайтырга чакыралар менә. Банкротлыкка чыгып, чор шаукымыннан бик тиз тез чүккән авылны аякка бастырырга кирәк, диләр. Нишләргә, нишләргә?

Ир мәһабәт гәүдәсенә килешеп торган ак күлмәк, ак чалбардан Мәмет елгасы буенда басып тора иде. Карашы, күреп туймас булып, авылның Бәкер очын иңләп үтте. Киеме пычраныр дип уйлап тормады, биек үләнне ерып, ярга якынрак атлады. Анда җитәрәк сусылланып үсеп утырган сөтлегән үләннәрен күреп алды, зур күзләренә шаян бер җемелдәү йөгерде. Бер ботагын чертләтеп өзүгә, үләннән ап-ак сөт тамчысы чәчрәп чыкты. Бала вакыттагыча, шул сөтне кул аркасына сөрткәндәй итте. Югыйсә кулның инде чебиләгән, сөялләнгән чагы да түгел... Тагын, тагын өзде, тагын сөртте, сутны көрәк йөзедәй киң учларына тигерде. Аларның балланып калганын тоеп, борынына якынрак китерде. Ерагайганнан-ерагая барган сабый чак исе килә иде. Учларында – сабый чак төсе иде.

Елга суында үз шәүләсен күреп, сискәнгәндәй булды. Нишләптер анда алып ир түгел, әле дөньяны таный гына башлаган, ялантәпиле, кояшта янып каралган ялангач тәнле, түп-түгәрәк йөзле нәни малай чагыла иде...

– Кит инде, кем шулай итеп чумсын?!

– Карап тор, үзем күрсәтәм!

– Күрмәгән ди... Башта кәҗә сакалы ашарга өйрән, җәме!

– Мин аны юри иренгә тигереп ашыйм, алай тәмлерәк, беләсең килсә!

– Суга башың белән чум дим бит, ирен чабырганы да бетә.

– Һәйт, чингачгуклар, бата күрмәгез анда, ата-анагызга хәсрәт ясарсыз.

– Ак яулыгын чөеп бәйләгән хатын, күлмәк итәкләрен җилфердәтеп җил-җил атлаган уңайга, яр буенда чупырдашкан бала-чагага күз ташлады да, аларның үз тавышларыннан гайре берни ишетмәүләрен аңлап, баш чайкый-чайкый яшелчә бакчасына таба атлады. Авыл баласы үзенә үзе баш, үзе түш: ачы таңнан кара төнгә кадәр колхоз эшеннән кайтып кермәгән әнкәләре итәгенә тагылып йөри торган түгел. Күрче бу вак-төякне, җәй кояшы астында бөтенесе чүл гарәбенә охшап беткәннәр. Бетәрләр дә, яр бакалары диярсең, Мәмет буеннан кайтып кергәннәре юк.

– Хәдячи гәзит апа миңа чингачгук диде, вәт!

Малайларның берсе алай да Гарифәбануның сүзләрен колак читенә элеп калган икән, чебиләп беткән аякларын зурларча, вәкарь белән генә аерып басты да сазга баткан шәрә тәнен ялтыратып, кояшка йөзен борды.

«Миңа» диюе бу ыбыр-чыбырдан бераз олыракларның горурлыгына тиде булса кирәк, алар, үзләренең төшеп калмаганын исбатларга теләп, кемузардан бер-бер артлы суга сикерделәр. Моңарчы читтә, сазлыкта гына чапырдашкан кечерәкләр дә, аларга кызыгыпмы, эчкәрерәк атладылар.

– Фәйзелхан батты-ы-ы! Батты-ы-ы!

Яр буен кинәт кемнеңдер шулай дип ачы тавыш белән сөрән салуы яңгыратты. Әлеге шомлы аваз, болай да фаҗига арты фаҗига кичерүдән башы чыкмаган авыл өстенә, аның тирә-ягында күкрәп утырган урман тарафына, Акай тау итәкләренә, Киленбиегән чокыры ягына, Җидегән чишмәсенең челтер суларына, Бигәнәй, Мәмет басуларына барып ягылды. Ягылды да татар авылының, биредәге шифалы суларның, күз иңләмәс иген кырларының, көлдән гөл ясарлык туфракның киләчәгеннән, шул киләчәк өчен барган көрәштән сыпылып чыккан бер кайтаваз булып, су буена әйләнеп кайтты.

Фәйзелхан, әле генә күз алдында пәйда булган малайны якыннанрак күрергә теләгәндәй, елгага иелде, учларына су алып, йөзен чылатты. Әйтерсең, ул чакта үзен коткарган Илгизәр абыйсы да әле генә янәшәсендә булган, авыл халкы үз итеп «хәдячий гәзит» дип кушамат таккан Гарифәбану апа да әле генә «Һәйт, чингачгуклар!» дип дәшеп үткән – аларның эзләрен күрергә өметләнеп, кайчандыр яшелчә бакчасы булган тарафка борылып карады. Таралып, таркалып килгән авылның мөлдерәмә карашы белән очрашкач, умыртка сөяге буйлап келәмгә, көрәшкә чыкканда гына була торган чемердәү төшеп киткәнен тойды.

Хәзер инде ирнең карары нык иде...

– Кайтам, эшлим. Түлке сез килеп, адым саен борчып йөрмәсәгез генә, – диде ул главага үз-үзенә нык ышанган тавыш белән.

Әйтүен әйтте дә... Тик авыл моңарчы гасырлар буе йөз тоткан кыйбласыннан авыш манара шикелле тайпылып килә иде. Пәриме, җенме, зобанимы, татар авылын, аның йөз аклыгы булган сыйфатларын төбе-тамыры белән юк итәргә җыенып, гөрзи белән селтәнгән диярсең. Элек, кырык-илле тирәсенә җиткән «кыз-кыркын» инде әби саналып, чәч-башына яулык каплап, ябык изүле күлмәктән йөрергә тырышса, хәзер, күр, ботка сыланып торган трико, билгә җиткән футболка киеп чишмәгә төшәләр... «Урлашсаң, кулың корыр» дип өйрәткән әбекәйләр сабагы да онытылган: банкротлыкка чыккан колхозның трактор-комбайннарын сүтеп ботарлау,

аларны металлоломга тапшыру, төзелә башлаган биналарның кирпечләрен сүтеп ташу караклыктан битәр, җай чыкканда, болганчык күлдән балык тотуга гына кайтып калган. Анысы, авыл халкы элек тә арба төбенә саламын-печәнен, тактасын-агачын, бодаен-арышын салып кайтуны гомер-гомергә урлашуга санамады, как арбада арт санына йомшак булсын өчен генә лә; колхозныкы – димәк, безнеке бит инде ул, дип, үз итеп кенә, юл уңаеннан гына эләктереп кайтыш иде ул. Ә хәзер... хуҗасызлыктан авылның йоны йолкынган тавык хәленә төшеп баруы. Әтисе Гарифҗан исән булып, бу көннәрне күрсә, «Без төзегәнне җимерер өчен тугансыз икән, шуның өчен фине, немесе, япуны белән сугышып йөргәнбез икән, – дияр иде дә, җан әрнүе белән фуражкасын күзенә үк тартып куяр иде. – Заман белән бил тартышыр җегетләр калмаган икән, корт чаккыры», – дияр иде.

Нишләргә? Алабугада гына түгел, татар илендә иң саллы авылларның берсе булган, гасырдан-гасырга умартачылары, көрәшчеләре белән дан тоткан, өч йөздән артык хуҗалыгы, меңгә якын кешесе булган Морт шушы хәлгә төшсен инде.

Татарның язмышына да, иленә дә, иренә дә, авылына да гомер бакый үзен яклап, үзенең көчсез түгеллеген исбатлап яшәргә язылгандыр.

Ил тарихын ирләр яза. Ир язмышы – чор елъязмасы ул.

Бүген ата-бабалар рухы алдында оят иде.

Алар, авылга куркыныч янаганда, күкрәкләрен калкан итеп куеп, аның яшәеше, дине, иманы өчен акыл һәм хәйлә белән көрәшә белгәннәр. Тарихына гына әйләнеп кара: чукындыру сәясәте белән йөргән миссионерларны авылга аяк та бастырмаганнар бит. Хәйлә аю тота дип эш йөрткәннәр: авылдан ерак китеп, сыер суеп, учак тергезеп, юлларына чыкканнар. Ят «туганнар»ның кәеф-сафа ратканы ул чакта да сер булмагандыр, шәп кенә итеп сыйлагач, «бу тирәдә чукындырырга яраклы татар авыллары юк», – дип, шәп кенә итеп озатып та җибәргәннәр. Чакырылмаган кунаклар якындагы Айталан, Елово, Февраль авылындагыларны чукындырганнар – Мортка юлны «тапмаганнар»... Совет чорында да үз сүзен кистереп әйтергә көче җиткән чын ирләр булган әле: борынгы зират урынына больница салабыз диючеләрне бик тиз урынына утырткannar, ул тирәне, мал-туар таптап, әби-бабайларыбыз рухын борчып йөрмәсен дип, тимер рәшәткә белән әйләндереп алганнар.

Бүген дә аяк терәп, үз сүзен әйтә алырдай корыч холыклы ирләр кирәк иде.

Авылның сулышы өзелмәсен өчен җан ярасына дәва табардай көрәшчеләр кирәк иде.

Ләкин никадәр көчле булсаң да, кулга сөлге тотып көрәшә торганга охшамаган монда. Көчсезне җиңгәнне көчле димиләр, көчсезгә көчлерәк булырга булышканны көчле дип тамгалыйлар. Ул исемне аклап калып булыр микән?..

Кичен туган нигез капкасын ачып кергәндә, ирнең адымнарына тиклем үзгәргән иде. Әнкәсе Мөкәррәмә, гадәтенчә, бакчада умарталары янында кайнаша иде булса кирәк – койма арасыннан аның ак яулыгы чагылып китте. Аякларым авырта дип тормый, яшен санамый – кортлары белән булашуны белә. Морт авылының исеме умарта сүзеннән алынган диюләре әллә хак микән соң, кешеләре чат ябышкан бит бал тирәсенә...

– Син, әни, аяклар авырта дип иркәләнеп кенә әйтәсең бугай, – диде Фәйзелхан, бакча түренә атлый-атлый, аның бер дә тик утыра белмәвенә ишарәләп.

– Монда сөйрәп чыгарлык хәлем барында чыкмый ни... Бер умарта күч аерган, чияне сырып алган, шуны җыеп тутырдым. – Әнисе үзалдына кеткелдәп куйды, син дә тик кенә торма, дигәндәй, улының кулына кечкенә җиз табак тоттырды. – Эскәмиягә чыгарып куй, монда аунап ятмасын.

– Эш табасың син, тун итәген булса да уа тор дисең алайса... Минекеләр кайда, тавыш-тыннары ишетелми? – Фәйзелхан күз карашы белән җәһәт кенә ишегалдын айкап алды.

– Фидель белән Фидания бала-чага тирәсендәдер. Резида сыер сава.

– Шәһәр кызы, шәһәр кызы, ди идең, бер дә аптырап тормый, ә!

– Киленгә тел тидерә торган түгел, авызыңны ерма! – Мөкәррәмә, бакчадан чыгышлый, түтәлдә эскәк белән генә йолкырдай бер-ике чүп үләне күрде дә иелеп шуны өзде. – Чуенга итле бәрәңге утырткан идем, пешкәндер. Керик.

Әнисе, үзенчә җәлт-җәлт атларга тырышып, баскычка юнәлде. Фәйзелхан да аның артыннан өйгә үтте.

Өйдә һава җиләс иде, тәрәзәләр киереп ачылган, чебен-черки кермәсен дип, һәрберсенә марля тарттырып куелган. Алай да кара җилем башлы чапалак күз уңында, мич кашагасында гына ята. Шакмаклы клеёнка җәелгән аш өстәлендә битләре ачык фотоальбом күреп, Фәйзелхан якынрак килде. Кләйләп ябыштырылган аклы-каралы фотолар арасыннан күзләрен җемелдәтеп, тешләрен балкытып, әтисе елмаеп тора иде. Сугыштан соң, алдынгы бригадир булган чакта төшкән фотосы. Кап-кара чәчләре, маңгаен тагын да биегрәк күрсәтергә теләгәндәй, дулкын булып өскә кайтарылган. Аксыл күлмәк өстеннән кара кәчтүмен кигән. Күзләрендә җорлык та, сынап карау да чагыла. Гүя ул, улының бүген нинди уйлар өермәсе уртасында калганын белеп, «Һәй, тотынгач булдырасың инде!» – дип сөенә-сөенә, көч бирергә тели...

Фәйзелхан альбом кесәсеннән чит-чите күренеп торган фотоны тартып чыгарды. Монысы – үзе. Иңбашында – Сабан туе тәкәсе. Фото артына «1971 год. Первый баран в жизни!» дип, галәмәт зур горурлык белән язылган. Авыл Сабан туе бу, Фәйзелхан моңарчы һичкемгә бил бирмәгән Фәрит Габдуллаяновны егып, батыр калган иде. Әниләре Рабига апаның: «Кит аннан, шул Кытай малаена ектырдыңмы?» – дип, Фәрит тирәсендә бөтерелеп йөргәне әле дә күз алдында. «Кытай» кушаматы Гарифҗанныкыларга гомергә беректе инде, каерып ала торган түгел. Кушамат тагарга маһир Бану апа теленнән төшеп калган сүз ул, Гарифҗанның, тамак чылатканның икенче көнендә кысылып калган күзләрен күреп, «Тач кытай бит бу», диюеннән ябышкан сүз.

Йә, менә хәзер синең җилкәңдә бәрән генә түгел, өч тапкыр Татарстанның абсолют батыры, ике тапкыр Рәсәй батыры, Алабуга, Әлмәт, Түбән Кама, Чаллының катлы-катлы баш батыры дигән исемнәрең бар. Гер чөеп уйнар кулларыңда көч бар...

Исеңдәдер, мәктәптә Маяковский шигырьләрен теттереп сөйли идең. Бервакыт Муса Җәлилнең кайсы шигырен ятладың әле? Яле, яле,

онытмадың бит, онытканга салышмакчы гына буласың... «Кем сокланмас көчкә, тимер сынса һәм су чыкса баскан эзеңнән; тик ни файда, көчең филдәй булып, эшең булса чыпчык тезеннән...»

Анысы, эшләгән эшләр чыпчык тезеннән генә түгел инде. Эш рәте белмәсә, ялкауланып кул кушырып утырса, Түбән Камада кибетләр, машина кую урыннары тотып, бизнес алып бара алыр идеме?..

Нишләргә? Авылны торгызырга алынам, дидең. Син бит кырык кат уйлагач кына, үз көчеңә ышангач кына тотына торган кеше, шаблон буенча эшләргә яратмыйсың. Әйттең исә – таш яуса да эшлисең, тотынганыңны ярты юлда ташламыйсың. Сиңа әле эшнең барып чыгуы гына түгел, аның көлеп торуы, матур булуы, күзне камаштырырлык булуы кирәк... Кайсыдыр акыллысы, эшнең шәп булуын теләсәң, үзең эшлә, дигәнме? Теш-тырнагың белән үзең җигелеп тартырга яратасың шул; юлыңда аяк өсте йоклап йөргән, үшәнрәкләр очраса, сиңа үпкәләмәсеннәр...

Хәзер артка чигенү юк. Нидән башларга? Авылында гына купкан башбаштаклык түгел бит, иле буйлап зилзилә узып бара. Җиңеп булырмы?

Соңгы уен кычкырып кабатлаганын сизми дә калган икән. Җиңнәрен сызганып, аш әзерләргә тотынган әнисе мич тирәсеннән башын күтәреп карады:

– Тагын көрәшкә барасыңмыни? Җиңәрсең, улым, син йөзлектә туган бала, бирешмәссең. Аллаһы Тәгалә акыл да биргән, көч тә биргән. Тикмәгә генә сакламагандыр үзеңне, җыяр ризыгы, эшлисе эшләре күп дигәндер, ничә тапкыр үлемнән калдың бит.

– Вәт Раузалия апа курыккандыр мин арба белән тәгәрәгәндә, ә, – диде Фәйзелхан, уйларын өзеп. Тагын бер күз ташлауга, альбомны шапылдатып япты да читкә алып куйды.

– Курыкмый ни... Үзе дә сабый гына, җиде яшь кенә ие. И-и, уйласам, әле дә йөрәккәем жу итеп китә... Безнең эштән баш чыкмый, тау башында арыш басуында арыш урабыз. Апаң каз саклаган җиренә сине кабык арба белән алып йөри ие. Авышрак куйган булды микән, арбаң таудан тәгәрәп төшеп киткән бит. Күрше урамнан хатыннар күреп чабыша икән, килеп җитешләренә арбаң белән каплангансың. Баш турысында гына алагаем олы таш яткан. Хикмәт инде, исән калукайларың хикмәт...

– Мунчада ис тиеп тә көчкә исән калдык, ди идең...

– Кит, искә төшермә... – Шулай дисә дә, әнисе, мич куеныннан чуен чүлмәкне кисәү агачы белән ипләп кенә алга шуыштырган арада үзе үк дәвам итә. – Бәләкәй иегез әле, Шәрифҗан белән сине мунча кертәм, бермәлне үзем ләүкәдә ауганмын, син идәндә тәгәрәгәнсең, ярый әле Шәрифҗан мүкәләп, ишектән чыгып җитешкән. Атаң күреп йөгереп кермәсә, беткән иек инде, беткән иек...

«Үлемнән калу» вакыйгалары инде кырыкмаса-кырык тапкыр сөйләнгән, өтеренә кадәр ятланган, шулай да хатирәләр сандыгының капкачы ачылып, кабат барлаганда, алар отыры җетеләнә генә бара төсле. Үзе хәтерләрлек яшьтә булмаса да, аларны күз алдына китергәндә, ирнең аяк табанына тиклем кымырҗап куя. Чыннан да, әнисе әйтмешли, эшлисе эшләрең күп әле дип саклавы булды микәнни?.. Эш дигән сүз авыл туфрагында кендек каны тамган һәркемнең маңгаена язылган инде ул. Авылның тапканы

да, югалтканы да эш, эш дип йөгергәннән. «Эшләгәнең кеше өчен булса, өйрәнгәнең үзең өчен», дия-дия, сыртка төялгән йөкне гомер буе тарта да тарта авыл кешесе. Зарланып уйлавы түгел лә, чоры-чоры белән кешеләрнең кеше икәнен онытырга мәҗбүр иткән елларны гына искә төшерүе... Таудан тәгәрәве дә, теге чакта Мәмет суында батуы да, төбенә тоз коеп уйлансаң, балалык ваемсызлыгы гына түгел шул... Сабыйларына күз-колак булырга вакытлары да, хаклары да жуелган әниләрнең кул-аягын колхоз эше тышаулаган: алар кем өчендер бары тик эш аты... Шуның аркасында төзәтеп булмас үкенечләре дә җитәрлек шул. Кәүсәр абыйсының язмышын гына кара... Аны күреп белмәсә дә, эти-әнисе өчен мәңгелек яра икәнен бик яхшы белә Фәйзелхан... Эштән кайтып килешләренә унбер яшьлек улларының үле гәүдәсе генә каршы алсын әле...

***

Көннең кичкә авышканы сизелә. Палатага берәрсе кереп, ут кабызганчы, шушы эңгер-меңгер яктылыгының тиз генә юкка чыкмавын теләп ятсаң гына инде. Алайса, караңгылык бүлмәне генә түгел, болай да көч-хәл белән тын алып яткан күкрәкне баса. Күкрәк белән бергә, җан изелә, җан сыза. Авыру белән көрәштә көчсезлегеңне аңлаудан йөрәк бәргәләнә. Барысына төкереп, шушы көндә, шушы минутта яшәп калырга ничек өйрәнергә? Бер генә минутны да кичәге көнне барлауга әрәм итмичә, иртәгәсе көн өчен куркуны баш миенә якын китермичә, бу мизгелдә яшәп каласы иде. Бу көн – аныкы. Бу мизгел – аныкы. Вакытның бу кишәрлеген аның хозурыннан беркем йолкып ала алмый, мизгелне ничек уздыру үзенә генә бәйле. Әллә ялгышамы? Монда, авыру каршында үзеңне корбан кебек хис итеп ят та вакыт агышына хуҗа бул, имеш... Ике аягыңда дөбердәп йөргәндә, дуслар, туганнар каршында да, тормышның көтелгән, көтелмәгән борылышлары каршында да үзеңне корбан сарыгы итеп файдаланырга ирек бирмисең анысы. Кул-аягың, җаның-тәнең бәйсез икән, ләббәйкә дип бил бөгеп тормыйсың. Рәхим ит, хәлне үзгәртергә телисең икән, үзең теләгәнчә эшлә: телең белән аңлат, кирәк тапсаң, йодрыгыңны эшкә җик; нидер ошамый икән – борыл да кит, кире кайтырга теләсәң, сукмакка бик салынмый. Монда бит... монда бит башкачарак. Аны үзгәртү дә кулдан килердәйгә охшамаган. Үзеңне корбанга санарга, мескенләнергә теләмәсәң, бу хәлләргә башка күзлектән карап баксаң гына инде. Бәла-казаның һәркайсы кешегә йә сынау, йә җәза, йә бүләк булып бирелә дигән идеме хәзрәт бервакыт җомга намазында? Фәйзелхан аның белән бәхәсләшеп тә алган иде: янәсе, әкият, ничек бүләк булсын инде... «Аллаһның шул рәвешле тагын да яманрак бәлаләрдән саклап калуы, җәзасын ахирәттә ут газабына калдырмыйча, бу дөньяда бирүе ничек бүләк булмасын», – дип җаваплаган иде хәзрәт.

Палата ишеге ачылды. Пыяла банка, шприц ише нәрсәләр тезелгән поднос тотып, аксыл-зәңгәрсу киемгә төренгән берәү кереп килә иде. Менә ул башта Резида яткан караватянына килеп, аның йөзенә иелеп, нидер әйтте. Ияккә кадәр тартылган ак җәймәне кайтарып, култык астына градусник куйды. Җәһәт кенә борылып, Фәйзелханның да йөзенә иелеп карагандай итте. «Не дождётесь» – ир шулай дип шаяртып дәшәргә теләде, тик теле аңкауга ябышкан сыман иде, авазы чыкмады. Перчаткалы җитез

куллар аның да юка күлмәге астына салкын градусникны китереп тыкты. Сабый балаларны юаткандай, шәфкать туташы мөлаем тавыш белән нидер сөйләнә-сөйләнә, кәгазь каптан дару капсуласы алды, аның башын мамыкка төреп чертләтеп ватты да шприц энәсенә кигерде.

Көчкә тын алып яткан Фәйзелханны кинәт сәер рәвештә көләсе килү теләге биләп алды. Үзе яратып караган «Кавказская пленница» фильмы исенә төште. «Бу шприц соң миңа... Моргуновка кадаган ише генә инде». Шунда ук баш миен икенче уй ярып керде: Моргуновларны хәтерләрлек булып яткач, яшибез әле, брат, яшибез!

Укол җиңеләйтеп җибәрдеме, әллә авыл турындагы хатирәләре, бүләк турындагы фәлсәфәсе җанын шифалы яңгыр урынына сугардымы – тамырларда кан агышы йөрешен үзгәртте, күкрәк читлеге киңәеп киткәндәй булды, ике чигәне кысып торган кыршау да йомшарды. Нинди генә халәттә дә уйдан арынмаган баш үзен яңа яссылыкта хис итә иде, ахрысы.

Әллә соң дөньялыкта белеп-белми кылган гөнаһлар шушы рәвешле җавап тотуны таләп итә микән? Уйла әле, Фәйзелхан, уйла. «Бер гөнаһым да юк, каян килеп?» дип каршы төшәргә маташма, син дә шул ук Адәм баласының фәлән миллиардтан берсе бит, синең дә калак сөягендә фәрештә канатлары үсеп чыкмаган... Кәбаир гөнаһлар исемлегенә үк кермәсә дә, чабуыңа ябышкан балачак шуклыклары да, яшьлек җүләрлекләре дә юк түгелдер. Исеңә төшер: соңгы елларда, мәчеттә намазга иелгән, вәгазьләр тыңлаган мәлдә үзең өчен нинди хакыйкатьне ачтың?.. – Бер генә адәми зат та җир йөзенә болай гына килмәгән, һәркемнең үзе башкарасы гамәлләре, кыласы изгелекләре, хата-ялгышлары була. Шуларның барысы өчен тәүбә итәр мөмкинлеге, ахирәттә җавап тотасы сәгатьләре була. Мал да, дан да кешегә сынау өчен бирелә. Шушы гади, гали ачышлар шаккаттырган иде түгелме үзеңне? Ә бит гомернең һәр кишәрлегендә малы да, даны да бар; игелекләр дә кылынган шикелле; кайчагында, артык уйланып тормыйча, кайбер сораулар йодрык белән генә дә хәл ителгән... Хет шунысына куан: бервакытта да үзеңне суган суфые итеп күрсәтергә тырышмадың, икейөзлеләнә белмәдең. Кемдер мактарга тотынса, үзең үк: «Юк, җайсыз кеше мин», – дип, «дөресләп» куя идең...

***

– Сыртыгызга эләктерәм хәзер!

Апалары кулындагы юеш идән чүпрәге аркага, йә йомшак җиргә төшкәнче, малайлар, табаннарыннан таплы эз калдыра-калдыра, өйнең түр ягыннан ялт кына урап чыгарга да җитештеләр. Раузалия селтәнгән арада, аның кул арасыннан балык кебек кенә шуып, күздән гаип тә булдылар. Шәрифҗанда да, Фәйзелханда да идән кайгысы юк, авыл башыннан көтүне каршыладылар, хәзер терекөмеш кебек кенә тәгәрәп, урамны әйләнеп кайтырга кирәк.

Йомры гәүдәле ике малай, әнкәләре пардан иш итеп теккән күлмәкләренең кесә тирәнлеген барлый-барлый, табан астыннан тузан туздырып, авылның Мөхсин очына юнәлделәр.

– Әни иртәгә ашка чакырды!

– Әни иртәгә ашка чакырды!

– Әни иртәгә ашка чакырды!

Кемнең капкасы, кемнең йөзе ачык – малайлар, тиен җитезлеге белән шул тирәдән әйләнеп чыгарга ниятләделәр. Кечкенә булсалар да, бик яхшы беләләр: авылның язылмаган үз кануны бар, хуҗа-хуҗабикә үз йортына аяк-баскан беркемне дә «тәк прусты» гына борып чыгармый. Чәйләп утырган мәле булса, өстәл тирәсенә чакырып, барын-югын уртак итәргә тырыша. Табынын җыеп өлгергән булса, самавыр яңартырга ашыга; кунак килсә дип, үзенең, балаларының авызыннан өзеп, кар базында яки келәтендә йомгак-йомгак язган маен, тәпәнендә кәрәз исе аңкытып утырган балын, чормасында балавыз күк балкып торган каклаган казын саклый. Бусагада бала-чага күренсә, аны буш кул белән чыгарып җибәрүчене авыл өендә көндез шәм яндырып эзләсәң дә таба алмассың. Ә монда, тирән кесәле күлмәкләрен җилфердәтеп, зур күзләрен ихлас елтыратып, олылап ашка дәшәргә ике малай килеп керсен әле!..

Урам очына чыгып җитәрәк, Шәрифҗанның да, Фәйзелханның да түш тирәсе шактый кабарган, кесәдәге хәзинә йөрәкне җылытып, җанны кыбырсытып тора иде, малайлар арытабан башка капканы кагып тормадылар, табан ялтыратып, су буена элдерделәр. Үлән өстенә таратып ташлагач, хәйран мул күренгән күчтәнәчләргә башта икесе дә шым гына карап тордылар.

– Мендәр кәнфитне миңа бирделәр! – Фәйзелханның кәнфиткә үрелгән кул аркасы абыйсының җәлт кенә чәпелдәтүеннән кызышып куйды.

– Сиңа гына ди... – Ике яшькә генә олырак булса да, абый – абый инде. Шәрифҗан, шулай икәнен искәртеп, абыйлыгын күрсәтеп алды. «Табын»дагы тәмлүшкәләрне, ләззәтен озаккарак сузарга теләп, бик җентекләп барлап чыккач кына, ике якка аерып тезәргә тотынды. Писүктә әвәләнгән тышсыз кәнфит, мендәр кәнфит, пчинҗә-прәннек, күрәгә-өрек ише тәм-том малайларның янып торган күз карашыннан ук берәм-берәм кими башлады да, бераздан, әфсен укып өргәндәй, бөтенләй юкка да чыкты. Өйгә кайтыр сукмакка төшкәнче, ике малай чишмә буена юл тоттылар, болай да бик хушланган күңелләрен салкын су белән тәмам түгәрәкләп куйдылар.

Капканы ачып ишегалдына кергәндә, әле аларга бернинди куркыныч янамый иде. Лапас ишеге ярымачык, әниләре сыер сава булса кирәк. Апалары эшен бетергән, баскычны да, сары май белән майлагандай, юып, ялтыратып куйган. Әтиләре фуражкасын кырын салып, тарантас белән капка төбенә кайтып туктаганда, барысын айт-двага бастырганда таң аткан булачак. Димәк, өйгә кереп, бу фыртавай күлмәкләрне салып ташларга да – ник дисәң, кесәнең кирәге бетте – уйнарга дип таярга мөмкин. Тик малайларның бу нияте тормышка ашмый калды, алар өйдән әйләнеп, тышкы ишекне ачарга маташканда, капкадан Галиябикәттәйнең кереп килгәне күренде. Ул, кулын каш өстенә куеп, әрле-бирле карана-карана ишегалды уртасына үткәндә, лапастан сөт тулы чиләген күтәреп, Мөкәррәмә дә чыгып җитте.

– Нихәл, Галиябикә, йомыш-мазарың бармы әллә? – диде ул, чиләген койма буендагы эскәмиягә утыртып, кулын кадакка эленгән сөлгегә сөртә-сөртә.

– Карале, Мөкәррәмә, аптыраганнан гына керүем. Уттай урак өстендә

ни дип аш үткәреп мазаланасың икән дим. – Галиябикә түти, ике кулын аркасына чалыштырып, сорау алган кыяфәттә аның каршысына килеп басты.

– Ниткән аш?

Бая гына ачылырга иткән ишек Мөкәррәмәнең чатнап торган тавышыннан шап итеп кире ябылды.

– Шуны сорыйм бит, нинди аш дим?

Берни аңламаган Мөкәррәмәнең кашлары аптыраулы җыерылды. Болай да арыган йөзенә канәгатьсезлек таралды. Аның кул хәрәкәтеннән койма башына эленгән буш чиләк шалтырап куйды.

– Башымны катырмачале, Галиябикә, кем нинди аш үткәрә?

Бу юлы чакырылмаган кунакның йөзенә берни төшенмәгән кыяфәт таралды. Ул күзләрен челт-мелт китерде:

– Соң, синең малайларың бөтен урамны иртәгә ашка чакырып йөри бит. Шуңа сорыйм, кылны кырыкка ярырдай урак өстендә ни кылануың дип.

– Аһ, тотып яргырлары! Тагын ни генә уйлап чыгарулары икән!.. – Мөкәррәмә, сыер сауганда кигән соры халатын җәлт кенә салып, кая эләкте шунда томырды да, күзенә чалынган сыек чыбыкны эләктереп, өйгә юнәлде.

Раузалия янбакчада чүп утап маташкан икән, энеләренең шуклыгы үзенең дә үзәгенә ярыйсы гына үткән иде, шулай да аларны җәлләп, тиз генә бакчадан чыкты, әнисен куып тотты.

– Ашка чакыра кергәч, күчтәнәч бирәләр бит, шуңа кызыкканнардыр. Бәләкәйләр бит әле, – диде кыз, үзе дә бала гына булса да, хәлнең мөшкеллеген аңлап, йомшартырга теләп.

– Хәзер күрсәтәм мин аларга күчтәнәчне! – Колхозның гектар-гектар борчак җирен ирләрдән уздырып чаба торган саллы куллар җиленнән ишек үзеннән-үзе ачылды.

Алар кергәндә, Шәрифҗан белән Фәйзелхан, катлы-катлы ястык-юрган җәелгән карават өстендә әүлия кыяфәтендә күзләрен томрайтып, икесе иңгә иң куеп утыралар иде.

– Атагызга әйтәм, җүнсезләр! – Әниләре кулындагы чыбык борын төбендә генә чыжылдап алды. – Кара син боларны!

«Атагызга әйтәм!» Авыл баласы өчен сыек чыбыктан, кычытканнан, каеш-фәләннән куркынычрак, дәһшәтлерәк, үтемлерәк чара шушы ике сүзгә сыеп беткән. Нинди генә булмасын – алып гәүдәлеме ул, чүрәкәй генәме, сугыштан кулсыз-аяксыз кайтканмы, ярты гәүдә белән генә йөриме, чебенне дә рәнҗетә белми торган йомшак күңеллеме – ата кешенең абруе шушы ике сүздә! Уйлап баксаң, кечкенә генә шуклык өчен дә малайларның йомшак җиренә әнкәләре кулыннан ныграк та, ешрак та эләгә, ләкин «атагызга әйтәм» дигән сүзтезмәдә колакны сагайта, күңелне шомрайта торган могҗизалы бер көч бар. Өйнең тоткасы – ата кеше, ир кеше кулында, соңгы сүзне барыбер ул әйтә, соңгы ноктаны ул куя.

Сугышны аркылыга-буйга гизеп, тормышның бар ачысын-төчесен татыган Гарифҗанның холкы ипи өстенә яккан бал да май түгел, балаларга мәхәббәте дә ирләрчә кырыслык белән сугарылган. «Атагызга әйтәм!» дигән сүзнең кайтавазы да каш астыннан бер, әмма берәгәйле итеп карап куюдан узмаска мөмкин. Фронттан кайтуының икенче көнендә үк МТСка –

машина-трактор станциясенә бригадир итеп куйганнар үзен, эштән айгырны чаптырып, тарантасны җилтерәтеп, кайчакларда ярты төн уртасында кайтып керә. Тамак чылатып, артык йомшарып киткән көннәрендә Гончар алып кайта үзен. Адәм акыллары бар диярсең, хуҗасының холык-фигылен ул да белеп бетергән: андый мәлләрдә аптырап тормый, йорт башының үз аякларына басып керә алмасын аңлап, чыгып алыгыз дип, тоягы белән капкага китереп тибә. Чыгалар инде, әнкәләре янәшәсендә балалар да кайнаша.

Шуклыкларына тиешле җәзаны алып өлгергән малайлар урын өстенә тәгәрәп, татлы йокыга изрәгән мәлдә этиләре кайтып керде. Тыгыз гәүдә, мәһабәт буй-сын, киң маңгай, дулкынланып торган чәчләрне яшергән «Сталин» фуражкасы, утыртма якалы яшькелт күлмәк – эштән түгел, армиядән кайткан, диярсең.

– А ну-ка встать!

Көр тавышлы мондый әмердән соң камыр кебек таралып ята алмыйсың, солдатларча ялт кына аякка калкынасың. Балалар да, түр якта башын ястыкка терәгән Мөкәррәмә дә гадәттәгечә чәчрәп сикереп тордылар.

Фуражкасын баш артына шуыштырган Гарифҗан күз карашы белән генә һәммәсен барлап чыккач:

– Нәрсә, барсы да нормальнымы? – дип, тыныч кына сорап куйды.

– Әйбәт, әйбәт, Гарифҗан. – Калку-таза гәүдәле, эшләп чыныккан нык беләкле, кайберәүләрне тырнак чиертеп тә почмактан почмакка очырырлык Мөкәррәмәнең тавышы бик сабыр иде.

– Ашарга бармы?

– Бар, бар, Гарифҗан.

– Малайларда тәртип?

– Тәртип, Гарифҗан, тәртип.

– Ярар. Отбой!

Вакыт-вакыт кабатланучы мондый күренешкә күнеккән малайлар, качып китәргә маташучы йокының җиңеннән эләктереп, җиңел сулап, үз урыннарына аудылар.

Өстәл янында әнкәләренең самавыр яңартканы, аш әзерләгәне ишетелде. Борынны кытыклап, ит шулпасы исе таралды.

– Расцветали яблони и груши, поплыли туманы над рекой…

Башланды. Гарифҗанның җыр белән сугарылган җаны, фронтта «запевала» булган көннәрен искә төшереп, төннең шушы мизгелен генә көткәндәй, иркенләп канат кагынырга кереште. «Катюша»дан башланган концертка Пугачёв җырлары ялганып китте, көр, моңлы тавыштан тәрәзә пыялалары да чыңлагандай тоела иде. Дон казаклары җыры яңгырый башлагач, моңарчы мич башында түзеп яткан мәче дә, койрыгын чәнчеп, идәнгә сикерде.

– Ехали казаки с Дона домой, обманули Галю, забрали с собой...

– И-и, Гарифҗан, син үлеп, берәр ел гына тынычлап яши алырмын микән? Ходай яшен белән дә сукмый бит ичмасам үзеңә, эчмәс идең бүтән... – Көнозын колхоз басуында, аннан йортта тиен урынына бөтерелгән, төн йокысы да урланган Мөкәррәмәнең чарасызлыктан әйтелгән сүзләренә ир көлеп кенә куйды.

– Ходай ул сиңа Җамали сукыры түгел, кемгә яшен белән сугарга кирәкне

үзе белә, – диде, каны кызганда, кулына ни эләксә, шуның белән китереп ора торган дуамал Җамалины күздә тотып. Аннан өзелгән җырны дәвам итәргә керешге.

Сабый гына булган Фәйзелханның иреннәренә дә, әллә өнендә, әллә төшендә, «Не шуми ты, дубравушка, рощица зелёная! Не мешай мне, добру молодцу, думу думати...» дип, әткәсенең җыр сүзләре килеп кунды.

Таң атканда гына өй эче кинәт тынлыкка күмелде. Тынычланып, башын мендәргә терәгән Мөкәррәмәгә генә йокы кермәде. Сыер саварга иртәрәк икәнен чамалап, черем итеп алырга җыенса да, күзләре шыр ачык иде. Үрмәкүч пәрәвезедәй чолгарга иткән уйлар ятьмәсеннән котылырга теләп, әле уңга, әле сулга әйләнде – йөрәгенә тынгылык иңмәде. Бер генә минут та эшсез торырга күнекмәгән кулларына урын тапмады – әле күкрәгенә кушырды, әле баш астына салып карады. Әллә каян гына, йөзеп кенә килгәндәй, башына бәхет турындагы уйлар агылып керде. Нәрсәдер инде ул бәхет дигәннәре... бу дөньякайларында кемгә генә тәтидер инде ул. Авылда капкаларны рәттән кагып кил – бәхеткә тиенгәнне күрермен, димә... Һәркем ишегендә яра өстенә яра эзе сызылган. Эшле-ашлы кешене, кулак дип, нигезеннән кубардылар да Себер сөрделәр. «Безнең силсәвит немесләр кәнүшниеннән дә хуже» дигәнрәк сүз өчен Гайнетдинне өтермәнгә илтеп тыктылар. Бичара Сабираны бер уч ашлык, ике-өч бәрәңге өчен, иреннән, баласыннан аерып, ун елга Колымага олактырдылар. Сталин үлгәч кайтып төшкән иде дә соң... Кочак җәеп көтеп торучы гына булмады. «Төрмәдә үлгән булсам, бу гарьлекне күрмәс идем», – дип, кан-яшь түкте, дүрт балалы тол иргә димләгәч, Мөкәррәмәнең туган авылына – Дөм-Дөмгә китеп барды. «Тәрәзәсез мал вагонында көн-төн бардык, беркая чыгармыйлар. Татар хатыннары кеше алдында хаҗәтен үтәргә ояла иде, кайберсе сидек куыклары шартлап үлде. Аннан халык эчләре китеп кырыла башлады. Урманга кергәч, поездны туктатып, вагон ишегеннән мәетләрне шунда ыргытып калдырдылар», – дип елый-елый, «кешегә чыгара күрмә», дип сөйләп алган иде... Сугышы тагын күпме кешенең башын ашады... Юктыр, кеше җиргә бәхетле булыр өчен тумыйдыр ла... Тфү, тфү, ниткән көфер уйга батуы... Янәшәдә сугыштан исән кайткан, өрлек кебек ире йоклап ята, алма кебек балалары үсеп килә, шуны бәхеткә санамасаң, анысын да күпсенеп куймасын... Алай дисәң... Бәхетле кеше дөньяга килүгә атасыз калып үсәр идеме? Аның йөзен дә хәтерләми бит Мөкәррәмә, атасы сугышка чыгып киткәндә туып кына калган бит. Әнкәсе тавышсыз гына елап сөйли торган иде: «Бер-бер артлы сигез кыз таптым, туганы бере үлә барды, бер син исән калдың. Атаң сугышка киткәндә әйткән ие аны. Монысы яшәр әле, дигән иде. Хак әйткән икән», – ди иде. Кем өчен көрәшкән, ни өчен сугышкан – кемнәр белсен. Акка, кызылга бүленеп, авылдашлар бер-берсенә мылтык атсын, кылыч кизәнсен инде... Яшәргә язгач яшисең икән ул. Һәркөнне шул яшәү өчен көрәшә-көрәшә... Яшьлегендә ни рәхәт күрде? – Дөм-Дөм авылында җиткән кыз булып өлгереп килгәндә, тракторчылар курсына укырга озатып, кулына руль тоттырдылар. Гарифҗан белән танышуы да шунда булды түгелме? Авыл Сабан туйларында көрәшеп дан алган егет тоткан җирендә өзә торганнардан иде: күрде, ошатты, өйләнәм, диде. «Усал бит ул, якын барма», – диделәр кызга, язмышыңа язылганнан узып

буламы? Язганы – Гарифҗан иде. Утыз сигездә туган уллары сугыш чорында кызамыктан үлде. Ул хәсрәт Мөкәррәмәне ярты картайткан иде, унбер яше тулган Кәүсәрнең суга батуы бәгыренә кара кан булып сауды, чәченә бер атна эчендә ап-ак бәс булып төште. Гарифҗан белән урман кисеп кайтып килешләренә, Мәмет буасы янында җыелышкан халыкны ерактан күрүгә үк йөрәге жу иткән иде. Акылдан язып егылмас өчен кайлардан сабырлык биргәндер. Кайгы күлләренә салып китте улы, мәңгелек хәсрәт сулары эчереп китте. Су кергәндә, көзән җыерган – һәр үлемгә бер сәбәп бар... Кайгыны шатлык белән алыштырырга теләп, берьюлы ике игезәк малай биргән иде дә соң Ходай, анның да берсен туган мәлендә үк үз хозурына алды, игезәк сыңары Шәрифҗаны гына исән калды. И-и, бала хәсрәтләре белән сынапмы сынады инде, калганнарына гомер бирсен дә акыл бирсен берүк... Раузалиясе үзенә охшаган, эшкә дә нык, гәүдәгә дә тач үзе, баскан җирендә ут уйната. Малайлар иллә мәгәр шук, берәр минут тик тора белсәләр... Абзар чистартырга чыгып кергән арада да әүмәкләшеп, көрәшеп, пыр тузып керәләр. Шәрифҗаны җитезрәк, Фәйзелханы бераз салмаграк. Каннан киләдер инде, аталары шикелле, бил сынашырга гына торалар, бигрәк ут борчалары. Йә инде, Мөкәррәмә, ни уйлавың? Алар соң кемгә охшап җебек булсыннар? Әллә онытып та куйдыңмы, үзеңнең соң, трактордан төшкәнеңә кайчан гына? Саҗидә, Зәйтүнә, Хәнифә, Миңнафа, Мәүҗидә, Дәлилә, Хәдичә, Маһруй идеме әле бригадагызда? Син бригадир ярдәмчесе булып, шул тимер ат белән басу-кырларны никадәр айкадың? Сугыш елларында да хатын-кыз дип тормадылар, барысын да күрде башларыгыз. Исеңдәме, бервакыт басуда җан тиреңә батып эшләгәндә, тракторыңның распредвалы таралып төште? Елап утырырга, кемнәндер ярдәм көтәргә вакытың юк иде, аптырап тормадың, Шырлыйм Хөсние тракторының тартмасын сүтеп, үзеңнеке белән алыштырып куйдың... Трактор ватылса, аны сүтеп, детальләрен ат арбасына салып, рәтләтергә Бондюг каласына барыш. Терсәкле валларны шомартырга Казанга ук барырга кирәк. Тракторлар җитешмәгәч, җирне үгез белән дә, сыер белән дә сөрергә, чәчүне дә кул белән чәчәргә туры килде.Барысы да фронт өчен дип, алны-артны күрми, баш күтәрми эшләдегез дә эшләдегез инде. Күпме хатынны Кизил шахтасына, күпмесен Сверлауга җибәрделәр, исән кайтканнары көн-төн урман кисеп, мичкәләрдә тимер-томыр эретеп, таш кисеп, юл түшәгәннәрен елый-елый сөйли торганнар иде. Ачлыкка, сагынуга түзә алмый качып кайтканнарны, трибунал ясап, бишәр-унар елга хөкем итеп, янә таш эшенә озатканнар иде...

Шулай, фашистларны җиңүдә кулына мылтык тотканнарның гына түгел, авыл туфрагында көнне төнгә ялгап эшләгән аналарның, балаларның да, читкә озатылып, күз яшьләре койганнарның да өлеше зур, Гарифҗан...

Мөкәррәмәнең әрнүле уйларын әтәчләрнең сузып-сузып аваз бирүе бүлдерде. Торырга вакыт иде. Тәрәзләрне каплаган кыска ак пәрдәләр аша, туар көннең якты һәм кояшлы булырына өмет уятып, алтынсу нурлар үрелгән иде.

...Гәүдәгә дә, йөзгә дә ике тамчы су кебек охшаш Шәрифҗан белән Фәйзелханга карап, Гарифҗан үзалдына борын астыннан гына көлемсерәп куйды. Әле генә бот буе иделәр, үсәләр, ташбашлар! Күз кабагыңны ачып

ябарга да өлгермәссең, канат ярган кош баласы шикелле, оядан очарга да күп сорамас болар... Сабан туе мәйданында бал кортлары урынына кайнашкан халык арасыннан көрәшне читтәнрәк кенә күзәтә иде Гарифҗан. Яшьрәк чагында бил бирмәгән көрәшче өчен бераз ямансу мизгел иде бу: җан мәйдан уртасына ыргыла, тик анда инде яңа буын, ватылмаган, җимерелмәгән буын көч сынаша. Күрче, аның ташбашлары да мәйдан уртасында, балалар көрәшендә бил алышмакчы. Икесендә дә йомры гәүдә, йомры баш, биек маңгай, туп-туры сызылган кара кашлар, бераз шешенкерәк кабаклар астыннан шаянлык та, тәвәккәллек тә бөркегән озынча зур күзләр, калынчарак иреннәр. Кызлар йөрәген яндырасылары бар икән... Ата кешенең күңел түрен горурлык тойгысы ярып үтте. Анысы да монысы, әнә, карагыз, Мөкәррәмә куенында тагын бер баһадир мес-мес килеп ята! Өч айлык кына булса да, ул да Сабан туен тамаша карарга килсен әле, һе... Белмәссең, буй җиткерсә, ул да көрәштә кимен куймас бәлки... Ата кеше ак биләүдә изрәгән малаена өметле караш ташлады. Шәфкать! Шулай дип исем куштылар төпчекләренә. Шәфкатьле булсын, миһербанлы булсын, картлык көннәрендә ата белән анага таяныч булсын! Туарга гына... тапты бит көнен... 8 Мартны көтеп яткан диярсең...

Монысын болай гына, юри генә, эчке горурлыгын басар өчен генә уйлап куйды Гарифҗан. Гомер булмаганны, әллә нишләп күңеле йомшарган шикелле әле, әллә малайларының егет, Раузалиянең җиткән кыз булып килүен яңа гына искәреп, гомеренең, ялларын тузгыткан аргамактай, елдырым гына узып баруын абайладымы... Әнә бит, Раузалияләре әле кайчан гына, «мин Зөһрә апа булам» дип йөри иде, авыл фельдшеры Зөһрә шикелле ак халат кияргә теләп; җидене бетерүгә, кай арада Алабугага, фельдшер-акушерлык мәктәбенә укырга да киткән...

Әллә соң олыгаеп килгәндә, тагын бер тапкыр әти булу шатлыгын татыгач үзгәреп киттеме? Балага узганын белгәч, Мөкәррәмәсе: «Кешедән оят бит, Гарифҗан, кырык биш яшьтә бала алып кайтыймны?» – дип өтәләнгән иде, «Алып кайтасың. Тәгәрәшеп үсәрләр», – дип кырт кисте Гарифҗан. Туасы җаннар тусын, әнә, каһәр төшкән сугыш аркасында кызлар кулы да тотып карамаган күпме асыл егетләр яу кырында ятып калды. Күпме балалар тумый, күпме толлар зар елап калды... Казакъ егете, старшина, әлүмин флягадагы «фронтовой» йөз граммны калай кружкаларга бүлеп, кулына алыр иде дә: «Ребята, давайте, помянем: всех погибших, без вести пропавших, всех утопших, всех усовших, без мужика страдавших», – дип, тост әйтер иде... Хәзер дөньялар тыныч әлегә: тусыннар, нәселне дәвам итсеннәр! Ныклы бәдәнле, корыч холыклы, көрәшче булып тусыннар! Тормыш итүнең майлы әпәй ашау түгел, ә тоташ көрәш икәнен аңлап, чын ир-егет булып җитешсеннәр. Көрәштә үз-үзен яклый алмаган егет ни рәвешле өен, илен, җирен якласын, ди? Сыек буынлыларны да күп күрде Гарифҗан, ир исемен йөрткән андыйлардан ераграк торуың хәерле...

Ат чабышы, олылар көрәше башланганчы, күрше-тирә, яшьти-туган – һәр гаилә алан читендә үләнгә җәелгән ашъяулыкка табын корып мәш килә. Кайсы гына «өстәлгә» күзең төшмәсен, өем-өем пешкән йомырка, калай тәлинкәгә турап тезелгән каклаган каз телемнәре, пешкән ит калҗалары, шырпы тартмасыннан күренеп торган эре тоз, кемдә өч литрлы банка

белән кукраеп утырган салкын чәй, кемдә мәй, сырлы табада тегермән ташы кадәр булып пешкән мич ипие, яшел кыягыннан аерылмый гына ялтырап яткан ап-ак суган башлары күзгә ташлана. Бу йортка тәгаен шәһәр кунаклары кайтканын искәртеп, кайбер табында божра-божра яки ярымай рәвешендә киселгән колбаса кисәкләре, елтыр тышлы кәнфитләр күренә. Ак яки кызыл башларын ялтыратып утырган шешәләр тирәсендә кырлы стаканнар зеңгелдәшә, берәү тамаша кылырга китә, икенчесе табын янына килеп утыра, кемдер гармун суза, кемдер җырлый.

Көтү кайтканнан соң авыл өстенә сөт исе ничек таралса, Сабан туе көнне иртәдән үк бөтен ишегалдына, бөтен тыкрыкка, чишмә буйларына, тау итәкләренә елга бер генә килә торган бәйрәм исе, бәйрәм рухы тарала. Әби-чәби сандыгыннан рәешкә кияргә дип кенә саклаган, нафталин исе килеп торса да, хәйран затлы күренгән, зәңгәр күзле кыр чәчәкләре төшкән дүртпочмаклы яулыгын йә чуклы юка шәлен тартып чыгара, күршегә-мазар керсәң, алышынып куя күрмәсен дип, үз тамгасын суккан кызыл эчле кәлүшен барлый. Бабайларның да эш хутта: моңарчы эш арасында йөреп каралып киткән кипке бәйрәм көнгә кер сабыны белән ышкып югач, өр-яңага әйләнгән! Шулай да шифоньер өстендә шәлперәеп утырган түбәтәйне алу хәерлерәк булыр; көн җылы булса да, мәйданга кәчтүмсез бару да килешеп бетмәс... Бала-чага Сабан туе аланында чиертеп йөрергә дип симечке кыздыра, аны салырга, район гәзитен ертып, бүрәнке ясап мәшәләнә. Кыз-кыркын урындык аркасына эленгән яңа күлмәгеннән күз алмый гына, чәч очына кушып үрергә дигән тасмаларын үтүкли. Морҗалардан иртәдән төтен күтәрелә: каланыкылар кайтып төшсә, хәл белергә дус-туган сугылса, йөз кызарырлык була күрмәсен! Кичләп кенә суелган сарык ите кар базына төшерелгән: майлырак тирәсе бәлешкә үтергән дә куйган, ашка да җитә, Алла боерса! Табынга дип тә, алай-болай күчтәнәчкә җибәрәсе булса дип тә, язган май йомгаклары әзерләнгән. Кичтән үк пешкән, мичтә төн кунган балан бәлешләре, тастымалга төреп, чоланга чыгарылган. Туң майда йөздертеп кенә алган төш, бавырсак та, әлүмин табакларны тутырып, чолан киштәсендә урын алган. Хуҗабикәләр, Сабан туена киткәнче, маңгай тирен сөртә-сөртә, шулай аш ягы белән чолан арасында бөтерелә. Үзенә кирәген ир-ат үзе карар, алай-болай җитмәс булса, келәттә, бодай арасында яшереп тотканны кыймылдатыр...

Мәйданга аяк баскач, уен карардан битәр, һәркем башта, «Кеше күреп, үземне күрсәтеп килим», – дип шаярта-шаярта, бер кат мәйдан тирәли әйләнеп чыгар. Сабан туе шул рәвешле дус-ишләрне, туган-тумачаны, балачак дусларны, сыйныфташларны, түбән очларны, югары очларны барлаудан башлана...

Ашъяулык читенә кырын ятып, ирен читенә яшел кыяк кыстырган Гарифҗанның кәефе шәп. Маңгайга чиртсә, кан чыгара торган юан бармаклары янәшәдә ишетелгән гармун тавышыннан тез өстендә биешә. Кеше күзеннән качып кына улын имезеп өлгергән Мөкәррәмә, баланы арбага салып, ашъяулык өстендә ипи кисә. Бүләккә тәтегән яулык-сөлгене әниләре кочагына сонарга килгән малайлар, күзләре кызып, табын янында тукталалар.

– Көрәштек дисез инде...

– Аха!

– Шулай... Җебеп тормагыз!

Әтиләренең мактавы шул сүзгә сыеп бетә. Малайлар канәгать, ап-ак йомыркаларны бер-берсенең маңгаена бәреп ваталар да, мәйдандагы ярышлардан мәхрүм калудан куркып, ашыга-кабалана авызга озаталар. Ипи телемен сындырып капкан арада валчыклар ашъяулык өстенә коела. Гарифҗанның карашы шунда төбәлә.

– Сугышта, Карелия сазлыклары арасында ипи бөртекләрен суда җебетеп ашый идек...

Малайлар шым була. Мәйдан тирәсеннән яңгыраган авазлар ымсындырса да, кузгалырга иткән җирләреннән кире түнәләр. Сугышта күргәннәре турында әтиләре ачылып бик сирәк, тамак төбе чамасын белеп җылынган мәлләрдә генә сөйли. Андый чакта әллә ниткән киноларың бер якта торсын, авыз ачып тыңлый малайлар.

– Әти, әти, безнекеләр фашистларны ничек кырганны сөйлә але!

– Фашист кына, ди... Фине дә, япуны да калмады дим бит. – Гарифҗан иренендәге кыяк чертләп өзелә.

– Әти, әти, иң әшәкесе кайсы ие?

– Нимес әле ул турыдан сугыша. Менә финнарга җитми, мал-лай. Вәт аларның «кукушкасы»! Звир! Бер прастуй снайпер дистәләгән кешене бәреп сала. Үзен каеш белән бәйләп, агач башында яшеренеп утыра бит ул. Сухой паек кыстырып, атна буе да утырырга мужыт. Үлсә дә табып булмый иде кайвакыт, агачны кисеп төшерәбез. Алар чаклы-ы-ы! Төнлә блиндажга үтеп керсәләр, бетте, башта часовойны үтереп, калганнарны берәм-берәм суеп чыгалар, бөтен бүректәге йолдызны җыеп чыгып китәләр. Пачему – патаму што боларга кеше башы саен көн өстәп отпускы бирәләр икән... Аларның хитрыйлыгы! Йоклап яткан солдатка китереп кадамый, алай итсә, тегенең акырып җибәрүе, бүтәннәрне уятуы бар бит. Башта төртеп уята, теге күзен ачкач, йөрәгенә генә китереп кадый. Кисәк уянып, шок хәлендә булгач, кеше аваз чыгарырга җитешми кала икән. Шуны белеп, берәмләп уята, берәмләп үтерә бит, кабих...

Малайларның сулышы кысыла, тын алырга батырчылык итмичә, күмердәй көйрәгән күзләре белән әтиләренә төбәләләр. Сөйләсен генә, туктый гына күрмәсен...

– Армиягә утыз сигездә киткән идем, япуннарны тукмагач кына кайтып җиттем.

– Кантужен булгач, кайтып килдең бит. – Әниләре дә, сүз җебе өзелә күрмәсен дигәндәй, ипле тавыш белән төзәтмә кертеп куя.

– Саклаган инде Ходай, мал-лай... Пагранвайскада ием бит, нимесне куып, Норвегиягә кадәр барып җиттем. Ну Карелия сазлыкларында могҗиза белән исән калган ием. 16 мең кешедән мең кеше чыктык. Юлны белмибез, ашарга юк. Мүк арасыннан су суырабыз... – Әти кешенең карашы кырысланып ала. Ике ирен арасына бу юлы яшел суган менеп кунаклый.

– Японга китешли дә өйгә сугылдың әле. – Мөкәррәмә түзми, янә ачыклык кертә. Аның «өйгә сугылдың» диюеннән Гарифҗан кеткелдәп куя.

– Соң, эшелон Можга аша үтә дигәч, ничек түзәсең, аннан авылга ывсиво илле чакрым. «Японнар үтереп ташласа, гаиләне күрми калам», дидем дә төштем дә калдым...

– Минем әнкәй бездә ие бит. Иртән өчләр, дүртләр булды микән, тышка чыккан җиреннән артына ауган: «Берәү капканы ачып маташа, җонлы кул, кияүнең кулына охшаган», – дип, йөрәге алына язган бичаракаемның. – Арбада аваз салган сабыйны тирбәткән уңайга Мөкәррәмә дә көлеп куя.

– Әти, сөйлә инде...

– Әйтәм бит, исән калмас кебек идем, шуңа, беткән баш беткән, өйдәгеләр белән саубуллашып калыйм, дидем... Карыйм: бер яралы капитан, беренче ранглы, малай. Ике чумаданы тора кырыенда. Булышыйм, мәйтәм. Ике кулыма ике чумаданын күтәрдем моның, барам инде янында ординарецы сыман. Капитанга бәйләнүче юк, «ординарец» булгач, миңа да... Патруль туктата да үткәреп җибәрә, мин дә капитан артыннан юыртам... Өйдә ике көн тордым да киттем, эшелонны куып җитәргә кирәк бит. Хабаровскида куып җиттем үзебезнекеләрне. «Ты где был?» – дип полк командиры бәйләнмәкче. «Отстал, догонял», мәйтәм. «Догонял – молодец, отстал – губа», ди бу. Тәки ике атнага «губа»га (гаупвахтага) ябып куйдылар, малай. Ну мин бит кирәкле кеше, катюшалар механигы бит, аларны кабызырга бүтән механик юк. Эзлиләр икән – ә мин губада. «Срочно сюда!» – дип чакыртып алдылар. Катюшаларны сопкага куарга диләр, иртәгә иртәнгә катюшалар шунда тезелеп тормаса, трибунал, диделәр. Арттан төтен чыкса чыкты, тәки әзерләп бетердек иртәнгә.

– Әти, «Батырлык өчен медале»н шуннан соң бирделәрме?

– Булгандыр инде... Ярар, барыгыз, бар, бар, Сабан туен карагыз... – Гарифҗан, тугарылып ташлавын чамалап, урыныннан калкына.

– Әти, бая гына бер абый «нам, татарам, всяраунa, что Сабантуй, что война», – дип көлә иде, кызык, име...

Шәрифҗанның самими сүзеннән әти кешенең йөзенә кара күләгә куна.

– Ахмактыр ул! Свулыч! Дары исе иснәмәгән... Бер булыр, атаң башы...

Табын яныннан малайларның эзе суына. Алар, сүзсез караш белән генә аңлашып, табан ялтыраталар.

Һе, «всяраунa», имеш... Гарифҗан шул берәүне тотып ярырга, авызына ямарга, алай түгеллеген шәпләп аңлатырга җыенгандай, йодрыгын төйни, тозлы-борычлы сүзләр өстәп, «всяраунa синң» дип авыз эченнән мыгырдана.

«Все равно» булса, сугыш кырында, баш очында пулялар сызгырганда, күктән бомба яуганда, өскә ыжгырып, фашист танклары килгәндә, татар ирләре капчык киеп түгәрәк әйләнер иде, күрәләтә үлемгә барганын белә торып, күкрәге белән ут эченә ташланмас иде. Җир белән күк кояш нуры үтеп керә алмас дәрәҗәдә бербөтенгә әверелгән мизгелләрдә, үлем чалгысы егетләрне берәмләп, дистәләп кенә түгел, йөзләп, меңләп кырып салганда, яшисе килү теләге никадәр татлы булмасын, бу көрәштә корбан икәнеңне, әмма җиңелүче булып түгел, җиңүче булып егыласыңны белү көч бирә. Ут эчләреннән могҗиза белән исән чыккан Гарифҗанга күпме егетләрнең күзен үз куллары белән йомдырырга туры килде. Кайберләренең иренендә ана сөте дә кибеп бетмәгән иде, җир йөзендәге мондый мәрхәмәтсезлеккә – тарихтан сабак ала белми әледән-әле кабатланып торучы сугыш афәтенә, адәм баласы булып туганнар йөзендәге вәхшилеккә шаккатып туймагандай, кайсы шомырттай кара, кайсы күк йөзедәй зәп-зәңгәр күзләрен шыр ачып катып калган иде. Алар арасында күпме якташларын, күпме татарларны

күрде Гарифҗан! Күзен йомдырып, кем икәнен белеп, кабергә иңдерү – анысы да бер могҗиза, бер бәхет. Ә бомба яңгыры астында туфрак катыш кан булып һавага таралганнар, окопта, танк чылбыры астында күмелеп калганнар, сугыш кырында карга-козгыннарга азык булганнарны кем барлар? Алар да көрәшчеләр! Үз гомере өчен түгел, ата-анасы, баласы, туган туфрагы, менә синдәй ахмакларның гомере өчен дошманга каршы көрәшкә күтәрелгән иде алар! Малакасус! Свулыч! Сабан туен сугыш белән чагыштырырга... Кайсы диванасы уйлап чыгарган диген... Сабан туе бит ул... Сабан туе бит ул... Әнә кара, күпме дус-туганны бер йодрык итеп җыйган! Кайсын дошман күрмәкче буласың? Колга башына менәргә чират торучыларнымы? Ат менеп, җилдәй узышкан егет-җиләннеме? Мәйдан уртасында биленә сөлге салып, бер-берсен сөзәргә җыенган үгезләрдәй әйләнгән авыл батырларынмы? Көрәшсеннәр! Алар дошман түгел! Җиңүчесе җиңелгәнен кул сузып тартып торгыза, җиңелгәне, авызында кара кан булса да, кеше алдында күрсәтми, көндәшенең кулын кыса; эчендә хөсетлек йөртмәсә, кичен Сабан туе батыры чакырган табында кунак булып, ысвижий тәкә итеннән авыз итеп, рәхәтләнеп күңел ача. Татарның элек-электән килгән йоласы, язгы кыр эшләреннән соң тәнне дә, җанны да сугарып, үзенә күрә бер җилләнеп алу, бәрәкәтле туган туфракка, җир-анага рәхмәт белдерү бу, агайне. Монда да сугышалар кайчак, тик анысы тамак чылатканнан соң кычытып киткән йодрыкларны гына чарлау лабаса. Андый чакта, борының җимерелгән, күз төбең күгәргән булса да, икенче көнне үк кул кысышып, дуслашу хөрмәтенә берәрне тотып куясың да шуның белән шул.

Авыл малаеның беренче чын күз яше дә, беренче гарьлеге дә, беренче чын горурлыгы да Сабан туенда, көрәш мәйданында күренә. Гарифҗан үзен белә-белгәннән бирле көч сынашты, җиңгән чагы да, җиңелгән чагы да булды; гомер буе «усал» дигән дан йөртә менә. Усал дисеннәр. Ир-ат халадис кебек мәлҗерәп тормас инде... Көрәшче рухы ирне ир итә, андыйлар әйтәсе сүзен ярып әйтә, тотынган эшен җиренә җиткереп эшли, булмастайга буш вәгъдә биреп, төлке шикелле койрык болгап йөрми. Шундый ирләр өен дә тота, илен дә тота. Сугыш белән Сабан туен, көрәш белән көрәшне бутама син, агайне...

– Кытай Гарифҗан күренми дип аптыраган идем, кызынып ятасың икән. Әйдә, берәрне нитик тә... Көрәш карарга киттек. – Хәл-әхвәл белешеп кул сузган яшьтиләре әле дә булса кырын яткан Гарифҗанны фәлсәфи уйларыннан арындыра, ир-атларның дустанә көр тавышыннан тирә-яктагы бәллүр һава чыңлап куя. Әлегәчә тыныч кына йоклап яткан кечкенә Шәфкать тә, уянып, «мин дә барам» дигәндәй боргаланып, арбаны тибрәтә.

Кардондагы Сабан туе аланына, тирә-яктагы урман куенына алтмыш икенче елның тыныч тормыш тәменә сөенеп туя алмаган шат авазлар тарала. Ак яулыкларын аркасына төшереп, ияк буеннан бәйләп куйган әби-чәби, күз карашында тирән сагыш чагылган апа-түтиләрнең кайберләре исә, кайчандыр шушы көрәш кырында бил чарлаган, аннан шушы туфрак өчен барган көрәштә башын салган ирләрен, әтиләрен, улларын искә төшереп, сиздерми генә күз яшьләрен сөртә. Бит очларын пешерергә өлгергән ул тамчылар, йорт бүрәнәсе ярыгында сакланган похоронка кәгазенә,

«хәбәрсез югалды» дигән хәбәрләргә ышанырга теләмичә, бәлки кайтыр дигән өметне гомер буе югалтмас хатыннарның, яудан кайтмый калган 254 ир-егетнең әйтелмәгән сүзе, язылмаган җыры, мәңгелек кайтавазы булып, җир-ананың күкрәгенә тама.

Ә мәйданда көрәш дәвам итә.

***

Коридор буйлап, күк күкрәгән тавыш чыгарып, әллә арба, әллә носилка тәгәрәтеп барганнары ишетелде. «Тагын берәрсе киткәндер». «Чират миндә микән?» Уйларны мәгънәлегә һәм мәгънәсезгә бүлсәң, икенче өем биегрәк булыр иде...

Курку һәм өметсезлекнең йөзен аеру мөмкин түгел иде. Ирек чикләнү җанны өненә куып кертелгән җәнлектәй бәргәләнергә мәҗбүр итә. Югыйсә акыл аңламый да түгел: бәргәләнеп кенә хәлне үзгәртеп булмый. Бәлки аның белән килешергә, әлеге мизгелне ничек бар – шулай кабул итәргә дә бу минутта исән икәнеңә, фикер йөртү сәләтен югалтмаганыңа шөкер итеп, тыныч кына ятаргадыр? Депрессиянең юньлегә илтмәгәнен, төшенкелеккә бирелүнең куркыныч икәнен бик яхшы белә Фәйзелхан, тик сәер хәл: шул куркынычны аңлаудан тагын да куркыныч. Табиблар борчылмаска куша кушуын, коронавирус белән авыручыларның бик күбесе шушы халәт белән көрәшә, үтеп китәр, дип юаталар. Үзеңнең хис-тойгыларыңа баш була белүнең дә олы бер йөк икәне турында моңарчы уйланганы юк иде, менә җай чыкты. Ул тойгыларны күрмәмешкә салышырга, алардан качарга, аларга бирелергә була; сөенергә, нәфрәтләнергә, еларга, үзеңне гаепләп кыйнарга була – бу халәттән курыкмаска һәм шул халәткә берегеп катмаска гына кирәк. Әкрен бару түгел, бер урында туктап тору куркыныч. Җанны берөзлексез кимергән бушлык хисен җиңәр өчен үзгә көч кирәген чамалый Фәйзелхан. Ә нинди көч ул, каян алырга – менә анысына җавабы юк әле. Тәненә көч кирәксә, перчатка киеп бокс грушасын төяр, гер чөяр, куна-төнә спорзалда ятар иде, җанга дигән көчне каян табарга?..

Әллә соң бу таҗлы вирус дигәннәре саташты микән, Фәйзелханның шул ук көрәшче Фазыл икәнен белмичә, ялгышып кына килеп ябышты микән?..

***

Буй җиткереп килгән, көчен кая куярга белмәгән Фәйзелханны бәхет басты. Алар сыйныфына җитәкче булып кайткан яшь укытучы – Равил абыйлары көрәш ярата, Сабан туе батыры. Уртача гына буена, чандыр гына гәүдәсенә карап, бер дә алай димәссең тагын... Эштән башканы белмәгән-күрмәгән авыл малайлары өчен бер могҗиза кебек тоелды ул. Үсмер малайның көрәшкә дәрте барлыгын каян сизеп алгандыр, әллә ни арада гына үз итте дә куйды. Дөресрәге, карачкы ясады... Үзенең кулы кычытып торамы, формасын югалтырга теләмәве булдымы – спортзалдагы иске маталар өстендә Фәйзелханны көрәш алымнарына өйрәтергә тотынды. Сигезенчедә укыган, буе 155 сантиметр, авырлыгы илле биш кило булган Фәйзелханны чөя дә ата, чөя дә ата. Малай да үҗәт: елыйсы килсә дә, бирешергә, ташлап качарга исәбе юк, тешләрен кысып укытучының биленә ябыша.

Тугызынчыга күчкәч, буе 165кә, авырлыгы 65 килога җитте Фәйзелханның. Ул инде мәктәп спорт залына тәмам береккән иде. Укытучысы белән көрәшеп арыгач, ял иткән арада стенага арка терәп утыралар да тиңдәшләр шикелле гәп куерталар.

– Көчеңне тиккә әрәм итмә, малайлар белән кыйнашып йөрмә анда. – Ни дисәң дә, класс җитәкчесе бит – Равил абыйсы остазларча гына сабак биреп алмакчы.

– Кит инде, Равил абый, булмаганны. – Фәйзелхан күзен дә йоммый аңа карап, шаян елмаеп куйды. Нәрсә-нәрсә, менә анысына вәгъдә бирә алмас. Дөнья бит бу.

– М.ны кыйнаганыңны беркөн генә үзең сөйләдең бит. – Укытучы да хәйләкәр елмайды.

– Ә-ә... Анысы әллә кайчан ла. Әләкләшмәсен иде.

Малайның йөзендә тагын шаян яктылык җемелдәде. Чыннан да күптән, башлангычта ук булган вакыйганы теленнән ычкындырган иде шул. Әй, кыйнау дип инде... Фәйзелхан үзе дә гаепле иде лә. Шуклык инде, нишләтәсең. Классташ кызны елатты. Укытучы апасы, ата-анаңнан башка килеп күренмә дип, кайтарып җибәрде дә җибәрүен, тик менә шулай дип өйдә авыз күтәреп ничек әйтмәк кирәк?.. Атна буе тинтерәп йөрде: иртән өйдән букчасын күтәреп, мәктәпкә дип чыгып китте дә, көнне Акай тау башында уздырып, башкалар укудан кайтканда гына кайтып керде. Беркөн чуан тишелде: кайтып, ишегалдында кер элеп йөргән әнисенең күзенә генә күренде дә, бер төркем сабакташының алар капкасына якынлашуын искәреп, болан күк уйнаклап, өйгә чумды. Кызлар арасында бердәнбер малай – М.ны гына чамалап калды Фәйзелхан, хәлнең кыркулыгын аңлап, ялт кына мич башына үрмәләде.

– Мөкәррәмә апа, Фәйзелхан нишләп мәктәпкә килми ул? – Бер кызның чатнап торган тавышы ябылмый калган ишек аша мич башына ук менеп җитте.

– Кит аннан, әнәтерәк кенә шуннан кайтты бит. – Әнисенең тавышы өй түреннән үк урап, кире ишегалдына атылды.

– Ю-ук, атна буе килмәде, әллә авырды микән дидек.

– Авырган ди... – Монысы – М. тавышы. – Теге көнне курыккан да шуңа килмәгән инде.

– Кайсы көнне? – Бетте, болай булгач, морҗа торбасыннан шуып чыгып кына да котыла алмассың, әнисе кызлардан сорау ала иде...

Бераздан җил-җил атлап, өйгә кергән Мөкәррәмә кулындагы җиз тасны мич алдына юл уңаеннан гына очырды да Фәйзелханны эзләп, күзе белән башта өй эчен айкады, аннан магнитлы таяк белән тапты диярсең, ялт кына үрелеп, мич башында, киез итекләр арасында үзенчә качып яткан малайны ботыннан сөйрәп төшерде. Ничек өлгергәндер: сөйрәгән шәйгә, цирк артисты диярсең, шундагы итекләрне дә эләктереп, саммай йомшак җиргә каты-каты гына итеп биргәләп тә алды.

– Ах, пүтсез, шайтан малай, кара, ничек котылмакчы, әй...

Икенче көнне Фәйзелхан М.ны кыйнады. Әләкләшмәсен иде, малай кеше лә ул... Егет була белсен иде...

Равил абыйсына сөйләгән иде, шуны искә төшереп төрттерә хәзер.

– Андый холкың белән башлангычта син каян рус классына барып кердең соң, анда бик «элитный»ларны гына алалар бит.

– Әй, яңадан укытучылар да, «Раузалия апасы бик әйбәт укыгач, тәртипле булгач, бусы да шулай булыр дигән идек», – диде инде...

– Ярар, ярар, борыныңны салындырма, болай гына әйтәм. Башың шәп эшли синең, укуың зарлана торган түгел. Физика-математикадан олимпиадаларда җиңәрлек булгач инде...

Морт авылы элек-электән аягында нык басып торган авыллардан санала. Заманында район үзәге дә булгач, хәл-әхвәле зарланырлык түгел. Кулы эш белмәгән беркемне тапмассың, эшкә дә ныклар, телгә дә осталар. Кайчандыр алпавытныкы булган йортны бирегә мәктәп итеп күчереп салганнар. Сугыш елларында, авылга Ленинградтан дүрт йөзгә якын бала эвакуация белән килгәч, беренчедән унынчыга кадәр рус сыйныфлары да ачканнар. Равил абыйсы әйтмешли, андый классларга балаларны сайлап кына алалар иде. Фәйзелханның да төшеп калмаганнардан икәнен белгәннәрдер... Мәктәп формасы үзе генә дә ни тора: малайларның башында йолдызлы фуражка, өстә костюм, бил каеш белән буылган, аякта күн итек!..

Фәйзелханны күпләр артист булыр бу дип уйлый. Телгә җорлыгы, осталыгы өстенә, әтисенә охшап, матур җырлый, татарча да, русча да өздерә генә. Мәктәптә Маяковский шигырьләрен сөйләп җибәрә – артистларың бер якта торсын. Бәләкәйрәк чакта уникe телле тальянда да уйнарга исәбе бар иде дә соң, гармунның телләре генә аның бармакларына чыдамады – беренче көнне үк ватылдылар да куйдылар. Шуннан соң, бәласеннән башаяк дип уйладылар микән, «борчак чапкан акчага алган идек, әрәмнәр иттең», – дип зарлана-зарлана, гармунны малайның күз уңыннан ераккарак яшерделәр. Ярар, спорт барында ансыз да ничава болай... Менә Шәрифҗан абыйсы өйрәнде. Ватык телләрне ыштан җыймасы, шөрепләр куя-куя рәткә салды да бераздан сыздырып уйный да башлады.

– Спортсмен чыгар синнән, үҗәтлегең бар. – Яшь укытучы укучысына өметле караш ташлады. – Чаңгыда да шәп йөрисең, ялкауланмаска гына кирәк.

– Чаңгыны калдырган юк!

– Чаңгы дигәннән, иртәгә урманны урарбыз. Зыбин белән икегезгә биш круг! Ярышка төшкәнче табаныгызны шомартырсыз бераз.

Авылга терәлеп диярлек торган урман – олысына-кечесенә ишегалды кебек инде ул. Җәйме, кышмы – сукмакны өзгәннәре юк.

Равил абыйлары Фәйзелхан белән Женяны район ярышына әзерли иде. Икенче көнне, Морт урманындагы наратлар шикелле төп-төз, мәһабәт булып үсеп килгән егетләрне чаңгыда ярыйсы гына чаптыргач, үзе дә арыды булса кирәк:

– Мондагы лесничий минем дус малай, әле генә өйләнде. Килгән-килгән, тиз генә котлап чыгыйм үзен, сез көтеп торырсыз, – дип сүз катты.

Егетләргә нәрсә, ике дөнья – бер морҗа, котларга икән – котларга. Ябалдашларына бүрек-бүрек кар утырган ак якалы агачлар арасыннан күңелле сызгырган чаңгы көенә үзләре дә җыр белән кушылып, абыйлары артыннан юл тоттылар.

«Хәзер чыгам» дип кереп киткән җиреннән шактый озакка гаип булды

укытучылары. Малайларның аягына суык йөгерә башлады. Борылып китсәң, яхшы түгел – көтеп торабыз дигәч, аймыл булулары бар.

Яланөс, башына бүрек чәпәп кенә урманчы өеннән килеп чыккан бер егет, аларны абайлап, яннарына килде дә кемнәр икәнен ачыклагач:

– Айн мамит, – дип, кире кереп китте. Бераздан, ике кулына ике калай кружка тотып, ишекне терсәге белән генә ябып, кабат пәйда булды. – Хәзер чыга укытучыгыз. Болай кәкрәеп торсагыз, катып үләсез бит. Мәгез, тотып куегыз әле, җылынып китәрсез.

– Чәймени? – диде Женя Зыбин, шул арада бияләен салып, кружкага үрелеп.

– Чәй, чәй... самадильный... җылынырга шәп дим бит, эчегез, эч.

Аны-моны уйламаган малайлар «чәй»не ялт кына бушатып, кружкаларны рәхмәтле йөз белән егеткә суздылар. Ул арада өйдән, хуҗалар белән гөр килеп саубуллаша-саубуллаша, Равил дә килеп чыкты. Чаңгысын киеп, малайларны әйдәкләде, бераздан, аларның артка калып, нишләптер бик сәер генә, йөзгәндәй генә шуып килүләренә игътибар итеп, яннарына борылып килде.

– Болваннар, эчтегезме әллә сез? – диде ул, малайларның саф һавадан түгел, бөтенләй башка сәбәптән кызарган йөзләренә, йомшарып-йомшарып киткән тез буыннарына шаккатып карап.

– Туңган идек...

– Вәт болваннар, вәт болваннар!

Исән-сау авылга кайтып җитсәләр, ата-аналарына ни дип җавап бирәсе булыр? Равилнең башында бер генә сорау бөтерелергә тотынды. Евгений Зыбинның әтисе Алексей Яковлевич үзе дә укытучы, алтын куллы рәссам, унҗиде яшендә сугышка китеп, яу кырын иңләп-буйлап кайткан фронтовик. Хатыны Неля Алексеевна (Наилә Әюповна) мәктәптә тарих укыта, гаҗәеп яхшы кешеләр, аларның күзенә ничек карарга хәзер? Шул арада бит, шул арада... Хурлыгы ни тора...

Ярый әле авыл урамына кайтып кергәндә, караңгылык иңәргә өлгергән иде. Кеше күзенә артык чалынмый гына Зыбиннарның капка төбенә килеп җиткәч, аларны көтеп кенә торгандай, капка ачылып та китте, аннан Женяның әтисе килеп тә чыкты. Күрәсең, малаеның озаклавына борчылып, ут йотып торуы булгандыр.

Мондый җәһәт очрашуны күзалламаган Равил, тотлыга төшеп:

– Вот, Алексей Яковлевич, Женя... выпил немного... – дип, сүзен әйтеп тә бетерә алмады, җилкәсенә юка шәл бөркәнеп, капкада чәчрәп пәйда булган Неля Алексеевнаның аһылдаулы авазы ишетелде:

– Что выбил? Что выбил? Глаз штоли? – дип еларга да тотынды ул бер култыгыннан Равил, икенчесеннән Фәйзелхан эләктергән улына коты очып төбәлеп.

– Мать! Иди домой! – Алексей Яковлевичның әмереннән соң, ничек күренгән – шул тизлек белән күздән дә юк булды хатыны.

Ата кеше малаеның якасыннан гына эләктерде дә, чаңгысы белән бергә сөйрәп, ишегалдына алып кереп тә китте.

Ни көләргә, ни еларга белмәгән Равил чаңгысына таянып, авыз ерып басып торган Фәйзелханның җилкәсенә шап итеп берне кундырды.

– Болваннар! – диде ул, бу юлы беркадәр җиңел сулап...

Инде буйга 178 сантиметр, авырлыкка 78 кило булган Фәйзелхан, көрәш техникасын белеп бетермәсә дә – күпме шөгыльләнсәләр дә, шул бер үк тактикадан ерак киткәннәре юк бит – беләк көче белән теләсә кемне урынына утыртырлык иде. Егет үзе өчен шуны ачыклады: көрәш беләкне генә түгел, йөрәкне ныгыта икән; үз сүзеңне турыдан өздереп әйтергә, гаделсезлекнең күзенә туры карап каршы чыгарга, һәр адымыңны алдан ук кыл иләктән иләргә өйрәтә икән. Әтисе дә, Шәрифҗан абыйсы да шул ук сүзләрне кабатлый иде, тормышның язылмаган кагыйдәсен аларның эзенә бастырып килгән энеләре Шәфкатькә дә төшендерәсе булмасмы әле...

Бу елның авыл Сабан туе, кызлар толымында тирбәлгән аллы-гөлле тасмалар шикелле, салават күпере төсләрендә балкыды. Бакчы, кояш күзеннән агылып төшкән һәр нур бөртегендә асылташ чагылышы бар икән бит. Дус-ишнең аркадан шапылдатып китүендә дә, күрше урам кызларының керфекләрен түбәнрәк кагып үтүендә дә, кәкре мөгезле тәкәне матай бишегенә салып маташканда, эти кешенең, «Кара, даны бар икән шул моның... Мин сине болай уктыр дип уйламаган идем», – диюендә дә моңа кадәр һичкайчан татымаган татлы бер тәм бар икән. Унҗиде яшендә беренче тапкыр авыл батыры булып калган Фәйзелхан, шул тәмне озаккарак сузарга теләгәндәй, тирә-якка күз салды.

Моңарчы өч улының мәйданда беренчелекне бирмәвенә күнеккән авылдаш апай, янәшәдә генә биленә таянып:

– И Алла, өчегез шул Кытай малаена ектырдыгызмыни? – дип, шул хәлгә ышанып җитә алмыйча аптырап, үз малайларының әле берсен, әле икенчесен тинтерәтә иде.

– Әллә Алабугага да барып карыйбызмы? – диде үзе батыр калган кебек дәртләнеп киткән Гарифҗан, Рабиганың сүзен бөтенләй ишетмәгәндәй, улының баһадир гәүдәсенә баштан-аяк күз йөгертеп. – Мужыт җиңеп тә ташларсың, кем белә...

Чыннан да, ә нигә әле көчне сынап карамаска?

– Киттек соң, – дигән булды Фәйзелхан, эчендә дөртләп кабынган янгынны сиздерми генә, артык каударланмый гына, кулындагы чигүле сөлгегә маңгай тирен сөртә-сөртә.

Район Сабан туе башкачарак. Халык көрәшкә чыгучыларны исемләп белә, һәрберсенең үз җанатары бар, алдан ук фаразлаучылары та табыла. Керәшен егетләре, бертуган Степан һәм Николай Кузнецовларның да, Алабуга милиция мәктәбе тренеры Володя Солгуновның да батыр дигән даннары тирә-якка таралган. Менә, быел да көрәш мәйданында шулар бил тота.

– Икенче, өченче урынга барганнар белән алышып кара да, булмаса, кайтырбыз да китәрбез, – диде Гарифҗан, улының болар янында әле «яшел» икәнен тиз чамалап.

Тик «яшелмен» дип тормады Фәйзелхан, көч белән алдырды, Кузнецовны да җиде секунд эчендә егып салды. Беренче урынга көрәшкәндә генә, Солгунов тиз арада «чистага» екты үзен. Тактиканы белмәгәч, артык бөтерелә алмыйсың, ни хәл итмәк кирәк...

– Маладис, көчең бар! – диде ата кеше, матай рулен тотып җилдереп кенә

кайтып килгән мәлдә, горурлануын, соклануын артык җәелеп сиздермичә. – Институтта да ташламассың көрәшеңне.

Бүгенге җиңелүне кырык иләктән иләп, күңелендә буран уйнап кайткан егет әтисенең сүзләрен башта тиз генә аңышып бетермәде. Аңлагач, мыек астыннан гына елмаеп куйды. Әле тәгаен гына кая укырга керәсен хәл итмәгән ләбаса... Эрләмәгән, сукмаган, Шыгай, сиңа ыштанлык, дигән сыманрак инде бу...

– Нигә көләсең? Авыл хуҗалыгы институтына җибәрәм мин сине. Җир хуҗасы булырсың. Кыяфәтең килгән. Синең ишеләр дә кайгыртмаса, бу басулар кем кулына кала дисең... Һе, авылга баш инженер йә агроном булып кайтып төшсәң, мишәйтләмәс... Колхозның тоткасы шулар инде...

Шул-шул... Улың авылда «вәжнәй» генә урында булса, йорт хуҗалыгында да, әпәйт-теки мал-туар тирәсендә дә күңел тынычрак булыр иде. Дандәрәҗәсе, курмысы-мазар дигәндәй... Ата кеше киң алдырып уйлый... Тыныч тормыштагы һәр көне авыл туфрагында, аның кырларында үткән, шул кырларга маңгай тире тамган Гарифҗан өчен туган җир дигән төшенчә дә бик кыйммәт, бик газиз. Җир кадере белүчеләр кирәк авылга, аның киләчәге булсын өчен белемле яшьләр кирәк! Күр, яшим дигән кешегә колач җәеп яшәрлек бит монда. Шәһәрдән ким җире юк. Салам түбәле йортлар калмады диярлек, һәркемдә шифер йә калай түбә. Һәр йортта диярлек радиосы, телевизоры бар. Урта мәктәп, больница, китапханә, клуб дисеңме... Мортның һавасы гына да соң... Күмәч өскәйләренә ягып ашарлык... Урманы өстеңә аварга тора. Елгасында балык тулы. Һәр бакчада умарта. Кирпеч заводы бар. Ярар, анысында кирпеч сугу бетте инде. Ат, сыер, сарык фермалары, бер түгел, әллә ничә кибет, чәйханә эшли. Биш ел элек «Сельхозтехника» берләшмәсе ачылды, эшлим дигән кешегә эш җитәрлек. Җитмешенче елга шулай кергәнне, тагын ике-өч дистә елдан чәчәк атарга тиеш бу авыл, гөл булып балкырга тиеш!.. Шәһәреңне бәреп екмасмы әле... Татарның тамыры бит ул авыл, җаны бит ул. Калага китеп, әлләкем булып йөргәннәрнең дә кендек каны авыл туфрагына тамган, тәпи басуы шул туфракта булган. Татар барда хәтәр түгел, татар барда эш бар, авыз тутырып ашарлык икмәк бар, сәке тулып тәгәрәгән бала-чага бар. Иллә мәгәр эштән аерсаңмы... Бетте, тамыры корый, сулышы өзелә авылның. Эшсез эленке-салынкы бер көн, бер атна, бер ай селкенеп йөргән ир-ат йә эчүгә сабыша, йә кәтүмкәсен төйнәп, читкә чыгып китә. Шахтасында күмер чаба, заводында станок артында бил бөгә, чит кавемне үрчетә башлый ул.

Өч улына да зур өмет баглый иде Гарифҗан. Шәрифҗаны ветеринария институтын бетерер, Фәйзелханы авыл хуҗалыгыныкына керер; Шәфкатьләре әле бәләкәйрәк, анысына да шәп кенә бер һөнәр табылыр... Типсә тимер өзәрдәй өч пәһлеван булып, авылга кайтып, гөр килеп яшәсәләрме...

Сабан туйлары шаукымы җилдереп кенә узып китте, авыл янә үзенең тыштан салмак, эчтән кырмыска оясыдай кайнап торган тормышына күмелде. Фәйзелханның да ике кулына бер эш табылды: ишегалдында, җәй үткәнче, лапас төзеп куярга кирәк иде. Ике катлы булачак: кышлыкка дигән печәнне шунда, өскә өячәкләр моннан соң. Күз курка, кул эшли дигәннәре хак: тырыша, җиренә җиткереп эшли торгач, аскы өлеше шәп кенә булып

сафка да басты лапасның. Өске өлешен дә биек итеп, дүртпочмаклы итеп эшләргә исәбе егетнең. Алайса, кыек түбәгә печән менгергәндә, йөдәп бетәсең, биленне турайта торган түгел, башың белән такта санап, кадак санап тик йөрисең... Анысына тотынганчы, вакыт табып, Казанга институтка документлар илтеп кайтсаң да ярар иде...

Бирим дигән колына, чыгарып куяр юлына, нәкъ шул көнне әтисе янына хәл белергә сугылган ахире Казанныкы булып чыкты, җитмәсә, кайдадыр доцент икән. Әллә дусты белән күрешү шатлыгыннан, әллә Мөкәррәмә пешергән тавык шулпасының төменнән май кояшы кебек балкыган кунак ике сөйләшергә урын калдырмады: документларны үзем алып китәм, үзем илтеп тапшырам дип, катлы-катлы вәгъдәләр, шул вәгъдәләр өстенә адресы язылган кәгазь дә калдырып, кайтыр юлына кузгалды.

Көннәрне сиздерми генә кыскартып, җәй узып бара иде. Лапасның икенче каты да күзгә күренеп, түбәсен ябасы гына калды. Сабакташларының барысы да документларын кайсы кая үз куллары белән илтеп тапшырган, клубка чыктың исә, телләрендә шул. Фәйзелханның да эченә корт төшә башлады, ничек тә Казаннан урап кайтырга кирәк дигән уй күңеленә тынгы бирми иде. Әтисенә үзе дә шулай дип сүз кузгалтты. Әнисе дә:

– Гарифҗан, әллә соң барып кайтсынмы, бер хәбәрсез ятканчы, – дип, җайлап кына сүз катып карады.

– Ничу вакыт әрәм итеп йөрергә... Лапасның түбәсе ябылмаган. Кәгазьләрне ахиргә бирдем, илтәм дигәч илтә бит инде, юкка көяләнмәгез, – дип кырт кисте Гарифҗан.

Фәйзелхан «доцентның» адресын, әнисе әзерләгән юл төенчеген куенына кыстырып, Казанга юл тотканда, гөнаһ шомлыгына, лапасның эше генә түгел, югары уку йортларына документ тапшыру вакыты да бетеп киткән булып чыкты. Әллә кайда, Боровое Матюшинода яшәп ятучы доцентны эзләп тапканда, аның бу кәгазьләрне беркая да илтмәве ачыкланды.

Караңгы төшкәндә, Казан урамында каңгырап йөргән Фәйзелханны гарьлек тойгысы биләп алды. Җитмәсә, үтереп тамагы ачты. Төенчектә әнисе юлга дип тыккан икмәк һәм ит телеме бар да соң, аларны монда, урам уртасында авыз күтәреп ашап утырмассың, оят бит... Әйләнеп-тулганып йөри торгач, Кабан күле буендагы комлыкта зонтик түбәләр күзенә чалынды. Аларның су коенучылар өчен киенә-чишенә торган корылма икәнен авылдан килгән егет әле каян белсен – тотты да шуларның берсе астына кереп чүмәште. Тамак ялгаган мәлдә онытылып торган баягы гарьлек тойгысы, елга суында битен-кулын чылатып алганнан соң, янә баш калкытты, егет, үзен тотып кыйнардай булып, яралы аю кебек бәргәләнде. «Вәт дурак! Кәгазьләрне атасы биргән, имеш. Үз башың юкмыни синең? Үзең уйлый белмисеңмени син?» Егет гарьлектән күз яшьләре белән елый иде.

Тормыш биргән беренче ачы сабак иде бу. Үз сукмагыңны үзең ярырга өйрән! Берәүгә дә салынма! Сикәлтәсе, упкыны, гарасаты, зилзиләсе очраганда да, бары үз көчеңә ышан!

«Баерга киткән түтекәй үлеп кайткан, ләң-ләң» дигән әкияттәге кебек, авылга сөмсере коелып кайтырга, этләрне дә, әтәч-тавыкларны да сөендерергә исәбе юк иде Фәйзелханның. Җәйнең бер саплам төне аңа

уй йомгагын сүтеп җыяр өчен җитәрлек булды. Беркем алдында мескен булып күренмә, ир-егет булып тугансың икән, башыңны югары тот! Юлыңа аркылы тәгәрәгән таш ул синә абынып егылыр өчен түгел, туганкай, ә шуңа басып, үз максатыңа тагын да тизрәк үрелер өчен генә... Онытма!

Өйдәгеләр бу хәлне фаҗига итеп кабул итмәделәр шикелле, артык ах-ух килгәннәре колакка чалынмады. Раузалия апасы, кияүгә чыгып, Әлмәттә төпләнгән иде, телефоннан сөйләшкәндә, энесенең шундый хәлгә таруын белгәч, тотты да аны үзләренә чакырды:

– Бездә кичке институт бар бит, әле анда документ алалар, әйдә, җыен да кил, – диде ул, ире, каенанасы, ике малае белән яшәп яткан дөньяга киң күңел белән энесен дә сыендырырга әзер булып.

Әллә ни озак баш ватмады Фәйзелхан, Казанга дигән өметләрен урлаган, шулай да ишегалдында кукраеп утырган өр-яңа лапас тирәли йодрыкларын учка кысып, бер-ике әйләнде дә, уй-фикерен тәртипкә салгач, Әлмәткә юл тотарга булды.

Нефтьчеләр каласы аны салкынча күз белән каршыларга җыена иде. Автобус тәрәзәсенә бәреп-бәреп яуган яңгыр тамчылары, егетне үртәргә теләгәндәй, качышлы уйный-уйный пыяладан тәгәрәп төшәләр дә күздән юк булалар. Ни авыл, ни шәһәр урамы дияргә белмәссең; зонтик тоткан, башына портфель каплаган, муенын якасына чүмәштергән кешеләрнең яңгырдан тизрәк качарга теләп, адымнарын ешайтканы күренеп кала.

Ярый әле апасы яшәгән йортта җылылык хөкем сөрә иде. Әсләм җизнәсе дә, аның әнисе Хурлыҗинан әби дә егетне көтелгән кунак итеп каршы алдылар. Рөстәм белән Илгиз әле акны карадан аерырлык яшьтә булмасалар да, дәү гәүдәле, башкаларны гел көлдерергә яратучы абыйларына бик тизияләштеләр.

Фәйзелхан институтның кичке бүлегенә бер каршылыксыз укырга керсә дә, берничә көн үтүгә үк нефть, газ темасы буенча дәресләрнең үзе өчен коточкыч күңелсез бернәрсә икәненә төшенде. Юк инде, тартмагач тартмый күңеле. Калын дәфтәрне, ручканы алдына сала да чукмар йодрыкларын аптыраулы халәттә тез өстенә куеп уйланып утыра: болай үз-үзен җәфалавы озакка чыдамас, пажалый...

Әлеге уе кич институттан апаларына кайтып барганда да, әрсез черки урынына башында бөтерелә бирде. Укырга киткәнче колхозның үләксә базын кул белән казып киртәләгәч, байтак хезмәт хакы тоттырганнар иде, шул акчага алынган вельвет якалы, тирән кесәле өр-яңа пәлтәсен киеп, аулак тыкрыкка борылган мәлендә каршысына бер төркем яшьләр килеп чыкты. Фәйзелхан, аны-моны уйламый, аларны әйләнеп үтәргә җыенган иде, төркемнән берсе аерылып, пәлтә җиңеннән бөтереп тотты:

– Деньги есть?

Тәкәллефсез сораудан Фәйзелханның җен ачуы кабарды. Аһа, шәһәр шпаналары, акча кирәкме сезгә? Булса да әллә тоттырыр дип өметләнгән идегезме? Тәненнән шыбыр тир агыза-агыза, сезгә китереп бирер өчен учлары сөялләнгәнче баз казып изаланган, ди, колхозда...

Пәлтәгә ябышкан кул мизгел эчендә сыдырылып төште. Мондый каршылыкны көтмәгән ач яңаклы егет, бөгелгән уңайга, чыраен сытып чинап җибәрде. Төркем исә, эт өере хәрәкәте белән Фәйзелхан өстенә

ыргылды. Аның таза йодрыклары әле берсен, әле икенчесен төрле якка мендәр мамыгы урынына очырып җибәрсә дә, егетләр күп иде, аяктан егарга теләп, алдан да, арттан да килеп куна тордылар. Фәйзелханның баш миен яшен утыдай ярып, әле күптән түгел генә үзе өчен үзе ачкан алтын кагыйдә сызылып үтте: бары үз көчеңә ышан! Шушы ярсулы уй аңа көч өстәдеме, егетнең йодрыклары тагын да елгыррак селтәнергә тотынды, җиңел табышка өметләнгән егетләр кайсы ияген, кайсы яңагын, кайсы төшкән тешен тотып, читкә тайпылдылар.

Алар күз бугандай юкка чыккач, Фәйзелхан яңа пәлтәсенең умырылган яка-кесәсенә, коелып беткән төймә урыннарына мыскыллы караш ташлап, үзалдына да мыскыллы елмайды: «Нәрсә, вельвет яка, авыл гыйбады, эләктеме үзеңә?» – диде ул, бу минутта тормыш китабына икенче сабак-кагыйдә язып куясын күңеле белән тоемлап. Үз көчеңә таянганда акыл да мишәйт итмәс!.. Алда ни көткәнен алданрак чамаларга өйрән!..

Фәйзелхан институтны үз итә алмый тагын бер-ике ай тинтерәп йөрде дә, моның вакытны суга салу икәнен анык белеп, ахыр чиктә тотты да ташлады. Туганнары җилкәсенә салынып ятарга җыенмый иде, өстеннән авыр тау төшкәндәй җиңел сулап, эш эзләргә тотынды егет. «Йөк ташучылар кирәк, хезмәт хакы 180 сум» дигән белдерүгә тап булгач, ике дә уйламый, шул конторага юл тотты.

– Үскәнем, анда цемент ташырга кирәк, сиңа 18 яшь тулмаган, алалмыйбыз, – диде кадрлар бүлегендә утырган, чәчен сап-сарыга буяп бөдрәләткән, кылыч борынлы хатын, паспортны сузып.

– Һәй, апа, тулмаса да, ике кулга ике капчык тотып ташый алам мин. – Фәйзелхан шаярту белән отарына өмет итте.

– Гәүдәңә карасаң, өчне ташыйм дисәң дә аптырамыйм. Ярамагач ярамый шул. – Шулай да, көче ташып торган егетне кире борып чыгарырга теләмәдеме, апа бер мизгелгә уйланып торды да өстәлдә таралып яткан кәгазьләренә җитез генә күз төшереп: – Әйдә, без сине слесарь өйрәнчеге итеп алабыз. Аннан карарбыз, – диде, егетнең кулындагы паспортка кире үрелеп...

Уйлап баксаң, тормышта бер генә кеше дә, бер генә нәрсә дә башкалар юлында тикмәгә һәм очраклы гына пәйда булмый. Күзгә күренмәгән ниндидер тылсымлы көч җир йөзендәге тереклекне бербөтен итә, кичәге белән бүгенгене, үткән белән киләчәкне тоташтыра. Көннәр-атналар агышындагы һәр мизгел – күпер...

Кулларын юып, өстәл янына килеп утырганда, Әсләм җизнәсе шунда ук Фәйзелханның көндәгедән кәефсезрәк икәнен чамалады.

– Ни булды, кайнеш, балтаң суга төшкәндәй күренә? – диде ул, егетнең калын җилкәсенә үз итеп каккалап.

– Әй... грек-рим көрәше секциясенә язылырга дип барган идем, алмадылар. Авылда көрәшә идем диюемнән көлделәр генә... – Фәйзелхан үртәлүен яшереп тормады. Үзен шулай борып чыгаруларына җаны көйрәгән иде.

– Безнең Фәйзелханның ничек көрәшкәнен күргәннәре юктыр, – дип, Хурлыҗинан әби дә сүзгә кушылды.

Аның болай диюеннән аш бүлеп маташкан Раузалия кычкырып көлеп җибәрде.

– Әнкәй, инде кызларың да көнләшә, «үз баласымыни, безнең Фәйзелхан дип авызыннан төшерми», диләр.

– Серләр килешә безнең аның белән, әйме, улым, – диде каенана, сүзгә кеше кесәсенә керми генә.

– Фәйзелхан, ашагач, малайларны паркка алып чыгып керерсең әле, синең кайтуыңны көтеп, күзләре күгәрде. – Апасы аның алдына хуш ис бөркеп торган шулпалы аш китереп куйды.

Фәйзелхан кашларын җыерды, урындыгы белән арткарак чигенде.

– Юуук, алып чыкмыйм бүтән. Теге юлы да, сез Мәскәүгә киткәч, Илгизне алып барган ием, тач үзең, улыңмыни дип теңкәгә тиделәр...

– Соң, туган булгач, охшар инде, аның ни гаебе бар...

– Мин бораулаучы кадрлар мәктәбенә укырга кереп кайттым әле, алты ай гына укыйсы. Берәр белгечлек кирәк бит инде, – диде егет, соңгы яңалыгын уртаклашып.

...Шулай дип кенә барып кергән мәктәпнең үз тормышында өр-яңа сукмак булырын Фәйзелхан бөтенләй күзалламаган иде.

Андагы физкультура дәресе егеткә уен кебек кенә тоела. Кайчандыр Равил абыйсы үзен чөеп «уйнаган» шикелле, чүрәкәй егет-малайларны ала да чөя, ала да чөя – кул көчен чарлап торырга шул да яраган шикелле.

– Кая, кил әле монда. – Физкультура укытучысы Миннәхмәт Мөхәммәтҗанов егеткә беренче көннәрдән үк игътибар иткән икән, беркөнне дәрес вакытында үз янына чакырып алды да: – Әллә көрәшкә йөрисеңме син? – дип кызыксынып куйды.

– Йөрүен йөрмим, авылда мәйданга чыкмый калган юк анысы. – Фәйзелханның тавышы бөердән чыкты, үз бәясен белә; тик алдында республиканың милли көрәш призёры, көрәшче басып торганын гына белми әле.

– Кил, тартып карыйм үзеңне. – Күзләрендә күмер чаткысы көйрәгән укытучы, башы белән генә ымлап, аны спортзал читендәге мата өстенә чакырды.

Фәйзелханга ни, анда Равил абыйсы өйрәткән шул бер алым гына инде – бот белән сугып төшерү. Шунысы да комачаулый: авылда эш белән көч туплаган булса да, гәүдәдә сыгылмалылык юк.

Ә Миннәхмәт әллә нинди алымнар кулланып, җәйран җитезлеге белән китерә дә бәрә үзен, китерә дә бәрә.

– Синнән була, үзем өйрәтәм мин сине! – диде ул бераздан, маңгай тирен сөртеп, читкә атлаган киң җилкәле егеткә чын-чынлап ышаныч белдереп. – Батыр чыгачак синнән!

Шул сүзе фәрештәләрнең амин дигән чагына туры килгәндер. Үзе дә яшь кенә булган көрәшче-укытучының киң күңеллелеге, ярдәмчеллеге тагын бер татар егетенең киләчәгенә якты юл сапкандыр. Миннәхмәт Мөхәммәтҗанов исеме, еллар үткәч, туган ягы Зәйдә генә түгел, татар көрәше дөньясында «бик күп чемпионнар әзерләгән остаз, лидер», дип олылап телгә алыначак; ул чорда чын-чынлап татар көрәше башкаласы булган Әлмәт командасының зур җиңүләре башында да тренер Илгизәр Димеев һәм шушы остаз торачак, соңрак Мамадышта көрәшне үстерүгә зур өлеш кертәчәк, Казанда, ветеринария академиясендә яшь көрәшчеләр

тәрбияләячәк. Соңыннан, ике шәкерте – Фәйзелхан Әхмәтҗанов һәм Гакыйф Борһанов «Татарстанның атказанган спорт остасы» дигән исем алгач, остазлыгы өчен «Татарстанның атказанган тренеры» исеменә лаек булачак. Әлегә ул Фәйзелханны татар көрәше серләренә өйрәтә.

Өйрәтәм дип торучы барында шул мөмкинлеккә ике кулы белән түгел, җаны-тәне белән чытырдап ябышты Фәйзелхан. Ике ай үттеме, юкмы, соры төстә тоелган кала урамнары да яктырып киткәндәй хәзер, кайчагында туктап калгандай җелеккә үткән вакыт та тизлеген арттырды, тик, ни гаҗәп, тәүлекнең сәгатьләре эшкә, укырга йөрергә дә, бокс түгәрәгенә барырга да, көрәш серләренә иркенләп төшенергә дә җитә иде.

...Менә ул! Менә ул көч, акыл һәм гыйлемнең аерылгысыз бербөтенгә әверелүе! Шәһәр беренчелегенә үткәрелгән милли көрәш бәйгесендә моңарчы әлмәтлеләргә бөтенләй таныш булмаган егет җиңүче калгач, халык та, хөкемдарлар да гөж килде. Кем бу, шәһәргә генә түгел, тирә-якка даны таралган көрәшчеләрне бер-бер артлы егарлык бу малай истә-санда юкта каян пәйда булган? Миннәхмәт Мөхәммәтҗанов укучысы икәнен белгәч, янә тел шартлаттылар: остазны узып китәрлек шәкерткә охшаган...

Җиңү тәме тәннең һәр күзәнәгенә үтеп керә, эфьюн шикелле, канны тилертә, аны ярсып, кайнарланып агарга мәҗбүр итә, үз көчеңә ышандыра һәм... бераз куркыта да икән. Яуланган биеклектән чигенергә ярамый! Баскычның тәүге бусагасыннан югарырак үрмәләсәң үрмәлә, иллә дә мәгәр артка чигенмә! Тормыш китабында урын алган чираттагы кагыйдә шушы иде.

...Үзалдына күңелле көй сызгырып энекәшләре белән әвәрә килгән Фәйзелхан, апасының бераз аптыраган йөз белән карап-карап куюын сизгәч, сорамый түзмәде:

– Апа, минем чырайга әллә теш пастасы сылаганнармы?

– Күзләрең урлап май ашаган мәченеке кебек елтырый, берәр нәрсә булмагандыр бит? – Раузалияне шул сорау күптәннән борчыган, ахры.

– Булды. Чапанымны күрделәр.

– Ниткән чапан? – Берни төшенмәгән апасы аңа каш астыннан янә аптыраулы караш ташлады.

– Хуҗа Насретдин мәзәген белмисеңмени? – Анекдот, мәзәк дигәндә, Фәйзелханга куш, мөмкин булса, көне буе да тел чарлап утырыр иде. – Хуҗа иске генә чапан киеп, берәүләргә кунакка килгәч, моны ишек төбенә генә утыртканнар, калдык-постык белән генә сыйлап җибәргәннәр, ди. Икенче көнне Хуҗа өстенә бик затлы чапан киеп килгән, моны хөрмәтләп түргә утыртканнар, алдына тәмле сый тезгәннәр. Хуҗа, өстәлдәге ризыкны алып, чапан итәгенә «аша, чапаным, аша», ди икән. Тегеләр аптыраган инде. Нишләвең бу, Хуҗа абзый, диләр икән. Сездә кунакны түгел, аның чапанын сыйлыйлар икән бит, менә, чапанымны ашатам, ди икән Хуҗа... – Фәйзелхан мәзәген керфеген дә селкетми, көлми-елмаймый сөйләп бетергәч кенә ачыклык кертте. – Шәһәр беренчелегендә җиңгәнемне күргәч, мине грек-рим көрәше секциясенә алдылар, үзләре эзләп килде.

– Ә-ә, әйтәм аны айның ундүртенче кичәсе шикелле балкып утырасың...

Теләк булса, беләк карышмый, диләр, дөрес икән. Өйрәткәнне йотып кына бара Фәйзелхан. Тыштан ипле генә, салмак кына күренсә дә, келәмгә

чыгып басса, хәрәкәтләренә күз иярми... Республиканың юниорлар бәйгесенә барганда, җиңү теләге әйдәкләде аны. Ул теләкнең үзе генә белгән, күңел түрендә йөрткән кечкенә генә сере бар иде. Әгәр җиңсә, әгәр җиңсә...

Көндәшләре балачактан район-шәһәрнең спорт түгәрәкләрендә шөгыльләнгән, тик кәнфит-прәннек ашап сыеграк буынлы булып үскәнме, әллә алар еллар буена алган гыйлемне Фәйзелхан шушы берничә ай эчендә чүмеч белән генә чумырып өлгергәнме – ни булса да булды, егет башкаларны кочаклап ала торды, капчык урынына бөгәрләп сала торды. Әлмәткә ул республика чемпионы исеме белән кайтып төште. Хәер, алай гына түгел, үз исеме дә, Фәйзелханнан Фазылга калып, Фазыл Әхмәтҗанов булып кайтты егет, телгә җайлы дип таптылармы, иптәшләре кыскарттылар да куйдылар. Киткәндә бөре хәлендә булган хыялы чәчәк атарга әзерләнеп, тизрәк Сабан туена ашкына иде. Егетнең исәбе – Алабугага кайтып, үзен сынап карарга. Чит шәһәрнең сине җиңүче дип тануы ул барыбер чын җиңү түгел әле. Менә туган ягы ни дияр?.. Бу юлы ничек тә туган туфрак йөзенә кызыллык китермәскә иде бит, көрәшчеләр авылы булган Морт данын, әткәсеннән килгән көрәшче канын, Әхмәтҗановлар данын якларга иде... Алдыңдагы чүлмәккә карап, аяк астындагы түмгәккә абынма, диләрме? Абынмас өчен көпә-көндез йолдыз санап, борын чөеп йөрмәскә, җир улы икәнеңне, туфрактан яралганыңны гына онытмаска кирәк. Аяк астына караган кеше базга очмас. Әткәсе авызыннан ишеткән иде микән бу фәлсәфәне, авылдагы башка берәү әйтте микән – әллә каян гына яшь егетнең исенә шул сүзләр килеп төште...

Борынгы Алабуга каласында, аның туфрагын сугарган чал Чулманның ярларында, бөдрә башлы нарат урманнарында әллә нинди могҗизаи бер сер бар: ял итәргә генә килеп туктасаң да, көлсу дулкыннарның, уйнак кылганнарның, җырчы кошларның нидер сөйләгәнен, нидер көйләгәнен ишетеп аласың. Ирексездән, Сөләйман йөзегенә ия булып, шулар телен аңлыйсы, кушылып сөйләшәсе, колак яфрагын иркәләп сизелер-сизелмәс агылган моң канатында тибрәләсе килә башлый. Кылганнар бу җирләрнең батырлар җире булуы хакында сөйли күк; бу җирләрдә җилдән җитез җайдаклар ат менеп кыз куу йоласында катнашкандыр; сәхтиян читекле болгар гүзәлләре ут йөрәкле егетләр арасыннан үз ярын эзләгәндер; кала капкалары янында, Чулмансу ярында кәрван-кәрван мал һәм изге ният белән килгән сәүдәгәрләрнең эзе ярылып калгандыр. Шайтан каласы янәшәсендәге манарадан азан тавышы, яу килгәндә, көрәшкә дәшкән чаң авазы яңгырагандыр. Алабуганың батыр йөрәкле ир-егетләре, денен-көнен, илен-җирен яклап, көрәшкә күтәрелгәндер.

Чал тарихтан килгән чакыру аһәңе тыныч тормышта Сабан туе мәйданына килеп сарыла. Сарыла да, кан хәтерен яңартып, егетмен дигән егетләрне көрәшкә дәшә. Бил алышырга, борынгы бабайлардан килгән көрәш дәртен яңартырга, буыннар чылбырының өзелмәгәнен расларга чакыра ул.

Фәйзелхан келәм тирәли ышанычлы адымнар белән урап килде. Соңгы талпынышта беренчелек өчен быел да Владимир Солгунов белән бил алышасы, димәк... Милиция мәктәбендә тренер булып эшләүче егет

былтыргы көндәшенә әллә ирония белән, әллә дустанә елмайды. Фәйзелхан, сабырлык һәм тынычлыгын бер ноктага тупларга теләп, сөлге тоткан кулларын бер җыеп, бер язып алды. Күз кырые белән генә мәйдан читендә ак кепкасын кырын салган этисенә, аякларын бөкләп, үләнгә утырган энесе Шәфкатькә карап куйды. Ничек тә сынатмаска иде... Сынатмаска...

Чүпләмле сөлге әле егетләрнең биленә салынмаган. Хөкемдарның әмерен көтәләр. Татарның йөз аклыгын саклаган сөлге дә көтә. Баш-башларына яшь кызларның, апа-җиңгиләрнең йөрәк сере булып төшерелгән чигүле чәчәк таҗында буыннан-буынга килгән хәтер яшеренгән. Халык хәтере ул, онытылырга хакы булмаган тиңдәшсез хәтер. Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк, дигән гыйбарәне саклаган ак хәтер анда. Бусагасына килгән кунакны татар кулына ак сөлге тотып, сөлге өстенә ипи-тозын куеп каршылый. Йөзе ачык, күңеле шушы сөлгедәй ак: үзенең тамагы туя ризык күрмәгән мәлдә дә кунакны йә мосафирны сыйсыз җибәрмәс. Мичтә күпереп пешкән кайнар ипекәйне дә, никадәр авыз суын китереп тормасын, йөзенә пычак тигерергә ашыкмастан, башта ап-ак сөлгегә әйләндереп тезәр: үзе үскән басулардан йөгереп кенә урап кайтсын әле, янәсе... Кәләшлеккә өлгереп килгән кыз баланың бирнә сандыгында да булачак ир хатынының, ананың уңганлыгына дәлил рәвешендә, таслап төреп куелган чигүле сөлгеләр ятар. Фани дөнья белән хушлашу сәгатьләренә әллә кайчан, күптән үк әзер торган әбекәйләр сандыгында да, әйтелгән йә әйтелмәгән васыять булып, гүргә иңдерер ап-ак сөлгеләр үз вакытын көтәр.

Юк, болар хакында уйланганы юк әле унсигезе туларга гына маташкан Фәйзелханның, яшьлекнең күлмәге җилбәгәй, канаты күбәләк аның... Егетнең җаны да, тәне дә тыгыз йомгакка әверелеп, «сынатмаска иде» дигән бер уй тирәсендә бөтерелә, шул уйга ияреп, ул кулындагы сөлгене уйната.

Халыкка икмәк кенә түгел, канны кыздырып җибәрә торган тамаша да кирәк. Елга бер килә торган Сабан туенда иң куәтлесе – көрәш инде, мәйданны аһылдарга, ухылдарга, көрсенергә, кычкырырга, тынсыз калырга, үзе чыгып бил алышканнан битәр кызарга, арып-талырга мәҗбүр иткән бу тамаша күз өстендә каш булырлык ир-егетнең исемен ачыклый. Ел саен бер үк көрәшчеләргә тап булганда, мәйданның тавышы беркадәр сүрелә төшә, чөнки кемнең җиңүче буласы көн кебек ачык тоела; шуңа да йөрәкне кайнар кан белән ярсытып җибәрердәй яңа йөз, яңа исем эзли ул.

Менә хәзер дә, моңарчы җиңүче исемен горур йөрткән Солгунов белән әлегәчә күз уңында булмаган Фазыл Әхмәтҗанов дигән яшь егетнең бил алышасын белгән мәйдан гөж килә. Яңа исем! Шушы мәйданда Степан һәм Николай Кузнецовлар белән көч сынашкан егет! Фазыл-Фәйзелхан! Кызыксынып, теләктәшлек белдереп төбәлгән исәпсез-хисапсыз карашлар җелеккә кадәр үткәндәй; умыртка сөяге буйлап кайнар дулкын йөгерә. Йә, сына үзеңне, сына! Тик... сынатма, яме. Авылда, балачактан бөтен эшне умырып эшләп, икенче класста укыганда ук колхоз басуында әниең белән гектарлап борчак чабып, юкка гына беләкләреңә көч җыйдыңмыни?.. Әлмәттә ничә ай буе татарча көрәшкә, грек-рим көрәшенә, классик көрәшкә өйрәнәм дип, спортзалларда тикмәгә генә селкенеп йөрдеңмени?.. Көндәшеңне биленнән кысып, аякларын келәмнән аерып, аркасына әйләндереп салырга, туган ягыңда батыр калырга дигән максатың үз

көчендәдер бит? Тормыш китабыңа теркәп куй, егет: максат куйдыңмы, артка юл юк! Мәзәк сөйләргә яраткан телеңдә нинди бар әле? – Бер рус кешесе татар кешесеннән:

– Как будет «вперёд» по-татарски? – дип сорый икән.

– Алга! – дип җаваплаган татар.

– А «назад» как будет?

– У татар нет такого слова, поворачиваемся и опять «алга», – дигән татар.

Синең дә артка чигенергә хакың юк, Фәйзелхан. Туган туфрагыңда басып торасың, онытма. Әнә, синең өчен җан атып, фронтовик әтиең келәм уртасына күзен төбәгән...

Арбитр, сыбызгысын сызгыртып, аларны уртага чакырды. Сөлгеләр билгә салынды, аларның бер ягы уң кулның беләзегенә салынып, кулдан шуып чыкмаслык итеп, баш бармак белән имән бармак арасына кысып тотылды. Егетләрнең хәзерлеге тикшерелгәч, сыбызгы икенче тапкыр аваз салды.

Ике көрәшче, аякларын чүгә төшкән халәттә келәм өстендә бөтерелгәндә, мәйдан урынынннан купты. Тәҗрибәле көрәшче каршындагы авыл егетенең көчен тиз чамаладылар, яшь булса да, төшеп калганнардан түгеллеге күренеп тора.

Фәйзелхан былтыр үзен чистага еккан Солгуновның көрәш алымын онытмаган иде: тәҗрибә дә, көч тә ташып торган көндәшен сыртка салу җиңелдән булмаячагын яхшы аңлады. Тренерларының өйрәткәне тагын бер кат яшен утыдай баш миеннән сызылып үтте. Монда да тормыш мәйданындагы кебек: көч кенә түгел, акыл да, уйлау сәләте дә, елгырлык та, алдый белү дә, хәйләкәрлек тә кирәк. Көндәшеңнең нинди алым кулланасын беләсең икән, аңа бу алымны ясарга мөмкинлек бирмәү, ничек тә каплап кую җаен карау мөһим. Әллә психологик яктан үзен әзерләве, әллә зеңләп торган һаваның һәр күзәнәгеннән үз җирем, үз җилем дип сыену табу, әллә әтисенең күренмәсә дә арка миенә үтеп кергән өмет тулы күз карашы, әллә максаттан чигенмәскә дигән уй Фәйзелханга җен көчләре өстәде, ни булса да булды, быел Алабуга батыры дигән исем аның иңнәрендә иде. Җитмеш икенче елның 18 нче июне иде бу.

Көрәшчегә дигән иң олы бүләкне – багана төбендә ятып тәмам арыган тәкәне җилкәсенә салып, түгәрәк буйлап әйләнгәндә, Фәйзелхан туган ягында алган шушы исемне, туган якта яуланган шушы җиңүне гомер буе иң зур җиңү дип санап яшәячәген белми иде. Яуланачак. Соңыннан әллә нинди үрләр яуланачак, Әлмәттә дә, Түбән Камада да, Чаллыда да әллә ничә тапкыр баш батыр калачак; Казанда да, Чиләбедә дә, үзбәк илендә дә, тагын әллә кайларда, әллә кайларда затлы-затлы җиңүләр булачак; Үзбәкстанда атаклы пәһлеван Каратай Юсупов истәлегенә үткәрелгән турнирда баш батыр булып, үзбәкләрне шаккаттырып, аларның түбәтәй-чапанын гына түгел, хөрмәтен алып кайтачак; Фидаил Шакиров, Данил Галиев, Раббани Гайфуллин, Бастам Газизов, Әсгать Фәхретдинов, Рәкыйп Хәмитов, Фоат Шәйдуллин, Габбас Әхмәдиев, Әүхәт Мөхәммәдиев кебек татар алыплары белән бил сынашачак, күп тапкырлар җиңүгә дә ирешәчәк; бөтенсоюз бәйгеләрендә катнашып, җиңүче исемен алып кайтачак; Җәлил турнирларында дүрт тапкыр җиңү яулаячак; еллар аның тормыш китабына

Татарстанның өч тапкыр абсолют батыры, ике тапкыр Рәсәй чемпионы, РСФСРның милли көрәш буенча спорт мастеры, СССРның грек-рим көрәше буенча спорт мастеры, Татарстанның атказанган спорт мастеры дигән титулларны язачак. Батырга бирелгән һәр бүләк артына, әнисе, бик кадерләп, бик тәфсилләп, кәкре-бөкре хәрефләр белән бу бүләкнең кайсы числода, кайсы бәйгедә бирелгәнлеген теркәп барачак. Бөтен нәрсәгә кытлык һәм талон чорында әллә ни булып тоелган бүләк-келәмнәргә, йорт җиһазларына, чәй сервизларына, быелныкын безгә бирерсең дип, туган-тумача алдан ук чиратка басачак. Дистәдән артык машина, батырның батырлыгына дәлил булып, бүләкләр исемлеген арттырачак. Әмма! Әмма... туган якта алынган менә шушы исем – Алабуга батыры дигән сүз бүләкләрнең дә бүләге булып, күңел түренә җуелмаска дип язылачак. Аклы-каралы фото артына числосын күрсәтеп, олы бер горурлык белән сырланачак та, соңыннан, гаиләнең кадерле ядкарьләре арасында иң-иңе, иң-иңе булып сакланачак...

Ә читтә, кеше күзеннән ераккарак китеп, яшьлеген утлы көрәш кыры урлаган көрәшче-фронтовик күз яшьләре белән елый иде...

Күңел нечкәлеген якыннарына күрсәтергә яратмаган, усал дигән атына тап төшерергә теләмәгән Гарифҗан өрлектәй улының Әлмәттә электрик булып эшләп, «селкенеп» йөрүенә риза түгел иде.

– Институтта да укымагач, нишләп йөрисең анда? Электрикка авылда да эш бетмәгән, әнә подстанциягә кеше кирәк. Кайт, – диде ул, Фәйзелханны авылга чакырып.

Улына әйтеп бетермәгән сере дә бар иде. Авыл туфрагыннан аерылмасын иде дигән яшерен теләген көчләп тагарга теләмәде. Кайтсын, өйләнеп җибәрмәсме, шушында төпләнеп, җир хуҗасы булып күкрәп яшәмәсме... Бригадир булып, җан тамыры җиргә, авылга береккән Гарифҗанның тагын бер сере бар иде. Гәүдә-кыяфәткә тыштан нык күренсә дә, сугышта кичергән михнәтләр үзенекен итә; белә Гарифҗан, саулыгы эчтән какшады, әкренләп булырмы, тизләнеп китәрме... Шуңа да малайларын йорт-нигезгә дә, авылга да терәк булыр дип өмет итә.

Кайтуын кайтты да Фәйзелхан, шәһәр ыгы-зыгысына, аның спортзалларына ияләшеп өлгергән рухы гына ел буе тынгылык табарга ашыкмады. Подстанциягә бара-кайта, ә ярты җаны шәһәрдә калгандай тоела. Мәктәпнең иске маталары өстендә күнегүләр ясап маташу сусаган җанга дәва түгел. Энесе Шәфкатьне көрәшкә өйрәтеп мәшәләнүе, аның елгырлыгын күрү генә беркадәр тынгылык бирә. Аның җан халәтен әнисе дә сизенә, ахрысы, кайчагында, нидер сорарга теләгәндәй, эзенә бастырып, әйләнеп-тулганып йөри.

Беркөнне әбәдкә ДТ тракторы белән кайткан иде Фәйзелхан, эшкә киткәндә, кузгала алмый тинтерәде. Капка төбенә чыгып баскан әнисе:

– Улым, син аның муфтасын әкрен генә җибәрә-җибәрә генә скурыстка тык, – дип өйрәтеп куймасынмы.

– Кара, әни, трактордан төшкәнеңә әллә кайчан, онытмагансың икән, – дип шаккатты Фәйзелхан, трактор кабинасын тотырып торган гәүдәсе белән тышка сузылып.

– Җелеккә төшкән ул чакларны алай гына онытырсың, бар...

Эшкә барып җиткәнче дә, аннан соң да Фәйзелхан кырык кат уйланып, авылның көйгә салынган тормышында үзенә ямь тапмавына тәгаен төшенде. Ни генә димә, барыбер укырга, үз юлыңны эзләргә кирәк.

Кичен шул хакта әтисенә өздереп әйтте. Кире Әлмәткә китәм, физкультура техникумында көрәш бүлеге ачыла, шунда укырга керәм, диде.

Гарифҗан тач үзенә охшаган улына берара текәлеп кенә торды, актан-карадан сүз дәшмәде. Киң маңгаенда сизелер-сизелмәс биешеп куйган буразналар хәрәкәтеннән генә аның үз-үзе белән гәпләшеп алуын чамаларга була иде.

– Китәм дисең, алайса... – Ата кеше, мич кашагасында торган чапалакны алып, күзгә күренми генә безелдәгән чебенгә селтәнде. – Ал-лай... Татарның канында инде ул. Бәхетен гел читтән эзләп изалана... Ахыр чиктә каф тавы артында түгел, туган җирендә икәнен аңлый да аңлавын, соңга калган була...

– Нигә алай дисең, әти? Кайтмаска китәм димим лә мин.

– Киткәндә, барсы да шулай ди... Шушында гөрләтеп кенә яшисе дә бит. Эх! Әнә, минем әткәй, Әхмәтҗан бабаңны әйтәм, егерме биш ел патша гаскәрендә унтер-хорунжий булып хезмәт иткән, урысның үзен сатып җибәрерлек итеп урысча сөйләшә, әллә нинди телләр белә иде. Туган җир дип, барыбер шушында кайтып төпләнгән. Шухри-мухри түгел, вулыс рәисе иткәннәр үзен!

– Кайтуын кайткан да, утызынчы елларда кулак дип сөрергә җыендылар, дип, үзең сөйләгән идең. Тыныч яшәргә барыбер ирек бирмәгәннәр. – Фәйзелхан әтисен кыздырып җибәрергә ярата, андый чакта Гарифҗан бөтен нәсел тарихын әйләндереп сала, хәтереннән әллә нинди вакыйгаларны тартып чыгара.

– Чоры шундый иде. Эшкә нык, булдыклы бөтен кешене юк итмәкче булдылар, авылның әллә күпме кешесен Магнитогорск төзелешенә озаттылар, күпмесен себер җибәрделәр. – Ата кешенең йөзеннән күләгә йөгереп уза. – Колхоз җыелышында безнең әткәйне дә куарга кирәк дип, пыр туздылар. Миңа ничә яшь була? – Тәк... унсигездә туганмын... ундүрт яшь кенә, ушлы булганмын инде, малай, елый-елый торып бастым: мин колхозда эшлим, әнә көне-төне буа будык, нишләп минем әткәй кулак булсын, мәйтәм... Калдырдылар әткәйне. Бер елдан үлеп тә китте инде ул... Бабай Сабир, аның атасы Садыйк исемле булган, данлыклы умартачылар ие, ди торган иде әткәй... Алты бала иек без. Бану апа – колхоз активисты, баскан җирендә ут чыгара, үзе шигырьләр чыгара, үзе оратор... Братлар нинди нәсел токкасы иде, ә! И-их, анасын корт чаккыры... Галимҗан Курск дугасында ятып калды. Ярый, анысы сугышта үлсен, ди. Калганнары, калганнары... Бәхет эзләп киткән җирдән бит, анасын корт чаккыры...

Китә казлар, китә казлар,
Китә казлар Донбасска...

Гарифҗанның йөрәк сагышы, күкрәк читлегенә сыеша алмыйча, башта йомры-йомры әчкелтем сүзләр, аннан «Шахта көе» булып, тышка ургылып чыга. Бәгырьнең әллә кай җирләрен чемер-чемер китергән җыр, бәхет эзләп шахтага юл тоткан татар ирләренең авыл капкасына сарылып калган соңгы

сәламе, аларны көтеп зарыккан сөйгәннәренең сагынудан саргайган бит алмасы, Донбасс туфрагында, таш астында өзелеп калган бихисап гомерләр булып, халыкның җан ярасы, тарихы, фаҗигасе булып, йорт бүрәнәләренә ягыла. Мөкәррәмәнең шау чәчәктә балкыган яраннарына, матчаның кайчандыр талбишек эләр өчен кагылган кәкре кадагына, караватөстендә кукраеп утырган мендәр чигүләренә кагылып уза.

Җыр кинәт өзелә. Йорт хуҗасының сүзе бетмәгән. Нәсел тарихын, туганлык җебен канга сеңдереп калсыннар, туачак балаларына да җиткерерлек булсын дипме, инде таныш, кат-кат барланган исемлекне малайлары алдында янә кабатлый.

– Заһри, ай, оста иде безнең, мал-лай! Теләсә нинди пичәтне, дукәминтне чыныннан аермаслык итеп эшли белә иде. Авыл кешесен кулына паспорт бирми тинтерәткән чакта, үзенә паспорт ясап, шахтага чыгып китүен кара син аның... Күрәчәгенә ашкынгандыр, шунда үлеп калды. Вахит та шунда вагонетка астында калып изелгән. Низамгали дә шахтада харап булды... Шушында, авылда колхоз рәисе иде бит! Туган җирдән... бәхет эзләп кит тә...

Олпат ир дым бәргән күзләрен малайларыннан яшерде. Тамчы тамып таш тишәр дигәндәй, туган җир кадере турында уратып та, турыдан ярып та улларына әйтә алган кадәр әйтә килде, муен өстендә чүлмәк түгел, үз башлары. Өч малайның берсе колакка элмәсә, бәлки икенчесе элә...

Уку йортыннан бәхете тәки үзенчә булды Фәйзелханның. Әлмәттә физкультура техникумында көрәш бүлеге гүя аның өчен генә ачылган... Шунда, СССРның халыкара класслы спорт мастеры, атаклы көрәшче, грек-рим көрәше буенча тренер Хафиз Тимашев дәресләрендә җиң сызганып укый башлаган җиреннән, укуын остазының хәер-фатыйхасы белән Омск физкультура институтында дәвам итәргә, Чиләбе институтында тәмамларга насыйп булды үзенә. Нәкъ менә Хафиз Шәйхулла улы аны бөтен ярышларга йөртте, грек-рим көрәше алымнарына, күкрәк аша ыргытырга, унике төрле ыргым серенә өйрәтте. Болай да таш астыннан чыккандай үткер, җор телле, аралашучан егеткә яңа дөнья, яңа кешеләр белән танышу, спорт серләренә ныграк төшенү файда өстенә файда иде: тормыш китабына торган саен яңа кагыйдәләр өстәлә барды. Мине берәү дә ега алмый дип беркайчан масайма, көлкегә калуың бар! Бүген син көчле, иртәгә синдәй көчле яки синнән дә көчлерәк башка берәү пәйда булачак...

Җитмеш дүртнең Сабан туенда аның алдында әнә шундый берәү пәйда булды да. Инде Әлмәттә батыр дигән исемен күпләргә таныткан Фәйзелхан аңа тиклем үз көндәшләрен, бил алышуга бирелгән ун минутның икенче-өченче минутларында ук һавага чөеп, әйләндереп салган, бәйгенең шул рәвешчә дәвам итәсенә шактый инанган иде. Мәйдан уртасында Куйбышев каласыннан килгән унсигез яшьлек Хәбил исемле егет белән кара-каршы калгач, аның шактый каты чикләвек икәнен тоемлады. Әйткәннәр иде аны, җиденче класста укыганда ук, 120 килолы штанганы уймак урынына күтәргән, дип... Хактыр, әнә бит, соңгы алышка чыкканчы, бил бирмәс Иван Максимовны да ничек җиргә сылады бу егет!.. Кыл кебек тартылган тәннең һәр күзәнәге хәлиткеч алышка әзерләнә, йөрәк, сабырлык таләп итеп, тук-тук ишек шакый; сулык-сулык килгән ике чигә кайнарланып ала. Давай, бирешмә! Былтыр Әлмәт батыры дигән данны яуладыңмы, быел да Әлмәт

данын яклап көрәшәсең икән, ул данны әллә кайдагы Куйбышевка тоттырып җибәрергә җыенмыйсыңдыр бит... Кан суына төшә. Сөлгеләр билгә ята. Сыбызгы тавышы ишетелә. Көрәш башлана. Мәйданның гүләвеннән келәмдәге ике пәһлеван мендәр йоны урынына икесе ике якка очар шикелле. Икесендә дә үгез көче, тау күчерерлек үҗәтлек... Мәйдан шартлый. Быел да Әлмәт батыры дип Фазыл Әхмәтҗанов исемен игълан итәләр.

Аны котлап кулын сузган көндәше берничә елдан соң үзенең дзюдо буенча Европа һәм СССР чемпионы булып таныласын бу минутта белми, шушы ук Фазыл белән Чаллы Сабан туенда кабат бил алышасын, татар көрәшчеләре исемлегендә Хәбил Бикташев исеменең дә алтын хәрефләр белән языласын күзалламый әле...

Шәһәр башкарма комитетында «Фатир бирәбез» дип ышандырып йөрүләре шактый озакка сузылып, Фәйзелханның тәмам эче поша башлаган иде. Апасы белән җизнәсе янында үзенә ялгыш кына да кырын караучы булмаса да, үз өемдә үз көем дигәндәй, үз почмагын булдырырга күптән вакыт. Бер центнерлы гәүдәң белән кайчанга кадәр кеше түрендә аунарга була... Ниһаять, бәхет елмаерга уйлады. Соңгы елларда үзенең җиңүләре белән Әлмәтнең данын күтәргән, инде ике тапкыр Россия чемпионы титулын яуларга өлгергән, Калмыкиянең Элиста шәһәрендә узган бөтенсоюз турнирында беренче урын алып, СССРның спорт мастеры исеменә ия булган егет фатир турындагы соравын янә кузгалткач, спортклубта барысы да хәл ителде: Кудряшев фамилияле берәүгә ике бүлмәле фатир биргәннәр, аның бер бүлмәле фатиры Фәйзелханга булачак. Кудряшев ул фатирның ачкычын Фәйзелханның кулына ук тоттырып куйды. Документларны рәсмиләштереп, кулга ордер алгач, өй туе гына ясыйсы кала!..

Ләкин бәхетеңне сыер сөзсә, көтү көткән акчаңны да җыеп алалмассың диюләре вакыт-вакыт хак булып куя икән.

Ордер алырга дип профком бүлмәсенә кергәндә, Фәйзелханның адымнары нык, йөзе май кояшыдай иде. Ләкин җирән чәчле ир-ат сузган ордерны кулына тотып, ныклабрак карагач, аптырап калды: аңа ышандырган бер бүлмәле фатирга түгел, каядыр вокзал тирәсендәге малосемейкага иде ордер.

– Миңа бит малосемейка түгел, квартира булырга тиеш...

Егетнең кыю гына шулай диюеннән ирнең йөзе үзгәреп китте, аңа мыскыллы елмаю таралды.

– Какая тебе квартира.. радуйся, что эту дали... Если не нравится, могу обратно забрать... – Тук чырайга янә мыскыллау йөгерде, ул, үзенең монда патша икәнен искәртеп, кәнәфи аркасына киерелебрәк утырды.

Фәйзелханда да бар ул горурлык, өстәлгә ике кулы белән таянып, йөзенә иелде:

– А ты кто такой? Ключи-то квартиры у меня!

Бу бүлмәдә һәрвакыт түше белән шуышып йөрүчеләрне күреп гадәтләнгән ирнең күзе маңгаена менде, ул урыныннан сикереп торды, өстәлне урап чыкты да:

– Ты, говно, с кем так небрежно говоришь? Сдай ключи и вон отсюда! – дип, сөякчел куллары белән Фәйзелханның изүенә үрелде.

Шул минутта сабырлык күрсәтсә, ялагайлана, төчеләнә белсә, кем белә,

язмышның бормалы сукмаклары бөтенләй башка юлга алып кереп китәр иде аны. Ә ул тотты да үзенә карата әйтелгән мыскыллау сүзен күтәрә алмыйча, тегенеңияк астына чәпәде. Өстәл аша очып төшкән ир заты артыннан кесәсендәге ачкычны да томырып, бүлмәдән чыгып китте.

Ачкыч белән бергә аерым фатир турындагы якты хыяллар да очты.

Икенче көнне шәһәр башкарма комитетына чакырганда, Фәйзелханга салкын акыл кайткан иде, әмма үкенәм дип, йөзендәге төген дә селкетмәде.

– Нишләп алай кыландың? Хәзер квартира дип авыз да ачып булмый; уголовное дело кузгатырга мөмкиннәр, – диюләренә дә тыныч кына җавап кайтарды.

– Бугазга ябышмасын иде. Мин аңа үземнең «говно» түгеллегемне генә аңлаттым, – диде ул, берсе-берсе бала башыдай йодрыкларын тыныч кына әйләндергәләп. – «Ловить нечего» икәнен аңлыйм, китәм мин моннан...

Урамда 1976 елның көзе иде. Кайчандыр авылдан килгән егетне соры көзе белән каршы алган Әлмәт аны шундый ук көздә Түбән Камага озатып калды.

Ә бит... ә бит... кулга балык урынына шуып кергән мөмкинлекләрнең барысын гел үз файдаңа аударып торсаң, әллә кем булырлыгың да бар иде! «Үз көчем, үз акылым», имеш...

Калтырча автобуста Түбән Камага үз яннарына дәшкән дуслары тарафына юл тотканда, өермә урынына бөтерелгән уйлар, кайчак бер эзгә төшеп, кайчак бер-берсенә каршы килеп, башны кайната иде.

Синдәй көрәшче егетләр аяк астында аунап ятмый! Шәһәр данын якларга, җитәкчеләрнең йөз аклыгын акларга кирәктә, синдәйләрне кулда күтәреп йөртергә әзерләр! Исеңә төшер, былтыр, шәһәр батыры исемен яулаган көнне мәйданда «Татнефть» берләшмәсенең генераль директоры Әгъзәм Вәлиханов үзе килеп кочаклап алды, соңыннан өенә дәшеп, түренә утыртты. Су сөлеге кебек кызы белән таныштырды. Ә син авыллыгыңны иттең, алтын кашык тезелгән табынны, алтын каминны күреп, ашык-пошык табан ялтырату ягын карадың. Янәсе, мондый тормыш синең өчен түгел. Башыңа төшсә өйрәнер идең. Чалгы тотып печән чапкан, кувалда белән селтәнеп, цехта эшләгән кулларның алтын кашык кына тотарлык рәте булыр иде әле... Үзең дә алтын кияүләр исемлегенә эләгеп, күн кәнәфиләрдә кемгәдер әмер биреп утырыр идең...

Юк һәм тагын бер тапкыр юк! Күңеленә уеп язылган, «үз көчеңә, үз акылыңа ышан» дигән кагыйдәгә хыянәт итәргәме? Егет сүзе шул булырмы? Юк, агайне, юк... Тормыш үзенең сынаулары белән кызык. Чын тормыш белән яшисе, янып, ялкынланып, үз сукмагың өчен көрәшеп яшисе килә...

Тормыш китабының яңа бите ачыла иде.

Түбән Кама – яшь тарихлы кала. Рәсәй иленең ихтыяҗы, канун-имзалары нәтиҗәсендә татарның җан җирендә калкып чыккан нефтехимия комбинаты – каланың, алай гына да түгел, халыкның ярасы да, дәвасы да. Яшьлек дәрте белән шәһәр һәм завод төзелешенә эшкә килгән, сулар һавада да хыялый ак болытлар гына күргән ал күзлеклеләр дә, гаеп-хаталарыннан качып сыену эзләгәннәр дә, тормышын чиста биттән башларга җыенганнар да, болганчык суда балык тотарга теләп, мажарага сусап юл сапканнар да, шәһәр читендәге төрмәләрдә җан асраучылар да җитәрлек монда. Халык

телендә заводларны китапча атау юк, «химия» дә «шинный» дип кенә җиппәрәләр.

Фәйзелханның техникумда бергә укыган дуслары Альберт Садыйков белән Таһир Вәлиуллин «Нижнекамскнефтехим» спортклубында тренер булып эшли иде, алар чакырды егетне. Тулай торакта урын булачагын да әйтеп кызыктырдылар.

Бар яклап үсәргә тотынган калага яшь белгечләр һәр өлкәдә кирәк иде, Фәйзелхан кебек спортчыны ике түгел, биш куллап эшкә алырга әзерләр. Чыннан да, хезмәт кенәгәсенә нефть-химия комбинатында аппаратчы дип язып, үзе тренер булып спортклубка урнашуга, Студентлар урамындагы тулай торактан бүлмә ачкычы да тоттырдылар.

Юл сумкасын җилкәсенә асып, бүлмәгә барып кергәндә, анда балта элеп куярлык төтен иде, ике егет тәмәке тартып утыра. Исәнләшеп, стена буендагы тар караватка сумкасын ташлауга, Фәйзелханның тыны кысыла башлады.

– Егетләр, пажалысты бүлмәдә тартмагыз!

– Нәрсәәә? – Егетләрнең күзе маңгайга менде. Кем бу, башы керсә аягы кермәгән, үз тәртибен урнаштырмакчы булып маташа инде әллә...

Фәйзелханның каприз күрсәтүе түгел иде. Ишек буендагы саргылт шкафны ачты, курткасын салып, шунда элде, сумкасын идәнгә төшереп куйды. Танышуны сүз көрәштерүдән, холык күрсәтүдән башларга исәбе юк иде, куе кашларын язып, киң итеп елмайды.

– Бәләкәй чактан калган, бүре тәмәкесе акылга утыртты...

– Да ну...

Егетләр әллә аптырап, әллә сүзнең дәвамын көтеп, бер-берсенә караштылар.

– Каз сакларга баргач, бала-чага килеш коры чирәм тартып маташа идек. Берәрсе әтисенең кесәсеннән «Байкал» чәлдереп килсә, шуны суырабыз. Берсендә бүре тәмәкесен төреп тарттык, мал-лай, аның агулы икәнен кем белгән. Менә костырды, менә костырды, агуланып, чак исән калдым... Шуннан бирле тәмәке исе башка ярамый, егетләр, җенем сөйми, психоз башлана минем. Шуңа әйтәм, пажалысты, хет баштан йөрегез, түлке бүлмәдә тәмәке генә тартмагыз...

Әллә Фәйзелханның ихласлыгы, әллә артист шикелле елмая-елмая мавыктыргыч итеп сөйли белүе үзенекен итте, бая гына киерелеп тартылган кыл шунда ук йомшарды, бу таләпне баш бәласенә санамаган егетләр (киләчәктә аларның берсе цех начальнигы, икенчесе баш инженер булып билгеләнәчәк!) уйлап карарбыз дигәндәй, җилкә җыерып куйдылар...

* * *

Гаделлеккә нигезләнгән ярыш-көрәшнең генә чын җиңүчеләре була. Егерменче гасыр Рәсәй халкын, диненә-милләтенә, яшенә-җенесенә карамастан, җитәрлек талкыды. Революцияләре, сугышлары белән җелеккә төште; җитәкчеләрнең үз халкына геноциды нәтиҗәсендә иң асыл, иң зыялы, иң гыйлемле, фикер йөртә белә торган затлар бер гаепсезгә төрмә стеналарына терәп атылды; Себергә озатылган җиреннән, хайван ташый торган вагоннарда ачлыктан, сусызлыктан, авырулардан җан тәслим кылды,

андыйларның кабык-гәүдәсен кайчак поезд барган уңайга урман эчләренә томыра тордылар; артык йөк һәм артык кашык саналган тоткыннар баржага төялгән килеш дәрья-суларга батырылды. Каһәр төшкән сугыш елларында нәсел сакчысы булырга дип дөньяга килгән ирләр миллионлап кырылды; кан-яшь түктереп, күкрәк баласыннан, сабыйларыннан аерып, окоп казырга, торф чыгарырга, урман кисәргә озатылган аналар, бетләп беткән завод баракларына, ФЗӨгә җибәрелгән яшь кызлар көчләнде, мәсхәрәләнде, үтерелде. Соңгы кабым ризыгы, күз текәп торган сыеры йә заем түләргә, йә фронтка дип тартып алынгач, күпме әби-бабай, бала-чага ачтан шешенеп үлде; тамакның тәмугка керткәнен белә торып, басудан бер уч бодай уып кайткан ач аналар төрмәләргә илтеп ябылды. Анда көчләнеп, кайберсе бала күтәреп кайтканнары үз йортының ишек төбеннән янә мәсхәрәләнеп куылды, аяк астына салып тапталды. Ярыш дәрте белән күзләр тонып, башта социализм, аннан коммунизм төзергә маташкан елларда кеше күз яшьләре һәм кеше сөякләре өстендә Магнитогорск кебек калалар калкып чыкты. Күпме язмышларны гарипләндереп, яңгыравык исемле төзелешләр гөрләде. Ялгыш юлдан барганны халыкка аңлатырга теләп, тел тибрәткәннәрнең күпмесе психушкага озатылды. Дөнья гүя берьюлы ике яссылыкта яши; социалистик ярышта көч сынаша-сынаша, җиңүләрнең аръягына чыгып, аяк салындырып утырган дәүләттә чын һәм ялган икесе бербөтенгә әверелгән; күчмә кызыл байракка, күчмә кубокка, грамоталарга, мактау кәгазьләренә күмелергә әзер дөнья шуларга ирешү өчен күзе-башы тонып көрәшә. Колхозлар көрәшә, заводлар көрәшә, калалар көрәшә, кешеләр көрәшә... Айлык ризыгыңны бер көндә ашап бетереп мактанган шикелле, бишьеллык планнарны өч елда үтәдек дип шәрран яралар; кәгазьдәге саннарга, план үтәлешенә, җиңүләргә карасаң, сөт елгалары шаулап ага, фермадагы сыерлар гына түгел, үгезләр дә бозау китергән дип уйларлык; фабрикаларда җитештерелгән җиһазлардан күз камаша.

Татар авылында көнне-төнне ялгап эшләгән колхозчылар гына, кемнеңдер Мәскәү кибетендә «сгущёнка» күргәнен, икенче берәүнең каладан колбаса алып кайтканын, хәлвә дигән нәрсә тәмләп караганын, түбән очтагы өченче берәүләрнең ялтырап торган, ике ишекле шифоньер алганнарын аһ итеп, шаккатып сөйли дә, андый көннәрнең бик тиздән, коммунизмга барып ирешкәч, һәркемгә килеп җитәсен күзаллап, күңеленнән генә куана.

Ялган җиңү һәм ялган дан артыннан куган җирдә син – миңа, мин – сиңа кануны, җинаятьчелек чәчәк ата. Ул җинаятьчелекнең төп сәбәбен беркем дә берәүнең дә күзенә төртеп күрсәтергә теләми. Иң уңайлысы – эчкечелеккә сылтау. Кибет басканмы, кеше үтергәнме, ут төрткәнме – салган баштан кылынган гамәлне сүтеп-җыю, андыйларга җәза бирү кемнәргәдер күпкә уңайлырак. Шуңа да аракыны «валюта» урынына күтәреп, аның дәрәҗәсен арттыру, җепкә кәгазь бәйләп, мәчене мавыктырган шикелле, ил өчен мавыктыргыч бер шөгыль кебек...

Шәһәр урамнарында төркемнәр оешып, кичләрен генә түгел, көндезләрен дә олысы-кечесе күңеленә шом салган чорда да җинаятьләрне исерекләргә бәйләп аңлату гадәте дәвам итә иде. Ләкин без иртәме-соңмы капчыкны төртеп чыга. Ил бу гасырдагы тагын бер фаҗигале тупсасына аяк баскан иде.

* * *

Фәйзелханның шәһәр шпаналарыннан куркыр күлмәге юк, спортклубта классик көрәш белән шөгыльләнгәнен инде белеп өлгергәннәр, якын килеп, «борчып» йөрмиләр. Габбас Әхмәдиев, Наил Зәйнуллин кебек көрәшче егетләр дә үзләре баш, үзләре түш булып көн күрә. Вакытына карап, дуска йә көндәшкә әверелгән мәл дә булгалап тора. «Шинный»да эшләгән Габбас белән җитмеш бишенче елда Бөгелмәдә, самбо ярышына баргач күрешеп-танышып калганнар иде. Ул чакта Әлмәттә грек-рим көрәшенә йөргән Фазыл-Фәйзелхан, бөтенесен җиңеп, беренчелекне алып китте. Ярышның кайда-ничек булганлыгы кемнеңдер исеннән дә чыгып куярга мөмкин, ләкин егетне бер күргән кеше аны гомерендә дә онытмый инде: мәһабәт гәүдәле, бөдрә чәчле, төз буйлы, бөтен кешене авызына каратып торган Фазыл яшенең-картының хәтер төпкеленнән җуела торганнардан түгел.

Сөйли белгән авызда йомычка да йомры була: телгә-сүзгә осталыгы белән Фәйзелхан инде монда да байтак дус-танышлар табып өлгергән, кызларга да бер күз кысуы җитә. Җырлы-биюле «пятачок»лардан соң Корабельная урамындагы тулай торакка әле берсен, әле икенчесен озата кайта. Кыяфәт тә кәттә: нейлон куртка, нерпа папаха, мохер шарф, болай да алып гәүдәне тагын да биегәйтеп күрсәткән үкчәле ботинка...

Көз белән кыш бил тартышкан бер кичне кызлар тулай торагыннан кайтырга кузгалып, урам ишеген ачканда, артыннан моңарчы таныш булмаган бер егет тә чыкты. Сәлам бирде дә:

– Сиңа кайсы якка? – дип, дустанә сорап куйды. Студентлар урамына икәнен белгәч: – Давай, миңа да шул якка. Вил булам, – дип, үзе белән таныштырды да бергә атлый башладылар. Тулай торак почмагына борылуга, шәрә артын ялтыратып йомышлап басып торган берәүне күрүгә, Фәйзелханның яңа танышы ялт кына аның янына атылды.

– Ну-ка, что-это такое?

Тирә-якны кинәт яралы аюдай үкергән тавыш яңгыратты.

Мизгел эчендә ни булганын юньләп аңламый да калган Фәйзелханның аптыравы йөзенә таралды.

– Нәрсә булды? – дип сорады ул, алны-артны күрми ук шикелле каядыр атылган егет тарафына күз ташлап. – Ник акыра ул?

Вилнең кулында пычак йөзе ялтырады.

– Моның белән төртеп алдым, – диде исе дә китмичә.

– Соң, кул белән генә аңлатсаң да булыр иде...

– Андыйлар алай гына аңламый... Ничу монда, кызлар тәрәзәсе алдында...

Сөйләшә-таныша әкрен генә атлап кайтып килгән җирдән, Химиклар урамын узып китүгә, үз артларында дөп-дөп чапкан тавышлар ишетеп, икесе берьюлы артка әйләнеп карасалар, ни күрсеннәр: кулларына күсәкләр тоткан егетләр төркеме болар артыннан куып килә иде.

– Аһ, с...-и! – Вил, алар арасында баягы егетне күреп, катлы-катлы сүгенеп куйды.

Торып йөгерүдән мәгънә юк иде. Йөзгә-йөз сугышканда да, бу хәтле кешегә икәүләп кенә каршы торырга. Ай-һай...

Күз ачып йомган арада Фәйзелхан белән Вилне бүре өередәй әйләндереп

алган төркем аларга артык сораулар биреп маташмады. Фәйзелхан үз өстенә берьюлы ташланган берничә малайны уңга-сулга селтәп томырырга җитеште, карлы боз өстендә аяк тая, кызлар озатырга гына яраган үкчәле ботинкалар өерелеп сугышканда комачау итә. Ул бераздан үзенең өер астында изелеп калганын абайлап, тешләрен кысты. «Сыталар икән болар». Ни гаҗәп, шул уй сызылып үткән мәлдә үк, әле генә өстенә өелгән егетләр чебен урынына выжылдап кирегә очарга тотындылар. Ул да булмады, Вилнең, ачы итеп:

– Всех зарежу, падлы! – дип, сөрән салганы ишетелде.

Соңыннан билгеле булганча, «мондыйларның баш белән генә аңламасын» чамалаган Вил, Фәйзелхан өстенә өелгәннәрнең һәрберсенең артына пычак очы белән аңлатырга тотынган икән...

Фәйзелхан шунысына гына аптырады: шундый мәлдә дә кайсыдыр берсе аның муенындагы мохер шарфны эләктереп китәргә өлгергән иде...

Яшьлек күкрәк киереп яшәргә ярата. Түш кесәңдә акча да булса, күкрәк тагын да киерелә, адымнар тагын да ышанычлыракка әйләнә, кызлар янында да үзеңне бетле хәерче итеп хис итмисең, бәяңне белеп кенә сөйләшәсең... Тик бер хезмәт хакына гына бик киерелеп булмый шул...

Шабашка булганда, төзелештә дә эшләп алалар, кәҗә маеңны суырса да, акча була дип юаналар. Көннәрдән бер көнне Фәйзелханның кулдашы, Ростов егете Виктор, шундый шабашкадан эт булып арып кайтып барган мәлләрендә:

– Слушай, а чё мы так мучаемся?.. Әйдә, ресторанга швейцар булып урнашабыз, беләсеңме, анда күпме акча эшләп була?! Ресторанда аракы ат бәясе тора... – дип, акча эшләүнең яңа ысулын тәкъдим итте.

Илдә аракыга каршы көрәш игълан ителгән, виноград куаклары киселгән, кайдадыр аракы сатылса, чакрымнарга сузылган чиратлар барлыкка килгән, ул чиратларда үз урынын сатып, кемнәрдер акча эшләгән, шул чиратларда кешеләр кысылып-басылып үлгән чор бу. Шулай да егетләр кайсы нокталардан бу «валюта»ны алып булганын беләләр, склад мөдирләре, сатучы кызлар үзләре белән матур итеп, тәмле итеп сөйләшә белүчеләрне дошман күрергә тормыйлар...

Шулай эшләделәр дә. Ничек кирәк алай табылган аракыны, ресторанда типтерүчеләргә, биш бәягә арттырып, ишек төбендә җайлап кына аткарырга ниятләделәр. Сату дигәндә, Викторда үзеңне дә сатып җибәрерлек сәләт бар. Фәйзелхан «страховкада»: көченең дә, һәр эшне дипломатларча хәл итә белүенең дә кирәге чыгуы бар, алай-болай бәйләнүче, тавыш чыгаручы, йодрыгы кычытучы күренсә, эшне ничек тә зурга җибәрмәскә кирәк... Кесәгә кергән акча күзгә күренеп артты. Инде егетләр үзләре дә ресторанда сыйланып, кызларны да таксида гына озатырга өйрәнеп килә башлаганнар иде дә...

Бер кичне ресторанда компания белән күңелле генә утыралар иде. Арадагы бер егеткә ашыгыч кына каядыр китәргә туры килде, ул үзенең йөргән кызын озатып куюны Фәйзелханга ышанып тапшырды. Мәҗлес азагына якынлашкач, Фәйзелхан белән Виктор такси чакырдылар да кызны өенә илтә киттеләр. Кыз, үзләренең подъезды янында төшеп калды да почмакта торган бер машина фараларын яндырып алуга, ялт борылып, шул машина эченә чумды.

Кузгалып китәргә җыенган таксистны шап туктатып, Фәйзелхан белән Виктор икесе дә атылып чыктылар. Ни дисәң дә, иптәш егет алдында җаваплылык дигән нәрсә бар, кызны исән-сау өенә кайтарырга вәгъдә бирделәр. Ә монда нәрсәдер аңлашылып бетми...

Сул ишекне каерып ачуга, Виктор кулындагы шарфы белән шофёр егетнең муеныннан эләктереп тә алды.

– Ты, гон...он, пид...рас, чё творишь, а? – дия-дия, аның башын руль астына китереп тә тыкты.

Фәйзелхан, кыз утырган яктан ишекне ачып:

– Галя, ты чё? – дияргә генә өлгерде, мизгелнең кайсыдыр бер өлешендә, бөкрәеп төшкән шофёрның иңбашында ялтыраган капитан погоннарын абайлап, машинаның теге ягына сикерде. Кабина эчендә шофёрны дөмбәсләп маташкан Викторга ябышып, аны йолкып алырга теләде:

– Виктор, тукта, җүләрләнмә!

– Ты чё меня тащищь? Яма берне үзең дә! – Викторның каны кызган, тиз генә туктатам, димә. Шулай да колак төбендә Фәйзелханның «мент бит бу» дип пышылдаганын ишетеп алды, тураеп басканын сизми дә калды. Фәйзелхан шофёрның муенындагы шарфны бушатып, тураеп утырырга булышты, «Кызлар аркасында була инде, гафу ит, брат», – дигән булып, хәлне үзенчә йомшартырга маташты...

Виктор да, Фәйзелхан да шәһәргә «уголовный розыск» начальнигы итеп яңа кеше билгеләгәннәрен ишетеп өлгермәгәннәр иде, шуңа да аларга руль артындагы егетнең йөзе бер дә таныш түгел иде шул...

Кемгә кул күтәрүләрен белгәч, Виктор:

– Мин үземнең Ростовка качам, – дип өтәләнергә тотынды.

Фәйзелхан ашыкмаска киңәш итте.

– Бездә, татарларда, кәтмәнгә каршы кәйлә бар, хәйләгә каршы хәйлә бар, диләр. Берәр җай табылыр, – диде, үзенең дус-танышларын күздә тотып. Үзләре гаепле, кәнишне, шулай да авыр хәлдә калган шушы минутта ярдәм кулы сузучы нужәли булмас...

Яңа начальник аларны икенче көнне үз янына кичке тугызларда чакыртты.

– Ну, кто гон...он, пид...рас, а? – диде ул, Викторның йөзенә гаҗәеп бер тынычлык белән карап.

– Нууу... я, наверно, – диде Виктор, шулай ук тынычлыгын җуярга ашыкмыйча.

– Иптәш капитан... – Фәйзелханның башланган сүзе һавага эленеп калды.

– Мин бит сезне теләсә нинди статья белән рәшәткә артына тыгып куя алам!

– Иптәш капитан...

– Яныгызга берәр кызны җибәрәбез, көчләде дип гариза яздырабыз, шуның белән вәссәлам. Йә, ничек? – Капитан аларның сабырлыгын сыный идеме, артык тыныч иде.

– Иптәш капитан... Ярар инде, салган авыздан әллә нинди сүзләр оча бит инде ул... Хрущёв булып Хрущёв шулай дигәнне... – Суга батучы саламга тотына, ди, Фәйзелханның да нияте шундыйрак.

– Причём монда Хрущёв? – Капитанның кашы җыерылды.

– Теге, ни... авангард рәссамнар күргәзмәсендә... «ясый белмисез, пид... расы проклятые» дип сүккән ди бит авторларны... Әйтелә инде ул... була инде ул... – Мондый четерекле сорауларны һәрчак йодрык белән генә хәл итеп булмаганны, кайчак таныш-белеш, кайчак хәйләкәрлек, кайчак йомшаклык кирәк икәненә төшенеп килә инде Фәйзелхан. Бу бүлмәдә анекдот сөйләп кенә башыңны саклап кала алмассың...

Җан биргәнгә җүн бирде тагын, начальник үзен егетләрчә тота белде, бу бәладән ничек кирәк алай исән-сау котылдылар. Кабинеттан тәмам аңлашып, Сабан туйлары җиткәч, су буенда тәкә ите ашарга кунакка чакырып, тыныч күңел белән чыктылар.

Башка юлы очрашканда, алар инде үзләрен бөтенләй дусларча хис итә иде.

– Иптәш начальник, мә, мороженое ашыйсыңмы? – диде Виктор, каршысына очраган капитанга, кулындагы яртылаш ашалган туңдырманы сузып. Үзе туңдырма дигәндә үлеп китә торган булгач, әллә ни урынына күрүе булдымы...

– Әллә шушының белән котылмакчы буласыңмы? Син миңа бер ящик мороженое йә бер ящик коньяк куярга тиеш, беләсең килсә, – диде капитан, уенын-чынын бергә кушып, егетләргә кул биреп исәнләшкәч.

Шулай дисә дә, җил кайсы якка иссә, шунда авыша торганнардан түгел иде ул...

Тәкә суеп, су буенда бәйрәм иткәндә, төрле уеннар да оештыралар иде. Уртага сызык сызып, ике якка ике кеше сузылып ята да, муенга бау бәйләп тартышалар. Капитан погоннары инде майорныкына алышынган начальник белән көч сынашуның ни белән тәгәлләнәсен чамалап булмый, көч җитәрлек, җиңүен җиңәрсең аны, менә шуннан соң ни булыр... Андый чакта Фәйзелхан хәйләкәрлеген эшкә җигә. Аны сызык янына диярлек тартып китерә дә туктап кала:

– Иптәш майор, әйдә болай итәбез: мин бирелəм, ә син, безнең малайлар кулыңа килеп эләгә калса, эшне йомасың...

– Йомармын менә мин сиңа!.. Күп сөйләшмә, тартуыңны бел...

Шуннан соң инде тыныч күңел белән тартырга була...

* * *

«Химиклар» мәдәният йорты янындагы «Факел» спортклубына көрәш серләренә өйрәнергә дип килгән егет-малайлар арасында төрлесе бар. Холык холыкка охшамый: кемдер матур итеп җиңелә, көндәшенең күзенә туры карап, кулын кыса белә; кайберәүләр, җиңелә калса, хаксызга санап, кырык сүзгә җитә, һаман кемгәдер нәрсәдер расларга маташа. Андыйларны бер-ике сүз белән генә урынына утырта Фәйзелхан:

– «Гнилой» булмагыз! Егет була белегез!

Шәкертләре арасында үзенә охшаган, тәвәккәл һәм максатчаннарны күз уңыннан һич ычкындырмый: алар белән тау күчерергә мөмкин икәнен чамалый ул. Әнә Шәңгәлче мәктәбеннән килеп йөрүче Геннадий Муллинны гына кара, ком суны ничек сеңдерсә, өйрәткәнне шулай сеңдереп кенә бара. Юниорлар ярышына баргач, Казанда, спорт мастеры белән өч периодта бил алышып, үзен ничек күрсәтте! Тегесе нибары бер балл эләктерә алды...

– Гена, давай, ирекле көрәш буенча көрәшәсең, – диде ул беркөнне истәсанда юкта, үзендә классик көрәш серләренә өйрәнүче егеткә, ярышлар башланыр алдыннан.

– Фәйзелхан Гарифҗанович, мин бит классика буенча шөгыльләнәм, ирекледә бер дә тотынып караганым юк, – диде Гена, якты күзләренә аптырау галәмәте чыгарып.

– Менә, берочтан өйрәнерсең дә. Көндәшең мондый алым ясаячак, син менә болайрак эшлә. Ул болай итсә, менә мондыйрак итеп алдыр, ничек тә капларга тырыш, – дия-дия, кыска гына вакыт аралыгында Фәйзелхан аңа дәрес тә биреп алды. Укытучысына каршы төшәргә базмаган егеткә, ни булса шул булыр дип, келәмгә чыгып басудан башка чара калмады.

Көндәшенең ирекле көрәш буенча биш ел буе шөгыльләнүен белә иде егет, шуңа бу ярышка әллә ни өмет баглап маташмады. Шулай да бәйге башлануга, тренерының күрәзәлек кылгандай әйтүен бик тиз исенә төшерде: көндәше нәкъ ул күрсәткән алымны ясауга, Гена аны Фәйзелхан өйрәткәнчә егып та салды. Көрәш башлануга нибары унбиш секунд үткән иде.

Бераздан, келәмнән читтәрәк, тренеры Таһир Вәлиуллинның әлеге малайны:

– Бу нинди хәл, биш ел буе шөгыльләнәсең, ә монда спортклубка килүенә ярты ел да булмаган колхозниктан ектырып ятасың, – дип пешекләвен ишеткәч, көндәшен жәлләүдән йөрәге сызды...

Фәйзелхан үз егет-малайлары өчен авторитетка әйләнгән иде. Күрми түгел: аныңча сөйләшергә, аныңча йөрергә омтылалар... Үзе дә егет кенә абыйлары алар өчен теләсә кайсы мизгелдә җилкәсен куяр булышчы да, киңәшче дә. Спорт серләренә төшендерү белән беррәттән, тормыш сабакларын да һәйбәтләп биреп куя: кайсы мәлдә үзеңне ничегрәк тотарга, кемгә ниндирәк сүз белән якын килергә – психологларың бер читтә торсын, әтиләреннән ишетмәгән киңәшләрне малайлар күбрәк аның авызыннан ишетәләр. Корылыгы да бар: «Авызыңны ачып торма!» – дип кенә җиппәрә. Малайларны иң шаккаттырганы – ул һәр көрәшченең алымнарын яттан белә, алдан күрүчәнлеге белән таң калдыра. Ярыштан соң хаталарыңны энәсеннән җебенә кадәр сүтеп тикшерә мәгәр: нигә болай эшләмәдең, көндәшең менә болай итте; син бу рәвешле каплап куярга тиеш идең... Ул мондый алым ясый башлаганда, аның юлың өзәргә, капларга тиеш идең, шулай балл алырга була иде... Нигә моны күрмәдегез? Күрә белмисез, дип шәпләп кенә сабак бирә.

Малайлар гына җилкә җыера: алар әле чыннан да күрә белми. Күрә белмәгәнне ничек күрәсең инде дип аптырыйлар гына. Һәм абыйларының «Ач күзеңне!» дигән сүзенә ияреп, дөньяга күтәрелеп карыйлар...

Түбән Кама көрәшчеләре ноябрь аенда Казанга, «Социалистик Татарстан» газетасының герой-шагыйрь Муса Җәлил исемендәге призлары өчен үткәрелә торган бәйгесенә әзерләнә иде. Үзләре телендә аны «Җәлил турнирлары» дип кенә йөртәләр, моңарчы дүрт ел рәттән, җитмеш икенче елдан бирле, команданың беренчелекне беркемгә биргәне булмады. Быел да шәһәр данын югары тотарга, җиңү яулап кайтырга ниятләре. Шуңа да спортзал түшәменнән төтен чыга.

Янә Казанны яуларга дип, юлга кузгалган командада быел Фәйзелхан да бар. Башкаланы дер селкетергә исәпләре! Данил Галиев үзе генә дә ни тора! Рәсәй, Татарстан чемпионы, йөз килограммнан артып киткән баһадир гәүдә! Наил Зәйдуллинны кара – дүрт тапкыр Түбән Кама Сабан туе батыры!..

Бу көннәрдә Казан чыннан да дер селкенде. Биш авырлык үлчәвендә Түбән Кама командасының һәр биш көрәшчесе дә үз үлчәүләрендә беренчелекне яулап, рекорд куйдылар, шәһәрнең көрәшчеләр каласы икәнен исбатладылар. 60 килограммда көрәшүчеләр арасында Нариман Әхмәтшин келәмгә җиде тапкыр чыгып, алты көндәшен «чистага» җиңде. Иң күп көрәшчеләр җитмеш һәм сиксән килограммлы авырлыктагылар булып, Әлмәт, Азнакай, Балтач, Казан егетләрен Наил Зәйдуллин җиңеп ташлады. Алардан авыррак үлчәүдә көрәшүчеләрне Михаил Минеев егып салды. Миша да, Наил шикелле үк, Зәй районыннан. Наил – Әхмәт авылыннан булса, Михаил – Сарсаз-Баграҗ авылында туып-үскән егет; Түбән Кама командасы белән мондый ярышка тәүге тапкыр гына килүе түгел.

Фәйзелхан туксан килограммда көрәшүчеләр исемлегендә иде. Казанның быелгы Сабан туе батыры Фидаил Шакиров белән, бер-берсен ега алмыйча, штраф очколары алып, байтак көч сынашты алар, ахыр чиктә Фидаил дә, аннан соң келәмгә чыккан Саба егете Әсгать Гайфуллин да финалдан төшеп калдылар. Беренче урын өчен Зәй батыры Исмәгыйль Баязитов белән бил алышып, җиңү Фәйзелханга тәтеде. Фәйзелхан Фидаилнең дә, Исмәгыйльнең дә алымнарын белә: икесе дә, күрер күзгә тотарга, эләктерергә бик җайлы тоелсалар да, көрәшә башлаганда инде тартып кына китерәсең – гәүдәләренең аскы ягы артка чыгып, пружина шикелле борыла да куя. Чамаламый калсаң, тотып бетердем дигәндә китереп бәрүләре дә бар...

Физкультура техникумында укыганда, психологик факторның спортчы өчен буш сүз түгеллеген баштан чыкмаслык итеп өйрәткәннәр иде, тормыш тәҗрибәсе аны үз сабаклары белән тулыландырып кына торды. Кайчак, көндәшеңне алдан ук сындыру өчен янына килеп, җилкәсенә суккалый-суккалый: «Да-а, малай, син быел тагын да мощныйрак күренәсең әле, җиңеп тә ташламассың микән», – дип сүз катып китү дә җитә... Татарстанның милли һәм классик көрәш буенча танылган тренеры Мәгазь Сәхәбетдинов Фәйзелханның уйлап, акыл белән эш итәргә яратканын тиз төшенгән иде, шуңа да аны күрсә, «Аһа, профессор килде. Алдый инде хәзер бу боларны...» – дияргә ярата...

104 килограммлы Данил Галиев иң авыр үлчәүле пәһлеваннар арасында көрәшә иде, барлык көндәшләрен ул берничә минут эчендә аркаларына төшерә торды. Бераздан, газета призына алтынчы мәртәбә ия булган пәһлеван исемен күтәреп, ярышны төгәлләде.

Җәен Түбән Кама Сабан туенда Фәйзелхан да Данил Галиев белән йөзгә-йөз калды. Татар көрәшенең затлы исеме – батыр исеме өчен көрәшә иде алар. Аңынчы, «мәйданда үз батырларыбыз гына сынаша, Әлмәт батырын кертмәскә», – дип, Фәйзелханны келәмгә якын китерергә теләмәгәннәр иде. «Хәзер безнеке ул, «химия»дә эшли», – дип раслаганнан соң гына аяк бастырдылар.

Мәйдан акылдан язар дәрәҗәдә гүли: бер сәгать буе барган көрәш ике

пәһлеванның көч-куәтен күрсәтеп, инде тирә-яктагы халыкны арып-талырга мәҗбүр итте, егетләрнең берсенең дә бирешергә исәбе юк иде. Икесендә дә үгез үҗәтлеге: моңарчы Түбән Камада гына түгел, республикада исемен яңгыраткан Данилда горурлык җитәрлек, шәһәрдә үзе кебек үк көчкә ия тагын бер көндәшнең барлыкка килүе гәүдәне туп шикелле тыгыз бер түгәрәккә җыярга, данга тап төшермәскә дип, сөлгене тагын да ныграк тартырга мәҗбүр итә. Былтыр Казан Сабан туенда Европа һәм Украина чемпионы, классик көрәш буенча халыкара класстагы спорт мастеры, СССР чемпионы Дмитрий Задверняк белән бил алышуы күз алдыннан сызылып үтә. Нинди көчле көндәшне кыска гына вакыт аралыгында биленә китереп салганны...

Фәйзелханның үз уе. Яңа шәһәрдәге яңа сукмагың батыр исеме белән башланса ярап торыр иде... Әнә бит, аны «Әлмәт батыры» дип олылыйлар. Тик ул – үтелгән юл. Бу шәһәрдә тормыш китабының яңа битләре ачыла. Батыр исеме белән башланса мишәйт итмәс иде... Көрәше матур! Чын пәһлеван белән бил алыша!

Икесенең дә канга батып беткән йөзендә, комарга бирелгән күзләрендә ярсулы бер чаткы уйнап алды.

Данилның көрәш алымын белә Фәйзелхан. Син аңа таба уң аяк белән атлыйм дигәндә, аягың җиргә басканчы, каплый да үзенең бот арасына аягыңны да, кулыңны да кыстырып куя. Аннан аяк аркылы, корсак аркылы елан урынына, пружина урынына бөтерелә-бөтерелә барып төшәсеңне көт тә тор. 120, 130 килограммлы көрәшчеләрне дә шулай төшерә. Шуңа да Фәйзелхан аягын кыстырырга бирми, Данилга үзен күтәрергә, ян-ягына, дүрт аяклатып җиргә ыргытырга, балл алырга җай калдырмаска тырыша. Көндәшенең үзен дә алып булмый, ул инде азу ярган...

Хөкемдарлар тагын унбиш минут бирде. «Давай, быелга икенче урынга ризалаш!» – диделәр Фәйзелханга, бүгенге көрәшнең ахырын көтеп арыгач...

Түбән Кама аның көчен таныды, егетне үзенеке дип кабул итте. Тик койрык урынына үзенә ияреп килгән бер сорау бар иде: егеткә фатир кирәк иде. Спортклубтагы иптәшләре белән профкомга кереп, шулай дип сүз кузгалткач:

– Сиңа хәтле күпме кеше чиратта тора! – дип, ironияле елмайдылар. – Спортсмен, имеш... Берәр результатың бармы?

– Соң, бу бит Әлмәтнең Сабан туе батыры, Рәсәй чемпионы!..

Мондагылар егетнең көрәш буенча Россия беренчелегендә катнашып, Уфадан да, Чабаксардан да чемпион булып кайтканын каян белсен...

Әлләкем булсаң да, алай тиз генә тәтеми икән шул фатир дигәннәре. Аның өчен дә бәхетле очрак кирәк икән...

Ни гаҗәп, андый бәхетле очраклар, бармак бөкләп санасаң, байтакка җыела икән. Тик һәркайсында да үзеңнең көчеңне раслау таләп ителә иде.

Акыллы җитәкченең берсе дә үзе утырган кәнәфи култыксасына гына берекми. Үзе җитәкләгән оешмамы, авылмы, шәһәрме – аның җан сулышын тоеп яшәргә омтыла, рухыннан хәбәрдар булып тора, шәхесләрен барлый. Моңы бар икән – кушылып җырлаудан, кулыннан килә икән – гармун телләрендә сандугач сайратудан, бии белсә – табаныннан ут чәчрәтүдән

тайчанмый, халык җанына кушылып, бәйрәмгә ямь өсти. Ә Сабан туе... Сабан туе – татарның хезмәт бәйрәме генә түгел, җан бәйрәме! Әйе, әйе, җанның, изүләрен җилбәгәй җибәреп, тугарылган, биек багана өстенә менеп кунаклаган мәле: монда дөнья кыры җәйрәп ята – тирә-як имин, яу чапкан дошман күренми дип сөенә җан. Ялларын тузгытып, җилләрне узып чапкан ат өстендә елгырлыгын сынаган мәле: илнең ут уйнатыр егет-малайлары бар, күрәсезме, берсе дә төшеп калганнардан түгел! Күзләрен бәйләп, алдында торган балчык чүлмәккә күсәк белән кизәнгән мәле: күңел күзең ачык булса, теләсә нинди каршылыкны орып атарга була!

Җитәкчеләр көрәш карарга ярата. Татар көрәше! Менә кайда иң гадел, иң хак көрәш! Юк, хөкемдарларның гаделлеге турында түгел сүз, анысы – һәркемнең намус-вөҗданында, үз алдыңдагы гаеп тойгысы гомер буе баш миеңне борау урынына бораулап, игәү урынына игәүләп торудан курыкмыйсың икән, намусыңа колак салмасаң да була... Шуңа да кем өчендер Сабан туе көрәшен тамаша кылу – үз җанын мунча кертеп кайтуга тиң ул. Көче белән сокландырган пәһлеваннарга хөрмәт тә шуннан: монда – чиста көрәш, хәрәмләшүгә, аяк чалуга урын юк...

Алдагы елның Сабан туенда Фәйзелхан үзен Чаллыда сынап карарга булды. Яшьләр каласында Фриль Әхмәтов кебек көрәшчеләрнең ат уйнатканын белә, шундый көчлеләр белән бил алышып карау кызыктыра да инде. Көрәшчеләр арасында 43 яшьлек атаклы Раббани Гайфуллинны күргәч, «Бу бабай нишләп йөри икән инде?» – дигән җилбәзәк уй йөгереп үтте башыннан. Ул мәлдә Фәйзелхан үзенең 55 яшендә дә көрәшкә керәсен әле каян белсен – яшь чагы, җүләр чагы...

Тик егетне келәмгә чыгарырга ашыкмадылар, читтән килгән, кертмибез, дип ыгы-зыгы куптардылар. Шулвакыт кырыйдагы төркем янында елмаеп нидер сөйләп торган берәү, күзлек кысасын төзәтә-төзәтә, егетләр янына килеп басты. Мәсьәләгә ачыклык кертергә теләп:

– Кемне кертмисез, әллә бу егетнеме? – дип шаяртып, үз итеп Раббаниның кулын кысты.

Киң маңгайлы, уртачарак гәүдәле, күзлек астыннан ачык елмайган бу ирнең КПССның Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре Рәис Беляев икәнен таныды Фәйзелхан.

Ике-өч сүз белән генә хәлне аңлаттылар.

Рәис Кыямович ашыкмыйча гына башта аның буй-сынына бер кат күз йөгертеп чыкты, аннан, каршысына килеп, егетне күтәреп карарга ниятләде. Моны кызык тапкан Фәйзелхан, ирен читенә йөгергән елмаюын яшереп, аяк очларына күтәрелгән булды. Күтәрелерсең дә, хәзер көрәштә катнашу-катнашмау шушы җитәкченең нибары бер сүзеннән торырга мөмкин...

– Мин үзем көрәшкәндә, бот белән сугып ата торган идем, – диде Беляев, күзлек астыннан туп-туры карап. – Керсен, көрәшегез.

...Җиңелергә тиеш түгеллеген әллә кайсы күзәнәкләре белән тойды Фәйзелхан. Тик, ай-һай, насыйп булырмы? Башкаларны җиңүгә ирешсә дә, әнә, баш батыр исеме өчен Минзәләгә генә түгел, бөтен татарга данлыклы Раббани Гайфуллинның үзе белән бил алышырга туры киләчәк... «ГАЗ-53» машинасының двигателен берүзе күтәрә, дип сөйлиләр аның турында! Раббаниның сабыр хәрәкәтләре, салкын канлылыгы аның тынычлыгын

урлады. Егетнең күз алмалары атылып чыгар дәрәҗәгә җитте. Әле бер, әле икенче алымны куллануы нәтиҗәсез: азу ярган көрәшче җай чыккан саен аны корсагына күтәреп бәрә. Шулай итеп Раббани үзенә ике балл алган иде. Көн кебек ачык: аз гына калган вакытны болай гына сузып торса да, аны җиңүче дип игълан итәчәкләр. Һавадагы торнага ымсынып, кулыңдагы чыпчыкны ычкындырма диюләренә дә колак салырга кирәк шул... Ул, булгач булсын, чистага егыйм дигәндер, егетне сөйрәп үзенә якын китереп, корсагына терәде. Мизгелнең кайсыдыр бер өлешендә Фәйзелхан, үзенә кулай шушы алымны көтеп кенә торган диярсең, көндәше аның аякларын җирдән аерырга омтылган мәлдә, бот аша сугып, аны күтәреп тә алды, әйләндереп тә салды.

– Үпкәләмә инде, Раббани абый, – диде ул, үз җиңүе өчен уңайсызлангандай, самими генә итеп.

– Ялгыштым шул, туганкай, ялгыштым... – дип аның кулын кысты Раббани, үзе дә аптырап туймаган бер кыяфәттә.

Көрәшнең һәр мизгелен керфек йоммый күзәткән Рәис Беляев Фәйзелхан янына килеп, кочаклап алды да:

– Ну, егет, син бит минем приём белән суктың! – диде, үзе җиңгән күк, чын күңелдән шатлануын яшереп тормыйча.

– Әйе шул, нәкъ вакытында әйттегез, рәхмәт! – дигән булды Фәйзелхан, йөзен тутырып елмаеп.

Мәйдандагы халык урыныннан купкан иде. Гөрләгән, шаулаган авазларның кайтавазы егетнең үзеннән дә алда Түбән Камага барып җитәчәк иде...

Куян шулпасының шулпасы булып килеп ирешсте микән, әллә хактан да шундый сөйләшү булган – Фәйзелхан анысын белми. Иллә дә мәгәр шул сөйләшүнең шаһите, дусты Альберт әңгәмәне текмә-тек бәян итәргә тырышты. Сабан туе бәйрәмнәре «Нижнекамскнефтехим» берләшмәсенең генераль директоры Николай Лемаев белән Рәис Беляевны урман аланында бер табын артында күрештергән иде. Мәҗлесне әзерләүчеләр арасында Альберт та булып, колагына шулар чалынган икән:

«Син миңа кемне җибәрдең, Николай Васильевич?»

«Тәк-тәк-тәк-тәк... Кайчан, кайчан, кайда, кайда ул, Рәис Кыямович?»

«Синең «химия»дән диделәр, көрәштә Чаллыларны егып, бөтен бүләкләрне, тәкәне Түбән Камага алып китте».

«Да-а-а?.. Молодец, молодец однако! Тәк-тәк-тәк-тәк, кем ул?..»

Менә шушы йомгактан башланган сүз Фәйзелханны Лемаев каршысына китереп бастырды да инде. Хезмәттә булса – кулыннан эш килә торган белгечкә ике куллап ябышкан, комбинат, шәһәр данын күтәрүчеләргә, көрәшчеләргә бөтенләй мөкиббән генераль директор аны колач җәеп каршылады.

– Молодец! 200 сум разовая премия!.. Нинди соравың бар – туп-туры үземә кер!..

Шуннан соң Николай Васильевич Фазыл-Фәйзелханны күз уңыннан ычкындырмады да. Үзенең дә энергиясе ташып торган, «химия»дәге эшчеләрнең күбесен исемләп белгән, теләсә кайсы проблеманы хәл итәргә омтылган директор аның нинди ярышларга баруын, нинди нәтиҗә белән кайтуын беркайчан игътибарсыз калдырмады.

Ә сораулар белән мөрәҗәгать иткән чаклар булгалады...

Хәтта акчаң ташып торса да, кибетләрдән җаның теләгән әйберне ала торган чак түгел, күрер күзгә буш алар. Куәтле тоелган илнең ялган идеалларга дан җырлаган, соңрак тарих киштәсендә «торгынлык еллары» дип урын алачак, Леонид Ильич Брежнев җитәкләгән чоры бу. Бәйрәмнәре, самимилеге, кешеләрнең бер-берсенә мөнәсәбәте белән сагындырып та куячак чор... Алдауга, күз буяуга корылган, бер генә халыкны «бөек» дип атарга җөрьәт иткән җәмгыять, еллар үткәч, бер милләтне икенчесенә каршы куеп, гаугалар чыгарачак, үзенең ачы җимешләрен күрсәтәчәк дип азлар уйланган чак... Дүрт гасыр элек үзенең ханын да, данын да, иреген дә җуярга мәҗбүр булган, гаярьлеген – баш июгә, чәчән сүзен күндәмлеккә алыштырган татар, үз урамына авыл башындагы чучка фермаларыннан агылган яман ис белән бергә, эчкечелек, әрәмтамаклык, пычраклык сазлыгына баткан кавемнең сыйфатлары да сеңеп килгәнен абайламый гына, баш күтәрми эшли дә эшли. Эшләгәненә аяк тибеп хак сорарлык чамасы юк – телләр тышаулы. Дәшеп кара... Шагыйрьләр, язучылар, совет кешеләренең генә җир йөзендәге иң бәхетле затлар икәнен миеңә сеңдерерлек итеп, берсеннән-берсе уздырып, илгә дан җырлаган әсәрләр иҗат итә. Мәктәп балалары, чит илдәге яшьтәшләренең ачтан тилмереп үлмәс өчен урамда байларның машинасын юып йөрергә, аяк киемен чистартырга мәҗбүр булуына шаккатып, «без бәхетле шат балалар, без кайгыны белмибез», – дип, җыр суза. Ата-аналар шул балаларга сандали, велосипед, кышкы пәлтә кирәксә – сәүдә тирәсендә эшләүчеләргә, карабодай ашатасы килсә – амбар ачкычы кулында булганнарга йөз суы түгә.

Туган һәр таң, «кеше бәхетле булмасын өчен ни уйлап табарга?» дип туа, ахры... Әллә, киресенчә, вак кына бәхеткә дә сөенә белсеннәр, диюе микән?.. Әнә бит, күпме аяк табаны туздырып йөргәннән соң бакча кишәрлеге алуга рөхсәт тәтегәч, кешеләрнең куануы! Булсын, өч сутый гына булсын, шунда бәләкәй генә өен, мунчасын, бәдрәфен, көрәк-сәнәк куяр өчен җыйнак кына келәтен салып куйсаң, кыяр-бәрәңге утыртырга да бик җитә җире. Шәһәрдән әллә кайда еракта, альпинистлар шикелле үрмәләп менәрдәй тау-таш арасындамы, билчәннән гайре берни үсми торган иң уңышсыз туфрактамы, бер яктан завод торбалары, икенче яктан шәһәр чүплеге карап торган урындамы – дача ул, дача! Елга буеннан, урман эчләреннән алырга теләсәң, гафу ит, башкачарак юллар кирәк булыр...

Акчаң булып, машина алырга теләсәң дә, хәлләр шулайрак тора. Машина... бар ул... юклыгы белән генә күренми...

Фәйзелхан генераль директордан машина алуда ярдәм итүен сорарга булды. Чакырган җиргә бар, куган җирдән кит, диләр бит. Соравың булса кер дип торганда... Аны-моны уйламый кабул итү бүлмәсенең ишеген ачып җибәргән иде, Лемаев янына үтәргә чират көтеп утырган җитәкчеләрне, директорларны күреп, бермәлгә югалып калды. Алай да борылып чыгып китмәде, буш урындык күреп, шуңа таба атлады. Ул да булмады, каршыдагы кабинет ишеге ачылды, кемнедер озата-озата, Николай Васильевич үзе килеп чыкты. Бүлмәдәгеләргә тиз генә күз йөгертеп, ияк кагып исәнләшкәндәй итте дә, Фәйзелханны абайлауга: «Әйдә!» – дип кабинетына әйдәкләде.

– Молодец! Но... – Николай Васильевич сул яктагы тартманы ачып,

«Советский спорт» газетасын тартып чыгарды, аны өстәлгә салып, бер урынга бармагы белән тукталды.

СССРның «Труд» спорт берләшмәсе ярышларында, «Нижнекамскнефтехим» командасы составында Фәйзелхан көрәш буенча җиңү яулап, чемпион булып кайткан иде. Газетаны күреп өлгергән иде, җиңүчеләр исемлегендә ул да бар. «Фазыл Әхмәтҗанов, Казаннан» дип язганнар.

Лемаевның кашлары сораулы җыерылды.

– Но причём монда Казан? Нигә Түбән Кама дип язмаганнар? – диде ул, бармагы белән әлеге исемлеккә кат-кат төртеп.

– Татарстаннан булгач, башкаланы гына күрсәткәннәр, – диде Фәйзелхан, артык фәлсәфәгә бирелмичә. Андагы журналистлар генераль директорның үзе төзегән завод һәм үзе төзегән шәһәр, аның кешеләре өчен фанатларча җан атып яшәвен каян белсен...

– Йә, әллә проблемаң бармы?

– Машина алырга чиратка басып булмасмы, Николай Васильевич? – Фәйзелхан сүздән аркан ишәргә җыенмады, алып кергән гаризасын аңа сузды.

– Мә, профкомга кертеп бирерсең. Озак тотмаслар. – Күз төшереп алуга, Лемаев, почмагына нидер язып, имзасын куеп, гаризаны кулына да тоттырды. – Синдәй егетләргә жалко түгел!

Моның шулкадәр тиз, күз ачып йомган арада хәл ителүенә ышанырга да, ышанмаска да белмәгән Фәйзелхан профком кабинетына төштәгедәй йөзеп кенә барып җитте.

– Менә, машина чиратына гариза... – дип, җөмләсен төгәлләргә өлгермәде, бер кулы белән телефон трубкасына үрелгән ханым икенчесе белән гаризаны егет кулыннан эләктереп тә алды, «ярар, калдыр», дип, ялт кына папкаларның берсе эченә шудыртып та куйды.

Ай арты ай үтеп, бер ым-хәбәр дә ишетелмәгәч, Фәйзелхан кабат профком ишеген какты.

– Ярты ел элек мин машинага гариза калдырган идем, ничегрәк икән анда? – диде ул, теге вакытта үз кәгазе кереп чумган папкага ишарәләп.

– Ярты ел? Соң, апаем, син түгел, саллы-саллы директорлар ничә еллар чират көтә... – Ханымның яшькелт күзләренә, нечкә иреннәренә көлемсерәүле елмаю йөгерде.

– Минем гаризага Николай Васильевич кул куйды, озак тотмаслар, дигән иде.

– Ә? – Күзләр мизгел эчендә төсен үзгәртте, нечкә иреннәр бөтенләй йомылып бетте, ханымның куллары үзеннән-үзе ялт та йолт килеп папкалар арасыннан шактый калын бүксәлесен йолкып чыгарды. Гаризаны эзләп тапкач, почмагындагы имзаны күргәч, тавышы да ярамаган эш өстендә тотылган мәче баласыныкыдай ишетелде. – И Аллам... карап тормаганбыз... Син берүк кереп әйтеп йөри күрмә, апаем, хәл итәрбез, яме...

Дөнья җайлап кына үз тәгәрмәчендә әйләнә иде.

Түбән Каманың соңыннан «Көрәшчеләр аланы» дип исем алачак урынында, күл буенда, Сабан туйларыннан соң казан асып, зурлап бәйрәм итү традициясен Фәйзелхан башлап җибәрде. Тәкә итеннән авыз итәргә

барлык көрәшчеләр, дуслар җыела, башкаларга да жәлке түгел – киң күңел белән бөтен спорткомплекс директорларын, профком рәисләрен, директор урынбасарларын, ОБХССтагыларны, милиция, прокуратура тирәсендәгеләрне дә чакыралар. Теш үтмәс мәсьәләләрнең барысын да кабинетта гына чишеп булмасын тормыш үзе төшендерде. Әнә, кемдер уч төбе кадәр генә булса да, дача җире дип өметләнә, кемдер хатыны, баласы белән бер бүлмәле фатир турында хыяллана... Еллар үткәч, шул рәвешле «бәхеткә тиенгән»дусларының күбесе, «су буенда синең дистәләп тәкәңне ашадык инде», – дип шаяртып искә төшерәчәк әле Фәйзелханга...

***

– Көрәш үзеңне якларга да, кеше арасына кирәргә дә булыша, сизгерлеккә дә өйрәтә: кемнең кем икәнен чамалыйсың, – диде Фәйзелхан, Шәфкатьнең дә спорт белән шөгыльләнүен хуплап. – Тик менә йә хәрби училищега, йә спортфакка барам диюең генә, энекәш...

Абыйларына охшап, тоткан җирдә өзә торган, гәүдәгә нык Шәфкать мәктәпне тәмамларга җыена. Фәйзелхан янына Түбән Камага килгән иде, инде менә бергәләп авылга кайтып барулары, үз көенә ашыкмый гына йөзеп барган су трамваенда киләчәк турында гәп куертулары. Мәктәптә бию түгәрәгенә йөреп, республикада урыннар алып кайткач, сәнгать тә күңелен кымырҗыта егетнең.

– Спорт та, җыр-бию дә хобби гына булса, шәп, энекәш, ну барыбер бер төпле һөнәр кирәк ул. Әллә соң мединститутка барып карыйсыңмы, врач булыр идең, әти-әни дә олыгаеп килә, – диде гаиләдәгеләрнең һәркайсы өчен кайгыртуны язылмаган бурыч рәвешендә кайчан үз өстенә алганын абайламаган Фәйзелхан. Болай дигәндә, әлеге һөнәрнең авырлыгын чамаласа да, никадәр кирәкле икәнен күздә тота иде. Табибларның хезмәт хакы турында кызыксынганы булмады, менә анысын белми, ник дисәң, үзенең акчага кытлык кичергәне юк. Төзелеш бригадасы туплап, җәй житсә шабашкадан кайтып кермиләр, уч тутырып, акча эшлиләр. Мамадышта, Сарманда, Азнакайда алар салган фермаларны саный башласаң...

Кая укырга керергә икәнен Шәфкать тәгаен белми иде. Моңарчы абыйсының киңәшләре гел өлге булганга, «врачлыкка барсаң...» дигәнен ишеткәч, берара уйланып калды. Абыйсы һәрчак алдан күрүчән, беркайчан юк-бар сүз сөйләп маташмый, җиде түгел, җитмеш кат үлчәп кисә...

Алабугага кайтып киткәч, пристаньнан шәһәр урамына күтәрелделәр.

– Тамагың ачтымы? – диде Фәйзелхан, абыйларча бер кайгыртучанлык белән. – Минеке ачты...

Ачмас, ди! Иртәнге бер чәшке чәй әзмәвердәй егетләргә нәрсә ул...

Абыйсы, Шәфкатьне урамда калдырып, ялт кына почмактагы кибеттән урап чыкты. Кулында ак күмәч белән юан бер таяк колбаса ялтырап күренде.

– Мә, тотып тор, – диде ул, нәрсәнедер онытканын искәргәч, кабат кибет ишегенә юнәлеп.

Өр-яңа пәкене учында уйната-уйната әйләнеп чыккач, ике кулын селтәп торган Шәфкатькә карады да кашын аптыраулы җыерды:

– Колбасаны кая куйдың?

– Ашап бетердем.

– Ә-ә?.. Ну ничек, авыр түгелме соң?

– Ю-ууук...

– И-и, энекәш... Болай булгач, точно көрәшче чыга синнән...

Шәфкатькә дә, үзе тренер булып эшләгән спортклубтагы егетләргә дә өмет баглап тора әле Фәйзелхан. Геннадий Муллин белән Флүр Ахуновның армиядән кайткач, көрәш түгәрәгенә кабат килүләре күңеленә сары май булып ятты. Мәктәптә тә бергә укыган бу ике дус егет теләсә кайчан берсе икенчесе өчен калкан булып баса торганнардан. Гена уйлап кына, бастырып кына үз сүзен әйтә, Флүрнең исә теле телгә йокмый. Яз көне, әнә, тренерыннан шампан шәрабын ничек каерып алды...

Фәйзелхан егетләрне метеор белән Казанга, классик көрәш бәйгесенә алып барган иде. Флүр финалга үткәч, икенче көнне тренеры аны спорт мастеры булган егет белән бил сынашырга әйдәде: «Шуны җиңсәң, үзем бер шампанское куям мин сиңа», – дип кыздырып та җибәргән булды. Флүр, көрәшкәндә, көндәшенә сөлек кебек ябыша, ничек атсаң да, өскә чыга, сизгерлеге бар. Спорт мастерының аны бала-чага урынына күреп, уйнап кына ябышасын, юк кына алым белән алып атарга ниятләвен Фәйзелхан сизеп тора. «Ул селтәнгәндә, шушылайрак итеп капласаң, кабыргага кыссаң, алып бәрәлми ул сине», – дип, егетне нәрсә көткәнен дә алдан ук өйрәтеп куйды.

Бу юлы да Фазылның тоемлавы алдатмады: аның өйрәткәнен йотып кына алган шәкерте күз ачып йомган арада үзенең көндәшен җиңәргә дә өлгерде. Җиңдем дип түгел, шампанское эчәбез икән дип сөенеп килүен кара син аның... Елга портына барып, Түбән Камага кайтып китәргә җыенганда, Фәйзелхан аның нидер әйтергә теләгәндәй бөтерелеп йөрүенә артык игътибар да итмәгән иде, егетнең, түзмичә, турыдан ярып: «Теге шампанское бик еракта микән?» – диюен ишеткәч, шаулатып көлеп җибәрде. Нишләсен, вокзал ресторанына барып, биш бәясенә булса да, сап-салкын шампан шәрабе күтәреп чыгарга туры килде тренерга.

Шулай, шәкерт остаздан да уздырмаса соң...

Җәй җиткәндә, спортклубтагы шөгыльләр бетте, тренерларны, гадәттәгечә, «сбор»га, ялга җибәрделәр. Янәсе, өч ай буе көч җыярга, шөгыльләнергә... Егетләрнең үз «сбор»ы: бригадир Галимҗан әллә кайчан әйтеп куйды, төзелеш бригадасы белән шабашкага, «Петровский» спирт заводын торгызырга алып китәм, диде. «Айга мең тәңкә түлисеңме – барабыз», – диде Фәйзелхан. Үткерлектә, елгырлыкта Галимҗанга тиңнәр юк, колхоз председательләре белән дә, кассир кызлар белән дә сөйләшә белә, акчасын да табар... Дүрт егет «котельный» ясарга тиеш булдылар. Кирәк-яракның барысын бригадир табып китерә иде, тик түбәгә чыгарырга торба кирәктә, эт белән дә эзләп табышлы булмады үзен. Егетләрнең тәк прусты вакыт үткәрергә исәпләре юк иде, «эшлекле» киңәшмә ясап алдылар.

– Нишлибез? Галимҗанны көтәбезме?

– Аны көтсәң, күз күгәрер...

– Күршедәге шабашниклар бригадасында торба бар, койма буенда тау булып өелеп тора...

– Ну?

– Шуннан эләктерсәк...

Әйтелдеме – эшләргә кирәк.

Фәйзелхан белән Габбас иртә таңнан, кеше-кара уянганчы шунда юнәлделәр. Дүрт-биш кеше бергә көчкә күтәрердәй авыр, унике метрлы торбага икәүләп теге яклап та, бу яклап та карап-карап тордылар. Торба кирәк, ничә йөз кило булса да алып кайтырга кирәк...

Үч иткәндәй, кыймылдаулары булды, күрше шабашникларның бригадиры тып итеп каршыларына килеп чыкмасынмы?! Ул берара шушы галәмәткә – коточкыч авыр торбаны икесе ике баштан җилкәләренә салып атлаган егетләргә шаккатып карап торды. Аннан:

– Ну, егетләр, сез аның кыскарагын алыгыз, нигә шулкадәр авырын, озынын күтәрәсез, имгәнәсез бит, – диде ул, аның «товарын» шудыручы егетләргә, әллә аптыраудан, әллә шок хәленнән айный алмаган халәттә.

Бу вакыйга мизгел эчендә авылга таралып, детектив рәвешендә дәвам итте. Нәкъ шул көнне бер егет үлеп, халык телендә: «Иртән теге авыр торбаны күтәргән егетләрнең берсе йөрәк тамыры шартлап үлгән икән», – дигән сүз капкадан-капкага шакып чыккан икән. Фәйзелхан белән Габбас аны-моны ишетергә өлгермәгәннәр иде, вак-төяк алырга авыл кибетенә килеп кергәч, сатучы кызлар аларны күреп:

– Үлмәгәннәр бит, исәннәр бит! – дип аһылдап җибәрделәр.

Баксаң, авылда кемдер сыйфатсыз аракы эчеп үлеп киткән булган икән...

«Шабашка»ның маҗаралар белән тулы өч ае үтеп киткәч, егетләр шәһәргә кесә тулы акча белән кайтып төштеләр...

***

Ят инде Казанда, бүлнис түшәменә күз текәп... Бәләкәй генә бер вирустан җиңелергә әзер булып. Менә адәм көлкесе... Ә бит нинди чаклар бар иде! Бөтен Татарстанның, һәр авылында, һәр районында, шәһәрендә берсеннән-берсе көчле үз батыры булган, шул батырлар барысы бергә көч сынашкан башкаласыннан, баш батыр исемен үз җилкәңә салып, башыңны мәгърур тотып кайтып киткән чакларың бар иде бит! Исеңә төшер, Фәйзелхан, исеңә төшер. «Бу авыру хәтерне гупчим бетерде», дип зарланырга ашыкма. Син бит ул елларны-көннәрне минуты-сәгате белән хәтерлисең. Дөньялар рәтләнеп, җиңүчегә машиналар биргән елларда үзеңә тәтегәннәреңнең төсен, маркасын оныткан булуың бар, әмма да элгәре чактагы бүләкләрнең – республиканың баш батырына бирелгәннәренең берсе дә онытылмаган. Юклык чорда, һәрнәрсәнең кадере һәм кыйммәте бар чакта, вак кына әйбергә дә зур итеп сөенә белгән чакта эләккән бүләкләр иде бит алар, исеңдәдер. Сиксән бердә – 16 сумлык «Смена» фотоаппараты эләкте, сиксән икедә – юньләп эшләмәсә дә, бик затлы күренгән транзисторлы приемник. Сиксән биштә абсолют батыр калгач – артына зур итеп «СССР» дип язылган спорт костюмы бирделәр. Исеңдәдер, машина алганнан болайрак сөендеңсин аңа...

Дәрья-сулар дулкынланып, кайчан да бер тына, ә менә алтын балык турындагы әкияттәге шикелле, җиңү тәмен бер татыган күңел тына-тынычлана белми икән. Алабуга, Әлмәт, Түбән Кама, Чаллы батыры дигән исемнәр генә җитмәде, Казанны, республиканы яулыйсың килә иде. Борының да югарырак булгандыр, кем белә: исемең татар көрәшчеләре

арасында язгы күкрәү булып яңгырый иде бит, Сабан туйлары җитсә, кайберәүләрне, «моңа якын килә күрмә», дип алдан кисәтеп куялар иде, янәсе, сөяк-санагыңны җыеп алалмавың бар...

Республиканың баш батыры дигән исемне беренче тапкыр кайчан яуладың, хәтерлә әле... Зарланма, сулыш алуы авыр, баш кыса, күкрәк изелә дип еламсырап ятма монда. Эшсез ятма! Хәтереңне булса да игәүлә!.. 1981 елның 14 июле идеме? Татарның 32 пәһлеванын Казанның Үзәк һәм ял паркына көч сынашырга җыйдылар. Олимпия системасы: бер егылдыңмы, ярыштан шунда ук төшеп каласың. Беренче әйләнештә өчәр минутлык ике период иде, көрәшчеләр саны байтак кимеде. Син анда башта Мамадыш егете Фәрит Сибгатуллинны ектың. Икенче әйләнештә дә җиңүчеләр сафында калдың. Ярымфиналда көрәш вакытын ун минут итеп үзгәрттеләр, исеңдәме? Ну анда егетләрнең иң-иңнәре калган иде шул, кайберсенә күз ачып йомган мизгел дә җитәрлек булды: Әнвәр Гыйләҗевны исеңә төшер, Фоат Шәйдуллинны 20 секунд эчендә аркасына салды! Финалда сез Әнвәр белән икәү калдыгыз. Аңа 21 яшь булгандыр, татар-башкорт көрәше буенча РСФСРның спорт мастеры. Бер-берегезне күтәреп салу түгел, урыннан да кыймшата алмыйча, биш минут буе әйләнеп йөрдегез, онытмагансыңдыр... Хөкемдарларның кисәтү ясавы гына кыздырып җибәрде үзеңне, тәнәфестән соң, көндәшеңне җирдән аерып, янбаш аша келәмгә тәгәрәттең. Шулай башта бер, аннан тагын, тагын баллар алып, өчкә ноль исәбенә җиңдең... Иптәшләрең центнерлы гәүдәңне күккә чөйде ул көнне...

Икенче җиңү Үзәк стадионда, сиксән икенченең июлендә булдымы? Ул елны көрәшчеләр саны кимрәк, егерме биш иде, ахрысы. Авыр үлчәүдә Әсхәт Фәхретдинов белән сиңа Марат Зәкиев, Хәмзә Шакиров, Нурсил Галиевлар ничек каршы торды, ә?! Ахырдан, ике авырлык үлчәвендә җиңгәннәр абсолют батыр исеме өчен көрәшкәндә, көндәшең Казанның Совет районы эчке эшләр бүлеге хезмәткәре Григорий Канашев иде. Синнән егерме килограммга кимрәк, ут егет, тиз генә күтәреп бәрә торган булмады үзен, беренче периодта «тоттырмый гына, йөгереп кенә» йөрде. Икенче периодта, сөлгеләрне билгә бәйләгәч, китереп кыстың...

Тагын шул ук мәйданнан сиксән бишенче елны баш батыр исемен алып киттең син. 33 көрәшче идегез, өч төркемгә бүленеп көрәштегез. Азакта, исемне яулау өчен, Фәрит Шәйхетдинов, Габбас Әхмәдиев белән бил алышырга туры килде, исеңдәдер. Фәрит синең 105 килолы авырлыгыңа артык каршы торалмады. Ә менә Габбас белән шактый озак бөтерелдегез. Көндәшеңнең ике кулын кыстырып, үзеңнең күкрәккә кысып ыргым ясый торган гадәтеңне белә бит Габбас, шундый мөмкинлек бирмәс өчен тырышты ул. Ахыр чиктә, сөлгеләрне билгә бәйләгәч, әйләндереп салдың...

Ә менә бер елны Чаллы Сабан туеннан соң, җиңелгәне өчен Габбасны ничек сүккән идең, исеңдәме? Габбас сиксән биш килограммлы авырлык үлчәвендә көрәшергә дип килгән иде дә, сиксән килолы авырлык үлчәве буенча көрәшәселәр икән. Ике-өч килограммы артык булгач, авыр үлчәүдәгеләр исемлегенә яздылар. Синең белән туры килсәм, алга җибәрермен, дип ниятләве дә булган... Ә сиңа бу юлы Хәбил Бикташевне җиңү насыйп булмады, балл алып, өстенлек яулады ул. Үзең дә инде... дзюдо буенча Европа чемпионы, сумо буенча ил чемпионаты призеры дигән

катлы-катлы исемнәре булган атаклы көрәшче алдында бераз каушабрак калдың, көрәш башланганда усаллыгың, үз-үзеңә ышанычың җитеп бетмәде. Югыйсә психологик халәттән күп нәрсә торганын бик әйбәт беләидең. Соңыннан, «эх, тагын бераз вакыт тигән булса» дип үкенсәң дә, кем әйтмешли, поезд киткән иде...

Ярымфиналда сиксән ике килолы Габбас белән 124 килолы Хәбил көрәшкәндә, һәркем, көндәшләр үзләре дә бары тик бер генә төрле финал көткән иде. Шулчак кеше ышанмастай хәл булды да куйды: үзенә «баласытып» кына караган көндәшеннән әле тегеләй, әле болай итеп «качып» йөргән Габбас, вакыт бетеп килгәндә, аның ике аяк арасына кереп, күкрәккә алып, ыргым ясады да, балл белән җиңеп тә куйды. Бу шулкадәр көтелмәгән хәл иде, тирә-яктагы халыкка шок булды, мәйдан өстен тоташ гүләү биләп алды.

Әлеге хәлгә үзе дә ныклап ышанып бетә алмаган Габбас финалда Исмәгыйль Баязитов белән калды. Алдагы атнада гына бу икәү Мөслим Сабан туенда көрәшеп, Габбас аны җиңеп кайткан иде. Бу юлы шуңа тугарылыбрак китүе булдымы... Инде балл арты балл алып, өч балл белән җиңүгә таба бара иде. Синең: «Кулыңны кыстырмаааа! Кулыңны бирмәәәә!» дип кычкыруыңны да колагы «өйрәтмәсәң...» диебрәк кенә ишетте... «Чистага бәрим үзен» дип тарткан бер мәлдә, шушы алымны, үзенең йолдызлы сәгатен көтеп кенә торган Зәй баһадиры аның кулын кыстырып та алды, әйләндереп тә салды...

Түбән Камага кайтып, дус-иш белән су буенда утырганда, әй, сүктең инде үзен: «Вәт җүләр, вәт җүләр! Өч балл була торып, нигә кирәк иде сиңа чистага сугам дип маташу... Күлмәгеңне салып ташлап, публикага фигура күрсәткән булып... Их, җүләр! Шулай итмәсәң, менә хәзер кильки консервасы ашап утырмас идек, тәкә боты кимерер идек...»

Шул чаклар, яшь чаклар, җүләр чаклар сагындыра. Әле дә, Габбас белән очрашканда, гел кабатлыйсың бит: «Элек акча да юк иде, кесәдә биш тәңкә күренсә, кафега-ресторанга кереп, дуслар белән рәхәтләнеп гөрләшеп утыра торган идек. Хәзер менә кешедә акча да бар, элекке дусларны гына җыеп булмый, таралыштылар, дөнья басты», – дип искә төшерәсең дә көрсенеп куясың...

Яшьлек беләндер инде, ул чактагы тормышның сорылыгы күзгә бөтенләй күренмәгән... Казанны гына кара... Юкса, кая ул бүгенгедәй гөлбакча булып утырган урамнар, киштәләре сыгылып торган кибетләр. Җилкәңә асарга спорт сумкасы, өстеңә кияргә спорт костюмы алам дисәң дә, кибетче кызлар алдында сандугач булып сайрарга, аларны елмайтыр өчен анекдот сөйләргә, җанатар итеп көрәш карарга чакырырга кирәк үзләрен. Шул чагында, Ходайның хикмәте, әллә каян астан гына сумканы да табып бирәләр, костюм да өстеңә менеп кунаклый.

Нигә әле кызлар дигәч, хәлсез башыңны Резида яткан якка борырга маташасың? Ул бит синең тормышыңа соңрак килеп керде, җүләр бөдрә чәчләреңнең кайберсе акыллы башыңны ташлап китәргә җыенганда, утызың тулып килгәндә. Аңынчы кызлар кулы тотып караганым булмады дип кычкырып әйтә күрмә, тавыклар кычкырып көләр... Ә тәүге самими мәхәббәт... Юк, анысына кагылма син, хәтер. Кайчагында, йөрәкнең ерак,

бик ерак почмагында, үз-үзеңнән яшереп куйган бәллүр хисләр була. Кагылма син аңа. Татарстанның халык артисты Рөстәм Закиров җыр сузганда, кушылып моңлануың бик җиткән:

Син мине яшәрттең, яшьнәттең,
Теләмим ярсуның тынганын.
Күрмәсәм мин сине дөньяда,
Яратмый китәсе булганмын.

Утка сал, суга сал син мине,
Үзең дә бер дөрләп ян әле.
Үземә булмасаң булмассың,
Җанымда яз булып кал әле...

Лутчы... көзге алдына басып, үз-үзең белән сөйләшкән мәлеңне хәтерлә: «Утызга якынлашып киләсең, пеләшең күренергә итә, синең кебекләр күптән инде өйләнеп, бала үстерә. Йә, кайчанга кадәр дуадак каз булып йөрергә уйлыйсың?» – дидеңме әле үз-үзеңә? Берәр тыныч, сабыр холыклы татар кызы очраса дигән уй да ярып керде, шулаймы? Җилбәзәк, ут борчасыдай кызлардан курка идең...

Юкарак гәүдәле, кара чәчле, көнчыгыш гүзәлләренекедәй озынча кара күзле Резиданы беренче тапкыр ул эшләгән җиһаз кибетендә күрдең. Юк, үзеңне алдавың. Элегрәк, әле ул бүләкләр бүлегендә сатканда, шундагы Римма исемле кыз янына сугылганда да күрми калмагансыңдыр. Әллә, артык тыйнак, ипле булып, чыннан да күзеңә чалынмады микән... Уртак танышыгыз Рөстәм алып кергән иде сине «мебельный»га. Резиданы киногa чакырдың, ә ул:

– Мин таныш түгел егетләр белән кинога йөрмим, – дип баш тарткан булды.

Шулай башланды бит очрашуыгыз?

Иптәш кызларының синең хакта «бөтен белгәннәрен» ачып салуы да куркытмагач, сиңа кияүгә чыгарга ризалык биргәч, куш йөрәкле булган инде үзе дә...

– Резида... – Пышылдаулы чыкса да, ирнең эндәшүе янәшә караваткa барып җитте.

Үз хәле хәл хатыны башын әкрен генә аның ягына борды, карлыгaн күзләре сүзсез сорау белән тын гына Фәйзелханга текәлде.

– Бүген... ничәсе?

Әйтерсең, менә монда, больница диварлары арасында көчкә сулыш алып ятканда, шушыннан да мөһим сорау юк.

Резида да белми. Вакыт исәбе күптән чуалды. Югыйсә коронавирус диагнозы куелып, дәваланып, инде аякка басабыз, дип өметләнеп йөргәннәр иде. Дәһшәтле давыл булып, көннәрдән бер көнне кинәт бөтенләй аяктан екты каһәр чир. Шуннан бирле икесе ике мендәрдә уйлар утравында бикләнеп калган шикелле.

Резида да язмыш йомгагын кырык сүтеп, кырык җыйды. Кызык та, кызганыч та: кайчак кешегә, үз гомере турында туктап уйланыр өчен әллә нинди катлаулы сәбәпләр дә кирәк икән.

Кояшлы Үзбәкстанның Чирчик шәһәрендә туып-үскән җиреннән урман куеныңдагы Морт авылына килеп төпләнер дә, дөбердәтеп сыер саварга,

каенанасы Мөкәррәмәгә ияреп, төтәсләгеч тотып, умарта карарга өйрәнер дип кем уйлаган. Әтисе Фатих белән әнисе Гөлсемнең иркә кызы, апасы Рәшидә белән абыйсы Рәшитнең тәти сеңлесе булып, беркемгә күтәрелеп бәрелми генә, тыныч кына яшәргә өйрәнгән җиреннән яңа гаиләнең кайнап торган тормышына килеп кушылыр дип, кем күзаллаган... Язмыштыр, Үзбәкстаннан Түбән Камага күчеп кайтулары да, Фәйзелханны очратуы да, әти-әнисенең булачак кияүне ошатулары да – барысы да алдан язылган язмыштыр...

Үзе баскан урынында ут чыгара торган ире бөтен кешене дә шулай булырга тиеш дип күзаллый иде, ахры, Резидага да, «тыныч хатын кирәк дип теләгән идем, кирәгеннән артык тыныч булып чыктың бугай», дип, кайчак турыдан ярып әйтеп куя. Уллары тугач, аның нәни гәүдәсенә шаккатып карап, «И-и, өч литрлы банка!» – дигәнен дә хәтерли әле Резида. Әйтерсең лә, сабый бала туганда ук, Фәйзелхандай пәһлеван булып туарга тиеш... Шулай булуын телүгәндер: башта Илнар дип исем кушкан җиреннән, бераз вакыт узуга, Фидель дип үзгәртеп куймас иде. «Фидель Кастро, йодрыкларын төйнәп, бөтен Американы куркытып тора. Минем улым да шулай нык булсын!» – диде ул чакта Фәйзелхан. Хакимнәр алышынган саен битлеген, кыйбласын үзгәртеп торучыларны җене сөйми, Куба башлыгын үз фикере булганы өчен хөрмәт итә иде.

«Улым да, кызым да эшнең нәрсә икәнен күреп үсселлнәр», – диде әтиләре. Авылга кайткач, мал тотмый гына яшәрлекләре дә бар иде, «хет профессор, хет кем бул – авыл эшен, эш рәтен белергә кирәк» – Фәйзелханның һәрнәрсәгә үз карашы. Сыерчык оясы ясыйлармы, өй төзиләрме – барысын җиренә җиткереп эшләргә кирәк икәнен үз мисалында күрсәтте. «Менә сиңа бер үгез, ашатасың, эчертәсең, астын чистартасың, итен саткач, акчасы үзеңә була», – диде ул Фидельгә, абзар ишеген ачып күрсәтеп. Үгезне тәрбияләп, итне сатып, хәйран акчага ия булган улының уйлы йөзен күргәч, мыек астыннан елмайды да: «Нәрсә, нишләргә инде бу акча белән дип баш ватасыңмы?.. Доллар сатып ал», – дип киңәш бирде. «Кайда, кем арасында булсаң да, ир-егет була бел. Әйттеңме – эшлә!» – дия-дия, Казанга, эчке эшләр министрлыгының юридик институтына озатты. Анда биш ел укуның эш стажына керәсен дә, шәләй-вәләй йөрергә урын юклыгын да, тәртипләрнең кырыслыгын да, стипендиянең шактый икәнен дә аркылыга-буйга үлчәгән булгандыр, мөгаен... Студент чакта, урып-җыю чорында авылга кайтып, Фидель «КамАЗ»ына да, комбайнына да утырды – егетнең дә, этисенә охшап, үҗәтлеге, чыдамлыгы, эшсөярлеге җитәрлек иде. Әнә хәзер Самараның районара тикшерү бүлеге җитәкчесе вазифасын башкара – даирәсендә, аның кебек, аһ-һай, тагын кем дә булса бар микән... Кирәксә, кирпечен дә тезә белә, бетонын да болгата, электрик булып та эшли ала. Кая барса да эшсез кала торганнардан түгел... Атасыннан күреп, ул үсә диюләре дөрес шул.

Ата кеше шулай буладыр. Малаенда үз дәвамын күрергә телидер.

***

Сабан туе килеп җиткәч, елдагыча, Гарифҗанның җаны урыныннан куба. Кем уллары дигәндә, аның уллары бил сынаша мәйданда! Шәрифҗаны, Фәйзелханы, инде менә Шәфкате үзен күрсәтте. Институтта укыган җиреннән көрәш түгәрәгенә дә йөри икән.

Үзенең көннәре санаулы икәнен аңлаудан да сыза ата кешенең җаны. Ашказаны, диделәр. Шулайдыр... Сугыш михнәте аша узып кайтканнар Мортта 261 кеше иде, еллап, айлап кими баралар, баштан кичкәннәр үзенекен итә, авыру-сызлау булып җелекләргә төшә. Хәерле булсын.

Иртәме-соңмы бу якты дөнья торып калыр. Гарифҗан иңләгән иген кырлары, авылның елга-чишмәләре торып калыр. Шул кырда арыш-бодайлар күкрәп үссен, чишмәләр челтерәүдән туктамасын өчен авылның җан сулышы өзелмәсен өчен көрәшүче булырмы? Әллә, убыр авызыдай үзенә суырган ташкалага киткән җирләреннән, киткән бере шунда берегеп калырмы? Ул чагында... ул чагында... тамырың синдә өзелсә, яшәдем дип яшәвеңнең ни мәгънәсе? Татарның тамыры ташкалада була алмый, булса да, җиргә түшәгән таш плитәләр арасыннан баш калкыткан зәгыйфь үлән булып кына калка ул. Колач җәйгән, түбәләре күккә ашкан мәгърур наратлар, чыршылар, имәннәр, әнә, Морт урманында күкрәп утыра, туган туфрактан көч алып, җәйрәп утыра.

Малайларында көч бар. Акыл да җитәрлек. Шәрифҗаны, ветеринария институтын бетереп, Түбән Камада үз һөнәре буенча эшләп ята. Фәйзелханы бөтенесенә терәк, җитмәгән җире юк. Былтыр җәен, күр, уч тутырып акча алып кайткан. «Алабугага барып кайтыйк, сугыш ветераны буларак, машинага чиратка басарсың», ди. Коты очты Гарифҗанның: ул, гомер буе эшләп, мотоцикл гына ала алды. Ә монда – машина!

– Әллә кеше талап йөрисеңме? – диде, улының күзенә туп-туры карап.

Төзелеш бригадасы белән өч ай буе колхоздан-колхозга йөргәннәр. Өч айга өч мең тәңкә акча эшләгән! Галәмәт! Ул чакта да беркемгә күрсәтми утырып елаган иде кеше арасында гомер буе «усал» атын йөрткән Гарифҗан.

Төпчегенең Алабуга батыры булып калуын ишеткәч тә, барысыннан качып, рәхәтләнеп елады. Шәфкать үзе кайтып кереп кенә эшне бозды, этисенең мондый йомшаклыгын күреп, аптырауга төште.

– Мин сине институтта биеп-җырлап кына йөрисеңдер дип уйлаган идем, улым. Батыр калдың бит, батыр! – диде этисе, инде күз яшьләреннән бер дә оялмыйча.

Күз яшьләренә барысы да сыйган иде. Имәндәй ир-егетләр үстергән ата горурлыгы да, яшьлеген, саулыгын илне яклау өчен сарыф иткән фронтовик хәтере дә, туган туфракны, туган авылны тиңсез хәзинә күреп, аны саклау өчен маңгай тирен түккән авыл иренең гомер турында уйланулары да. Китәр көннәрнең якын икәнен чамалау ни кырыс тоелган бәгырьнең дә йомшак җирен эзләп таба икән дә, уй диңгезенә илтеп сала икән... Янәшәсендә гел кеше булды, җор теле белән күз уңыннан, усал дигән даны белән телдән төшмәде. 17 яшендә Алабуга МТСы каршында оештырылган алты айлык курсларда укып, тракторга утырган иде. Сугыштан кайткач та, шунда бригадир итеп эшкә куйдылар. МТСларның куәтле чагы, дүрт-биш төркем булып, тракторлар белән төрле колхозларга чыгып китәләр. Шуларның барысының «тоткасы» – Гарифҗан. Гончарны җигеп, тарантасына утырып яннарына килеп туктый, басымнарны үзенчә каты куеп, катлы-катлы сүгенеп ала – тракторчылар да, кайчак, аныңча тырышып карыйлар, юк, атнакы, килеп чыкмый, болай Гарифҗан гына булдыра. Теге юлы да... теге юлы да... тозлы-борычлы сүзләре аркасында аздан гына партбилетыннан

колак какмады... Армалы авылының чәчүлек җиренә килеп туктаган иде, урыс тракторчылар исерек, эшкә тотынмаганнар. Үзенең дә тамак чылаткан чагы булгандыр инде, теле белән «кыйный» да башлады. Шул мәлдә әллә каян гына яннарында пәйда булган колхоз рәисе Фёдор Дмитриевич тавышгауганы туктатырга маташып өтәләнде:

– Гриша, успокойся, Гриша, успокойся...

Үзе дә сугыш кичеп, кулын имгәтеп кайткан фронтовик, Гарифҗанны тынычландырырга маташкан уңайга, машинадан төшкән ак күлмәкле, галстук таккан ят иргә уңайсызлангандай карап-карап та алды.

– Что это такое? Бөтенегез исерек! Кем монда старший? – Ак күлмәкле ирнең «гонор» белән шулай диюе Гарифҗанның горурлыгына тими калмады. «Мин, шуннан нәрсә?» – дия-дия, аңа таба атлады. Болай да йөрәк янган чак, көннең һәр минуты кадерле, тракторлар тик тора, чәчү тукталган, ә монда кемдер нәрсәдер ачыклап вакыт әрәм итмәкче...

– Коммунистмы син? – Таныш түгел ир-егет, Гарифҗан аның кем икәнен дә, чәчү барышы белән танышып йөргәнен дә белмәгән шикелле, Гарифҗанның эчендә ни кайнаганын белми иде.

– Коммунист!

– Мин синең партия билетыңны алам!

– Нәрсәәә? Мине партиягә син алмадың, пошшол вон...

Бетте, кырыйда болай да өтәләнеп торган Фёдор Дмитриевичның ярты җаны күккә ашты. Ул, Гарифҗанның контузиядән соң юньләп ишетеп бетермәгән колагына иелеп: «Гриша, ты чё? Бу бит Усманов, Гомәр Исмәгыйлевич, министрлар советы председателе», – дип пышылдаганда, чәчү өстендә «буталып» йөргәннәргә әйтергә теләгән бөтен әчкелтем сүзләр теш арасыннан чыгып очкан иде.

Ярый әле бу юлы җиңел котылды Гарифҗан. Алайса, йодрыгын эшкә җиксә, тагын таш капчыкка илтеп тыгарга да күп сорамаслар иде. Гомер булгач, анысын да күрде. Колхоз җыелышында районнан килгән вәкилләрнең әллә кем булып сөйләнеп утыруын сабыр гына тыңлап тора белмәде, «Ерунду не несите», – дип төзәтеп җибәрде. Бронь алып, сугышка бармый калган тәти егетләр авыл халкы өстеннән үзләрен патша итеп хис итәргә күнеккәннәр, әле генә япуннарны тукмап кайтып кергән Гарифҗанның исә аларны дөнья кендеге дип санарга исәбе юк. Җыелыш беткәч, ишек төбендә эләгешеп киткәннәр иде, ул Гарифҗанның вәкилгә берне «тартуы», тегесенең баскычтан тәгәрәп төшүе белән төгәлләнде.

Озаттылар. Алты ай Алабугада төрмә шулпасы чөмереп үтте. Алты ай буе Мөкәррәмә, күкрәк баласы гына булган Раузалияне күтәреп, Алабугага «передача» ташыды – бала белән булгач, кызгануларына, ире белән күрештерүләренә өмет бар иде. Бала кочып, егерме чакрымлап килә, егерме чакрымлап кайта да иртән тракторга утыра...

Ул чакта Гарифҗанның үзегенә үткәне ирексезлек кенә түгел иде... Алабугага илтеп куюны күршеләрендә яшәүче милиционерга йөкләделәр. Моңарчы дус булып, барын-югын уртак итеп яшәгән, гаиләсенә Гарифҗаннан кирәк чагында ярдәм тиеп торган күрше ире, винтовка күтәреп, җәяүләп, аны өтерменгә алып китте. Армалы тирәсендәге ялгыз нарат янына җиткәч, «Туктап бер тартып алыйм», – дип, ни сорады

Гарифҗан, тыңламады, «Әйдә, атлавыңны бел», – дия-дия, ашыктыра-кабаландыра юлын дәвам итте күрше... Менә шушы хәл бәгыренә тиеп калды Гарифҗанның, кешелексезлеккә җаны көйрәде.

Һәй, уйласаң уй инде, башын-азагын табармын, димә... Эштә үтте гомер, кул кушырып түгел. Иләмсез тракторлар көнгә ике-өч мәртәбә ватыла. Ремонттан соң кул белән кабызырга кирәк. Ир-егетләргә җиңелрәк, ә менә хатын-кызларның трактор бригадасында өчәүләп, бишәүләп ручкага бау бәйләп әйләндерәләр. Алар арасында Мөкәррәмә дә бар... Колхозы да бит, оештыру җыелышы 8 Март көнендә үткәнгә, «8 Март» колхозы дип атала... Ә колхоз дилбегәсе гомер буе ир-атлар кулында булды! Шулай булырга тиеш тә! Әле менә, коммунизмга барып җиткәнче, авылны теш-тырнагың белән сөйрәп барырга кирәк, егәр кирәк, көч кирәк! Барып та җитәрләр, тик... Гарифҗан күрә алмас шул ул көннәрне. Фронтта, батырлык өчен йөз граммны йота-йота, арыслан кебек көрәшергә өйрәткәннәр иде дә соң, ул гадәт татар ирләренә ияреп, татар авылларына да кайтып төште. Тик җелегеңне киптерә торган чиргә килеп олгашканда, алай итеп кенә көрәшә торган түгел икән... Күңеле сизә Гарифҗанның: китәр көн кул сузымында.

***

Шомырт чәчәгенең сурәте тәрәзә пыяласына күчкән. Юк, чәчәк түгел, иген башаклары икән. Тышта чатнама суык микәнни? Соңгы елларда кары да, яңгыры да, салкыны да тансыкка әверелеп бара... Башаклар бәйләм-бәйләм, мул күренә, ел әйбәт килер, игеннәр уңар, Алла боерса. Кышын, тәрәзәгә төшкән бизәкләргә карап, әтисе дә шулай ди торган иде...

Фәйзелханның өзек-өзек уйлары кырт бүленде: мендәр читендә яткан телефоны челтерәп тавыш бирде. Түбән Камадан, Геннадий Муллин икән, хәл белешеп шалтыратуы.

– Ничек, Фәйзелхан Гарифҗанович, алга табамы? – диде ул, аның да, Резиданың да хәл-әхвәлен сорашып.

– Китеп барырмын инде, Гена, – диде Фәйзелхан, тавышының йомшарып чыгуыннан кыенсынмыйча. – Алып китә бу чир мине. Озак интегеп ятарга гына язмасын инде.

– Бусы тагын нинди сүз? Үзең безне ничек дип өйрәтә идең, хәтерлә әле. Җиңүнең 50 проценты настройдан тора ди идең түгелме? – Фәйзелханнан көрәш серләренә өйрәнә башлаганда, әле яшүсмер генә булган Гена күптән инде Геннадий Николаевичка – үзе дә республикада исеме билгеле шәхескә әйләнгән, остаз һәм шәкерт арасындагы дуслык җебе беркайчан өзелмичә, бүгенгәчә сакланып калган иде. – Сине аякка бастырырга дип күпме кеше тырыша, врачлар йөгереп йөри, без монда көне-төне теләктә торабыз. Каян килгән паника ул?

– Ансы шулай... – Трубканың теге ягындагы тавыш ныгый төште. – Настройдан күп әйбер тора... Карале, Р. ничек анда, күренгәлиме, әйбәт кенә йөриме? – Фәйзелханның элек үзендә шөгыльләнгән егет турында сорашуы иде.

– Әйбәт, әйбәт, Фәйзелхан Гарифҗанович.

– Салмыймы хәзер?

– Юк, эшләре гөрләп бара!

– Менә, малай... Салуны ташлагач, ә!.. Мине дә «валлаһи, билләһи» дип алдап китә торган иде бит заманында... Син аны ташлама инде, Гена.

– Юк инде, аралашып торабыз, борчылма.

– Флүрне күрсәң... Аңа да сәлам әйт.

– Аның белән дә күрешеп торабыз, әйтермен.

– Ут иде, ә... Кара, синең ботинканы...

Трубканың теге ягында Геннадийның, шул вакыйганы искә төшереп, рәхәтләнеп көлгәне ишетелде. Ул чакта да Данил Галиев, Фәйзелхан үзе егетләрне Казанга ярышка алып барганнар иде. Күз ачкысыз буран чыгып, иске аэропортта кайталмыйча утырып калдылар, самолётларның кайчан очасы билгесез, тиз генә булмас, кичкә тынса гына инде, диләр. Вакытны ничек уздырырга белми йөдәп беткәч, Гена белән Флүр шәһәргә чыгып киттеләр. Геннадийның армия хезмәте Казанда үтте, еш кына үзәктәге «Военторг» кибетеннән штабка товар алып кайталар иде; дустын шуннан урап килергә күндерде. Сатучы кызлар аны онытмаган икән: якын туганнары килеп кергәнмени, сөенә-сөенә гәп куерткан шәйгә, үз кеше итеп кенә, кулына дефицитның дефициты булган, ялтырап торган, мех эчле, үкчәле кап-кара чех ботинкасы китереп тоттырдылар. Бәясе хутлы булса да, ботинкасы күзне кыздырырлык иде, дөньясында юк җирдән кулыңа килеп керсен дә... Моны бит көндез чыра яндырып эзләсәң дә, таба торган түгел! Кесәдәге бөтен акчаны-кырып себереп алса да – ярар, кич барыбер кайтып китәләр бит инде – егетнең күңеле мәтәлчек ата иде. Тик аэропортта эшләр хөрти булып чыкты, көрәшче егетләргә кичен дә очып китү тәтемәде, буранның тынарга исәбе юк иде.

– Егетләр, үзегезне үзегез кайгыртасыз инде, ашарга дип бирелгән талоннар бетте, – диде Фәйзелхан, икенче көнне дә аэропортның как эскәмиясендә төн үткәргәч, буранның һаман басылмавын күреп.

Кесәсендә сукыр бер тиен акчалары калмаган Гена белән Флүрнең кая да булса кереп тамак ялгарлык рәте юк иде. Икесе дә пошаманда, җитмәсә, иртәгә кичкә кызларның туган көненә чакырулы иделәр, барабыз дип вәгъдә биреп киттеләр. Бу буран мужыт атна буе дулар ул, ачка койрык чәнчеп монда ятсаң...

– Әйдә, синең ботинканы сатабыз! – диде Флүр, котылу чарасы тапканына куанып.

– Кит инде, андыйны бүтән мәңге таба торган түгел... – Хыялында бу ботинканы киеп, туган көн мәҗлесенә килеп кергән Геннадийның йөзе сүрәнләнде.

– Берне түгел, йөзне табарсың әле. Сатыйк дим! Башта туйганчы бер утырып ашыйбыз. Аннан вокзалга барып, поездга билет алабыз да әллүр Нижнекамскига. Самолётка ышаныч калмады, малай... Туган көн дә бар бит...

– Шулаен шулай да... – Ботинка кызганыч булса да, туган көн бар шул... – Кемгә сатам мин аны? Гомердә дә әйбер сатканым юк.

– Һи, шул да проблемамы?! Хәзер, шушында, аэропортта үзем момент сатып бирәм...

Ярар, язмаган мал булгандыр... Геннадийның моңсу күз карашы дустының култык астына кыстырылган чешский ботинканы озатып калуга күп тә үтмәде, кош тоткандай сөенеп борылып килгән Флүр аны тимер юл вокзалына алып китте.

Куян алданрак ычкынса, эт куып җитә алмый, ди, шуның шикелле, самолёт очмагач, поезд белән элдертергә теләүчеләр Гена белән Флүр генә түгел икән шул, бер генә билет та калмаган иде. Егетләрнең башка чарасы юк иде, беткән баш беткән дип, Чаллыга кузгалырга торган поездга «куян» булып кына сикерделәр. Бәхетләре бөтенләй үк юк түгел иде: плацкарт вагонның кырыенда, тар гына өске катта бер буш урын табылды. Алмаш-тилмәш йоклап алырбыз дип килешкәч, Гена менеп яткан гына иде, вагон буйлап билет тикшереп йөрүче контролёрлар пәйда булды. Чират Флүргә җиткәч, спектакль башланды. Эчкә борылып яткан Гена дустының да, контролёрның да йөзен күрми, тавышларын гына ишетә.

– Сезнең билет?

– Бар. Әнә, дус егеттә. Икебезнеке дә.

– Кая, уятыгыз.

– Юк, юк, юк, берүк уята гына күрмәгез. – Үтенүенә караганда, Флүрне идәнгә тезләнеп, кулларын үзбәк картыдай күкрәгенә кушырган дип күз алдына китерерлек. – Болай да көчкә йоклаттык үзен. Уянса, бетте баш, тагын дуларга тотынса...

– Но...

– Билет өчен борчылмагыз, икенче керүегезгә алам мин аны кесәсеннән... Түлке хәзер якын килмим... Ул уянсамы, ул уянсамы... бетте баш...

Ни хикмәт, билет тикшерүчеләр икенче тапкыр килеп борчып йөрмәделәр. Аның каравы, егетләр ничек итсәләр иттеләр – кызларның туган көненә вакытында кайтып керделәр. Ботинка саткан акча бүләккә дә бик җитә иде...

Соңыннан боларны кызык итеп, урыны белән су куша-куша, Фәйзелханга да сөйләгәннәр иде, күзеннән яшь тибеп чыкканчы рәхәтләнеп көлде ул, этиләре шикелле аркаларыннан каккалый-каккалый көлде. Фәйзелханның мондый халәте Геннадийны гаҗәпләндереп тә куйган иде. Күңел йомшаклыгын, нечкәлеген башкаларга беркайчан күрсәтергә тормый иде бит...

Гена кайчак аны үз этисе белән чагыштырып ала. Язмыш тез астына китереп суккач, тормыш йөге тулаем этисенең иңнәренә өелеп калган иде. Аны тол, сигез баланы гомерлек ятим итеп, кырык алты яшендә әниләре үлеп китте. Генага – унөч, төпчекләренә – тугыз яшь. Кышкы буранда, мәктәп яшендәге биш баланы ат чанасына утырта да укуга илтә Николай. Вакыт-вакыт балаларына борылып караганда, күзләрендә тирәннән-тирән сагыш дәрьясы, мөлдерәп тамарга торган яңгыр тамчысы шәйләнә. Шушы караш – әнисезлек кайтавазы – ир-атларның да йөрәге таш түгеллекне, аларның да йомшаклыгын күрсәтергә хакы барлыкны раслап, егетнең бәгыренә гомерлеккә уелып калды.

Ә менә тренерлары таш яуса да, кеше алдында күз яшен күрсәтүчеләрдән түгел. Көрәшче ир-егеткә алай килешми, дип санавы микән.

Бүген нишләптер тавышы йомшарган кебек тоела әле...

Фәйхелхан үз хәлен оныткан иде, сөенүе тавышына чыкты. Нишләтәсең, шәкертләрнең тормышы белән кызыксынып, аларны барлап тору электән канына сеңгән. Алар турында яхшы хәбәр ишетсә, куанып туялмый. Теге чакта, ялгыш юлга кереп киткән малайларны туры юлга бастырыр өчен күпме йөгерде. Язмышлары тапланмасын, тормышны чиста биттән башларга

мөмкинлек бирелсен өчен байтак кешеләрнең ишеген шакырга туры килде. Бая телгә алган егеткә дә ярдәме аз тимәде, хәзер дә, тормышының көйле эзгә салынганын белсә дә, барыбер борчылып, сорашып тора.

Телефонны куйгач та, сөенечле бер тойгы хәлсез генә елмаю булып, ирен читенә таралды. Күп танышлары аңа: «Син тормыштан ике-өч адым алдан барасың, алдан күрә, сиземли беләсең», – ди. Дөрес тә әйтәләрдер... Спортклубта малайларны: «Спорт хобби булырга тиеш, дөньяга күзегезне ачып карагыз, үз юлыгызны табыгыз», – дип өйрәтә торган иде. Аның сүзенә колак салганнар берсе дә төшеп калмады. Дөнья болганып, спортчыларның да, тренерларның да кирәге калмаган бер чорда, штанга белән гердән башка берни белмәгәннәр, берьяклы гына фикер йөрткәннәр упкын читенә килеп терәлгәндәй булды. Кулы эш белгән, киң карашлылар аягында басып тора белде. Әнә Геннадийны кара: Ключ Труда дигән авылдан күрше Шәңгәлче мәктәбенә кышын чаңгыда, язын-көзен җәяү йөреп чыныккан малай тугызынчыда ук Түбән Камага, спортклубка килеп шөгыльләнә иде, армиядән кайткач та ташламады. «Бәләкәй чакта, шәп атларда, кошовкаларда гына йөргән колхоз председателен күреп, йә председатель, йә кибет директоры булам дип хыяллана идем», – дип сөйләгәне булды. Хыялына омтылган кеше, үҗәтлеге җитсә, максатына ирешми калмый ул. Механик та булды, прораб та булды, хыялын тормышка ашырып, кибет директоры да булды. 33 ел буе нинди куәтле «Медтехника» холдингын җитәкли, генераль директор! Республикадагы бөтен клиника-больницаларны медицина җиһазы белән тәэмин итеп торалар! Каныңда көрәшче рухы булмаса, базар шартларында шул биеклектә басып калу ай-һай кыенга туры килер иде.

Хәер, көрәшче рухы булу белән генә түгел, ул рухның аек акыллы булуы да кирәк шул әле. Күр, дөньяларның асты-өсте килгән теге елларда никадәр асыл егетләр бер-бер артлы харап булды... Фәйзелханны да күпме кыстадылар: безнең көч белән шәһәрне дер селкетеп торачакбыз, торгашларга крыша булыйк, тегеләй-болай, дип өзми-куймый үгетләделәр. «Юк, егетләр, алай йә үтереп бетерәчәкләр, йә төрмәгә илтеп тыгачаклар», – диде Фәйзелхан, үз сүзеннән бер адым да артка чигенмәячәген кискен аңлатып. Дөрес әйткән булып чыкты, әле 65 яшьлек юбилеена кунакка килгәч, Габбас Әхмәдиев: «Заманында бик күп малайлар юкка чыкты, без Фазылның зирәклеге аркасында исән калдык», – дип, шул чакларны искә төшергән иде.

«Что ты, мой добрый конь, рано спотыкаешься»... – Бу җыр да әтисе «репертуарыннан» иде, әллә каян гына тел очына килеп, авыз эчендә көйгә салынды. Иртәдән бирле бимазалаган җырлар, аннан Шәфкатьнең «абый, көрәшергә кирәк» дигән сүзләре, Геннадийның «җиңүнең илле проценты настройдан тора» диюе, барысы бер җепкә тезелеп, күңелен күтәрергә итә инде әллә... Фәйзелханның эчендә чыннан да көрәшче «җене» кузгалырга маташа иде. Дусны көендереп, дошманны сөендереп, бил бирергә әзерләнеп ятуы иртәрәк түгел микән соң? Әле бит эшләнмәгән күпме эшләр бар. Европа вариантында ике олы ферманы салып бетерәсе... Белгечләргә дигән йортларны рәткә саласы... Атларның баш санын арттырып булмасмы... Татар булган җирдә ничек инде атлар утлап йөрмәсен... Яннарына килеп басасың, ялларын тузгытып, кырыеңнан үтеп киткән булалар; кырыкмыш тайлар уйнаклап йөри...

Кайчандыр әтисе Гарифҗанның: «Җир хуҗасы булырсың. Синең ишеләр дә кайгыртмаса, бу кырлар кем кулына калыр», – дигән сүзләре яшьлек белән бер колактан кереп, икенчесеннән чыгып киткән кебек иде дә, чыгып китмәгән икән. Буыннан буынга тапшырылган бер аманәт булып, күңел түренә язылган икән ул...

Нигә болай мәлҗерәп ята соң әле? Бүлнис түшәмен беренче тапкыр гына күргән кешедәй... Булды бит, «үләм икән» дип уйлаган көннәре булды. Әле ул чагында кырык яше генә тулган иде. Йөз дә утыз килограммлы авырлыгыннан сиксән килога калды: авыртуга чыдый алмыйча, идәндә тәгәрәп йөргән көннәре булды. Яшәргә кирәк дип, үз-үзен чәченнән йолкып чир авызыннан тартып алды. Алай гынамы... Сабан туенда түзмәде, көч-куәтен сынап карарга теләп, келәмгә чыкты. Түбән Камадагы иптәшләре, «әйдә, безгә терәк булырсың, әйткәләп, өйрәткәләп торырсың», дигән булып, күңелен күтәрергә теләп, үзләре белән Сарманның «Петровский» совхозы Сабан туена алып киткәннәр иде. Ничекләр читтә тамашачы булып кына торасың, йөрәк бар бит, дулавын тыеп булмаган йөрәк бар... Кем белә, бәлки җиңелеп тә куйган булыр иде... Көндәшләренең үзара сөйләшкәнен кемдер килеп колагына пышылдагач, эчендә арыслан кузгалгандай булды. «Иң опасный кеше бу, якын килеп көрәшмә моның белән», – дигән берсе. «Бумы? Чир бәргән, беткән бит инде», – дигән икенчесе. Шулаймы? Беткәнгә саныйсызмы?.. Карап карарбыз!.. «Беткән» дигән көндәше мизгелнең кай өлешендә чыбыркы урынына сузылып ятканын абайламый да калды.

Беренчелек өчен көрәштә Чаллы батыры, атаклы «Копчёный» – Рәкыйп Хәмитов белән кара-каршы калып, бер-берсенең биленә сөлге салдылар. Фәйзелхан аның елмайган күзләренә бер генә сынап карады: йә, син дә мине беткән, йөзләре саргайган, көчсезләнгән дип уйлыйсыңмы?.. Не дождётесь!.. Рәкыйп белән келәмдә беренче тапкыр очрашуы түгел. Чаллының, республиканың ничә тапкыр баш батыры булып калган данлыклы көрәшче! Вагон урынына гына сөйрәп китерә алдына, тегеләй китереп «сындыра», болай китереп«сындыра». Шешә авызыннан атылган бөке шикелле атылып очканыңны сизмәвең дә бар... Тәүге тапкыр икәүләп Казанның Идел буе районы Сабан туенда көрәшкәннәр иде. Ул чакта әле «Копчёный»ның ничегрәк эш иткәнен белү юк... Сыбызгы тавышы ишетелүгә, һәркем үз «тотуын» алмакчы булды. Рәкыйп физик яктан көчлерәк, ныграк каера, үзенә сөйрәп ала, Фәйзелханны янга егып та куйды, балл алды. Яңадан тотынышып көрәшкәндә, тагын бер балл яулады. Классик көрәштә туры элэктереп атарга гадәтләнгән Фәйзелхан, ни булса шул булыр, «ва-банк»ка барам дип, аның каршысына туп-туры килеп басты. Көндәше өчен көтелмәгәнрәк булдымы, якыннан тоткач, шома эләктерәсен чамалап бетермәдеме, үзен егып куйганны абайламый калды, вакыт бетеп килгәндә, бу юлы Фәйзелхан балл алды. Икегә бер исәбе белән җиңелгәндә, ул үз хаталарын да, көндәшенекен дә кыл иләктән иләргә өлгергән иде.

Икенче юлы очрашканда, шул хаталарны кабат искә төшерде: монда якыннан басу кирәк, алай көндәшенең сизгерлеге кими... Шул уй белән аны уңгарак тартты. Көндәшенең сулга тайпыласына өмет иткән иде, шулай булып чыкты да. Үзенең үк «сикерү көче» белән очырды аны Фәйзелхан.

Бүләккә бирелгән тайны һәм «Таврия» машинасын алып кайтып

барганда, Фәйзелхан аны гына түгел, чирне дә, үзен дә җиңгәнне төшенгән иде.

Дөрес әйтәләр. Әле йөрәгендә яшәү көче беткәнгә охшамаган. Димәк, көрәшергә кирәк. Көрәшергә һәм җиңәргә!

***

Казан юлыннан борылып, Мортка таба юл тоткач кына, Шәфкатьнең күңеле бераз тынычлана төште. Аңынчы юл буе абыйсының бүгенге сүзләре кайтаваз шикелле колагында чыңлап, күңелен сызлатып йөдәткән иде. Авырып ятканда, күңел төшенкелегеннән дә яманрак нәрсә юк, абыйсын андый халәттә күрү пошаманга төшергән иде.

Мәмет буасы аша салынган күперне узуга, йомшак кына, басынкы гына итеп кар иңә башлады. Әйтерсең, авыл аны үзенең ак җаны белән каршылый; авыл хуҗалыгының яңа базасы ягыннан, борынны кытыклап, әле генә пешеп чыккан икмәк исе аңкый. Шәфкать түзмәде, өйдән урап килергә дигән ниятеннән кире кайтып, машинасын сулга борды, челтәрле зур капка каршына килеп туктады. Аны гына көтеп торгандай, капкадан Фәйзелханның кияве Айрат килеп чыкты. Мондагы база аның өстендә, биредә кышын беркадәр тынычрак тоелса да, язгы кыр эшләренә әзерлек башланса, тынгы күрермен, димә. Ашлык чистарту, киптерү складлары, тегермән, икмәк пешерү зонасы, ишегалдын тутырып торган техника, дисеңме – барысына да күз-колак кирәк.

– Ничек, тәртипме? – дип сорап куйды Шәфкать, кар сырган трактор-машиналарны күз карашы белән генә айкап.

– Тәртип, – диде Айрат, гадәтенчә, тыныч кына итеп. Дөньяга коронавирус афәте тарала башлаганнан бирле, кул сузып исәнләшү гадәте башка төсмердә иде – ирләр йодрыкка йодрык тигереп алдылар. – Анда ничек, больницада?

– Икәүләп матур гына яталар.

Аларның бу авыруны барыбер җиңеп, авылга үз аякларында кайтып төшәчәгенә ышана иде Шәфкать, үзе дә өметсезлеккә бирелергә, башкаларны да куркытырга җыенмады. Хәер, өметсезлеккә бирелеп, кул кушырып утырырга җае да юк, агрофирманың җаваплылыгы аның иңнәрендә. Кыек-мыек җире генә килеп чыксын, терелеп кайтуга, абыйсы утлы табада биетәчәк...

Машинасын кабызып, авыл урамына юл тотканда, багана башындагы утлар кабынды. Ут яктысында кар бөртекләренең вальс әйләнә-әйләнә салмак бөтерелгәнен күреп, Шәфкатьнең кәефе күтәрелеп китте, кайчандыр үзенең дә бии-бии Казанга тиклем барып җиткәнен, бәйгеләрдә катнашып йөргән елларын күзаллап, үзалдына елмайды. Тормыш һәркем өчен үзе дә тоташ биюдән тора түгелме соң? Әле табаның кызганчы тыпырдыйсың, әле шушы җем-җем кар бөртекләредәй, иркәләнеп кенә әйләнеп аласың; кайчак, колагыңа шәрык көйләре ишетелгәндәй, тәнеңнең, җаныңның һәр күзәнәгеннән дер селкетеп куясың; тау бөркетедәй, канатларыңны киереп, кыя-тауның күзенә карап томырыласың... Туктап тын алырга җай эләккән мәлләрдә дә уй дәрьясы өстенә басып биергә мәҗбүр итә тормыш. Абыйсы да шулай уй чоңгылында бәргәләнеп ята булса кирәк.

Аның бөтен нәселне тартып баручы икәнен тану Шәфкатьнең күңелен тагын да нечкәртеп җибәрде. Бәкер очына, капка төпләренә кайтып җиткәч, машинасын сүндерергә ашыкмады, ут балкыган тәрәзләргә текәлеп, кабинада утыра бирде. Күз алдына кайчандыр шушы капка төбеннән, туган йорт нигезеннән, абыйсының киңәшенә таянып, Казанга, медицина институтына имтихан бирергә дип чыгып киткән мәле килеп басты. Фәйзелхан да Казанда ярышта иде ул көнне, имтиханың беткәч, Яшьләр үзәгенә килерсең, мин шунда булырмын, дип озатып калды. Шәфкать көнозын институтта йөреп, физикадан имтихан тапшырып килгәндә, бер төркем көрәшче дуслары белән өстәл янында чәйләп утырган абыйсы аның йөзенә чыккан кәефсезлекне тиз чамалады, бер сорау да бирмәде, энесен табын янына утыртып, алдына ризык тезде. Бераздан түзмәде, колагына иелеп кенә:

– Ничек, бирәлдеңме соң? – дип сорады.

– Бирдем, – диде Шәфкать, исе китми генә.

– Ничәле? – Сорау сагаюлы иде.

– «Биш»ле. – Җавап «башкача ничек булсын» рәвешендәрәк яңгырады.

Сөенеченнән сикереп торган абыйсы «ур-ра» кычкырып җибәрде, Шәфкатьнең җилкәсен каккалады:

– Соң, нигә аны башта ук әйтми торасың? Мин сине бирәлмәгән дип торам, чыраең-мазарың юк.

– Көн буе йөреп тамак ачты, чырай кайгысы юк...

Үзе имтихан биргәндәй куанган Фәйзелханның ур-ра кычкырганын бөтен дуслары күтәреп алды.

Ныклап уйласаң, әтиләре Гарифҗан вафат булганнан соң, гаиләнең бөтен йөк-мәшәкатен абыйлары үз җилкәсенә салган лабаса. Раузалиянең ире Әсләм бик яшьли йөрәк белән китеп барганнан соң аның өчен дә терәк булды, Түбән Камага, үз янына чакырды. Әниләре Мөкәррәмә авырып китә калса, аның өчен күгәрчен сөтен дә табарга әзер иде. Шәрифҗан абыйсының үлеменә инде беркадәр вакыт узса да, әле һаман шул чынбарлык белән килешә алмый тинтери. Ә Шәфкатьнең үзен соң... Авылга, ата нигезенә кайтару өчен бер генә җөмләсе җитте: «Кайт, колхоз бетә, авыл бетә бит!» – диде абыйсы. Алабугада стоматолог булып эшләгән җиреннән, күтәрәмгә калып барган колхозга рәис булып кайтты Шәфкать. Әтиләре хыялланган коммунизмга барып җитәлмәгән иде авыл, тез чүккән, тәмам бетәшкән иде. Аны аякка бастырырга, кешеләрне эшле, ашлы итәргә теләп, үзе оештырган агрофирманың кирәк-ярагы артыннан ярты саулыгын бетереп чапкан абыйсын аңлаучылар да, ярдәм кулы сузучылар да, авырлыкны бүлешергә әзер торучылар да, «алпавыт» дип, канына тоз салучылар да җитәрлек иде. Ныклы терәкне барыбер кан туганнарында күргәндер, юкса, инде авыл дилбегәсен сыйныфташы Фәиз Закировка тапшырган, башта Морт участок хастаханәсендә, аннан Алабуга район үзәк хастаханәсендә баш табиб булып эшләгән Шәфкатьне, «сәламәтлек какшады, хуҗалыкны үз кулыңа ал», дип, агрофирмага директор итеп чакырмас иде ул. «Авылны яшәтергә иде» дигән уе булмаса, Түбән Камада менә дигән эшләре, фатирлары булган килеш, кызы Фидания белән кияве Айратны, оныкларын Мортка кайтарып утыртмас иде. Финанс институтын бетергән кызы да, химия-технология

институтын бетергән кияве дә агрофирманың эшләрен алып барганда, зур таяныч булып тора үзенә.

Шәфкать, уйларыннан арынып, машинасыннан төште дә, ишегалдына керүгә, беренче эш итеп, мал абзарына үтте. Гадәтенә сеңгән инде, эштән кайтышка, элек-электән аяклары шунда юл ала иде. Аның үгез асравына кайберәүләр: «Нигә кирәк ул, акча җитмимени сиңа?» – дип аптырый иде. Анысы җитә, акча да җитә, ит тә җитә. Хикмәт анда түгел. Өйдә ике малай үстер дә мал асрама, имеш. Авыл баласын эш тә тәрбияләмәсә, ничек була инде ул... Абзар чистартылган, мал асты алынган икән, димәк, җиң сызганып селкенгәннәр. Юк икән... Андый чакта, өйгә керүгә Шәфкать, уллары Адель белән Маратның күзенә туп-туры карап:

– Сез бүген кайда йөрдегез? – дип кенә сорап куя.

– Әти, әле кайттың гына бит, каян белдең? – дип аптырауга төшә малайлар. Иренең гадәтен белгән Рузиләнең күзләренә елмаю йөгерә...

Авыл урамыннан, кышкы кичнең яңа яуган карын шыгырдатып, кечкенә генә төркем булып, яшь-җилкенчәк үтеп бара иде. Аларның бар гамьне онытып шаркылдавыннан битлек кигән бүгенге дөнья берчә сискәнеп, берчә яктырып киткәндәй тоелды. Шулай, Фәйзелхан абыйсы хак әйтә: авылның җан тамыры өзелмәсен дисәң, яшьләр кирәк шул, яшьләр, аларның күлне күккә асар елгырлыгы кирәк...

***

Салулады, кәлиядән чыкты, әллә нинди эзгә керде дөнья. Чир йоктырмыйм дип, авыз-борыныңны томалап, көнозын битлектә йөрсәң дә, котылып калышлы булмады әле бу... Моңарчы күренми торган катлы-катлы битлек киеп яшәгәннәргә өсте-өстенә йөзне каплау тагын да кыенрактыр...

Көндезге эчпошыргыч халәт сәгать уклары кичкә кереп барганда, отыры көчәя төште. Бая утны кабызып чыгып киткәннәр иде, шулай да ул пыскып янган тычкан утыдай гына тоела, өскә ябылган ак җәймәне пыр тузып болгап атасы да дөбердәп аякка басасы, кайда нинди лампочка бар – барысына-барысына ут элдерәсе, дөньяны яктыртасы килә иде.

Ә менә сулыш алу бераз җиңеләйгән шикелле. Гүя күкрәкне сытып торган ташны кемдер аз гына күтәргән дә бармак чите белән генә эләктереп тора.

Кара, акыллы кеше белән сүзсез генә сөйләшү дә рәхәт икән үзе... Фәйзелхан, нишләргә дигән сорауга җавап эзләп, байтактан үз-үзе белән гәп куертып ята иде. Көрәшергә, көрәшкәч җиңәргә кирәклеген бик яхшы аңлый да соң, тик һаман шул бер балык башы: ул тиклем көчне каян алырга... Теге вакытта, үлем белән тартышып яткан авылны коткарырга алынганда, җиңелрәк булган: аның ялантәпиле балачак эзләрен саклаган туган туфрак үзе көч биргән. Туфрак кына микән? Бәлки... бәлки... аны җир хуҗасы итеп күрергә хыялланган әтисе Гарифҗанның рухы да таяныч булгандыр?

Ә бит Түбән Камада аяк тибеп яшәр мөмкинлеге бар иде. Көрәшче буларак дан яуланган, Сабан туйларында бүләккә тигән машиналар кайберәүләрнең төшенә дә керми. Базар мөнәсәбәтләре башланганда, дөньяның кай якка тәгәрәгәнен бик тиз абайлап, үз вакытында товарны акчага, акчаны товарга алыштырып өлгергән, бизнесы гөрләп бара. Машина кую урыннары, гараж кооперативлары, сату нокталары...

Кайчандыр вельвет якалы пәлтә кидертеп, яшь егетне авылдан алып киткән сукмаклар ир уртасы Фәйзелханны авылга алып кайтты. «Фидан» дип аталган крестьян-фермер хуҗалыгыннан башлап, Алабуга районында гына түгел, Татарстанда үз урынын яулаячак куәтле «Морт» агрофирмасына әверелгәнче, байтак сикәлтәле юлларны узарга туры килде. Канатын сындырган, борынын канаткан чаклар да булмый калмагандыр, тик авырлыкларның барысын җиңәргә күнеккән көрәшчене алар гына туктата алыр идеме...

Ул елларны исеңә төшер әле, Фәйзелхан. Банкротлыкка чыккан авыл хуҗасызлыктан күз алдында таркалып ята иде. Колхозның бар булган байлыгы гүя дию пәрие сыбызгысыннан юкка чыккан... Элек, Совет власте төзелгән елларда, кешенең үз көче, тырышлыгы, акылы белән эшләп тапкан бар малын – йортын, җирен, кибетен, заводын, фабрикасын канъяшь түктереп тартып алганнан соң, халык байлыгы итәбез, уртак итәбез дигәннең бумеранг булып ил өстенә кайтып төшүе бу. Ваучер, приватизация дигән сүзләрнең телгә үз булып килгән чагы...

Фермерлыкка тотынгач та, иң беренче эш итеп, салына башлаган йортың янына унсигез көн эчендә склад төзеп куйдың: урып-җыю чоры җитә, ашлыкны урнаштырырга каплаулы урын кирәк иде. Әллә кайчан алынган тегермән Түбән Камада җиде-сигез ел үз сәгатен көтеп тик яткан икән, аны кайтарып, беренче, икенче сортлы он чыгара башладыгыз. Сенаж базларында ким дигәндә бер еллык азык запасы булырга тиеш дип, ул тирәне рәткә китерергә ниятләдең. Кредит алуның упкын системасы икәнен белә идең, шуңа да үзең нәрсәнедер сатып, нидер алуны хуп күрдең, Сабан туе бүләге булган «УАЗ»ик машинасын тракторга алыштырдың, тәмам финансистка әверелдең ул чорда. Техниканы арендага алып акча түкмәдең, лизингка биш «МТЗ», ике «ДТ» тракторы, өч «Дон» комбайны кайтардың. Сыерларның күбесендә лейкоз авыруы иде – баш санын киметүдән курыкмыйча, туксан җиде сыердан нибары утыз сыер калдырдың.

Директор булып, ак күлмәк киеп, галстук тагып йөргәнеңне хәтерләмисеңдер дә. «Галстук таксам, буылам мин», – дисең бит. Өстеңә спорт костюмы киеп, ферма тирәләреннән урап кайтудан, берәрсенең техникасы ватылса, янына барып булышудан җан рәхәтлеге аласың түгелме?

Иң беренчеләрдән булып егылган авыл иң беренче булып аякка да басты. Хәзер, күр, эшлим дигән кешегә күпме эш урыны! Яшим дип кайткан белгечкә, рәхим ит, фатир ачкычы! Буш торган йортларны сатып ала да, гөл итеп рәтләтеп бирә Фәйзелхан абыегыз. Ноль процент ипотека белән, үз бәясенә бер тиен өстәмичә!.. Ат, сыер, бозау фермаларында хәзер элекке шикелле резин итек киеп, авыр бидонны кул белән күтәреп йөри торган түгел – ялтырап тора, бөтен нәрсә техникага көйләнгән. Әнә, тагын дүрт йөз сыерга дип, өр-яңа ике ферма төзелеп килә. Комбайннар, тракторлар – чит илнеке, эчендә рәхәтләнеп ак якалы күлмәк киеп утыр – климат-контроль анда, тузанга батасың юк. Машиналарга, КамАЗларга ягулык кирәксә, заправка төзелгән. Ашлык киптерү, ашлык чистарту корылмалары, чәчү комплекслары – ялт иткән. Биш мең гектар җирдә үзебез үстергән ашлыктан үзебез он тартабыз, ипи пешерәбез. Үзебез чәчкән кукуруз, люцерна малларга кышкы азыкка җитә. Мөселманча мал сую цехы да бар,

дүрт тонна ит сыйдырырлык суыткычлар да шунда; хәләл ит кирәк дисәң, алдан әйтеп кенә куй... Ял итәм дисәң, буаны менә дигән итеп эшләттек, кармагыңны күтәреп төш тә, карп, сазан, алабуга каптыр...

Уйларында авылның һәр почмагын, урамын урап, эшләнгән эшләрне барлап ята торгач, Фәйзелханның борынына яңа пешкән ипекәйнең хуш исе килеп бәрелгәндәй булды. Монысы ышанырлык түгел иде, чөнки вирус зәхмәте ис тоюны күптән оныттырды. Тик каяндыр өсте кояш төсенә кереп кызарып, күпереп пешкән, чит-читләре кетердәп торган ипи исе килә бит! Авыз тәме югалуны да оныттырып, тәмле булып килә! Киң йөзле пычакны алып, кибән башын каерып кисәсе иде дә, кәрәзләнеп торган телемгә, кетер-кетер китереп, тешләрне батырасы иде! Шуны күзаллагач, балачактагы кебек, әнисе мич куенынннан алып, мендәр яки кызыл башлы сөлге өстенә каплатып тезгән ипекәйләрнең суына төшкәнен сабырсызланып көткәндәгечә, ирнең авыз сулары килде. Яңа пешкән ипи телеменә өйдә язган май сылап, өстенә писүк тә сибеп җибәрсәңме... Шушы телем кулыңа килеп кергәнче, күпме кешенең маңгай тире түгелгәнне, кул көче кергәнне малай гына Фәйзелхан ул чакта каян белсен, әтисенең «туган туфрак, туган җир» дигән сүзләренең мәгънәсен кайлардан төшенсен... Менә хәзер аңлый, әтисенең улларын авылга кайтарам дип, сүзсез өзгәләнүен дә аңлый. Туганнарының, уенын-чынын кушып: «Әти сине күбрәк ярата иде ул, син бит аңа охшагансың, шуңадыр инде», – диюләрен дә аңлый. Әтисе белән икесе арасында гомер буе күзгә күренмәгән җепләр булганлыгын да аңлый. Яши-яши, әтисезлек белән тулы буш еллар аңлатты аны. Нибары алтмыш дүрт яшь иде бит әтисенә, нибары алтмыш дүрт... Аның шулай бик иртә китеп баруы кырыс чынбарлыкның гади дә, гали дә фәлсәфәсен тизрәк төшендерергә теләү булганмы? – Күпме генә йөгерсәң дә, бу дөньяны куып тота торган түгел; үзеңне генә кайгыртып яшәүнең бәһасе сукыр бер тиен. Адәм баласы сабый бала булып туганда, дөньяны менә шулай учлап тотармын дип өметләнеп, йодрыгын йомарлап туа. Мәңгелеккә киткәндә, ике буш учын җәеп, хакыйкатьне аңлатып китеп бара... Әтисе дә шулай дип китте. Бәгырьгә кан саудырып, иртә китте. Менә хәзер Фәйзелхан үзе җиденче дистәсен түгәрәкләп килә, әле дөбердәтеп яшәр чак тоела. Һәр мизгелнең кадерен белеп яшәр чак. Кулыңнан килгән кадәр савап эшләп калдырыр чак.

***

Аръякка, Мөкәррәмә чишмәсенә төбәлеп торган Фәйзелханның карашы бер ноктада берегеп калды.

Кайбер авыллар чите чатнаган бәллүр касә шикеллерәк: бәхете китек була. Җир күкрәгеннән чишмәсе бәреп тормаса, андый авылны ничекләр бәхетле дип әйтәсең... Морт туфрагын бәрәкәтле яралткан Аллаһы Тәгалә: кай җирдә аяк басма – чишмә тибеп чыга. Акай тау итәгендәге, Мәмет, Бурсык, Морт, Киленбиегән елгаларының ике ярындагы чишмәләрне генә күр, учларыңа җыеп, зәмзәм суыдай шифасын тоеп кына эчмәле...

Кайчан гына, шушы урында басып торганда, «Менә монда басма салып куйсаң, хатын-кыз керт-керт кенә басып, аръяктагы чишмәгә йөрер иде дә соң, эш дип чабып, һаман кул җитми тора бит», – дип, үзен битәрләгән

иде. Җәй башы иде ул, яр астында гына ниндидер тавыш ишетеп, якынрак килеп карагач, авыл аксакалы Тимерхан агайны күреп алды.

– Ни җимерүең, Тимерхан абзый? – дип исәнләште Фәйзелхан, аның бөкрәя төшеп нидер эшләвенә игътибар итеп.

– Менә дигән чишмә, әрәм ята. Кондызлар еккан агачларны юнып, чистартып куйыйм, мин әйтәм. Басма салсаң, йөрүчесе дә табылыр ие. – Агайның кулында балта-пычкысы ялтырап китте.

– Тимерхан абзый, икебез бер уйда икән. Берүзеңә авырга туры килер, мин сиңа ярдәмчеләр дә җибәрәм, тактасын-кадагын да китерәм. Шәп кенә итеп эшләп куйыйк әле шушы чишмәне.

– Һии, тотынсаң, курчак өе кебек итәргә була.

– Алабуганың Шайтан каласы кебек эшләтсәк? – Фәйзелхан башына килгән уйдан сөенечле елмайды. Нинди эшкә тотынса да, рәссам күзе белән карау канында бар инде, нишләтәсең. Булдымы-булды итеп түгел, үзенчәлекле, сыйфатлы, затлы итеп эшлисе килә!..

«Мөкәррәмә чишмәсе» булачак ул. Әнисе шикелле, бер генә минутка да тынгы белми торган чишмәгә газиз кешесенең исемен кушыйк дисә, авылдашлар каршы килмәс. Әни бит ул! Җиде кат күк катыннан «пүтсез малаеның» һәр гамәлен карап-барлап торучы, кайчагында ак күбәләк булып бакчадагы чия куагы, умарталар тирәсендә бөтерелүче, таң җиленә әверелеп, тәрәзәгә сарылучы әни бит ул! Җирдә яшәгәндә, намазлыгына сәҗдәгә иелгән саен балаларына да, үзенә дә ике дөнья җәннәте сорап дога кылган әни бит ул! Мәңге яшәтергә теләсәң дә, көннәрдән бер көнне бөтенләйгә калдырып киткән әни бит ул!.. Яшәтәсе килә, бик килә иде, алты тапкыр инсульт булганда, кулдан килердәйне-килмәстәйне эшләп алып калдылар әниләрен, җиденче тапкырында Мөкәррәмә күзен йомды. Күпме генә сузарга тырышсаң да, гомер чиксез түгел иде...

Иске фермалар ягындагы су башнясын да төзекләндерәсе бар иде, анысын да Шайтан каласы кебегрәк эшләтергә ниятләде Фәйзелхан. Астына табигый таш түшәп, һәйбәтләп эшләп куйсаң, гасырларга җитәчәк әле ул...

Тимерне кызуында сугып, алтын куллы егетләргә эш кушып кына өлгерделәр – чишмә дә, су башнясы да тарихи ядкарьләрдән һич ким булмыйча балкып утыралар иде. «Гали Хөсәене белән Гали Хәсәне эшләде, Чандыр Вәли Рамиле түбәсен япты», дип, башняга беркетелгән тактага язарга да онытмадылар. Кайсы Хәсән дип баш ватканчы, болай, ичмаса, күз төшерүгә, олысы-кечесе аңларлык...

Аның кулы җиңел булдымы, Мортның булдыклы егетләре Нурулла уллары Назимулла белән Разим авыл уртасындагы Балавыз чишмәсен төзекләндерергә тотынганнар иде. Күз явын алмалы булып утыра хәзер, халык су алырга гына түгел, рәхәтләнеп ял итәргә дә шунда килә.

Гәзитне ачсаң, тоталар да «хәзер чын ир-атлар калмады» дип, чаң сугалар. Нишләп булмасын, бар алар, бүтән җирдә тапмасагыз, әнә Мортка килеп эзләгез. Рөстәм Шиһапов нинди матур мәчет төзетеп куйды, менә сезгә бер мисал. Узган гасыр башыннан калган ике катлы иске мәчет совет чорында ниләр генә күрмәде. Яңасына бәхетле язмыш язсын берүк. Шунда йөри-йөри, Хәйдәр абыйның вәгазьләренә колак сала-сала, иплән кенә намаз-кыямына да өйрәнеп килгән чак... Сугышта һәлак булганнар һәм

тыл ветераннары истәлегенә куелган стеланы күрегез – 1970 елда ачылып, соңыннан халыктан җыелган үзара салым хисабына төзекләндерелде ул, аның авторы – авылның аксакалы, Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Расих Хисаметдинов. Асыл җегетләр турында Фәйзелхан абыегыз әйтеп бетермәсә, авыл башлыгы Фәиз Закировтан сорарсыз. Авылның бөтен кешесен биш бармагы шикелле ул белә.

Ахырзаманда, кемне уйласаң, шул алдыңа килер ди – Фәйзелхан үз янына Фәизнең машинасы туктаганны абайламый да калган икән.

– Фәйзелхан абый, тагын бирәр идея белән минем башымны катырырга җыенасың микән?.. – Шаярып әйтсә дә, Фәиз аның еракка төбәлгән уйлы карашыннан ук сизеп алды: тәгаен бер-бер план белән янарга тотынган... Шулай булып чыкты да.

– Слушай... – Фәйзелхан башын авыл уртасына борды. – Гает намазына халык клубка җыела бит.

– Шунда инде, мәчеткә генә сыеп булмый. – Фәиз башындагы кепкасын арткарак шуыштырды.

– Корбан ашлары да шунда үтә.

– Шунда, шунда... Хореография залы да шунда. – Фәйзелханның тел төбенә төшенмичә, монысын да өстәп куйды Фәиз.

– Беләм инде... «Көзгеләр кирәк», дип килгәннәр иде, алдык, ясадык.

– Башта миннән сораганнар иде. «Фәйзелхан абыйдан сорап карагыз әле, бик күп кешегә ярдәме тия, сезгә дә булышмас микән», дип, сиңа җибәрдем.

– Вәт төлке... Бер дә җиңел түгел синең белән эшләве.

– Анысы, син үзең дә хәйран җайсыз кеше инде, Фәйзелхан абый... Шаяртам инде. Давай, сузма, тагын ни майтарырга җыенасың?

Берара тынлыктан соң гына Фәйзелхан күңелендә күптән йөрткән, инде менә тәмам аркылыга-буйга уйланган ниятен ачып салды.

– Мәчеткә тоташтырып, спорткомплекс эшләргә исәп. Малайларга көрәш түгәрәге ачып җибәрербез. Тренер табарбыз.

– Аңа зарплата... – Фәизнең соравы ярты юлда калды.

– Анысы синең проблема түгел. Өйрәтсен генә – түлим... Зур итеп эшләргә исәп. Гает намазына халык шунда килер. Корбан ашларын да шунда уздырырбыз, аш бүлмәсе дә көйләрбез. Иркен итеп, кеше сыярлык итеп эшләргә кирәк. Клуб залын карадым мин...

– Әйтәм аны шунда кергән саен бер сүз эндәшми генә идәнен-түшәмен күзең белән үлчәп чыгып китә идең. Аптырый идем аны. – Бу юлы баш чүмечендәге кепка Фәизнең учына кереп йомарланды. Була икән хәлләр, тагын бөтен кешене биетә башлый икән Фәйзелхан... Ниятләгән икән – таш яуса да эшләячәк. – Түлке... нигә үз өстеңә үзең мәшәкать эзләп йөрисең икән син, ә?

– Савап булыр... Бу заманның ыбыр-чыбыры да өйрәнсен татар көрәшенә. Морт малайлары алар!.. Мичкә керсәләр артларыннан таныйрлык булсын! Каенлысы, Имәнлесе, Чишмәлесе бөтен районда бар, Морт дигән бүтән авыл юк Татарстанда, безнекеләр икәнне әллә каян белерлек булсын!

– Үтерәсең син, Фәйзелхан абый... – Андагы горурлыкның йөзендә ялкын булып уйнаганын күреп, бу зур эшләрнең бик тиздән башланып та китәсен аңлады Фәиз. Таякның иң авыр башы Фәйзелханның үз җилкәсенә төшсә дә, башкаларга да читтән генә карап торырга туры килмәячәк иде.

Авылның исеме дә, галимнәрнең язганына ышансаң, кайда «умарта», кайда «кеше» дигәнне аңлата бит. Бал кортыдай тынгы белми торган кешеләр дисәң, дөресрәктер дә әле... Икенче берәүләр мортны галәмдә үз урынын табалмаган дәрвиш дип тә атый. Имеш, аларның һәркайсы дошманнарына куркусыз, үз кешеләренә бик таләпчән. Буйлары зур түгел, әмма таза, ныклар, сугыш чукмарлары икән: һәр нәрсәне бары сугышып кына хәл итеп була дип ышанганнар... Ялгызлык яраткан, үз эченә бикләнгән кешеләрне дә мортлар дип атаганнар, алар яшьтән үк бары үз көчләренә генә ышанган, ди...

Авылның нәсел башында торучыларның берсе, Бигәй батырны тирә-якта бер көрәшче булган, диләр, аңа каршы чыгарга берәүнең дә батырлыгы җитмәгән. Кызык итепме, имеш, бер татар бае, күп җирләрен һәм кызын бирергә вәгъдә биреп, бер урысны Бигәй батыр белән бил алышырга күндергән. Үз исеменә тап төшерәме соң инде Морт батыры? Егып салган көндәшен. Тегесе шул хурлыкны кичерә алмаган, Чулман елгасын аркылыга йөзеп чыкканда, көймә белән килеп, Бигәй батырны батырып үтергән, диләр.

Көрәшчеләр чылбыры өзелсә, бабайлар рухы гафу итмәс дип уйлавы микән Фәйзелханның? – Машинасын кабызып кузгалып киткәндә, Фәизнең башыннан шулар йөгереп узды.

«Җайсыз кеше» диме Фәиз? – Аның артыннан уң кулын йодрыклап, өскә чөеп саубуллашып калган Фәйзелхан кинәнеп елмайды. Бүтәннәрнең шулай дип ачуланып әйтүләре түгел, үзләренчә төрттерүләре инде. Бер-бер эшкә тотынганда, киңәш-табыш иткәндә, башкаларның фикерен яхшырак, саллырак дип таба икән, үз туксанын туксан иткәне юк Фәйзелханның, киресенчә, сөенеп ризалаша. Дөрес түгел дип таба икән, бөтен кеше шимбә дип кычкырганда, берүзе җомга дия торган гадәте бар, бүген килеп кенә үзгәртә торган түгел. Бервакыт район башлыгы аны үзенә урынбасар булып эшкә килергә чакырды, кырт кисте Фәйзелхан. «Мин бит кеше кушканны гына үтәп йөри торган түгел. Үз фикерем бар икән – әйтми тормыйм. Сез минем белән өч көн дә эшли алмаячаксыз», – диде ул боргаланмый гына. Районда-мазар җыелышта утырса да, кайберәүләр шикелле «әйе шул» дип, баш селкеп кенә торуны белми, телен тешләп калмый.

Бер елны, республиканың авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре киңәшмәсендә, халыкны ничек авылга кайтарырга дигән сорау күтәрелде. Фәйзелханның сүзе кыска иде:

– Өй бирергә, эш бирергә, зарплатаны шәһәрдәгедән артыграк түләргә кирәк. Аны бирер өчен керем күп булырга тиеш. Яңа техника кирәк, төзелешләр кирәк.

Киңәшмәдә авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Готыф улы Әхмәтов үзе дә катнаша иде, эшләгән кешенең дә, эшлекле сүзнең дә кадерен белә торган акыллы җитәкче, Фәйзелханның хөрмәте зур аңа.

– Марат Готович, минем шундый тәкъдимем бар. Менә безнең авылда тузган торак программасы белән төзелгән буш йортлар тора. Әгәр шуларны сатып алып, рәтләп, газын-суын үткәреп, эшкә килгән авыл хуҗалыгы белгечләренә ноль процент ипотека белән бирү җае табылса, агрономын да, инженерын да авылга кайтарып булыр иде, – диде Фәйзелхан, бу проектны ничегрәк күзаллавын тәфсилләбрәк аңлатып.

– Бер каршылык та юк. Хуплыйм гына, – диде министр, аның фикерен куәтләп. – Кулдан килгәнчә булышырбыз, өй туена чакырырга онытмассыз.

Егет сүзе бер булыр. Йортларны җиң сызганып, курчак өе кебек итеп төзеп тә куйдылар, өй туена да дәштеләр, эшкә кайткан мал табибына ачкычны Марат Әхмәтов үзе тапшырды.

Һәр авылда менә шулай эшлим дип яна торган, икътисадчы да, архитектор да, төзүче дә, артист та, көрәшче дә, эшмәкәр дә була белгән ир-егет җитәкчелек итсәме?!. Ә менә кайбер хуҗалык җитәкчеләре еш кына зарланырга ярата, эшчеләренә хезмәт хакы түли алмый тинтериләр.

– Булдыксызлар алар, ничек инде эшчегә хезмәт хакы түләп булмасын?! Менә шулай эшләсәңме... – Фәйзелхан, агрофирманың басу-кырларын, фермаларын күрсәтеп йөргән арада үзенең бетмәс-төкәнмәс идеяләрен ярып салды.

– Район белән җитәкчелек итәрлегең бар, тик җайсызрак кеше син, Фәйзелхан Гарифҗанович, «неугодныйрак», бигрәк турысын әйтеп сөйләшәсең, – дип шаяртып алды министр, авылның аякта нык басып торуына соклануын яшермичә.

Фәйзелхан бу сүзләрнең хаклыгын белә бит, киресен раслап маташмады, күзләрен хәйләкәр кыса төшеп, елмаеп кына куйды. Келәмгә чыгып көрәшкәндә дә, кайчак хәтта хаксыз әйтсәләр дә, хөкемдарлар белән бәхәсләшкәне булмады аның, чиста ук екмадың дисәләр, кабат чыга иде, көрәшә һәм үзенең көчен дәлилли иде. Җайсыз кеше диюләренә дә үпкәләми: бөтен нәрсәне йон уңаена сыпырырга күнеккән кеше тормыш келәмендә үзе тоткан сөлге башына абынып егыла ул, аягында озак басып тора алмый...

***

Төнгә кереп барыш иде. Моңарчы утыз тугыз-кырыктан кими белмәгән температура әллә төшәргә итте микән, маңгайга салкын тир тамчылары бәреп чыккан. Фәйзелхан учы белән йомарлаган җәймәне йөзенә якынайтып, маңгаен, йөзен сөртте. Тагын бер көннең үтеп баруын аңлау җанны башта тагын тынгысызланырга, аннан кинәт гаҗәеп бер җиңеллек белән таганда атынгандай тирбәлергә мәҗбүр итте. Үз-үзе белән фәлсәфә кору инде тәмам туйдырган да шикелле, тик күздә йокының әсәре дә юк, бердәнбер юаныч – уй, уй, уй... Ярый соң, уйлансын. Икенче берәүне чәйнәп ятмый бит, үзен кыйный. Башкага бармак төртеп күрсәтмә, калган өч бармагың үзеңә карый, диләр, шуңа үзеңне сүтеп җыюың мең хәерле.

Бүген. Берничә сәгатьтән ул «кичә» булып калыр. Иртәгә яңа «бүген» туар. Мәңгелек үлчәү бизмәнендә мондый «бүгеннәр» бәлки тузан бөртегенә дә тормыйдыр... Ул «бүген»дә синең шушы урында, шушы халәттә булуың тикмәгә түгел, димәк, синең өчен шулай хәерле – шуны аңлау хәлне җиңеләйтә, ахры. Менә бит, гомер буе йөгергәндә туктап уйланырга да җай чыкмаган, вак-вак шатлыкларга иркенләп сөенергә вакыт табылмаган; тел очында йөргән җылы сүзләр дә әйтелмичә калган, әрнүләр дә читкә атып бәрелмәгән. Кызык: әрнүләр генә түгел, уйлар да, вак сөенечләр дә, әйтелмәгән сүзләр дә ташлап калдырылмаган лабаса, алар барысы да йөрәкнең ерак почмагына яшерелә генә килгән. Үз-үзеңнән

качырып... Ашыкканда, кием шкафына агын-карасын этә-төртә тутырган шикелле... Берсе өстенә икенчесе, өченчесе, дүртенчесе... сыена биргән. Һәм, аларның авырлыгын да абайламыйча, шушы йөкне өстерәп, гомер юлы буйлап барасың да барасың икән.

Җай чыкты. Күкрәк читлеген ачып, җанны чистартырга, яшәү дәверендә җыела килгәннәрнең тузанын кагарга, кирәксез дип тапканны бөтенләйгә алып ыргытырга, тиңсез хәзинә булып та, моңарчы бикләнеп ятканны кояш күзенә чыгарырга җай чыкты.

Җанга энә булып кадалып, сызлатып торган әрнүләрне кабат урынына куюдан мәгънә юк. Җилләр белән очыртып җибәрергә дә онытырга, онытырга, онытырга гына кирәк. Уй калсын. Уйлаудан туктасаң – яшәүдән туктыйсың. Яктылары, самимиләре калсын. Каралары... Андыйлары әллә күренми инде? «Болай әйтсәм рәнҗетмәм микән» дип тормыйча, уйлаган берен турыдан ярып әйтә торгач, шулай тузгып-чәчелеп беткәннәр микән...

Вак сөенечләр бигрәк күп икән, алмаз бөртекләредәй җемелдәп яталар. Улы Фидельнең, кызы Фиданиянең тәүге кат тәпи басып китүләре. Эш белән мавыгып, шул кәкре адымнарны көлә-көлә күзәтергә дә вакыт булмаган... Нәни кызының су коену костюмы кечерәеп киткән. Фәйзелхан, кулына энә-җеп ала да, бавына киңрәк резинка өстәп, җәлт кенә зурайтып та бирә. Фиданиянең ул чактагы сөенүен, күзләреннән ташып торган горурлык һәм шатлык чаткысын менә хәзер генә абайлап алды... Резида өйдә юк. Фидания беренче тапкыр чебурек пешерә. «Кызым, син аның чит-читләрен менә болайрак ит, матур була», – дип, Фәйзелхан чәнечке тотып камыр читен бизәкләргә өйрәтә. Кызының шомырт күзләрендәге җылылыкны да хәзер генә тотып алды...

Сөенечләрнең елгыр йомгагы булып, оныклар тәгәрәп йөри. Улы белән килененендә – нишләп бабаема да, миңа да бер исем дип дәгъва белдерүче Фазыл һәм гөлчәчәктәй Айсель, кызы белән киявендә – күбәләк кебек биюче Әмилә һәм Тәминә.

Әйтелмәгән сүзләр хәйран күренә. Әйтелгәннәре арасында да корылары күбрәк... Улы Фидель, юридик белем алып, шул өлкәдә эшли башлагач: «Кара аны, берәрсеннән ришвәт алсаңмы?!..» – дип, шактый каты итеп әйтеп ташладымы?.. Анысы да... кай арада ир булган... Подполковник! Нәсел дәвамчысы! Кытай Гарифҗан нәселе анда дәвам итә! Кайчан гына, өйләнәм дигәч, Гүзәлнең кулын сорарга Чистайга юл тотканнар иде. «Безнең нәсел кушаматы – Кытай», – дип таныштыра башлагач, булачак кода-кодагый шаулатып көлеп җибәргән иде... Аларның да кушаматы «Кытай» булып чыкты... Улы булдыра! Ни тотса, шул кулыннан килә. Мәгәр көрәш юлыннан китмәде. Әтисеннән уздыра алмасын белә иде, уртакул булып йөрергә теләмәгәндер... Ничава, үз һөнәрендә бер дә уртакул түгел, эш рәтен дә белә, таләпчәнлеге дә, гаделлеге дә бар. Иптәшләре арасында тикмәгә генә «шиш обманешь» дигән сүз йөрмидер...

Җылы сүзләрнең күбесе нишләптер еракка яшерелгән. Әллә соң көрәшче ир-егетнең тел очына килеп кунса, йомшаклык, көчсезлек дип саналганмы? Уйлап карасаң, аларны иң якын кешеләреңә вакытында әйтә белү, киресенчә, бик көчлеләр эше түгелме соң?

Чылбыр-чылбыр уйлар өзелә дә ялгана, өзелә дә ялгана. Җан яктырып китә. Бу авыру янәшәсендәге билгесез бер куркудан, үз-үзеңне гаепле

тоюдан, кичә һәм иртәгә дигән төшенчәләрдән арына барганда, ике чигәдәге тукылдау авазлары да тына төшә.

Шулай. Бер генә җиңү дә ансат кына бирелми. Менә бит, җаныңа үрмәләгән авыруны сыртына салыйм дисәң дә, караватта чалкан ятып, иң әүвәл үз-үзеңне җиңү кирәк булып чыкты. Теге юлы, келәмдә, данлыклы бер көрәшчене җиңеп куйгач, ул ризасызлык белдергәч, нәрсә дип ымлаган идең әле аңа? Башта үзеңнең беләгеңә төртеп күрсәтеп: «Бу гына җитми», – дидең, аннан, башыңа төртеп: «Бу да кирәк», – дидеңме, үзеңчә шаяртып? Чөнки беренче тапкыр гына көч сынашуыгыз түгел иде, синең нинди алым белән «бәрергә» яратуыңны онытып җибәрмәсә, исенә төшерсә, ул алымны ясарга мөмкинлек тудырмаган булыр иде. Синең бу ым-хәрәкәтең, телдән-телгә күчеп, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнехановка да барып җиткән иде. Алабугага килгәч, авыл хуҗалыгы җитәкчеләре арасында сине күреп, «Бу гына җитми, бу да кирәк»... дип, беләгенә һәм башына төртеп күрсәтеп, шаяртып куйган идеме?..

Шулай. Бер генә җиңү дә, бер генә үр дә, дан-дәрәҗә дә, исемеңә булган ихтирам да алмагачтан өзелгән алма шикелле тып итеп кенә алдыңа килеп тәгәрәми. Алдагы бәхеткә дә, хөрмәткә дә үз көчең һәм үз акылың белән барасың; кем әйтмешли, без барабыз, ул килми...

Яңа таң туарга күп калмагандыр.

Әлегә – бүген. Ул синең яныңда, җаныңда. Тирә-якта да бүген хакимлек итә. Җиргә мул уңыш юрап, тасма-тасма яуган кар да бүген ява, палата ишеге өстендә төнгелеккә кабызылган сүрән ут та бүген яна, сулыш алу да – димәк, яшәү дә – бүген. Аллаһтан сиңа яшәр һәм уйланыр өчен бирелгән көн ул – бүген.

***

Фәйзелханның спорткомплекс төзергә дигән нияте тикмәгә түгел иде: шушы залга көрәш серенә өйрәнергә килгән малай-шалай бәләкәйдән үк яшәеш серенә дә өйрәнеп үссәме... Аларны ватсап, инстаграм әллә юньлелеккә өйрәтә, дисеңме... Авылның гына түгел, илнең, җирнең булачак сакчылары бит алар, беләк көче дә, йөрәк көче дә нык булсын. Акны – карадан, хәләлне – харамнан, хакыйкатьне ялганнан аера белеп үссеннәр.

– Бу якны да чистартып бетерергә кирәк, гает көнне машиналар күп була, урын эзләп тинтерәмәсеннәр, – диде ул үзе белән янәшә атлаган Шәфкатькә, төзелеш эшләре тәгәлләнеп килгән бинаның тирә-ягын сөйләшә-сөйләшә әйләнеп чыккач. – Малайларга тренер таптым, Мамадыштан Айнур Гатияуллин дигән егет килеп өйрәтәчәк. Урам якка элмә такта ясатырбыз. «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы зат һич юк. Мөхәммәд – аның колы һәм рәсүле» дип, иман кәлимәсен татарча да, гарәпчә дә, русча да язарга кирәк. Ат бәясе түгелдер.

– Ярар, малайларга бишәр йөз меңлек маталар алып кайтып куйганыңны, тактага гына калгач... – Абыйсыннан торган саен бер яңа идея ишетергә күнеккән Шәфкатьнең колагына монысы гына үзгә тоелмады. – Стенд матур итеп беркетелгән, күрдеңме?

– Булган. – Нәкъ әтисе шикелле, Фәйзелханның да соклануы, мактавы шушы рәвешлерәк.

Залның түр стенасына Сабан туе батырларының фотоларын зур итеп эшләтеп элделәр, кайсы елда авылда кем батыр калган – әнә, ишектән керүгә, каршы якта, түрдә тезелеп торалар. Илтөзәр, Азат, Мөдәррис, Илгизәр, Камил, Рифкать, Нурулла, Фәрит, Рәис, Шәфкать, Шәрифҗан, Фәйзелхан... Алтмыш сигездә авыл батыры булган, аннан соң малайларга көрәш чире йоктырган Равил абыйларының сурәте дә шушында.

– Үзеңнең шәһәрдә татарча көрәш буенча судьялар коллегиясендә биш-алты ел буе баш судья булганың язылмаган, төшеп калган бит, абый, – диде Шәфкать, болай, төрттереп кенә. – Гадел булгач, куркып торалар, дип сөйли идең...

– Язганы җитәр. Синең «Татарстанның атказанган табибы» икәнең, сигез тапкыр Алабуга батыры булганың төшеп калмаган бит... – Төрттерергә дигәндә, Фәйзелхан да кимен куймый. – Нәрсә инде ул, халык үзенең көрәшчеләрен дә белмәсә... Санаулы гына алар. Хәтер болай да кыска ул, барлап торсаң да, таманга туры килә... Әнә, Данил Галиевны кара, татар көрәшендә легендар кеше бит, 45 яше дә тулмый үлеп китте. Биектауда үзенә бюст куеп ничек шәп эшләделәр, җыйнаулап бардык туган ягына. Түбән Камада Данил истәлегенә ел саен кайчаннан бирле милли көрәш турниры үткәреп киләләр. Хәтерне яшәтәм дисәң, шунсыз булмый. Сабан туе батырлары йөзек кашы ул, исемнәре менә шулай түрдә эленеп торырга тиеш, кыр батырларыныкы кебек.

– Абый, сиңа, бераз ут төртсәң, хәзер дә мәйданга чыгып бил алышыр идең. – Шәфкать көрәш турында сөйләгәндә, Фәйзелханның күзләре түгәрәкләнеп, тавышы күкрәп, тагын да җанланып киткәнен күреп, көлемсерәп баш чайкады: чыгар да, әнә бит, көрәшчеләр каршына ике кулын бөеренә куеп, аякларын як-якка аерып килеп баскан.

– Чыгарсың... Яшеңне санамасаң... Һәр кешенең үз вакыты, үз мизгеле була. Үзеңнең көчсезләнгәнеңне сизсәң, ничу йөрергә... Келәмнән матур итеп, җиңүче булып китүең хәерле. Йөрәк ярсый инде ул, тыеп торсаң гына... Йөрәген тыңлата алмаганы чыга, хәлсезләнсә дә, чирләсә дә, җиңәм дип түгел, шул ярсуны басам дип чыга. Яшьләр, шуларны җиңсә, «мин фәләнне җиңдем!» дип күкрәк каккан була. Син аны күкрәп торган чагында ек, шуннан соң сөйләрсең... Әле Данилга бюст ачарга туган ягы Биектауга баргач, бер көрәшче: «Минем аны екканым булды», – дип сөйләп маташа. Аңа да әйттем, кеше гомер буе формада тора алмый, абсолют батыр булып кала алмый, син аның белән Россия чемпионы булган чагында көрәшеп кара идең, дидем. Данил Галиев ул татар көрәшендә генә түгел, классикада да бер феномен! Бюст ачканда, район башлыгы Рөстәм Кәлимуллин да шулай диде. Син аның титулларын гына кара... Грек-рим көрәше буенча СССРның спорт мастеры, татар-башкорт көрәше буенча РСФСРның спорт мастеры, татар-башкорт көрәше буенча Татарстанның атказанган спорт мастеры. Россиядә 8 тапкыр, Татарстанда 12 тапкыр чемпион, 2 тапкыр Татарстанның абсолют батыры исемен яулады, Җәлил турнирында да 6 тапкыр җиңеп чыкты. Мизгел эчендә «взрыв» ясап, ул гына шулай тотып ата торган иде, аныңча беркем аталмый; китереп эләктерсә, чыбыркы урынына төшерә...

Спорт сәхнә түгел шул, күпкә рәхимсезрәк. Яшьлегең, көчең бар чагында ул сине лимонны сыккандай сыга да аннан чүп чиләгенә тотып атарга

да күп сорамый... Көрәш аеруча кырыс: монда син яшькә-өлкәнгә карап түгел, гәүдә авырлыгыңа карап көч сынашасың. Кайчагында яшьлекнең җиле дә көчлерәк булырга мөмкин... Фәйзелхан үзен 42 яшендә ветеран-көрәшче буларак Түбән Кама Сабан туенда сынап карады. Аны да, бәлки, кемдер «бу бабай нишләп йөри икән» дип, мыек астыннан гына елмаеп каршылагандыр да... Бик тиз авызын җыйгандыр: абсолют батыр исемен дә, аңа бирелгән тәкәне дә, «Ока» машинасын да Фәйзелхан алып китте. Башка болай «шаярырга» уйламаган иде, тик Сабан туйлары якынлашкан саен шартлар дәрәҗәгә җитеп ярсыган йөрәкне басар бүтән чара тапмады: 2008 елда, илле бишем тула дип тормады, Алабуга Сабан туенда мәйданга чыкты. Үз вакытында классик көрәштә дә, милли көрәштә дә, иректә көрәштә тә, грек-рим көрәшендә дә җиңәсен җиңгән, исемен яңгыраткан пәһлеванның, әле дә бил бирмичә, финалга барып җитүен күргәннәр аһ итте. Каршысында – билбау көрәше буенча берничә тапкыр Россия чемпионы булган яшь егет Ринат Әхмәтшин. Фәйзелхан сизеп тора: исәп тигез, өчкә өч булса да, кайчандыр 18 яшьлек Фазыл-Фәйзелхан шушы мәйданда көрәшкәндә, аның өчен ничек җан атсалар, бүген дә халык... яшь көрәшче өчен, яңа исем өчен җан ата. Шуны аңлап, җиңүче дип танып, көндәшенең кулын кысты Фәйзелхан.

Дөнья бер урында тормый. Дәвам итә, тормыш мәйданына яшьләр килә. Аларга шөгыльләнер өчен бөтен мөмкинлек бар хәзер. Анысы, Фәйзелхан үзе гер, штанга күтәреп маташмады, келәмгә партнёр алып кереп, дүртәр-бишәр кеше белән көрәшеп, җитезлеген чарлый торган иде. Бүген спорт сарайлары да, бассейннар да, тренажёрлар да җитәрлек, һәр районда берсеннән-берсе талантлы көрәшчеләр туып тора. Тусыннар, көрәш тәмен белеп көрәшсеннәр, акыллары да, өлкән буынга хөрмәтләре дә булсын. Картлык, иртәме-соңмы, исән булса, бөтен кешегә дә килә ул, гел яшь, гел көчле булып кына калалмыйсың... Исәннәрнең дә, үлгәннәрнең дә кадере булса иде... Фәйзелхан, берәр көрәшченең юбилее җитсә, бәйрәмнәр көтелсә, үзе дә тынгысызлана, башкаларны да кыбырсыта башлый. «Менә шуның юбилее җитә иде, үткәреп алыйк әле», – дип, спорт министры урынбасары Хәлил Шәйхетдиновка да эндәшеп ала. «Марат Готович, бөтен абсолют батырларны бергә җыеп очрашу уздырсак...» – дип, Татарстан көрәш федерациясе президиумы рәисе Марат Әхмәтовка да үз идеяләрен җиткерә.

Исән-сау чакта бергә күрешү – истәлекләрне яңарту, үткәннәрне барлау гына түгел бит әле ул, бүгенге көн дә бар бит! Бүген дә көрәшчеләр бар. Картлар сүзен капчыкка сал, яшьләр сүзен янчыкка сал, ди. Әле картлар исемлегенә керергә ашыкмасалар да, кайчандыр мәйдан тоткан буынның әйтер сүзе бар аның...

Аның, әнә, хәзер үз мәйданы: «Морт» агрофирмасының данын шушы биеклектә тотарга, тагын да югарырак күтәрергә кирәк. Моңа кадәр беркем алдында ким-хур булырлык түгел иде: республика бәйгесендә «Агропромышленность комплексы предприятиесенең иң яхшы җитәкчесе» дип бүләкләделәр үзен. Хезмәтен бәяләп, «Казанның 1000 еллыгы», «Фидакарь хезмәт өчен» медальләре бирделәр. Туган якның иң олы бүләге – «Алабуганың почётлы гражданины» исеме белән хөрмәтләделәр.

Терлекчелектәге, игенчелектәге уңышлар белән танышасың килсә – рәхим ит, баш очында тургайлар биегән басу-кырларны да, амбардагы көшел-көшел ашлык өемнәрен дә, иркә кызлардай бил уйнатып атлаган озын торыклы атларны да, көн саен Алабуга комбинатына тонна-тонна сөт озатып калган сөтлебикә сыерларны да үз күзләрең белән килеп күрә аласың...

Фәйзелханның үз-үзенә ясаган иң олы бүләге – ул бүген туган туфрагында күкрәген киереп басып тора. Кайчак, сабый бала кебек, шул туфракка яланаяк басканда, табан астын чемер-чемер китереп, рәхәт бер дулкын күтәрелә; гүя ул янә көрәш мәйданына, келәмгә чыгып баскан; тик туфрак ярып бөтенләй башка, нәзберек тойгылар – камылларның кытыклавы, бәбкә үләннең иркәләве, ат тоягы эзендә җыелып торган яңгыр суының җылысы, сары күзле ромашкаларның ак сулышы җанга үрмәли. Алар һич кенә дә сиңа көндәш түгел. Киресенчә, туган якның кычытканы да, мең шифага ия тигәнәге дә үзеңнеке, үз...

– Эх, гомергә бер үкенечем булды: күбрәк бала алып кайтасы калган! – Фәйзелхан, зур, иркен спортзалны күзе белән айкап, уфтанып куйды. – Кара, авылга Дагыстаннан кайткан лезгин гаиләләрендә итәк тулы бала! Барысы да монда, көрәш түгәрәгенә киләм дип атлыгып торалар. Бүтәннәрне дә кушкач, егермегә якын бала йөрердәй.

– Эше күп калмады, йөрерләр. – Шәфкать тә уты-суы кергән, җылылыгы үткәрелгән, вак-төяк эшләре генә калган бинаның эчен карашы белән барлап алды. Мәчет белән тоташкан коридорга күз ташлады. – Без үскәндә булсамы болар...

Аның ни уйлаганын бик тиз эләктереп алды абыйсы.

– Без шул әнинең фатихасы белән яшәгәнбездер инде...

– Ул чагында кем аңлаган диген. – Шәфкать, җөпләп, ияк какты. – Сугышканда да әнинең намазы аркасында гына исән калганбыздыр...

– Әле сугышып та йөрдеңмени син? – дигән булды абыйсы, үзе әүлия шикелле, кашларын җыергалап.

– Әллә шәһәр сине битеңнән үбә-үбә каршы алдымы... Ничава, авыл малае булсак та, эшләп җыйган көчнең нәрсә икәнен тиз күрсәттек... «Тяп-Ляп»ларның Казанны дер селкеткән чагы бит ул, алар каршында җебек булсаң, көчең булмаса, исән калуың да икеле... Таксилар белән килеп, общаганы әйләндереп алалар... Андагы бер кыз байтактан соң бер очрашкач сөйләде: моның бүлмәсенә дә килеп кергәннәр, чишен дип бәйләнә башлаганнар. «Мин Шәфкатьнең сеңлесе, дип кенә котылдым», – ди...

– Авторитетың булган инде... – Фәйзелханның кисәк уйчанланып калган карашы мәчет ягына төбәлде. Көчне дә, акылны да кемнән, ни рәвешле сорарга икәнен хәзерге балаларга төшендерәсе иде. Бөркет булып очарга теләгәннәр күркә көтүендә буталып йөрмәс – монда килсеннәр, яшәү серенә өйрәнсеннәр. Иманның һәм көрәшчеләрнең бик кирәк чагы! Әтисе әйтмешли, үзен яклый алмаган ир-егет ничек итеп җирен, илен якласын...

***

Иң гадел хөкемдар Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән яңа таң туды. Аның могҗизасы белән үз урыннарын, үз вакытларын һич бутамыйча, бер-берсен алыштырган Ай һәм Кояш хәрәкәтендә бүгенге көн башланды.

Коридор буйлап әллә арба, әллә коляска тәгәрәтеп үттеләр.

«Болар да... тынгы белми».

Ирнең көнне төнгә ялгап эшләгән санитаркаларны күздә тотуы булды.

«Резида йоклый алды микән...»

Кичәге уе кабатланмады, ул кичәгедә калган иде.

И Ходаем, рәхмәт Сиңа,
Рөхсәт бирдең
Бу дөньяда яшәргә.
Моннан соң да язсын шулай
Сынауларыңны үтәргә.
Рөхсәт бирче безгә
Сине мактап, намаз кылып,
Аллам диеп дәшәргә.

Эх, тәки бер ручка юк кул астында... Илһам килгән моментында теркәп куймагач аны, кабат искә төшереп булырмы?..


Кайдадыр нәрсәдер үзгәргән шикелле.

Яшәүнең ике дөнья арасындагы мизгел икәнен ныграк аңлауданмы?

Ул мизгел көрәш һәм сынаулар белән тулы. «Бу миңа ни өчен бирелде, җиңеп чыга алырмынмы?» дигән уйларын бер толымга үрә-үрә, кеше яшәү өчен көрәшә. Кайчагында авырлыкларга юлыгасыңны алдан беләсең, кайчак алар бөтенләй көтмәгәндә, башыңа ишелеп төшә. Сынауларның һичшиксез булачагы һәм аларның иртәме-соңмы яныңа килеп басачагы гына көтелмәгән нәрсә түгел дә соң... Тешләрең белән килеп ябышсаң да, җиңел генә җиңеп булмаслыкны аңлаганда, ул сынауларга бәлки ераккарак китеп карargaдыр? Чишәр юл эзләп, Аллаһы Тәгаләдән шул юлларны күрсәтүдә, булышуда ярдәм сорап... Сынауларны котылгысыз бер хәл дип кабул итәргәме, аларны җиңү серен өйрәнергәме; кайсы сынау безгә тормышта өр-яңа юл күрсәтә, ә кайсы бары тик гади чишү юлы гына таләп итә – шулар хакында уйланып...

Яшәү – мизгел.

Кеше дигән зат, шул мизгелне үтәр өчен үз куллары белән алдына күпер сала-сала, гомер юлыннан атлый. Кадагы дөрес кагылмаганмы, тактасы күтәрелеп калганмы – үкенү, артка борылып, нидер төзәтү мөмкин түгел, кирегә юл юк, ул үткәндә, кичәгедә калган. Үтелгәнне барларга гына була, әмма нидер үзгәртергә – юк. Иртәгә күпернең кай басмасын салырсың, ерак китә алырсыңмы, аргы очта ни көтә – кешегә анысын белү сәләте дә бирелмәгән. Анысы – иртәгә. Тәкъдир китабының бит санын үзгәртү дә, язмышыңны язу хокукы да җир-күкләрнең бердәнбер хуҗасы Аллаһы Тәгалә кодрәтендә генә. Кем белә, бәлки ел саен, Кадер кичендә, язмышлар да, кылдан нечкә, кылычтан үткен күпер аша үтәсе мизгел дә үзгәртеп язылададыр. Анысы – иртәгә. Анысын белә алмый адәм баласы. Ул бары тик шулар хакында уйланып, бүген яши. Һәр сулышы, фанилыктагы һәм бакыйлыктагы урыны өчен көрәшеп. Бүген, шушы мизгелдә... Яши.



Айрат
Суфиянов

# ХАК ТӘГАЛӘ БЕЗНЕ ҖАНЛЫ ИТКӘН...

## Мең-мең шөкер

Пегас ялын төшләремдә тарап,
Талпынсам да Парнас тавына,
Биләмәм – тар… гүя эләккәнмен
Яктылыксыз гасыр авына.

Кысыр болытларның ятьмәсендә
Чәбәләнгән әллә тургаймын.
...Рәхмәт, язмыш, ярый хәтер саклый
Сөтле исен бәрхет тугайның.

Кояш чыккан якка сабый чакның
Колыннары уза чабышып.
...Туган якка бәйле истәлекләр –
Күңелемнең баллы табышы!

Мең-мең шөкер, хыялым да якты,
Сау-сәламәт, исән, үлмәгән!
Парнас түбәсенә дәшкән юлын
Тау-таш өеп, беркем бүлмәгән...

Өстәгеләр... бәлки, саташасың,
Ычкынгансың тәмам диярләр.
Башкалардан үзгә сәер җаннар,
Үз көченә үзе ышанганнар –
Пегасны да беркөн иярләр...

---

Айрат СУФИЯНОВ (1958) — *шагыйрь; «Кылычлы җил» исемле китап авторы. Чаллыда яши.*

## Мәгънә эзлим

Мәгънә туа – бәбкә пипелдәсә,
Мәгънә туа – таллар шауласа.
Мәгънә туа – күккә якын торган
Тауга баскыч – түмгәк яуланса...

Йөгәннәрсез тайлар кешнәп узса,
Уйларыңа уйлар өстәлә.
Мәгънә туа – хикмәт кояшыдай
Икмәк балкып ятса өстәлдә.

Мәгънә туа – халкың йөрәгенә
Дөреслекнең нурын юлласаң.
Туган туфрагыңа тамырланган
Үз телеңне тыңлап юансаң.

Мәгънә туа, эткәң, әнкәңне дә,
Туганнарыңны да кочканда.
Хәләл ярың күзләренә багып,
Сөю канатында очканда.

Мәгънә туа – улың, кызың көлсә,
Оныкларың йөрсә кайнашып.
Мәгънә туа, үзең үзең белән
Җирдә яши белсәң аңлашып.

Мәгънә туа – таңнар аткан чакта,
Мәгънә туа – кояш баеса.
Адашудан үзен саклый-саклый
Ак, караны кеше аерса.

Мәгънә туа – иҗтиһатың җимеш
Биреп, бүтәннәр дә татыса.
Гасырларга кирәк шәхес итеп,
Дошманың да хәтта таныса...

Мәгънә эзлим, безнең дәвам булган
Илне күтәрәчәк яшьләрдән...
...Саклый күрче, язмыш, кешелекне
Җирдә мәгънә тапмый яшәүдән...

Хак Тәгалә безне җанлы иткән,
Аңлы иткән – юкка түгел лә.
...Җирдән, күктән, һәрбер күзәнәктән
Бәйләнешле мәгънә түгелә...

## Кошчык

Бәхете кайгылы таң ата –
Караңгы яктыга төбәлеп.
Ялкынлы салкында бер кошчык
Өнсезлек шавында тирбәлеп,
Утыра дөньяны өйрәнеп...

Сагышлы шатлыкка сыенган
Газапның ләззәтен кузгатып,
Өздереп, тавышсыз сайрады
Күз яшьсез тойгыма куз атып...

Ширбәтле ачы моң тәэсире
Кәефне төшереп күтәрә.
Каршылык эченнән мин таптым
Шәфкатьле усаллык күкләрдә...

Тирәнлек сайлыгын үлчәп тә,
Кысылып төртелдем чикләргә.
Акыллы тиле мин, үлгәч тә,
Гади сер булырмын күпләргә...

Канымда – ярсулы тынычлык,
Канымда – көчсезлек куәте.
Ачылып йоклаган күзләрдә
Яманнан яхшылык эзләгән,
Ак-кара болытлар сурәте.

Җавабы сораулы төн килә,
Нигә дип түбәнлек югары?
...Зинданда зынҗырсыз төш күрә
Илемнең ирекле коллары...

Бәхете кайгылы таң ата...

## Без авылдан килдек

**1**

Без авылдан килдек… Алып килдек
Әнкәйләрнең хәер-догасын.
Юлдаш иттек, хәтер, гамь яшәгән,
Татар таҗын бизәп, ямь яшәргән
Гореф-гадәт, әхлак дөньясын.

Без авылдан килдек… Алып килдек
Бал исенә төреп, җан хисен.
Нәзафәтле, тыйнак сөйгән ярның
Карашыннан тамган таң төсен.

Без авылдан килдек... Алып килдек
Чишмәләрнең көмеш чыңын да.
...Куллар һаман сузылып калган килеш –
Күк чагылган чәчәк чыгына.

Без авылдан килдек... Язмышларны
Җирсү төсе кушып чигәбез.
Алга, дибез, әллә чынбарлыкта
Көчсезләнеп... артка чигәбез.

Киңлекләрнең сулышыннан язып,
Таш капчыкта иза чигәбез.
...Сизелми дә арткан чал чәчләрнең
Биләмәсе инде – чигәбез.

Без авылдан килдек... Алып килдек
Урман шавын, кырлар исен дә.
Бака туен тыңлап әсәрләнгән
Ай-йолдызлы зәңгәр кичен дә.

**2**

Без авылдан килдек... Эшләп үскән
Ир-егетләр, кызлар булып та.
...Ах, ничекләр, белмим, акланырбыз
Авыл бушап калган минутта?..
Шуны уйлап янам мин утта.

Бездән башка авыл үксез, ятим...
Сәбәпчесе без үк түгелме?
«…Шәһәрнеке итеп булмый икән,
Туган ягын изге Ватан иткән
Әтәч кунаклаган күңелне...»

Без авылдан килдек… Алып килдек
Йөрәкләргә төйнәп бар моңын.
Туган якның үпкәләве юкмы
Тавышында тальян гармунның?

Яшәсәк тә, чит казанда кайнап,
Олы-олы эшләр майтарып,
Авыл җанын җыр-бишеккә салып,
Кичер диеп, күзләренә багып,
Бирә алырбызмы?
Бирә алырбызмы кайтарып?..

Башлангычым – чишмә, көмеш суын,
Әллә яшен коя диңгезгә?
Тавыш-тынсыз гаҗизлегем сыктый
Башын төртеп туган нигезгә.

…Корымаска өндәп, асылыма
Туган туфрак сөтен имезә…

Без авылдан килдек…

## Кем эзләгәнен тапты?

Илдә янып егылганчы
Безне бәхет көтәме?
Гадел яшәеш кайда соң,
Җир астында? Күктәме?

Кайда Вөждан? Кайда Иман?
Кайда догалы таңнар?
...Куркып баса үләнгә дә
Аттай дагаланганнар...

Заман авачак, таянса
Түбән, рухи аксакка.
...Кайда акыл тантанасы
Баш имәгән ахмакка?..

Кайда әхлак төшенчәсе,
Ышаныч киләчәккә?
Байлык колы – бирәннәргә
Шәхси утары – Мәккә...

Үлгән хыялым кошына
Җырым ак кәфен япты...
Канунсызлык баткагында
Кем эзләгәнен тапты?

## Күк гыйлемен бирче

Хикмәткә тап булган чагыммы? –
Туктап калды вакыт агымы.
Яфрак төшеп тынды учымда.
Басып тордым балкыш очында,
Җаным белән күккә ашыпмы?
Саташыпмы, Җирдән качыпмы?
Ләйлә, күреп, зәңгәр киңлеккә
Чиксезлектән дәшкән иреккә
Мәҗнүннәрчә мин соң гашыйкмы?
Җирдә татымаган бәйрәмгә
Назлап туймаган да гамь-ямьгә
Тоташыпмы? Серен ачыпмы?
Кәүсәр чишмәсенең тынышннан
Һушымны ук җуйдым шашыпмы?

Мөлдерәмә тулган хис-касәм,
Йолдызларның дымын иснәсәм,
Түгелергә тора ташыпмы?
Күкнең капусы да ачыкмы?
Арынып аң соңгылыгыннан,
...Төшенермен кебек соңыннан...
Көн-төн сорый шуңа аһ-ваһым:
– Күк гыйлемен бирче, Аллаһым!.

## Яратучы ярлыкамас

Җир өстенә төшсә Дәҗҗал,
Канлы сугыш, гауга, җәнҗал
Кемгә дә бишек булмас.
Фирдәвес җәннәтләренә
Ачылган ишек булмас.

Нух көймәсе тиранны да
Кала алмас коткарып.
Сүнәр... сүнәр кабынмаска
Фани дөнья утлары...

Яный бүген тереклеккә
Давыл алды тынлыгы.
Карагруһлар өеренең
Кабих астыртынлыгы.

Барчабызны да йотмасмы
Караңгылык чоңгылы?
...Кайсы диндә чагылмаган
Кыямәтнең чынлыгы?.

Һәр чорда да бәндә – корбан...
Юкмы сайлау хокукы?
Ахрысы ул язылганны
Укый белмәгән сукыр...

Күргәннәр урап узалар
Алдында торса упкын.
...Безме – иманнан язганнар,
Безме – тәмугка утын?..

...Җирдән күкләргә тоташкан
Уйларым дулкын-дулкын.

Үз язмышы белән инсан
Уйнар кайчанга кадәр?
Яратучы ярлыкамас,
Гөнаһка батсак әгәр...

## Шауласын

Болганчык буа суында
Көн нуры ята череп...
Чак сулаган алтын балык –
Ләм томалаган ирек.
Аны коткарып булырмы
Хәер-садака биреп?..

И тереклек, кузгатсаңчы
Буаны аксын өчен.
Мизгел саен кодрәт туплап
Үз юлын тапсын өчен.
Каршындагы киртәләрне
Җимереп атсын өчен.

Фидаи, үҗәт көрәшнең
Иркенә тапшырылып,
Шауласын гомер буена
Тиңдәшсез ташкын булып.
...Тоташсын ярсу диңгезгә
Уйлары ашкынулы...

Равил
Сабыр

# ФӘХРИНЕ ҮТЕРЕП ТАШЛАДЫЛАР*

РОМАН

## 11. Бүре бер күзе белән генә йоклый

– Ә Кадыйр? – дип сорады Диләрә. Аның күзләреннән яшьләр тама иде. – Кадыйрның гомере ничек өзелде?

– Бик аяныч булды аның үлеме.

– Һәркемнең үлеме аяныч инде, аяныч булмаган үлем юк, – диде Галимҗан калтыравык тавыш белән.

– Белмим, миңа Кадыйрның китүе нык үкенечле булды, – дип дәвам итте Зөлмәт. – Нишләтәсең, тәкъдиренә шулай язылган булгандыр инде. Хәер, үтермәгән булсалар да, күп калмаган иде инде аңа.

– Ник алай дисез? – дип сорады Диләрә, елаудан томаулана башлаган борынын тарткалап.

– Сизенә иде күп калмаганын.

– Сизенә?

– Төгәлрәге белә иде.

– Берәр чире бар идемени?

– Ябыгып, кибеп беткән иде инде ул соңгы арада, ап-ак иде, йөзеннән нур качты, хәле бик тиз бетә башлаган иде, – дип, Зөлмәт авыр сулап куйды, күзләрен уып алды.

– Нинди зәхмәт эләктерде соң ул?

– Туберкулёз. Аның да ниндидер бик әшәке формасын, үпкәсен ашый торганын, кешене бик тиз аяктан ега икән андые. Күп калмаганын аңлапмы, авыртуны басмасмы дип микән инде, Кадыйр соңгы araларда кокаин белән дә мавыга башлады. Кешелектән чыгып беткән иде инде, кыскасы.

– Ник дәваланмады? – Илгизәр кулын иягеннән алып, кинәт телгә килде.

– Дару эчүдән узган иде бугай инде аның хәлләре. Аннары... Белмим, бәлки миңа шулай тоелган гынадыр...

– Нәрсә тоелды соң сезгә? – дип сорады Диләрә.

– Бик теләмәде дә бугай ул дәваланырга. Кадыйр бу чирне эләктергәненә... сөенде дип әйтә алмыйм, тик артык көенмәде дә. Вакыт җиткәндер инде миңа, Санчо, диде. Аның үзе турында китап яздыруы да шулай итеп үзенчә гомеренә нәтиҗә ясау кебек булды...

* Журнал варианты.

*Ахыры. Башы узган санда.*

– Китап, димәктән, – дип, сүзгә кушылды Галимҗан, – исеме бик сәер тоелды миңа – «Фәхрине үтереп ташладылар»...

– Нәрсәсе сәер?

– Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы шул җөмлә белән башланып китә, ә монда – китап исеме...

– Белмим, нигәдер Кадыйр бу җөмләне кабатларга ярата иде. Ул әйткәндә, бу сүзләр ничектер магия төсмере алып яңгырый иде. Еш әйтә иде ул аларны: берәр дустыбызны соңгы юлга озатканда да, ниндидер эш барып чыкмаса да, киресенчә, берәр олы эшне башлар алдыннан да, болай гына, тик торганнан да әйтеп куя иде. Теге Император белән очрашып, китап турында сүз чыккач та, шундук әйтте: китапның исеме «Фәхрине үтереп ташладылар» булачак, диде.

– Нигә нәкъ менә шундый исем? Нинди мәгънә салынган әлеге очракта бу сүзләргә? – диде Галимҗан, үҗәтләнеп.

– Китап бик ошап бетмәде миңа, дөресен генә әйткәндә, – диде Зөлмәт. – Исеме дә... Анда Кадыйр төшенкелеккә бирелгән, бар нәрсәгә күнгән бер адәм булып күзалдына килеп баса. Бәлки соңгы вакытларда аңарда декадентлык та булгандыр, тик аның гомере бит алай узмады, ул бит, беренче чиратта, көрәшче иде! Ә китапта нәрсә? Без алданган буын, без башта мәйданнарда «Азатлык!» дип кычкырып, ирек даулап йөрдек, аннары бу идеаллардан кире кайттылар, саттылар безне, ди ул. Башта мәктәптә бер төрле кыйммәтләрне башыбызга сеңдерделәр, ә үсә төшкәч, мөстәкыйль тормышка аяк баскач, бәтенләй башкалары өскә калкып чыкты, ди. Безне сызып аттылар, үтереп ташладылар, дип әйтмәкче була Кадыйр китабында.

– Сез сүзне юри читкә алып китәсезме соң, аңламыйм мин?! – диде Диләрә, психланып. – Кадыйрга ни булды соң, сөйләгез инде, зинһар?!

– Әйе, бырат, аңлатып бирче әле! – диде Хамис. – Ату бүген Диләрә әллә нинди инсценировкалар турында сөйләде, каберен дә күрдем, тик аныкы түгел ул, ди үзе. Белеп сөйләнәме соң бу хатын, бабские сплетни гынамы бу?

– Өченче ходкасы алдыннан воляда йөргәндә, «Боксёрлар» группировкасы белән бик каты конфликт булып алды аның.

– Авторитетлар белән уртак тел таба белә иде, дигән идең бит үзең? – Хамис шулай бер-бер артлы сораулар яудыра башлады.

– Нинди генә зирәк-акыллы булсаң да, нинди генә сыгылмалылык, дипломатия күрсәтсәң дә, братва арасында яшәгәч, конфликтлардан барыбер качып-котылып булмый. Бүре бер күзе белән генә йоклый, ди торган иде Кадыйр.

– Бүре утлавында ишәк йөрми, дигәне дә бар әле тагын, – дип өстәде Галимҗан.

– «Боксёрлар» белән ни бүлешә алмады Кадыйр? – дип сорады Илгизәр.

– Профессор икенче ходкадан кайткач, элеккеге тәртипләрен кертә башлаган иде районда, алай асат кына килеп чыкмады ул. Кадыйр төрмәдә чакта «Боксёрлар» шактый көчәеп китеп, моның урынын алганнар. Убыр китте, урыны калды, диләрме әле? Профессорның, әлбәттә, үзенекен кире кайтарасы килде.

– Ике дәрвиш бер паласка сыя, ике патша җир йөзенә сыя алмый, – дип куйды Галимҗан.

– Конфликт озакка сузылды, зурга китте, ахыр чиктә ике арада ачыктан-ачык сугыш башланды. Бәлки ишеткәнсездер дә, заманында тавышы күп булды, Яңа Ужым авылында берьюлы тугыз кешене үтергәннәр иде. Шул боксёрлар эше инде бу. Профессорның иң якын ярдәмчеләренең берсе туган көнен уздырды үзенең коттеджында. Өй хуҗасын, хатынын, өч баласын, тагын безнең дүрт малайны калашниктан кырдылар. Пуля тиеп кенә үлмәгәннәрен суеп чыкканнар иде, кабахәтләр!.. Анда Кадыйр белән мин дә булырга тиеш идек. Рәхмәт төшкере, кичектереп булмый торган эш чыгып, Мәскәүгә китеп калдык. Әллә ничә мәртәбә чак кына үлемнән калды инде ул Профессор. Машинасы өч мәртәбә автокатастрофага эләкте, берсендә, ресторанга килгәч, машинадан чыгып, дүрт-биш адым гына ясаганбыздыр, очты да китте мерин һавага! Ничек килгән, шулай китте, диде Профессор. Аттылар да инде аңа, агуламакчы булып та карадылар, әмма ул чакларда Аллаһы Тәгалә ничектер саклап килде үзен...

«Боксёрлар» бик каты китереп кыстылар, кыскасы, Кадыйрның барыр җире калмаган иде, аны почмакка куып керттеләр: йә бирелә, йә үлә. Шунда ул гениаль план уйлап тапты! Бирелә алмый бит инде берничек тә?! Димәк, үләргә кирәк. Куштырнаклар эчендә үләргә, – дип, Зөлмәт бармаклары белән куштырнаклар ясап күрсәтте.

– Ничек була соң ул? – дип сорады Хамис.

– В кавычках, Сансыз! Җүри генә дигән сүз! – диде Галимҗан.

– В кавычках икәнен аңладым мин, дурак түгел! – дип ырылдады аңа Хамис. – Просто күз алдына китерә алмыйм ничек алай була алганын!

– «Чикаго» клубында әледән-әле зур кешеләр җыела торган иде кәрт уйнарга. Оныткавда бер бик зур суммаларга зур уен оештыралар иде. Менә шундый уенның чираттагысы булырга тиеш иде. Без уенга Кадыйр да килә, дигән хәбәр тараттык. Боксёрлар «Чикаго»га иң зәһәр киллерларын җибәрделәр Профессорны кокнуть.

– Анысы нәрсә инде, үтерү дигән сүзме? – диде Галимҗан, күзлеген төзәтеп.

– Әйе. Озын сүзнең кыскасы, киллерның үзен кокнули без, тик шундый легенда ясадык, имеш, клуб бәдрәфендә Профессор белән киллер пистолеттан атышканнар һәм шунда бер-берсен үтергәннәр. Полициядә дело ачтылар киллер белән Профессорның үлеме буенча, ЗАГСта үлем турында таныклык бирделәр. Зурлап күмдек Профессорны, процессияне гаишниклар озата барды, оркестр, веноклар, кабер ташы, анда исеме язылган «Шириязданов Кадыйр Гариф улы», туган елы, үлгән елы – кыскасы, барысын да Кадыйр чыннан да үлгән кебек итеп оештырдык. Аның исән икәнен мин һәм тагын ике кеше генә белә идек. Бик күп братва җыелган иде Кадыйрны озатырга. Боксёрлар да килгән иде.

– Туктагыз әле, ә сез чынлыкта кемне күмдегез соң? – дип шикләнеп сорады Илгизәр.

– Ышанасызмы, юкмы?! Моргтан бер бомжның үле гәүдәсен сатып алырга туры килде. Беркем килеп алмаган мәетләр күп икән анда! Бесхозный дип йөртәләр андыйларны. Шундыйларның берсен күмдек Профессор урынына.

– Ә боксёрлар ничек сизмәде моны? – диде Илгизәр, әле һаман бик ышанып бетмичә.

– Әйе шул, – дип өстәде Галимҗан. – Үлгән кеше белән хушлашу була бит инде, гадәттә, матәм вахтасында торалар якыннары-дуслары, мәетнең йөзе ачык була.

– Әйе, әйе, болар барысы да булды! – диде Зөлмәт. – Беркем дә шикләнмәсен өчен Кадыйр үзе ятты табутта. Битенә күп итеп пудралар сөртте. Ничек бер дә селкенмичә ята алгандыр ул шулкадәр вакыт? Хәер, яшисең килсә...

– Бата торган кеше еланга да тотына, – дип куйды Галимҗан.

– Аннары теге бомжны табутка кайчан, ничек салдыгыз Кадыйр урынына? – дип сорады Илгизәр.

– Хушлашулар тәмамлангач, Кадыйрны катафалкка чыгарып салдык, – дип дәвам итте Зөлмәт. – Микроавтобус чакырткан идек. Шундый капкара тәрәзәле, тыштан караганда, берни күренми инде эчтә кем нишләгәне, кыскасы. Теге бомжның мәете шунда яшерелгән иде. Катафалк юлга кузгалгач, кеше-кара күргәнче, кара этләр өргәнче дигәндәй, шул бомжны тартып чыгардык та, Кадыйр урынына салып куйдык. Зиратта төргән кәфенлекләрне кире сүтеп, йөзләрен ачып тормадык билгеле.

– «Үлгәч» нишләде инде Кадыйр? – диде Илгизәр, сизелер-сизелмәс елмаеп.

– На дно залёг инде, нишләсен! – диде Хамис бик белдекле кыяфәт белән.

– Әйе, ике-өч ай тын гына утырды, – диде Зөлмәт. – Боксёрлар азрак тынычланды, киеренкелек бераз тынды, Кадыйрның ашыкмыйча гына әйбәтләп уйларга, яхшы план корырга, көч җыярга вакыты да, мөмкинлекләре дә җитәрлек булды. Без боксёрларның зур һәм бәләкәй дошманнары турында бөтен нәрсәне белештек: кемнәрне үпкәләткән булганнар, кемнәр аларга рәнҗеш саклый? Шулар белән акрынлап контактка кердек, куллар кысышып, бергә булырга килештек. Боксёрларның башлыгы Димон Пёс туган көнен үзенең ресторанында уздырды – «Тихий Плёс» дип атала ул. Атала иде, хәзер башка исемле ресторан инде анда. Боксёрлар да юк бүтән. Димонның туган көнендә винегрет ясадык без аларның атаманнарыннан, калганнары үзләре таралып бетте. Дөрес, берсе калган булган икән. Димон Пёсның энесе Пёс Молодой ул чакта төрмәдә утырган. Профессор үлеп терелгәч, – анда адвокатлар документ эше белән күпме чапты әле! – кыскасы, боксёрларны тар-мар итү аның эше икәне беленгәч, Пёс Молодой ант биргән: «Профессорны барыбер иртәме-соңмы завалю!» – дигән.

– Шул үтерде дәме? – дип сорады Галимҗан, куркып кына.

– Әйе, шул адәм актыгы, – диде Зөлмәт. Аңа бу сүзләрне әйтүе авыр икәне, хәзер дә җан сызлаулары басылмаганы йөзенә чыккан иде. – Үзе генә түгел инде, Эдик Фарисов бандасы белән.

– Фарисовские, – дип куйды Хамис.

– Әйе, шулар.

– Теге Иосиф Гилбертны үтергән бандамы әле ул? – диде Галимҗан, нидер исенә төшерергә теләгәндәй.

– Кем ул Иосиф Гилберт? Нигә үтерделәр аны? Фарисовские дисезме? Алары кемнәр? – дип, сорау яудырды Диләрә.

– Нишләп, бер дә ишеткәнең юкмыни? – дип аптырады Хамис. – Бер ел элек аның турында бөтен газеталар язды, радиодан сөйләделәр,

телевизордан күрсәттеләр, үтүкне кушсаң, ул да сөйли иде «Сатурн-металл» директоры, депутат Иосиф Гилберт турында.

– Юк, мин бу турыда берни белмим. Газета укымыйм мин, телевизор карамыйм, – диде Диләрә.

– Короче, бу фарисовскийлар Гилбертны күзәтү астына алганнар, озак кына артыннан карап йөргәннәр. Кая бара, ниләр эшләп йөри дигәндәй, – Хамис тагын бик белдекле кыяфәт чыгарып, кулларын болгый-болгый сөйли башлады. – Шундый бер закономерность тапканнар: көн саен иртә белән эшкә барышлый Гилберт «Сатурн-металл»ның баш бухгалтеры Инна Виноградованы кереп ала икән өеннән. Ул шул ук коттеджный посёлокта, күрше урамда гына яшәгән. Түлке туры эшкә бармыйлар болар, көн саен диярлек Каргалы урманына тукталалар. Менә шунда эләктергәннәр инде Гилбертны тёпленьким, – дип гыргылдап көлде Хамис.

– Сансыз! Авызыңны чамалабрак ач инде, мәрхүмнәр турында сөйлисең бит син! – дип ачуланды Галимҗан.

– Дөресен сөйлим бит инде? Тагын ничек сөйлисең инде аны?! – диде Хамис һаман көлүдән туктый алмыйча.

– Фарисов бандитлары полицейский формасын кигән булганнар, – дип аңлата башлады Галимҗан Диләрәгә. – Гилберт белән Виноградованы машинага утыртып, Идел ярына алып киләләр, аннары моторлы көймәдә «Барон» теплоходына илтәләр. Бер миллион доллар түләмәсәгез, үтерәбез, дип яныйлар. Гилберт эшенә шылтырата. Мин Мәскәүдә командировкада, ди, бер миллион доллар күчерегез миңа хәзер үк, ди. Хезмәттәшләре аптырап-шикләнеп калалар, чөнки Гилберт командировкага китүе турында беркемгә берни әйтмәгән, документлар тутырмаган була. Өстәвенә Виноградова да югала бит инде. Гилберт үзе әйткәч, акчаны күчерәләр болар күчерүен, тик шул ук вакытта полициягә шалтыратып, үзләренең шикләрен дә сөйләп бирәләр. ФСБ да шундук бу эшкә кушыла. Тик тоткыннарны азат итәргә җитешмиләр. Акча килү белән Гилберт белән Виноградованы бер утрауга алып киләләр, анда алар өчен чокыр казылган була инде. Шул чокыр янына бастырып куялар да атып үтерәләр. Аннары күмеп куялар. Виноградованың бармакларында бриллиантлы йөзекләр, муенында алтын муенса, аңа бриллиантлы асылмалы бизәкләр эленгән була. Берсенә дә тимиләр, шул килеш күмәләр.

– Тоттылармы соң ичмасам бу ерткычларны? – диде Диләрә, күз яшьләрен сөртеп.

– Әйе, утыралар, – диде Зөлмәт. – Күпме әйтте аңа Профессор, күпме әйтте!

– Нәрсә диде? – Диләрә Кадыйр турындагы һәрбер сүзне йотлыгып, аеруча зур игътибар биреп тыңлый иде.

– Эдик Фарисовны – кличкасы Харя – Профессор юктан тук итте, кеше рәтенә кертте, – диде Зөлмәт. – Үз башына!

– Кеше – тун җиңе түгел шул, йә дигәнче әйләндереп карый алмыйсың, – дип куйды Галимҗан.

– Кем иде соң ул? – дип сорады Хамис.

– Беркем дә түгел, түп-түгәрәк ноль! – диде Зөлмәт ачу белән. – Аның атасының абыйсы Профессорның дусты булган. Төрмәдә утырганда, Кадыйрның кулларында үлгән. Ну, шулай итеп әкренләп кереп киткән иде

бу Харя урлашу юлына. Профессор аңа бригада туплап бирде, аннары да гел булышып торды. Берзаман Харя шоколад фабрикасы директоры белән конфликтка керде. Тегесенең акча түлисе килмәде крыша өчен. Ахыр чиктә Харя урлады бу Твиксны.

– Кемне? – дип сорады Галимҗан.

– Шоколад фабрикасы директорының кличкасы шундый иде, – дип дәвам итте Зөлмәт. – Иделдәге утрауда тоттылар моны атна-ун көн. Акча күчергәч, өенә кире кайтармакчы булганнар да, бу Твикс үзе – нәрсә уйлагандыр инде ул, качмакчы булды микән?! – фарисовскийлар белән сугыша башлаган. Шунда берсе пычак белән чәнчеп үтергән аны. Ә акча бит килгән счётка! Әйбәт кенә сумма! Шуннан Харя эрерәк балыкка кармак салмакчы булган, Гилбертны күзәтү астына алган. Ә ул бит депутат! Эшмәкәр генә түгел, хөкүмәт кешесе. Аңа кул күтәрү – кирәкмәгән дуамаллык, чөнки депутатны яклауга дәүләт бөтен булган куәтен җигәчәк. Профессор Харяга шуларны аңлатырга тырышты, тик...

– Аңламадымы шуны, дурак? – диде Хамис.

– Чама хисен югалтты Харя, ис сизми башлады, чикләрне чамалаудан туктады, полициянең, гомумән, беркемнең дә аңа теше үтми барыбер, дип уйлады, күрәсең. Юкса атасы урынына калган Кадыйрга кул күтәрмәс иде...

– Кадыйр Гилбертка тимәскә кушкан идемени Фарисовка? – дип сорады Хамис.

– Әйе, – диде Зөлмәт. – Ә Харя икесен дә юк итәргә карар кылган: Гилбертны да, Профессорны да. Шундый ул, кеше өстенә кояш белән айны да чыгармас иде, көченнән килсә.

– Пёс Молодой белән дигән идең? – Илгизәр тагын идәндәге бер ноктага төбәлеп утыра иде.

– Белмим ничек табышкандыр алар, тик Профессорны үтерүгә бик җентекләп әзерләнгәннәр, – диде Зөлмәт. – Кадыйр «Артемида» ресторанында еш була иде. Пёс Молодой оптикалы мылтык белән урамның икенче ягындагы йорт түбәсендә Профессорның чыкканын сагалап яткан. Ничә тапкыр аткандыр, тик Кадыйрга ике пуля тиде. Без аны шундук машинага этеп-төртеп керттек, шофёрга тизрәк больницага чабарга куштык, хәзер артыгыздан килеп җитәбез, дидек. Кадыйрның машинасы кузгалып та китте, шартлап күккә дә очты... Барысын да җентекләп уйлаганнар! Хәтта без Профессорны машинага утыртмыйча кире ресторанга алып кергән булсак та, анда да шартлатырлар иде. Ресторан ишеге янында стенада эленеп торган брада мина таптылар соңрак...

Күпмедер дәшми утырдылар.

– Мондый чакта бер дога кылырга кирәктер дә инде, – дип, беренче булып телгә килде Галимҗан. – Белмибез шул беребез дә догаларны...

– Кайда күмдегез Кадыйрны? – дип сорады Диләрә. – Ичмасам чын каберен барып күрим... Чәчәкләр салыр идем.

– Күмерлек әйбер калдымы соң анда? Машина күккә очты, дисең бит? – дип сорады Хамис.

– Чын кабере юк Кадыйрның, – диде Зөлмәт, авыр сулап. – Кадыйр үзе васыять әйтеп калдырды: «Үлгәч, минем гәүдәмне яндырып, көлен Чуртан тавы өстенә таратырсыз», – диде.

– Тараттыңмы соң?

– Әйе.

– Ничек?

– Оча торган шар ялладым. Матур иде шундый! Зу-у-ур, ап-ак.

Диләрә тагын үкси-үкси елый башлады.

Оча торган шар турында сүз чыккач, Галимҗан имәнеп китте һәм тагын көзгегә карады. Бу юлы анда кышкы каен урманы күренә иде. Бөтен җир ап-ак, ябалак-ябалак кар ява. Урман уртасында көрткә баткан ак бия басып тора иде. Аның янына чаңгыда спорт костюмы, шлемнар кигән Михаэль Шумахер килеп туктады да аркасындагы рюкзактан аракы шешәсе чыгарып, бияне сава башлады. Бия исә күндәм генә бер урында басып торырга теләмәде, гел йөреп торды. Берзаман ул урман уртасында ике каен арасына утыртып куелган әбрәкәй янына барып җитте. Бәдрәфтән Кристиан Диор килеп чыкты да бер кулы белән атны йөгәненнән тотты. Аның икенче кулында шайтан таягы иде, бия бик тәмләп шуны ашый башлады. Ул арада болар өстеннән себеркегә атланган Диләрә сызгырып очып узды. Бу юлы ул бөтенләй шәрә, бары «Miss Universe» дип язылган тасмасы гына калган иде. Диләрә урман өстендә берничә әйләнеш ясады да уракка охшап торган айга менеп утырды. Ай күктә кояш белән янәшә эленеп тора иде. Диләрә каяндыр бер кап «Күгәрчен сөте» дигән кәнфит тартып чыгарып, телләрен ялый-ялый ашарга кереште.

## 12. Бәхетле булырга ярамый микәнни?

– Минем бер генә сорау калды? – диде Илгизәр. Ул идәнгә текәлеп утырган җиреннән башын күтәреп, Зөлмәткә карады. – Хамис әйткәндәй, причом монда майор, практикантка һәм контракт?

Хамис белән Галимҗан нидер исләренә төшереп шундук җитдиләнделәр, гәүдәләрен турайтыбрак утырдылар.

– Ә минем сораулар бик күп әле, – диде Зөлмәт. – Хәзер Мерлезон балетының икенче өлешенә күчәбез.

– Нинди балет тагын? – диде Хамис.

– Тынычлан, Хамис. Зөлмәт шаяртып әйтә, юмор ул шундый, – диде Илгизәр. Аннары тагын Зөлмәткә таба борылды: – Нинди сорауларыгыз калды безгә?

– Ә сез белмисезме?

– Кешенең күңеле – океан, аның нинди генә уйлары булмас? – диде Илгизәр.

– Ярар алайса, бер ишарә биреп карыйм. Кадыйрның туган көнен тагын бер исегезгә төшерегез әле? – диде Зөлмәт, күзләрен кыса төшеп.

Илгизәр белән Диләрә бер-берсенә карашып куйдылар.

– Дөрес чамалыйсыз, – диде Зөлмәт аларга. – Кадыйр белә иде сезнең ул кичтә...

– Син сөйләдеңмени, сарык?! – диде Диләрә Илгизәргә ачу белән.

– Мин беркемгә берни сөйләмәдем!

– Сөйләмәдең! Каян белгән соң алайса Кадыйр?

– Мин каян белим?!

– Мин чё то не догоняю! Ни турында сөйлисез сез? – диде Хамис.

– Мин беләм, – диде Зөлмәт. – Аңларсыз микән инде?.. Хикмәт шунда, төрмәдә кешенең вакыты нык күп. Ул узмый берничек тә, ул аны кая куярга белми интегә. Вакыт уздырыр өчен кеше әллә ниләр эшләргә әзер. Гомер уйламаган кешеләр шигырь яза башлый, мәсәлән. Ә ни өчен шулай? Чөнки баш икенче төрле эшли башлый. Менә шулай бер уйланып ятканда, Кадыйр исәпләп чыгарган сезнең икегезнең аңа хыянәт иткәнен. Аның туган көнендә.

– Ничек? – диде Диләрә һаман ышанасы килмичә.

– Болайрак сөйләде инде ул, кыскасы, – диде Зөлмәт. – Туган көн мәҗлесе бетеп, кеше таралгач, бүлмәдә Диләрә белән икебез генә калдык, диде Кадыйр. Малайлар кайсы кая таралып бетте, кызлар озатыргадыр инде, диде. Әйбәт кенә сөйләшеп торган җирдән талашып киттек Диләрә белән. Әлеге дә баягы, сары шайтан таягы, дигәндәй, акчадан чыкты инде ул талаш, дип сөйләде Кадыйр.

– Әйе, әйе, Кадыйр сүзләре бу! – дип куйды Галимҗан. Ярата иде ул шулай дип кабатларга: Әлеге дә баягы, сары шайтан таягы!

– Бүлдермәле, Буржуй! – дип ырылдады Хамис.

– Менә кем ул шайтан таягы! – дип үпкәләде Галимҗан.

– Җитте инде, җитте! Булды! – дип кычкырды аңа Хамис. – Брат, давай, дальше сөйлә. Бик кызык булып китте әле бу!

– Сиңа кызык инде, – диде Галимҗан, – кызык булмыйча соң!

– Бүләккә, гадәттә, конвертка салып, акча бирәләр бит инде күбесенчә, – дип дәвам итте Зөлмәт. – Мин ул конвертларны ачып та карамыйча Диләрәгә биреп бардым, дип сөйләде Кадыйр. Күпме акча бүләк иттеләр соң, дип сораган идем, Диләрә, белмим, санамадым, ди. Бир үзем саныйм дигән идем, үпкәләде бу, мин синең акчаңа тимим инде, ышанмыйсыңмыни миңа, дия башлады. Мин дә кызып киттем, ул да кимен куймады, пәрмәпәр килеп талашып беттек без салган баштан, диде Кадыйр. Әйтмәгән сүз калмады бер-беребезгә, диде.

– Синең аркада ул, Сансыз! – дип куйды Диләрә.

– Ничек инде минем аркада?

– Соң сиңа биргән бит Диләрә Кадыйрның акчаларын! Теге егылып аракыларны челпәрәмә китергәч! – диде Галимҗан.

– Ә-ә-ә!!! Вон оно чё! – дип куйды Хамис. – Ә юк, туктагыз әле?! Причом монда мин? Мин Диләрә белән үбештем генә! Әнә Штирлиц ниткән бит!

– Кыскасы, Кадыйр психланып, урамга чыгып киткән, – дип дәвам итте Зөлмәт. – Диләрә өстәл җыештырып, бүлмәдә калды, диде. Әзрәк тынычланганчы, суынганчы урамнарны ураган да ул кире кайткан. Бүлмәгә кермәкче булган идем, бикле, ди. Шакымакчы гына булган идем, карават шыгырдаган, ятакта гына чыга торган ыңгырашулар ишетелде, ди. Илгизәр кызын алып кайткан икән, дидем дә, тагын урамга чыгып киттем инде, диде Кадыйр. Бер сәгать чамасы узгач, кайтсам, Хамис белән Галимҗан да кайтып, йөзенче төшләрен күреп, пос-пос йоклап яталар иде, дип сөйләде Профессор.

– Шушының нәрсәсе шикле тоелган инде аңа? – диде Илгизәр.

– Икенче көнне, – дип дәвам итте Зөлмәт, – лекцияләргә барырга җыенып йөргәндә, Диләрә килеп керде, диде Кадыйр. Малайлар, мин кичә

туган көндә сездә үземнең муенсамны калдырганмын, дип, Илгизәрнең тумбочкасы өстеннән асылма бизәк – алтын ярымай тагылган цепочкасын алып чыгып китте, ди. Ул вакытта Кадыйр моңа әллә ни игътибар бирмәгән. Ләкин төрмәдә чакта, шул туган көнен кат-кат исенә төшергәндә, ул бер нәрсәне аңлаган. Сез, Диләрә, ул ярымайлы муенсагызны бер дә салмыйча диярлек киеп йөргәнсез. Эсседә дә, суыкта да, дигәндәй. Хәтта берсендә бергәләп, саунага кергән идек, анда утырышлы түгел иде, борын-колак очлары пешә иде, шунда да салмады ярымаен, дип сөйләде Кадыйр. Сез, Диләрә, аны бер очракта гына сала торган булгансыз... «Ярамый бит кияүгә чыкканчы, гөнаһ!» – дип әйтә торган булгансыз. Төрмә нәчәлнигын бәлки бик теләгәндә, гафу итәргә дә булыр иде, ни өчен дигәндә, Диләрә ул очракта минем хакка, безнең мәхәббәтебез хакына корбан биргән, тик Илгизәр белән хыянәтен гафу итә алмыйм, диде Кадыйр.

– Ә ул бит хыянәт түгел иде! – дип куйды Диләрә.

– Ни иде соң ул? – дип сорады Зөлмәт.

– Улмы? Ул... Ул шундый бер мизгел генә...

– Ярата идеңмени, Диләрә? – диде Галимҗан хатынның гамәлен аңларга, аның хәленә керергә тырышып.

– Юк ла инде! – дип куйды Диләрә. – Илгизәр, гафу ит! Хыянәт түгел бу, аңлыйсызмы, бу бөтенләй башка нәрсә! Сез менә күз алдына китерегез: шәраб башка бәргән, кан кызган, күңелдә Кадыйрга ачу кайный, аңа үч итеп, нидер эшлисе килә. Шунда бүлмәгә Илгизәр кайтып керә, күзләрен мөлдерәтеп карап тора сиңа. Ә сәгать телләре келт тә келт, вакыт уза, тиздән Кадыйр булмаса башка берәү килеп керергә мөмкин бүлмәгә! Икең дә бер сүз дә дәшмичә аңлыйсың – менә хәзер генә, бер генә мәртәбә параллель дөньяга, белмим, башка галактикага барып кайтырга була. Анда икебездән башка беркем дә юк, анда рәхәт! Һәм бу сәяхәт турында беркайчан да, беркем дә белмәячәк! Белергә тиеш түгел иде...

– Илгизәр, ә син бит бүген беренче мәхәббәтең белән үбешү турында сөйләгәндә, андый рәхәтлекне минем бүтән беркайчан да тойганым юк, каядыр очып китәсең, мин гомерем буе аның белән очарга риза идем, дидең. Син Диләрә турында әйттеңме?

– Әйе, Диләрә турында, – диде Илгизәр теләмичә генә.

– Нишләп шундый көйсез соң бу дөнья?! – дип, авыр сулады Галимҗан.

– Нәрсәсе көйсез? – дип сорады Хамис. – Ни дип әйтмәкче буласың син, Буржуй, чё то тагын не догоняю мин?

– Сөйли китсәң, озак инде ул, – дип авыр сулады Галимҗан.

– Ә безнең бүген вакыт до фига! Без бүген беркая да ашыкмыйбыз, Штирлиц әйтмешли, – диде Хамис, көлеп.

– Бик нечкә тема инде бу, дулкынландыра, күңелгә бәрә торган тема, – диде Галимҗан. – Ышанасызмы, юкмы, менә хәзер, бу турыда сөйләргә җыенгач та, тез буыннарым калтырый башлады, аркам тирләп чыкты. «Нишләтәсең, язмыш!» дип авыр сулыйсы гына кала, анасын саткыры!

– Охо! Синме бу, Буржуй?! – дип куйды Хамис. – Әллә чыннан да сүгендең инде?

– Хамис, үтенеп сорыйм, бүлдермә, зинһар, болай да зиһенем чуалган чак, – диде Галимҗан. Аннан бераз нидер исенә төшереп утырды да сөйләп

китте: – Кыскасы, җиденчеме, сигезенчеме класста укый идем мин. Район үзәгенә чаңгы ярышларына алып барганнар иде... Кыш. Каен урманы. Бөтен дөнья ап-ак, чип-чиста! Каеннарның кәүсәләре дә ап-ак, аларның ботаклары да, шуларның кайберләренә яткан кар бүрекләре дә, каеннар арасына ясалган чаңгы юлы да – барысы да, барысы да ап-ак. Ябалак-ябалак кар ява. Шундый зур, эре кар бөртекләре уйнап йөри һавада, тирә-як шундый матур, әйтерсең лә, бу өн түгел, төш, әйтерсең лә, син ниндидер әкияткә эләккәнсең. Һәм шушы матурлык уртасында – бер могҗиза!

Гүзәлләрнең гүзәле диләр бит? Менә шунда аңладым мин ул сүзләрнең ни аңлатканын. Күрсәгез иде сез ул кызны! Бу дөньяда андый чибәр кыз була алмыйдыр кебек иде миңа. Ул каяндыр башка дөньядан, бүтән планетадан – белмим, Айдан сикереп төшкән Зөһрә кыз кебек иде. «Искиткеч чибәр!» – дисәң дә, берни әйтмәгән кебек инде аның күз явын алырдай матурлыгын, гаҗәеп гүзәллеген аңлатыр өчен. Бик сөйкемле ул үзе, аңардан нәфислек бөркелеп тора, таң калырлык инде менә! Таң калырлык! Искиткеч!

Син аңа берничек тә игътибар итмичә калалмыйсың. Шул секундта, шул минутта, шул вакытта ул кыз дөньяның үзәге иде. Аны ниндидер дуслары сырып алган, алар ясаган түгәрәк уртасында басып тора иде ул. Үзе генә түгел, киеме дә таң калдырырлык иде аның. Үзегез беләсез, без бит инде сәвит балалары, дефицит чоры балалары, авыл балалары әле, җитмәсә тагын. Безнең өстә... Юк, алай җыртык-портык әйбер түгел иде, тик иске булмаса да, шул сәвит чыгарган спорт костюмнары иде инде: кемнекедер кара, кемнекедер зәңгәр. Ә аныкы ак иде! Ап-ак! Мамыклы бияләйләре дә ап-ак, башындагы бәйләнгән башлыгы да ап-ак, шул башлык очындагы зур йомры шар да ап-ак. Помпон диләрме әле аны? Ә озын көдрә чәчләре чем кара иде. Сызылып киткән кашлары да, очып китәргә әзерләнгән кебек бөгелеп торган керфекләре дә кара, чиксез тирән күзләре дә шомырт кара иде.

Аһ, ул күзләр! Ниндидер тылсым бар иде кебек аларда. Аларны бер күргәч, аерыла алмыйсың, алар сине кол итәләр, сихерләнгәндәй, шуларга карап сокланып тора башлыйсың. Белмим, исәрләнеп күпме торганмындыр, бәлки әле тагын бик озак шулай дәвам итәр иде, тик ничектер очраклы гына аның карашы миңа төште. Мин шундук икенче якка борылдым. Ник борылдым – белмим. Ә юк, беләм инде хәзер. Чөнки миңа алиһә караш ташлады, ничек аның белән күзгә-күз карашып тормак кирәк? Мин куркып кына, аңа сиздермәскә тырышып, тагын бер мәртәбә аның ягына күз ташладым. Ул елмая иде. Елмайгач, ул тагын да гүзәлрәк, мең, миллион, миллиард тапкыр чибәррәк тоелды.

Бу көн, бу вакыйга, бу очрашу, бу могҗиза, бу алиһә минем көнкүрешемнең астын өскә китерде, мине ниндидер бер яңа үргә менгерде, минем тормышымның яңа сәхифәсенә үзенә күрә бер күпер кебек булды. Мин башка кешегә әйләндем: бу көнгә кадәр бер төрле идем, аннан соң бөтенләй икенчегә әйләндем. Ышанасызмы-юкмы, мин шигырьләр яза башладым. Чын шигырьдән бик ерак иде алар, әлбәттә, тик, шуннан аңлагыз инде күңелемнең ул чактагы халәтен. Малайлыктан егетлеккә адым ясавым булгандыр бу, мөгаен.

Түшәмдә бер нокта табып, шуңа сәгатьләр буе карап уйланып ята торган хыялый бер кешегә әйләндем мин. Тәнем әллә нишләде: аяк-кулларым

ничектер сызлап кытыкланган сыман иде. Әйтерсең лә, тән аркылы бик көчле булмаган ток җибәргәннәр һәм шунлыктан нервлар соңгы чиккә кадәр тартылган. Берничек тә, нишләсәң дә узмый торган, интектергеч һәм шул ук вакытта ниндидер бер үз рәхәтлеге булган халәт иде ул.

Ә тагын нинди генә җыр тыңласам да, ул җыр минем белән аның турында сыман иде. Нинди генә фильм карасам да, анда уйнаган актриса аңа охшаган кебек иде. Ә урамнан атлап барганда, тыкрыктан кинәт ул килеп чыгар сыман иде...

Вакыт – иң яхшы дәва, диләр. Тора-бара мин аның турында сирәгрәк уйлый башладым, тик шулай да бу кыз минем күңелдәге бик якты, чиста, нәфис бер хатирә, онытылмас бер образ булып калды. Ә биш ел узгач, ышанасызмы, без тагын очраштык!

Мёрфи закон дигәнне дә беләсез бит инде, шулай бит? Гомергә бер эшкә соңга калып килсәң, каршыңа әбизәтелне нәчәлник очрый. «Тфү-тфү!» – дип агачка кагасың килсә, якын-тирәдә бөтен нәрсә металл, пластик, пыяла һәм катырылган опилкадан ясалган булып чыга, агач табалмый интегәсең һәм башкалар, һәм башкалар. Шушы кабахәт законның тагын берсе бар: диңгез буенда ял иткәндә, пляждагы иң шәп, иң чибәр кыз син иртәгә китәм дигән көнне генә пәйда була.

Җәйге каникулны авылда үткәрдем. Август азагы җитте, кире Казанга укырга китәргә кирәк. «Хушлашу гастрольләре» сыман әйбер ясарга булдык без малайлар белән: өч-дүрт матайга төялеп, якын-тирә авылларны урап кайтырга булдык. Зерәгә бензин яндырып кына йөрдек түлке, бер кызык та булмады ул төндә. Кызыгы иртән булды аның! Чәй эчеп утырабыз энекәш белән. «Их, кичә клубта син булмадың! Бер чибәр кыз чыккан иде, Наил абыйларга кунакка кайткан», – ди бу. «Ярар, карап карарбыз кич белән», – дим. «Кич белән проблемалар килеп чыгарга мөмкин. Бүген җомга, шәһәрдән егетләр күп кайта кунакка», – ди энекәш. Нишләргә соң? Озак уйлап-нитеп тормадым, тоттым да юк йомышымны бар итеп киттем мин Наил абыйларга.

Килеп керсәм – ул! Ишетәсезме сез, теге каен урманындагы могҗиза, алиһә!.. Нидер әйткән булдым инде мин Наил абый белән Нурия апага, нидер сөйләндем инде шунда, хәтерләмим ни икәнен. Алар да җүләр түгел инде, аңлыйлар минем нигә килгәнне.

«Менә кунак кызы бар бит әле бездә, – ди Наил абый, булмаган мыегы астыннан гына елмаеп. – Таныш булыгыз – Зөһрә».

Зөһрә исемле икән бит ул... Айдан төшми каян төшсен инде мондый кыз?! Бик мәзәк һәм көлкеле кыяфәттә булганмындыр инде мин ул чакта. Чөнки бөтенесе миңа карап елмаялар иде: Наил абый да, Нурия апа да, Зөһрә дә. Ул миңа карап елмая иде...

«Менә Зөһрә кичә клубта егетләр тапмаган бит әле, – дигән була Наил абый. – Син, кем, ни, күрше, – ди бу миңа, – бүген кичен кереп ал инде аны, яме, клубка чыкканда. Йә адашыр, барып җитә алмас өч өй аркылы», – ди Наил абый, үзе һаман елмая.

Миңа шул кирәк иде бит инде! «Ярар, керермен!» – дидем дә чыгып очтым мин.

Кич җитте. Ә юк, җитмәде, каян җитсен?! Андый чакта вакыт гел узмый икән ул, сәгать телләре юри әкрен йөргән кебек. Йөрәк җилкенә, йөрәк

ярсый, йөрәкне ут алды, кан кайный, җаным тәнгә сыймый, ничектер үзенә урын тапмаган, менә-менә сикереп чыгар сыман иде. Энекәш миңа карап: «Нишләдең син?» – дип аптырап әйтеп тә куйды хәтта. «Нишләдең, нишләдең! Үскәч белерсең!» – дим.

Алга таба ниләр булганын ничек итеп сөйләргә дә белмим. Күз алдына китерәсезме, бу минем гомеремдәге иң бәхетле көннәрнең берсе, бәлки, иң бәхетлеседер, тик мин ул көнне, дөресрәге, төнне хәтерләмим диярлек. Юк, алай да кайбер нәрсәләр күз алдына килә. Култыклашып, клубка кергән истә – анда кеше мыжгып тора иде! – бөтенесе авыз ачып, безгә карап тордылар. Зөһрә белән биегәнебез, авыл урамнары буйлап йөргәнебез, Наил абыйларның капка төбендәге эскәмиядә таң ата башлаганчы пышылдашып утырганыбыз истә. Ни сөйләшкәнбездер, хәтерләмим... Хәер, сөйләшүдән күбрәк, үбештек бугай без... Андый чакта сүзнең кирәге бармы соң инде...

Ә! Тагын бер нәрсә истә! Гел: «Миңа керергә кирәк инде», – дип пышылдады ул. Үзе минем тездә утыра, торырга җыенмый да. Керергә кирәк, дип әйтүе дә миннән: «Тукта, утырыйк инде әзрәк», – дигәнне ишетер өчен генә әйтелгән сыман иде. Аерылышасы килми бит бер дә! Миңа икенче көнне Казанга бит, ул да китә авылына, аның әле тагын бер ел мәктәптә укыйсы бар.

Хат алышырга вәгъдәләштек. Казанга укырга кил, дидем мин. Тырышырмын, диде ул. Берзаман ишегалдыннан Наил абыйның ачулы тамак кырганы ишетелде. Зөһрә сикереп тә торды, кош кебек пырхылдап очып кереп тә китте.

Икенче көнне Казанда идем инде. Сезгә студент тормышының ни икәнен аңлатып торасы юк инде: дискотекалар, концертлар, ШТК, спектакльләр, туган көннәр – бөтен җирдә кызлар кайнап, мыжлап тора! Зөһрәгә берничә хат язып салдым, Яңа ел, 8 Март бәйрәмнәре белән котлап, открытка җибәрдем.

Теге кичтән соң бер ел узгач, Зөһрә Казанга укырга килде. Аңардан хат алдым, «мин фәләненче тулай торакның төгәненче бүлмәсенә урнаштым», дип язган иде. Мин бит инде бу хәбәрдән соң кош тоткандай йөгерә-йөгерә шунда барырга тиешле кеше идем югыйсә. Тик нигәдер бармадым. Һаман саен ниндидер эш килеп чыга торды. Югыйсә күңелемдә аңа тартылу бар иде. Ник шундук бармадым, хәзер дә аңламыйм. Кара көзгә кергәч кенә, көннәр бик салкынайткач кына бардым мин аның янына.

«Птичье молоко» дигән кәнфит алып барган идем күчтәнәчкә. Шуңа исе китте инде Зөһрәнең! «Каян белдең минем бу кәнфитне яратканны?!» – дип аптырады. Тәмлене кем яратмый инде?!

Дүрт кыз бер бүлмәдә торалар иде. Бишәүләп чәйләр эчеп сөйләшеп-көлешеп утырдык озак кына. Аннары икесе каядыр җыена башладылар. Зөһрә аптырап сораган иде: «Кая җыенасыз?» – дип, берсе әйтә: «Апа әллә кайчан кунакка чакыра инде, без бүген барырга булдык аның янына, кунып калырбыз, мөгаен, төнлә кайтып йөрмәбез», – диде. Үзе миңа сиздермәскә тырышып, Зөһрәгә күз кысты һәм баш бармагын күрсәтте. Шәп(!) егет каптыргансың, янәсе. Хәзер генә уйлап утырам, вакыт шактый соң иде инде, кая апаларына барсыннар инде төн җиткәндә?! Күрше бүлмәгә кереп йоклагандыр инде. Без икебез генә калсын дип...

Тик без икебез генә калмадык. Өченче кыз – каядыр күргән дә бар

сыман үзен – беркая да китәргә җыенмый иде. Минем дә китү турындагы уй башыма да кереп карамады. Зөһрә дә урынын җәеп, мине үз янына яткырды. Болар барысы да ничектер бик табигый, шулай булырга тиеш кебек кабул ителде ул чакта.

Утны сүндергәч, теге Наил абыйлар капка төбендәге очрашуның икенче сериясе башланган кебек булды. Нидер турында пышылдашып яттык, күбрәк үбештек инде... Тик шуннан артык берни дә булмады. Мин анда талпынып карадым инде үземчә, тик Зөһрә... Менә сез күз алдына китерәсезме, кыз үзе урыннар җәеп, үзе сине янына яткыра, тик үбешүдән артык берни ярамый! Шуңа үпкәләдем микән инде мин, җүләр?..

– Булмадымыни?! – Хамис бүлдерми түзә алмады.

– Кыскасы, икенче мәртәбә Зөһрә янына би-и-ик озак вакыт узгач кына бардым мин. Килеп керсәм, бүлмәдә бер егет чәй эчеп утыра, ә кызлардан Зөһрә үзе генә. Мин егет алдындагы чәшкене чәй тәлинкәсе белән каплап куйдым да: «Апаңа рәхмәт әйт тә, чыгып кит әле син, брат, безнең сөйләшәсе бар иде», – дидем. «Мин беркая да чыкмыйм», – ди бу. Күзләрен күтәрми үзе, чәшкегә карап каткан. Ярар алайса, дип, мин Зөһрәне коридорга чакырып чыгардым. «Җыен әйдә, киттек», – дим. Кая, ди. «Әгәр җир читенә дисәм, барасыңмы соң?» – дим. Юк, ди. Борылдым да киттем мин. Өзелде шуның белән...

Юк, алай да вакыт-вакыт Зөһрә искә төшкәли иде, тик ул, беләсезме, ничектер берничә секундка гына күзалдына килә дә, аннары уйлар тагын башка нәрсәгә күчә иде. Тора-тора гел онытылды инде. Шулкадәр нык онытылган...

Болай булды ул, кыскасы! Хатын белән балаларны авылга кайтардым да шәһәргә үзем генә киттем. Ярты юлда, Карлыгач авылы башында, бер хатын тора юлда кечкенә малае белән. Машинаны туктатып утырттым мин боларны. Киттек шәһәргә. Малае белән сөйләшеп бара бу, тегесе әллә ниләр сорый: «Яфраклар нигә яшел? Күк нигә зәңгәр?» Әнисе иренмичә җайлап кына аңлата. Үзе ничектер бу эшне автомат рәвештә эшләгән кебек. Мин көзгегә юк-юк та карап алам, аның карашы әллә кая еракка, юл кырындагы басулар читенә юнәлгән. Каядыр күргән дә бар сыман үзен. Шул малае белән сөйләшеп утырган җирдән кисәк кенә әйтеп куйды бу миңа: «Син Зөһрәне хәтерлисеңме?» – ди. Мин җүләр аны-моны уйламыйча: «Кайсы Зөһрәне?» – дидем. «Нык көтте инде ул сине... Би-и-ик озак көтте», – ди.

Мин әле һаман берни аңламыйм, ашыга-ашыга кайчандыр таныш булган Зөһрәләрне искә төшерә башладым. Ишетәсезме, мин аны онытканмын! Кайчандыр алиһә итеп күргән кыз минем тормышымнан, хәтеремнән, уйларымнан төшеп калган!

Тагын көзгегә карадым. Шунда искә килеп төште бит бу хатынны кая күргән бар икәне! Общагада Зөһрә белән кунган төнне бүлмәдә тагын бер кыз бар иде, дип сөйләдем бит? Менә шул бу! Димәк, алар һаман да аралашалар, димәк, алар һаман дуслар, димәк, Зөһрә мине һаман да ярата. Күз алдыңа китерәсезме, мин күктәге йолдыз дип, мәңге буй җитмәслек дип кабул иткән кыз мине ярата, ә мин... Җүләр инде, җүләр!

– Маладис, признал наканис, – дип кыстырды Хамис.

– Ну, сораштырдым инде мин бу хатыннан Зөһрә турында. Бухгалтер булып эшли икән, ире белән ике малай үстерәләр, тегесе-монысы... Аннары

интернеттан кереп карадым – хәзер җайлы бит, бөтен кешене шуннан табып була. Теге классташлар сайтында бик күп фотолары бар. Бөтен тормышы җитеш: үз йорты, ире, балалары, юбилейлар, фото астындагы язуларда дуслары-туганнарының котлаулары, матур теләкләре, комплиментлары, тегесе-монысы. Сизми дә калганмын, хатын да минем янга килеп карап тора икән. Зөһрәнең иренең фотосын күрде дә: «Кем бу? Әллә берәр ерак туганыңмы? Бигрәк сиңа охшаган», – ди. Җентекләбрәк карасам, чыннан да бар икән охшашлык ниндидер... Их, Зөһрә, Зөһрә... Күрсәгез фотоларын! Бөтенләй үзгәрмәгән, дисәң дә, бер дә ялган булмас. Тик күзләре генә бик моңсу. Ниндидер иксез-чиксез сагыш бар аларда, әйтерсең лә, бу тормышта ниндидер коточкыч зур үкенече бардыр сыман. Мондый тормыш турында хыялланмаган идем бит мин, дип әйтәләр кебек алар.

Менә, кайсыгыз белә? Нигә кеше шундый кабахәт, мәнсез, акылсыз һәм дуамал зат ул? Баш белән уйлап карасаң, мин бит үлеп гашыйк идем ул кызга?! Аллаһы Тәгалә аны минем юлыма чыгарып куйган иде. Җитәкләп дә алга таба бергәләп атлап кит кенә бит инде югыйсә?! Юк, кешегә нигәдер үзенең яшьлек хыялларын пычракка салып таптарга кирәк. Ник шундый без? Кеше бу дөньяга бәхетле булып яшәргә дип туадыр да бит, ләкин кемгәдер башкалар аяк чала, башкалар аяк чалмаса, кеше бәхетен үзе җимерә, соңгы кирпеченә кадәр ватып бетерә, тузанга әйләндерә. Ярамый микәнни кешегә бәхетле булып яшәргә? Ә, сез ничек уйлыйсыз? – дип сорады да Галимҗан тынып калды.

### 13. Кан тамызып ак сөткә...

– Җылырак, җылырак, Галимҗан, – диде Зөлмәт, хәйләкәр елмаеп.

– Аңлап бетермәдем? – диде Галимҗан, чәчләрен маңгаеннан артка сыпырып.

– Әйе! Нәрсә җылы-салкын? Аңлатып сөйләш! – диде Хамис.

– Сезнең бу хикәятне сөйләвегез бик әйбәт булды әле, – диде Зөлмәт, Галимҗанга карап. – Безнең сөйләшүгә дөрес... тон дип әйтимме, атмосфера бирде, димме... Кыскасы, алга таба да сөйләшү шушы дулкында барса, һәркем ихлас күңелдән, чын йөрәктән сөйләсә, бик яхшы булыр иде.

– Ни турында? – дип сорады Илгизәр.

– Хәтерегездә Кадыйрның туган көнен тагын бер яңартып карагыз әле шулай да, – диде Зөлмәт. – Анда бит тагын бер зур, онытылмаслык вакыйга булган.

– Онытылмаслык булса, минем истә калыр иде! – диде Хамис бәхәскә урын юк дигән сыманрак.

– Ә шулай да?!

– Ант эчүне әйтәсеңме әллә? – диде Диләрә, куркып.

– Өстенә бастыгыз, Диләрә ханым! – диде Зөлмәт, шатланып.

– Нинди ант эчү? Аракы гына эчтек без анда! – диде Хамис.

– Ә бит Кадыйрга ант эчүнең ни икәнен мин аңлаткан идем, – диде Галимҗан уйчан кыяфәттә. – Ничектер берсендә ялгышып «ант итәм» дип әйтәсе урынга, ул «ант эчәм» диде дә, мин аңа хатасы нидә икәнен сөйләп бирдем.

– А в чём разница? – диде Хамис.

– Ант бирү – ул бер генә кеше дә башкара ала торган нәрсә. Әйтик, солдатлар армиягә хезмәт итәргә килгәч ант бирә, – диде Галимҗан. – Ә ант эчү бер кеше катнашында гына була алмый. Безнең кайбер борынгы бабайлар, әйтик, ике кеше гомерлек дус булырга ант итешкәндә, шуның билгесе итеп кулларын кисеп, бер савыт кымызга каннарын тамызып эчкәннәр. Менә шул ант эчү дип аталган. Бу икәү яки өчәү булалармы, бишәүме – үзләренеке белән бергә иптәшләренең канын да эчкәч, кан кардәшләр хөкемендә булып, мәңге дус булып, хәтта бер-берсе өчен җан да биргәннәр. «Идегәй» дастанында, мәсәлән, «Кан тамызып ак сөткә, Ант эчешкән ир иде», дигән сүзләр бар. Шушыларны сөйләп биргәч, Кадыйр тел шартлатып: «Шәп йола бит бу!» – дигән иде.

– Әйе, аннары ул бу йоланы туган көнендә үткәрде, – диде Диләрә. – Каяндыр табып, энәләр дә алып кайткан иде. Исегездәме, теге кан биргәндә, бармак тишә торган энәләр? Мин шундый курыккан идем аны бармагыма кадарга!

– Ә-ә-ә! Искә төште хәзер! – дип кычкырып җибәрде Хамис. – Бер шешә аракыны сыра кружкасына салды да Кадыйр, һәрберебез бармагын тишеп, шунда ике-өч тамчы кан тамызды. Аннары эчтек шуны барыбыз да!

– Ә эчкәнче ни булды? – дип сорады Зөлмәт.

– Берни булмады? Ни булсын? – диде Хамис. – Туган көн булды, аракы эчтек. Аңа хәтле кансыз гына эчкән идек, соңгысын кан тамызып эчтек.

– Соңгысында аракы эчмәдек, ант эчтек, – диде Галимҗан.

– Хет терәп атыгыз, тик анты минем истә түгел! – диде Хамис.

– Кемнең исендә? – дип сорады Зөлмәт. – Илгизәр, бәлки сез хәтерлисездер?

– Хәтерлим әзрәк, тик бик төгәл түгел, чамалап кына әйтә алам, – диде Илгизәр.

– Мин дә шулай, – диде Галимҗан.

– Диләрә ханым?

– Мин дә.

– Гаҗәп! Ничек шуны онытырга мөмкин?! – диде Зөлмәт хәйран калып. – Беләсегез килсә, Кадыйр өчен бу, гомумән, аның тормышындагы иң зур, иң мөһим, иң хәлиткеч вакыйга!

– Аптыратма, брат, давай үзең әйт инде, барыбер безнең җүнләп искә төшми инде ул хәзер! – диде Хамис.

– Алайса, тыңлагыз! – диде дә, Зөлмәт телефоннан аудио кушты. Кадыйр тавышы ишетелде:

– Кадерле дуслар! Сез бүген мине котлап, бик күп матур сүзләр әйттегез, изге теләкләр теләдегез, бик зур рәхмәт барыгызга да!

– Бу бит Кадыйр тавышы! – дип кычкырып җибәрде Диләрә. – Искә төште! Мин бит аның тостын магнитофонга яздырган идем.

– Диләрә ханым, әйдәгез бергәләп тыңлыйк игътибар белән, яме, – диде дә Зөлмәт язманы яңадан кушты.

«Кадерле дуслар! Сез бүген мине котлап, бик күп матур сүзләр әйттегез, изге теләкләр теләдегез, бик зур рәхмәт барыгызга да! Минем дә сезгә әйтәсе бер сүзем бар иде. Без түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелдек!

Төгәлрәге, күтәрелеп киләбез, безне әле яулап аласы бик күп үрләр көтә. Алдыбызда – озын юл. Аны узу җиңел генә булмас, ул гел туры гына да бармас, борылмалы урыннары да күп булыр, тауларга да менәргә туры килер, ватык күперләр очрап, елгаларны үткел аша кичәсе дә булыр. Тик болар берсе дә безне куркытырга тиеш түгел, чөнки без чын дуслар һәм һәрвакыт бер-беребезгә ярдәм итеп, бер-беребезгә булышып, көч-дәрт биреп торырбыз. Мин бу дуслыкны ант эчү белән ныгытырга тәкъдим итәм. Тик минемчә дус булыйк дип кенә ант эчү безнең кебек егетләр өчен ваграк күренә. Безнең һәрберебез яшь, талантлы, белемле, зиһенле, без теләсә кайсы бурыч-максатларга ирешә алабыз. Әгәр син химик икән, Менделеев кебек химик элементлар таблицасын уйлап тап, шулай таныт милләтеңне дөньяда! Әгәр син педагог икән – Монтессори бул, тегүче икән – Кристиан Диор бул, галим икәнсең – Нобель премиясен ал, шофёр икәнсең – Михаэль Шумахер кебек бул. Сине, димәк, татарны, бөтен дөнья белсен! Шунлыктан, әйдәгез, кан кардәшләр хөкеменә күчкән бу сәгатьтә һәрберебез: «Мин бөтен булган көчемне, мөмкинлекләремне үземнең газиз татар милләтемне дөньяда таныту эшенә сарыф итәрмен, тормышымны шуңа багышлыймын!» – дип ант итик!» Антмы?

– Ант! – диде Галимҗан.

– Ант! – дип кабатлады Диләрә.

– Нинди ант турында сөйлисез сез?! – дип куйды Илгизәр. – Уен гына иде бит ул, Кадыйрның чираттагы шаяртуы!

– Сезнеңчә бу темага бу рәвешле шаяртырга ярыймы? – дип сорады Зөлмәт.

– Кадыйрга бар да ярый иде, беркем дә берничек тә тыя алмый иде аны, – дип җавап бирде Илгизәр.

– Ләкин ул бит шаяртмаган, чынлап ант эчкән ул кичтә! – диде Зөлмәт.

– Милләткә хезмәт итәм, гомеремне шуңа багышлыйм, дип ант иткәндә, аракы эчмиләр, – диде Илгизәр тыныч кына, салкын канлылык белән. – Цирк бит бу, шапито!

– Юк! Бу цирк түгел! – диде Зөлмәт, ярсый башлап.

– Цирк түгел, Илгизәр! Юк, уен-муен гына түгел бу Кадыйр өчен, – диде Диләрә. – Менә хәзер генә аңладым! Ул апасын Израильгә киткән өчен түгел, төгәлрәге, киткән өчен генә түгел, антын бозган өчен кичерә алмаган. Алар икесе ант иткән булганнар, без үрнәк татар гаиләләре корып яшәрбез, чын татар балалары үстерербез дип. Ә апасы тоткан да, яһүдкә...

– Сез эшнең никадәр җитди икәнен аңлап бетерә алмыйсыз һаман, – диде Зөлмәт. – Мин монда сезне Кадыйр кушканга җыйдым! Сезне аның исеменнән хөкем итәргә!

– Хөкем итәргә? – диде Галимҗан.

– Кадыйр исеменнән? – дип сорады Диләрә.

– Әйе, нәкъ шулай: Кадыйр исеменнән хөкем итәргә, – диде Зөлмәт, тынычлана төшеп.

– Нәрсә өчен хөкем итәргә? – диде Хамис.

– Үләренә бер ай чамасы алданрак бер сөйләшеп утырган идек без аның белән, – диде Зөлмәт. – Иркенләп, ашыкмыйча, сабыр гына, озын-озаклап. Шунда әйтте ул миңа: «Санчо, барысын да тап, бергә җый, антны исләренә

төшер, шуны бозган өчен суд оештыр!» – диде. Мин Кадыйрның бу васыятен үтәргә бурычлы һәм монда сезне уен уйнарга, шаярып утырырга дип җыймадым.

Галимҗан янәдән көзгегә карап куйды. Анда Кадыйр Фемида кулындагы үлчәүнең тәлинкәләренә борчак хәтле генә ташлар салып уйный иде. Бер як тәлинкәгә сала да, анысы аска төшеп китә башлагач, икенче як тәлинкәгә дә таш салып куя.

– Шулай итеп, җәмәгать, суд утырышын ачык дип белдерәм. Гаепләнүчеләр эскәмиясендә – Илгизәр Сүлтиев, Галимҗан Гыйлемҗанов һәм Хамис Шәрәфуллин. Диләрә Бәхтегәрәева шаһит сыйфатында гуаһлык бирәчәк. Беренче булып сезнең эшне карарбыз, Илгизәр. Судка тулы исемегезне, туган урыныгызны һәм туган көнегезне атагыз.

– Мин адвокат таләп итәм! – диде Илгизәр елмаеп һәм учларын ачып, кулларын як-якка җәйде.

– Сез үз-үзегезне генә якларлык хәлдә, – диде Зөлмәт. – Өстәвенә адвокат вазифаларын дусларыгыз да башкара ала.

– Ярар соң алайса, – диде Илгизәр һаман авызын җыя алмыйча. – Сүлтиев Илгизәр Насих улы. 1980 елның 9 маенда Җәлил посёлогында туганмын.

– Хәзер кайда яшисез? Ни белән шөгыльләнәсез?

– Алманиядә яшим, Мюнхен шәһәрендә. BMW Group Компаниясендә эшлим.

– Гаилә хәлегез?

– Өйләнгән.

– Ничәнче мәртәбә?

– Өченче.

– Балаларыгыз ничәү?

– Бишәү.

– Ничә-ә-әү?! – дип сузды Хамис. – Бер малай гына иде бит әле синдә?

– Мин синең хатынның да берәү генәдер дигән идем? – диде Галимҗан.

– Беренче мәртәбә мин Рания исемле татар кызына өйләндем, – диде Илгизәр. – Алманиягә килеп урнашкач та, татар җәмгыятен эзләп тапкан идем, шунда таныштык. Өйләнергә кирәк бит инде? Татар кызына өйләнергә кирәк – вәт өйләндем. Бер ел бергә торып карадык та... Кыскасы, аның минем белән яшисе килмәде. «Син минем белән түгел, башка кеше белән яшәгән кебек, без өчәү», – диде ул.

– Яхшы психолог булган, – дип куйды Галимҗан.

– Хатын-кыз сизгер зат инде ул шундый, – диде Диләрә.

– Аннары Хелена очрады, – дип дәвам итте Илгизәр. – Ниндидер хисләр дә бар иде кебек башта, малай туды.

– Унике яшь диденңме әле аңа? – дип сорады Галимҗан.

– Әйе, унике, – дип авыр сулап куйды Илгизәр.

– Син яңадан өйләнгәч, ул хәзер әнисе белән торамы?

– Әнисе белән дә тора, минем белән дә, ике арада йөри шулай, – диде Илгизәр.

– Нишләп Хелена белән аерылыштыгыз? – дип сорады Диләрә.

– Авыр ул икең ике дөньядан булгач, – диде Илгизәр. – Башта бернинди проблема булмас кебек, тик яши-яши ул ике дөнья бер-берсеннән торган

саен ераклаша бара... Бик вак әйберләр дә зур каршылыкларга, хәл итә алмаслык проблемаларга әверелә.

– Мәсәлән? – дип сорады Зөлмәт.

– Ашагач амин тоткан өчен дә шелтә-кисәтү белдерүләре мөмкин.

– Да ла-а-адно?! – дип куйды Хамис.

– Өченчесендә кемгә өйләндең? – диде Диләрә.

– Белмим.

– Ничек инде? – диде Хамис исе китеп.

– Шулай инде менә, – диде Илгизәр. – Алай да була икән тормыш булгач.

– Аңлатыбрак сөйләле син, Илгизәр? – диде Галимҗан.

– Төрек хатыны ул, Акгөл исемле, – диде Илгизәр. – Тик Акгөл туганда кушылган исеме түгел, ул аны сигез ел элек кенә, Төркиядән Алманиягә килгәч алган үзенә. Гаиләләрендә җәберләнгән хатын-кызларга ярдәм үзәгендә.

– Кайда? – дип куйды Галимҗан.

– Ничек анда килеп эләккән соң ул? – диде Диләрә.

– Үзегез беләсез бит инде, Алманиядә бик күп төрекләр яши, – дип дәвам итте Илгизәр. – Алар үз илләрендә яшәмәсәләр дә, зур күпчелеге гореф-гадәтләрен изге күреп, күз алмасыдай саклыйлар. Төрек егете Алманиядә кәләш таба алмаса, аңа Төркиядән алып киләләр. Акгөлне дә гомерендә бер мәртәбә генә күргән егеткә кияүгә бирер өчен Алманиягә алып килгәннәр. Ул кайсыдыр шәһәрдә таксист булып эшләүче егет булган, берничә ел элек әти-әниләренең туган ягына кунакка кайткан булган, шунда олылар аны Акгөлгә өйләндерү турында килешкәннәр. Тик ул вакытта кәләш бик кечкенә булган әле, ә балигъ булгач, абыйлары аны булачак ире янына Алманиягә алып килгәннәр. Алга таба ни булганын бик төгәл белмим, Акгөл үзе турында сөйләргә бик яратмый. Шунысын гына беләм, ике-өч ай яшәгәч, иреннән качкан ул, хатын-кызларга ярдәм үзәгенә мөрәҗәгать иткән. Шундый махсус үзәк бар икән, гаиләләрендә җәберләнгән хатын-кызларга булыша торган.

– Нигә анда? Ник туганнарына шалтыратмаган? – дип сорады Галимҗан.

– Син нәрсә?! – диде Илгизәр, күзләрен акайтып. – Аны ким дигәндә иренә кайтарып бирерләр иде! Кыйнап атмасалар!

– Алманиядә дә андый хәлләр булып ята икән XXI гасырда, – диде Диләрә, авыр сулап.

– Аңа шул үзәктә яңа документлар ясаганнар, башка шәһәрдә эш, яшәү урыны табып биргәннәр.

– Ә син ничек таныштың аның белән? – диде Галимҗан.

– Юл һәлакәтендә аяк-кулларны сындырып, сырхауханәдә яттым мин шактый озак. Акгөл анда эшли иде: идән юа, авыр хәлдәге авыруларга булыша иде.

– Ул сиңа дүрт бала таптымы? – дип сорады Диләрә.

– Әйе, – диде Илгизәр, аның йөзләре балкып китте.

– Кайчан җитештегез дүртне ясарга? – дип сорады Хамис.

– Алты ел элек улыбыз туган иде – Искәндәр, – диде Илгизәр. – Ә өч ел элек Аллаһ безгә өч игезәк кыз бүләк итте – Гөлестан, Гөлсинә, Гөлгенә.

– Җитте моңа дурак сатып йөрергә, шушы төрек хатыны белән генә

торсын, дигәндер инде Аллаһ, – диде Хамис. – Хәзер койрыгың бозга каткан инде!

– Дүрт балалы хатынын ташлап китсә, Аллаһ шундый итеп орыр, сөякләрен җыеп алалмас! – диде Диләрә.

– Тем более, аның бу дөньяда синнән башка беркеме дә булмагач, – дип өстәде Хамис.

– Минем аны ташлап китәргә җыенганым да юк!

– Мин гомерем буе очарга риза, дидең бит үзең. – Хамис тагын гыргылдап куйды.

– Риза идем, – диде Илгизәр, Диләрәгә гаепле караш ташлап.

– Шундый бер тип хатыннар бар – гомерләре буе, үлгәнче ниндидер әкияти, тылсымлы, зур мәхәббәт эзлиләр алар. Шундый ирләр дә бардыр дип белми идем, – диде Диләрә.

– Ул синең кебекне эзләгән, ахрысы, Диләрә, – диде Галимҗан. – Карале, Илгизәр, ә ник син болар турында шундук сөйләмәдең?

– Ничек инде шундук? Менә сөйләдем ич инде, ни кирәк тагын?

– Хәзер сөйләдең, әйе. Ә очрашкач та, гаиләң турында сорагач, Хелена белән Ральфны гына искә алдың бит?

– Ралифны.

– Ярар Ралифны булсын! Нигә Акгөл турында бер сүз дә әйтмәдең?

– Чөнки Хамис Хелена турында гына... – диде дә Илгизәр, ничектер имәнеп китте.

– Нәрсә Хамис? Нишләгән ул тагын? – диде Галимҗан.

– Ярар инде, – диде Илгизәр. – Аннары аңлатырмын.

– Кайчан соң ул аннары? – диде Галимҗан, һаман да төпченеп.

– Ник бәйләнәсең кешегә, Буржуй? – диде Хамис. – Какая разница, кайчан сөйләсә дә бер түгелмени сиңа? Главное ул түгел бит, главное хәзер койрык бозга каткан. Беркая китә алмый хәзер Штирлиц, вәт хикмәт нәрсәдә!

## 14. Бабам Сталин белән кочаклашып йөрмәгән

– Үз илен ташлап китә алган кеше өчен ун балалы хатынны ташлау да берни тормый! Бала җоны да селкенми аның, – диде Галимҗан. – Беркайчан да аңламадым бәхет эзләп, башка илгә китүчеләрне, аңлый да алмам инде, мөгаен.

– Гомер бер генә бирелә бит, Галимҗан, шуны кешечә яшисе килә, – диде Илгизәр, елмаеп.

– Ничек була соң ул кешечә? Без хайванча яшибезмени? – диде Галимҗан.

– Әле беркөнне генә Росстат хәбәр итте – игътибар ит, Галимҗан, «Голос Америки» түгел, Росстат! – Россиядә яшәүчеләрнең бишесенең берсе, үзәк канализациягә кушылмаган йортларда яши икән. Авылда, гомумән, өч кешенең икесе! Бу ни дигән сүз? Бу кешеләр XXI гасырда ел әйләнәсенә җәен дә, кышын да, урамдагы бәдрәфкә йөри дигән сүз! Шулмы синең кешечә яшәвең? Ул мәгариф, медицинаның җимерелеп бетүен әйтеп тә тормыйм инде. Илдә трусик та текми башладылар бит хәзер!

– Бүген авылларда да бәдрәф күп кешенең өендә инде, – дип кайтарып сукты Галимҗан. – Ялкауларга карама син, тырышып эшләүчеләрнең ничек яшәгәненә кара.

– Газ өстендә яшәп, ил халкының күпмесе утын яга! – дип дәвам итте Илгизәр. – Күпме кеше пенсия күрми үлеп китә! Өстәвенә пенсия яшен арттырып та куйдылар әле хәзер. Чиста булмаган су эчеп, күпме кешенең тешләре коела!

– Син безнең өчен борчылма, суны чистартып эчәрбез!

– Рактан күпме кеше үлә! – дип дәвам итте Илгизәр шул бер кызган килеш. – Ә аны бит кешеләрне тикшереп торсаң, килеп кенә чыккан мәлендә күрсәң, дәвалап була. Дарулар чыгару турында уйларга кирәк, балалар өчен иркен, матур, уңайлы уен мәйданчыклары төзү турында, компьютер, смартфоннар, электромобильләр чыгару турында уйларга кирәк, корал культын үстерү турында түгел!

– Очма, очма шулкадәр! – дип кырт кисте Галиҗан. – Булды, җитте! Әкренләп кенә барысы да эшләнә тора бит. Йортлар да төзелә, аларда шәп кенә балалар мәйданчыклары да бар, искеләрен дә яңарталар.

– Хәзер бер әйбер күрсәтәм мин сиңа, – дип, Илгизәр телефоныннан нидер эзли башлады. – Ә, менә таптым, тыңлагыз! «Мин ярты-порты сөйли белмим, хәйләли дә белмим, бу минем холкыма туры килми. Россия үзенең якты киләчәген дини караш-агымнарда – мистицизмда, аскетизмда, пиетизмда да түгел, ә мәдәният, мәгариф, гуманлылык үсешендә күрә. Аңа вәгазьләр кирәкми (туйды инде ул аларны тыңлап!), догалар да кирәкми (ул аларны тәкрарлап арды инде!), аңа халыкның уянуы, россиялеләрнең үзләренең кеше икәннәрен искә төшерүләре, гасырлар буе пычракта һәм тирестә тапталган абруйларын күтәрүләре, аек акыллы һәм гадел кануннар кабул ителүе һәм аларның мөмкин кадәр нык үтәлүе кирәк. Моның урынына без котчыккыч күренешле илне күрәбез: монда берәүләр икенче кешеләр белән сату итә; адәмнәр үз-үзләрен исем белән түгел, кушамат белән атап йөртәләр – Ванька, Стешка, Васька, Палашка, диләр; ниһаять бу илдә шәхес, намус, милеккә кагылышлы бернинди гарантияләр дә юк, ул гына да түгел, хәтта полиция тәртибе дә юк, ә бары тик төрледән-төрле карак чиновникларның урлашыр өчен корылган дәү-дәү корпорацияләре генә бар. Хәзерге вакытта ил күләмендәге иң тере сорауларның берсе – бүгенге көндә кабул ителгән кануннарны булса да катгый үтәүне тәэмин итү. Моны хәтта хөкүмәт тә сизә, бу хөкүмәт тарафыннан кулланылган кыюсыз, нәтиҗәсез, ярым-йорты чаралардан да күренә. Гаеплеләрне дә, гаепсезләрне дә тотып ярырга кирәк, дисез сез. Анысы инде аның бездә еш була торган хәл, хәер, хаклы кешене ешрак кыйныйлар, бигрәк тә ришвәт бирерлек мөмкинлеге булмаса, гаепсездән шундук гаеплегә әйләнә». Белинскийның Гогольгә язган хатыннан өзек бу. Беләсезме кайчан язган? Йөз җитмеш дүрт ел элек! Йөз җитмеш дүрт! Бүген язган кебек бит! Белинский Зальцбруннан җибәрә бу хатын. Әле шунысын да искәртә, Россиядә яшәсәм, мин бу юлларны яза алмас идем, ди. Ә син, Галимҗан, һаман нидер яхшырыр дип ышанасың...

– Компьютер-смартфоннарга килгәндә, аларны хәзер без генә түгел Америка да Кытайдан кайтарта, – дип куйды Галимҗан, Илгизәрнең Белинский хатын укуын ишетмәгәндәй. – Әйе, барысы да ал да гөл түгел. Тик син шуны онытма: безнең ил сугыш аркасында башкалардан ярты гасырга артка калган – мәңгелек яра бит ул!

– Тарих укытам, дидеңме әле син, Галимҗан? – дип сорады Илгизәр.

– Әйе, ә нәрсә булган?

– Молотов-Риббентроп килешүе турында сөйлисеңме соң укучыларыңа?

– Бөек Ватан сугышы темасына мәктәп программасында алты сәгать бирелгән. Ул вакытта гына балага барлык нечкәлекләрен дә аңлатып бетереп булмый. Сугышның кайчан башланган, кайчан беткәнен истә калдырса, әйбәт инде, – диде Галимҗан.

– Сөйләгез тарихны һәрьяклап, надан балалар тәрбияләмәгез! – диде Илгизәр.

– Без тарихны беләбез, Илгизәр, – диде Галимҗан.

– Белеп бетермисез шул менә! – диде Илгизәр, тынычлана алмыйча.

– Минем бабам Ленинград фронтында бер күзен калдырып кайткан, аның баш сөягеннән ничәмә-ничә мина кыйпылчыгы чүпләп алганнар госпитальдә. Аның гомерлек инвалид булып калуында Гитлер, Муссолини, Черчилль, Рузвельт – барысы да гаепле! Ә бабамның соң ни гаебе бар? Ул бит сугышта Сталин белән кочаклашып йөрмәгән!

– Вермахт армиясенең гади солдаты Гитлер белән кочаклашып йөргәнмени? Беләсеңме, миңа нимес авылларында шактый йөрергә туры килде. Безнең бабайлар шикелле гап-гади кешеләрне мәҗбүриләп җибәргәннәр сугышка! Әллә аларның ниндидер бөек идея өчен үләсе килгәндер, дисеңме? Бер дигән сыра эчеп, матур табигать кочагында яшәп, тыныч тормышта иген үстереп яткан ирләрнең сугышка барасы килгәндер дисеңме? Аларны да аналары елап озатып калган!

– Төкерәм мин иләмә басып кергән нимеснең анасы елаганына! – ачуыннан Галимҗанның күзлеге ялтырап куйды.

Галимҗан сикереп тә торды, бар көченә селтәнеп, Илгизәрнең авызына тондырмакчы булды, тик аның кулы нишләптер һаваны гына ярды. Ул моңа бер мизгел аптырап торды, ни булганын аңламады, аннары гына идәнгә күзе төште: Хамис Илгизәрнең өстенә атланып, авызын йодрыгы белән төя иде инде.

– Кем оккупант? Минем бабай да оккупантмы?! – дип акырды Хамис.

– Хамис, җитте! Нишлисең? – дип кычкырды Диләрә. – Галимҗан, аер аларны! Нишләп карап торасың?

– Хәзер, аерырмын, төйсен инде әзрәк шуның сасы авызын, – диде Галимҗан тыныч кына. Көзгегә караган иде, Кадыйр, елмаеп, баш бармагын күтәреп күрсәтте, шәп, янәсе.

– Җитте дим, Хамис! – дип илерде Диләрә. – Галимҗан!

Тегесе теләмичә генә килеп, Хамисны артыннан кочып алды да торгызып, Илгизәрдән читкәрәк алып китте.

– «Можем повторить!» Әйеме, Сансыз? – диде Илгизәр. Ул идәндә утырган килеш ярылган иреннәннән аккан канны кулы белән сөртеп куйды.

– Можем шул! Әллә тагын кирәк?! – дип, Хамис Илгизәр ягына тартылды, тик Галимҗан аны җибәрмәде.

– Берсендә мин ничектер ялгышып, «Фольксваген» автосалонына яңа модель презентациясенә эләккән идем, – диде Галимҗан. – Тантана башланганчы квартет уйнады, ике скрипка, альт, виолончель. Шундый идиллия инде менә бер яктан карасаң. Тик анда ике нимес тә килгән иде: берсе сап-сары, икенчесе җиз кыңгырау кебек җирән. Үз телләрендә

мыркылдап йөриләр болар нидер. Бабай искә төште дә, аның сугышта күзен калдырулары, башы тулы мина кыйпылчыклары турында уйладым да, җанымда бу ике немескә карата шундый көчле җирәнү катыш нәфрәт хисе уянды, мин сиңа әйтим, шундый нык итеп ачуым чыкты, әздән генә болар белән сугыша башламадым! Үтерегез, аңламыйм: ничек шулар иленә күчеп китеп, шулар белән бергә яшәргә була?

– Минем бер дус хатынның әти-әниләре яшь чакта Казакъстанга киткән булганнар, – дип сүзгә кушылды Диләрә. – Казакъстанга, немес иленә түгел. Ә аларның биш баласы да монда, Татарстанга, кем әйткәндәй, бер төенчек күтәреп кайтып, үз тормышларын нульдән башлап, яңадан үзләре корганнар. Шул дус хатынымнан кызы берсендә сораган: «Сез нигә монда кайттыгыз соң? Казакъстанда бит баерак яшиләр, климат та яхшырак?» – дигән. Без Ватаныбызга кайттык, дигән дус хатыным. Менә шундый без, Илгизәр. Син аңламый торган ватанпәрвәрләр без – үзебезнең илебезне яратабыз. Теләсә кайсы бала ата-анасын яраткан кебек. Чөнки ул безнең туган ил! Ә син, еллар узгач, туган илеңә бөтенләйгә кайтырга уйламыйсыңмы әллә? – дип сорады Диләрә.

– Әйе, синең дә кайтасың килә башласа картайгач? – дип өстәде Хамис.

– Кайтса ни? Сезнең ни эшегез бар?

– Әгәр үләргә монда кайтырга уйласаң, синең сүзләрең бик аңлашылып бетми, – диде Галимҗан. – Син ни өчендер – белмим, аңламыйчамы, әллә юриме – ил белән идарә итә торган номенклатура һәм халыкны бер итеп күрәсең. Тик бездә алай түгел бит ул. Хөкүмәт үзе аерым, аның үз максатлары, халыкның үзенеке. Безнең бабайлар, совет халкы – оккупантлар түгел, киресенчә, азат итүчеләр. Европа халыклары өчен дистә еллар буена бу шулай булды, какшамас нәрсә төсле иде, тик соңгы елларда Европа лидерларының сәясәте үзгәрде, алар өчен, гомумән, бернинди изге нәрсә дә юк. Син сөйләгәннәрдән шул аңлашыла: Илгизәр, күрәсең, хәзер мәктәпләрдә немес балаларына совет солдатларын оккупантлар дип өйрәтәләрдер. Ә без үз балаларыбызны үзебезчә тәрбиялибез – туган илгә, Ватанга мәхәббәт хисе сеңдерергә тырышабыз аларга. Дөрес эшлибезме, юкмы икәнен син белә алмыйсың, Илгизәр. Чөнки сиңа таныш нәрсә түгел ул туган илгә мәхәббәт. Син башка дәүләттә яшисең һәм шул дәүләтнең гимнын җырлыйсың.

– Авызыңны ерып, адвокат сорап утыргач, башта мин сине җитди сөйләшмисең, дип уйлаган идем, – диде Диләрә. – Троллинг бу, мин әйтәм. Аннан тыңлап утырдым, утырдым да... Минем бер сорау бар сиңа, Илгизәр. Әгәр безнең илдә тәртип юк икән, яки булган тәртип сиңа ошамый икән, шундук чыгып качарга кирәк дигән сүзме? Бәлки тәртип булсын өчен үз өлешеңне кертергә тырышырга кирәктер? Әгәр син үз илеңне ташлап киткәнсең икән инде, Алманиядә барысы да ал да гөл икән, анда сиңа рәхәт икән, ник шунда тыныч кына яшәп ятмыйсың соң син? Һаман бездәге начарлыкларны чокып чыгарасың, бездә монда хәлләр алама икәнен исбатламакчы буласың. Койма артыннан өреп яткан эт кебек, билләһи! Ничектер политинформация сәгатендә утырган кебек тоя башладым мин үземне. Син безне сукыр дип уйлыйсыңмы соң? Берни күрмиләр, аңламыйлар болар дип уйлыйсыңмы? Барысын да күрәбез, барысын да аңлыйбыз без, дурак түгел. Тик бездә, синең күзлектән

чыгып караганда, җүнсез илдә яшәүчеләрдә, позитив, яхшы кәеф һәм оптимизм күп мәртәбәләр артыграк. Һәркем кайда тели, шунда яши. Минем Төркиягә дә, Чехиягә китәргә дә мөмкинлекләр бар иде. Мин китмәдем. Бу – мин үзем сайлаган язмыш, мин шулай теләдем. Менә кешечә яшәү, дисең син, әйеме? Ә чынлыкта сине бит бөтенләй борчымый бит минем ничек яшәгәнем. Дөрес әйтте Галимҗан, ялкауларга карама син, тырышларга кара. Гаиләләрдә икешәр машина, кулларында айфон гына, чит илләрне дә күрмәгән кешеләр түгел, ял вакытында барып, биш йолдызлы кунакханәләрдә яшәп кайтабыз. Тик ничә кешедән ишеткәнем дә бар, мин үзем дә шулай, күп дигәндә, бер атнадан туябыз, җитә безгә шунысы да. Менә шушы җүнсез ватаныбызга кайтасыбыз килә, аңлыйсыңмы син шуны?

## 15. Дуслар серпентарие

– Биш йолдызлы отельдә яшиләр алар, имеш! Бер атнада ни күрәсез, ни аңлый аласыз соң сез? – диде Илгизәр, мыскыллы елмаеп.

– Ә ни күрергә, ни аңларга тиеш инде без синеңчә? – дип сорады Галимҗан.

– Без барыбыз да татарча сүзләр әйтәбез кебек, тик сөйләшү барыбер төрле телләрдә килеп чыга, – диде Илгизәр. – Туган ягымны мин дә бик яратам, сагынам. Ләкин дөньяны чынлап торып танып белер өчен күп укырга гына түгел, күп йөрергә, күп күрергә кирәк. Күпне күргән кешеләр белән аралашырга кирәк. Алар белән сөйләшү дә гел икенче төрле. Үз оясыннан башын чыгарып, тирә-якны да күзәткән, төрле илләрдә булып, аларны чагыштыра алган, плюс-минуслары турында фикер йөртә алган кешеләр белән аралашу кызык. Ә гомерендә үз авылыннан чыкмаган кеше белән ни турында гәпләшеп була? Кишер үстерү белән колорадский жук темасынамы? Ну, окей, анысын сөйләштек ди, ә тагын нәрсә турында?

– Әти-әниең белән ни турында сөйләшәсең? – дип сорады Галимҗан.

– Әйе, ни йөрәгең белән ташлап киттең син аларны? – дип өстәде Диләрә.

– Бердән, мин аларны ташламадым, кимендә елга бер кайтып торам яннарына, – диде Илгизәр. – Болай да телефоннан гел сөйләшеп торабыз. Хәзер җайлы бит, интернет заманы, видео белән дә күпме телисең, шуның кадәр сөйләшергә була.

– Алар белән дә кишер үстерү, колорадский жук турында сөйләшәсеңме?

– Юк инде, – диде дә Илгизәр, бераз уйланып торгач, дәвам итте. – Хәер, әйе, бәрәңге, тавык-чебеш тирәсендә инде күбрәк сөйләшү. Образлы итеп әйткәндә. Аллага шөкер, аяк-куллары йөри, үз-үзләрен карыйлар. Кыскасы, кишер үстереп яталар шунда бакчада, аларга башка нәрсә кирәкми дә.

– Вот заладил бу! Кишер дә, кишер! – дип ырылдады Хамис. – Чөгендер үсә әле тагын бакчада, суган, кыяр, помидор, җиләк!

– Ә менә бабай андый түгел иде, – диде Илгизәр сагышлы, ямансу тавыш белән. – Менә ичмасам кеше иде ул! Курск дугасында булган ул, Сейм елгасы кып-кызыл булып акты, дигәне нык истә калган. Ләкин сугыштагы үтерешләр турында сөйләгәнен бик хәтерләмим. Берничә ел элек архивтан үзем эзләп таптым. Баксаң, шәхсән үзе 10 немесне штык белән кадап үтергән өчен «За отвагу» медале биргән булганнар икән аңа. Шул вакытта ул аягын югалткан.

Дарулар булмагач, бер стакан спирт эчертеп, кул пычкысы белән аягын кисκәннәр. Минем Нәсим бабайны шундый газап-җәфаларга, интегүләргә дучар иткән нәрсә изге була алмый, дәһшәт булган ул! Ә сугыштан кайткач? Бабайның иң авырткан урыны иде ул, берничә мәртәбә шул турыда сөйләгәне истә калган. Менә сез күзалдына китерегез, яшь егетләр, чын күңелдән ышанып, Ватанны коткарабыз дип көрәшеп кайтканнар һәм инде без нимесне җиңдек, тормыш яхшырыр дип ышанып, тылда да фронтовикларча көрәш алып бара башлаганнар. Ә монда сугыш законнары эшләми, тыныч тормышның үз кагыйдәләре, ә иң мөһиме, бу тыныч тормыш бер дә яхшырмый. Аннары алар бит сукыр түгел, күреп торалар: кайберәүләр сугышка бармый калганнар, тегеләй-болай алдаштырып баеп ятканнар. Ә фронтовиклар шинель белән генә кайткан, җиң сызганып, эшкә тотынганнар. Аларның бит күбесе Европада тормыш ничек корылганын, аларның ничек яшәгәнен үз күзләре белән күреп кайткан. Тик фронтовикларга тормышны үзләре теләгәнчә көйләргә ирек бирмәгәннәр. Шуннан соң инде гаярь егетләр бер-бер артлы сына башлаган, алардагы күңел күтәренкелеге, дәрт-дәрман сүнгән, балаларча беркатлылык белән уйлау, наивлык беткән. Шуннан алар орден-медальләрен салып ташлап, тыныч тормыш законнарына буйсынып, үзләре дә тормыш җаен җайларга дип башларын иеп, муеннарына камыт киеп дигәндәй, эшкә җигелгәннәр, бик күбесе үзләренең Ватан сугышы чорындагы матур уй-хыялларын, теләк-планнарын онытканнар. Ә бүгенге хәлләр мең мәртәбә начаррак, хәтта куркынычрак. Минем бабай халык байлыгын талап ятсыннар дип сугышмаган. Ул оныклары урыс рухында тәрбияләнсен, татарлар икенче сортлы булсын дип тә сугышмаган. Беләсегез килсә, аның борынгы бабасының үз мәдрәсәсе булган, ул анда хәтта укытырга Гали Чокрыйны чакырып китерткән булган. Нәсим бабай безне, оныкларын, тормышка башкача күз белән карарга өйрәтте. Гел чит ил радиоларын тынлый иде ул, совет телевизорыннан, «Правда» гәзитеннән башканы күрмәгән кешеләргә дөнья хәлләрен иплəп кенә аңлата иде. 74 яшендә үлеп китте.

– Ватанны, әнине сайлап алмыйлар, Илгизәр. Ватаныңны ничек бар – шулай яратырга кирәк, – диде Галимҗан. – Без – крестьян баласы, безнең кендек җиргә бәйләнгән. Бер ай туган авылга кайтмый торсам, һава җитми башлый, яшәү өчен уңай энергетика бирә миңа туган якларым. Авыл урамыннан бер урасаң, су буйларына, чишмәгә төшеп менсәң, басу юлыннан бер үтсәң, урманга беразга гына булса да кереп чыксаң, бөтен арыганлыкларың бетә, яшәргә көч аласың үзеңә.

– Ни дисәң дә, Илгизәр, барыбер үз илем – алтын бишек, кеше иле – үтә тишек, дигәндәй, анда барыбер чит мөһит, чит культура, чит кешеләр. Син барыбер алар өчен үз кеше түгелсең, – диде Диләрә.

– Бер футболчы бар иде – Осаз Одемвингие исемле, – дип куйды Галимҗан. – Иде дип, хәзер дә исән инде, күптән түгел генә уйнаудан туктады. Каны яртылаш татар. Атасы – Нигериядән, анасы – татар хатыны, Рәйсә исемле. Ташкент мединститутында укыганда өйләнешкәннәр. Алсу исемле сеңлесе бар моның. Шул Осаз бер интервьюсында әйткән, Мәскәүдә без Алсу белән кара дип исәпләнәбез, Нигериядә ак диләр, кая барсак та үз итеп күрмиләр, дигән.

– Әйе, татар каны барлыгы сизелеп тора шул бу футболчыда, сүзләрендә

мескенлек ярылып ята, – диде Илгизәр. – Басынкылык, изелгәнлек, рухсызлык татарның ДНК-кодына кереп урнашкан микәнни инде? Ничек бетмәсен инде бу татар? Коллык психологиясе канына сеңгән микәнни шулхәтле?

– Без барыбыз да – Аллаһ коллары, – дип куйды Галимҗан.

– Мескен коллар сез! – диде Илгизәр, ярсый башлап. – Пенсия яшен күтәреп куйдылар, сез ләббәйкә тотасыз, бөтенләй бирми башласалар да, рәхмәт, дип, әппәр әйтәчәк кешеләр сез!

– Карале, брат! – диде кинәт Хамис Зөлмәткә. – Син бит суд була дигән идең түгелме соң? Ә монда ниндидер диспут бара, тарих, эмигрантлар турында? Негрлар да килеп керде монда хәзер.

– Бик әйбәт сөйләшү бара, мин бик канәгать! Тик менә иң кирәкле, иң мөһим сүз әйтелмәде әле һаман. Тиздән яңгырар дип ышанам, – диде Зөлмәт Хамиска. Аннары башкаларга дәште. – Дәвам итегез, зинһар, безгә игътибар итмәгез.

– Әйтеләсе сүз әйтелде, ахрысы, инде, – диде Галимҗан. – Акыллы кеше үзе эчкән коега төкерми, Илгизәр. Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың, ди, әлбәттә, татар мәкале, тик нимес ипиен ашыйм дигәч тә син...

– Нимес ипиенең ни катнашы бар монда? – диде Илгизәр. – Мин ашаган иң тәмле ипи – нимеснеке, беләсегез килсә. Улым да шулай ди. Ашап караган булсагыз, бәлки сез дә шулай дип әйтер идегез. Сыйфатлы ул чөнки. Нимес ясаган башка әйберләр кебек үк. Нимес туфлиен бер кигәч, «Спартак»ны бер дә киясе килми бүтән, БМВда йөргәч тә «Лада»га утырасы килми.

– Син, Илгизәр, читтән карап, туган илеңне мыскыллап ятма, килешми җегет кешегә, – диде Галимҗан. – Безгә ничек яшәргә кирәк икәнен бездән дә яхшырак белсәң, мәктәптә балаларны бездән шәбрәк укыта алсаң, кыскасы, алай бик оста булсаң, кайт та эшләп күрсәт, менә шулай кирәк, диген. Вәт булырсың җегет!

– Да! Не учи учёных, карочы говоря, – дип кыстырды Хамис.

– Без белгәнне балалар инде күптән киптереп элгән. Алар бездән ушлырак, үткенрәк, Аллага шөкер, – диде Илгизәр. – Башы булган, әз генә уйлый-фикерли белә торганнары барысы да Көнбатышка чыгып таю турында хыяллана.

– Ә син каян беләсең барысы да икәнен? – диде Галимҗан.

– Барысы да димәдем мин, башлыраклары, дидем. Каян беләсең дип... Социаль челтәрләрдән, сораштыру нәтиҗәләре дә шуны күрсәтеп тора. Гомумән, бу беркемгә дә сер түгел, – диде Илгизәр.

– Балаларда инде бөтен өмет, – дип авыр сулады Галимҗан. – Алар безгә караганда уңышлырак, бәхетлерәк булыр дип ышанасы килә. Яхшырак яшәрләр, иреклерәк булырлар, безгә караганда күбрәккә ирешерләр дип өметләник.

– Карале, Штирлиц! А тебе не кажется, что син ыслишком много ызнаешь? Тебе череп не жмёт? – диде Хамис.

– Кушаматың бигрәкләр дә нык туры килеп тора инде үзеңә, Сансыз! – диде Илгизәр, елмаеп. – Кем килгән иде соң минем янга, гаиләне Алманиягә күчереп булмас микән, дип? Мөмкинлек булганда таеп калырга кирәк, дигән иде, ә?

Хамис, йодрыкларын йомарлап, янәдән Илгизәр ягына ыргылган иде, Галимҗан җәһәт кенә аның каршына төште һәм кочаклап алды.

– Туктале, тукта, Сансыз! – диде Галимҗан. – Монысы ни дигән сүз булды моның тагын?

– Җибәр! – дип ырылдады Хамис. – Алдаша ул! Илгизәр үзе чакырды мине! Кадыйр безне болай гына калдырмас, берәр нәрсә уйлашырга кирәк, диде.

– Нәрсә соң ул берәр нәрсә? – Галимҗан һаман Хамисны җибәрергә җыенмый иде әле.

– Сора үзеннән! Мин каян белим? – диде Хамис.

– Ну, нәрсә турында сөйләштегез соң? – дип сорады Галимҗан, үҗәтләнеп.

– Ну, мыркылдады инде ул шунда нәрсәдер, Кадыйрның төрмәдән чыгуына әзер булып торырга кирәк, ул безне гафу итмәс, диде. Ә без гафу итмәслек нишләгән соң шулхәтле? Тегеләй дә, болай да исәпләп карадык та инде... Җибәр әле мине, Буржуй! Нәрсә баядан бирле кочаклашып торасың?! Син тегенди ыштули?! – дип, Хамис Галимҗанны үзеннән читкәрәк этеп куйды. – Ну, ярар, әйдә, әзерләнәбез. Ә ничек? Окоплар, дзотлар казыйбызмы? Отстреливаться будем, Кадыйр безне үтерергә килгәндә? Идиотизм какуй-то...

– Әйе, идиотизм булганга монда хөкем көтеп утырабыз бит инде, – диде Илгизәр.

– Ну, сатлыкҗан икәнсең, Штирлиц! Белә идем канишны предатель икәнеңне, тик бу хәтле үк сатлыкҗан булырсың дип күзалдына да китерә алмый идем! – диде Хамис, ярсып.

– Син үзең кем соң? – дип кычкырды Диләрә Хамиска. – Шундый ук сатлыкҗан бит инде үзең дә!

– Минем беркемне дә сатканым юк! – диде Хамис. – Туган илемне дә ташлап китмәдем мин, кайберәүләр кебек!

– Әмма җыенгансың! Кеше күк ат җигә дип, син дә күк бия җикмәкче булдыңмы?! Димәк, син дә нәкъ Илгизәр кебек хаин! – диде Диләрә.

– Менә! – дип сикереп торды Зөлмәт! – Ниһаять, иң төп сүз әйтелде! Кайчаннан бирле шушы сүз яңгыраганын көтеп утырган идем!

– Нинди сүз тагын? – диде Илгизәр.

– Төп сүз – сатлыкҗан, хаин, – диде Зөлмәт.

– Берни аңламыйм, башымда бөтен нәрсә буталып бетте, – диде Илгизәр.

– Барысын да аңлыйсыз сез, Илгизәр, – диде Зөлмәт. – Күзләрегездән күреп тордым, мин майор дигәч тә барысын да аңлаган идегез инде.

– Ләкин бу бит шантаж! – диде Илгизәр. – Ә иң мөһиме: мин аңламыйм, нигә әллә кайчангы пычрак керләрне актарып чыгарырга? Нигә кирәк ул сезгә?!

– Сез ашыкмагыз, Илгизәр, – диде Зөлмәт тыныч кына. – Башкалар әле берни белми бит, аларга да аңлатып китик. Шулай итеп, җәмәгать, әйткәнемчә, төп сүз, ниһаять, яңгырады – сатлыкҗан. Менә ул сатлыкҗан, сезнең алдыгызда утыра. Ә менә аның сатлыкҗан икәнлеген дәлилли торган документ.

Зөлмәт кесәсеннән нindидер кәгазь чыгарып укый башлады:

– Я, Сультиев Илгизар Насихович, паспорт – монда номерлары язылган

– обязуюсь добровольно помогать органам в их работе, скрывая от всех факт сотрудничества. Принимаю псевдоним Джавдет». Имза куелган, 1999 елның 30 декабре диелгән.

Укып бетергәч, Зөлмәт башын күтәреп, Илгизәргә карады:

– Бу документ турында судка ни хәбәр итә аласыз, гражданин Сүлтиев?

– Бу бернинди кыйммәте, бернинди мәгънәсе булмаган кәгазь кисәге, – диде Илгизәр, авыр сулап.

– Ничек инде кәгазь кисәге? – диде Галимҗан. – Анда синең имзаң тора, принимаю псевдоним Джавдет, диелгән. Син донослар язып яттыңмыни студент чакта? Кем өстеннән? Безнең өстән дә яздыңмы?

– Тынычлан, зинһар, Галимҗан! – диде Илгизәр. – Мин үз гомеремдә бер генә донос та язмадым. Билләһи дип әйтәм!

– Каян чыккан Джавдет соң ул алайса?

– Хәтерләсәгез, ШТКда бер уеннан соң җыелыш җыеп, җитди сөйләшү уздырганнар иде, – дип сөйләп китте Илгизәр. – Сәясәт темасына, президент турында, гомумән, хакимияткә кагылышлы шаяртуларның артык булуы, башка темаларга күбрәк игътибар итәргә кирәклеге турында сүз барды анда. Икенче көнне мине проректор кабинетына чакырдылар.

– Кайсы проректор? – дип сорап куйды Галимҗан.

– Социаль мәсьәләләр һәм тәрбия эшләре буенча, – диде Илгизәр. – Аның кабинетында кырык яшьләр тирәсендәге ир утыра иде. Проректор мин килүгә каядыр барасым бар дип чыгып китте, без бу ир белән икәү генә калдык. Ул таныклыгын күрсәтте. Майор Алексей Соколов дип язылган иде анда.

– Ни сөйләштегез инде аның белән? – диде Галимҗан.

– Әллә нәрсә сөйләшмәдек инде, – диде Илгизәр. – Һәрхәлдә нindидер серле, яшерен әйберләр турында бернинди сүз булмады. Безнең ШТК командасы турында сораштырды, номерларны ничек әзерләгәнебез белән кызыксынды, темаларны кем тәкъдим итә, тегесе-монысы...

– Син ни дидең инде? – дип сорады Диләрә.

– Дөресен әйттем, – диде Илгизәр. – Бөтенебез бергәләп уйлап табабыз гадәттә, бу коллектив иҗат җимешләре, дидем. Майор алдагы көнне җыелышта булган сүзләрне тагын бер кабатлады. Сәясәт, президент, хакимият...

– Ә син ничек Джавдетка әйләндең соң? – дип сорады Диләрә мыскыллы елмаеп.

– Сөйләшү ахырында майор миңа рәхмәт әйтте, без бер-беребезне аңладык, диде. «Кирәк булган очракта сез янәдән очрашырга каршы түгелдер бит?» – дип сорады. Юк, мин әйтәм, каршы түгел, безнең команданың сездән яшереп кылган бернинди эшләре дә юк, безнең бөтен иҗатыбыз кеше күз алдында, сәхнәдә, дидем. Майор очрашу турында беркемгә дә әйтмәскә кушты. Мин ярар, дидем. Шуннан ул әйтә: «Мин сезгә, әлбәттә, тулысынча ышанам, ләкин бездә тәртип шундый инде, менә бу кәгазьне тутырырга кирәк, подписка о неразглашении бу», – ди. Мин язып бирдем дә чыгып киттем проректор кабинетыннан. Аннан соң гына башка типте, «о неразглашении» түгел бит бу кәгазь, «о согласии доносить» мин әйтәм. Тик терсәк якын булса да, тешләп булмый иде. Шулай бит инде

ул – татарның акылы төштән соң. Тик мин сезгә ант итеп әйтәм – ипидер менә! – үз гомеремдә беркайчан да, беркем өстеннән дә бер донос-мазар да язганым булмады. Ул майор белән дә без урамда бер тапкыр ялгыш кына күрешеп, аяк өстендә тиз-тиз генә сөйләшеп алдык та, бетте китте шуның белән.

– Сездән ант итәм дигәнне ишетү мәзәгрәк ничектер, – дип куйды Зөлмәт.

– Ә сезгә ничек килеп эләкте ул кәгазь, сер булмаса? – дип сорады Илгизәр.

– Сер шул, – диде Зөлмәт, елмаеп. – Элек әйткәнне генә кабатлый алам. Кадыйр бик оста аудара иде кешеләрне үз ягына, теләсә кем белән идарә итә ала иде. Монысы, бердән. Икенчедән, сатлыкҗаннар бөтен җирдә дә бар, никадәр генә кызганыч булмасын.

– Ә нәрсәгә кирәк бу сезгә? – диде Илгизәр. – Максатыгыз нидә?

– Мин Кадыйрның васыятен үтәргә бурычлы, – диде Зөлмәт. – Сезне миңа кирәкле вакытта миңа кирәкле җиргә җыяр өчен бик шәпләп чакырырга кирәк иде бит.

– Нәкъ Кадыйрча инде бу, – диде Галимҗан, як-ягына каранып. – Бөтен җирдә символизм, киная. Дүрт төрле арыслан башлары гына да ни тора – ишектә дә шулар, түшәмдә дә, хәтта урындык аяклары башында да! Өстәвенә Фемида белән Анубис, патша сараедай җиһазланган, бай интерьерлы бу бүлмә...

– Чынлап әйтәсеңме син, Галимҗан, көлеп әйтәсеңме? – дип сорады Илгизәр. – Мондый зәвыксызлыкны беренче мәртәбә күрәм! Кич буе ниндидер ялган сәнгать! Патша сараеның кызганыч һәм көлкеле бер копиясе генә!

– Нәкъ менә бу бүлмәгә җыелуга Кадыйрның бер катнашы да юк. Шәһәрне дә, кунакханәне дә, бу люкс бүлмәне дә мин үзем сайлап алдым, – диде Зөлмәт. – Символизм-кинаяләрне махсус эзләп йөрмәдем, шулай туры килде генә ул. Тәкъдир шаяртуыдыр бу, күрәсең...

– Мин алган хат бер дә юмористик стильдә язылмаган иде, – диде Илгизәр.

– «Крёстный отец» фильмында ничек әле? – дип елмайды Зөлмәт. – «Мин аңа шундый шәп тәкъдим ясадым, ул берничек тә каршы килә алмый иде», – диме? Икенче төрле әйткәндә, сез минем чакыруны читкә какмасын өчен һәрберегезнең иң авырта торган җиренә басарга, кем әйткәндәй, шкафка яшерелгән скелетын тартып чыгарырга кирәк иде. Шунсыз киләсе түгел идегез бит берегез дә монда – бу дуслар серпенатриена. Шулай бит, Хамис?

## 16. Белем – хәсрәт ул

– Мин шушы секундтан башлап бер сүз дә әйтмим! – диде Хамис. – Мине юрист өйрәтеп куйган иде, андый-мондый хәл килеп чыкса, дип. Конституциянең 51 нче статьясы нигезендә мин үземә каршы, шулай ук якын туганнарыма, якын кешеләремә каршы показанияләр бирмәскә могу.

– Ай-һай ансат кына котылмакчы син ә, Хамис! – диде Зөлмәт, елмаеп. – Тик төлке никадәр генә хәйләкәр булмасын, аның туны кеше өстендә. Ярар соң алайса, син дәшми генә утыр, мин сөйлим. Шулай итеп, җәмәгать

гаепләнүчеләр эскәмиясендә бүген утыручыларның берсе – Шәрәфуллин Хамис Халит улы. 1980 елның 19 июлендә Ульяновск өлкәсе Кычыткан авылында туган. Өйләнгән, өч баласы бар. «Кызыл балан» фирмасының генераль директоры. Компаниянең ни өчен шулай аталганын беләсеңме соң син, Хамис?.. Дәшмисең, белмисең чөнки. Кадыйр Шукшинның «Калина красная» фильмын карарга бик ярата иде, шуннан килеп чыккан исем ул.

– Кадыйрның ни катнашы бар Сансызның фирмасына? – диде Галимҗан.

– Сансызның ни катнашы бар Кадыйрның фирмасына, дип сорасаң, дөресрәк булыр, – диде Зөлмәт. – Чынлыкта «Кызыл балан»ның төп максаты ярты дөньядан җиләк-җимеш кайтартып сату түгел, гәрчә ул эш тә уңышлы гына алып барылса да. Бу фирманы Кадыйр заманында акча чистартыр өчен, аны легаль счетларга салу схемасын булдырыр өчен оештырган иде. Баштагы мәлләрдә ул, әлбәттә, мондый ук зур колачлы компания түгел иде әле, акча әйләнеше дә әллә ни зур түгел иде анда. Менә шул чакларда Кадыйрга бу фирмага кемнедер директор итеп куярга кирәк булган.

– Хамис, син Кадыйр белән бергәләп эшләдеңмени? Аралашып тордыгызмы әллә сез? – дип сорады Диләрә.

– Аралашмадым мин беркем белән дә! – дип кырт кисте Хамис. – Мин, гомумән, аңламыйм бу кешенең ни лыгырдаганын!

– Хәзер аңларсың, – диде Зөлмәт. – Кадыйр кассирына Хамис белән элемтәгә керергә кушкан, директор вазифасын Сансызга бирик, тик ул фирманың минеке икәнен белмәскә тиеш, дигән.

– Ник аңа? – дип сорап куйды Галимҗан.

– Ну, бердән, белгән кеше, авызлыклап тотарга уңайлырак, – дип аңлатты Зөлмәт. – Икенчедән, сез нәрсә, Кадыйрны белмәгән кешедәй утырасыз? Аңа кызык булган, нишләр икән Хамис, дип уйлаган ул. Кадыйрның кассиры эзләп тапкан Хамисны. Ул чакта Сансыз «Жигули»га запчастьләр сату белән маташкан. Ялган запчастьләр инде, әлбәттә. Иртәме-соңмы эләктерәләр сине барыбер, утыртып куялар, бездә дә андый куркыныч бар барын, тик аның тормышка ашу ихтималы нульгә омтыла, дигән кассир. Хамис озын-озак уйлап тормыйча, ризалашкан. Ә нәрсә, шәп бит инде? Арт җыртып, әллә ни эшлисе юк, үзеңә үзең хуҗа дисәң дә була. Каядыр, ниндидер мифик хуҗа бар барын, тик аның исемен әйтергә теләмиләр, ә акчасын түләп барсалар, нигә кирәк соң ул, аның исеме, әйеме, Хамис? Шулай итеп Сансыз зиц-председатель вазифасына керешә. Бик тиздән ул үзенең генераль директор булуына чынлап торып ышана башлый. «Кызыл балан»да бухгалтер булып эшләүче Кадыйрның кассиры гына аны, артыгын кылана башласа, әледән-әле тәртә арасына кертеп куйгалый. Эш бара, Кадыйр Хамисны күзәтүдән кызык таба, бар да ал да гөл... Кебек иде соңгы вакытларга кадәр, әйеме, Хамис?

– Ә ни булды соңгы вакытларда? – дип сорады Илгизәр.

– Хамисның көймәсе комга терәлде, – диде Зөлмәт. – «Кызыл балан» бүген банкрот хәлендә, бөлде Сансыз, кесәсендә җилләр уйный. Ул бүген монда, бу очрашуга, зур өметләр баглап килгән иде дә соң, яңа контракт төзү турында сүз барыр дип уйлаган иде, тик килешү ул уйлаганча акча белән бәйле түгел, башка нәрсәгә кагылышлы булачак.

– Шундый бер тип кешеләр бар, – дип куйды Галимҗан уйчан гына. –

Ничегрәк атыйм икән аңлашылсын өчен? Шыр куык инде болар, кыскасы, бушны бушка аударып, бушка гомер уздыручылар. Өч тиенлек белемнәре юк боларның, биш тиенлек акыллары. Тик нигәдер шундый кешеләргә тормыш итүләре күпкә җиңелрәк була. Җайлы бит агым уңаена агып барулары. Кызыктыргыч, вәсвәсәле нәрсә ул, Фәйзуллин да язган бит, «Башны салларга салып, китәсе иде агып», дип. Галёрадагы кол кебек ишкәк ишәсең юк, берни турында уйларга кирәкми. Суда батмый торган кизәк сыман агасың да агасың. Кайчагында шулай да була, зур көчле дулкын күтәрелеп, бу кизәкне ул бер дә уйламаган, күз алдына да китерә алмаган биеклеккә менгезеп куя. Кизәк үзе белән ни булганын аңлый алмый, әлбәттә, тизәк бит ул, мие юк тегенең, үзем ирештем барысына да дип тоя, шуңа ышана. Әзрәк башлырак, уйлый белә торганрак кеше булса, шикләнеп калыр иде, мин бу урынга лаекмы соң, осталык-сәләтем бармы бу эшкә, хезмәт күнекмәләрем җитәрлекме, дияр иде. Ә бу кизәк, юк, берни уйламый, беләме-юкмы барып тотына, боерыклар тарата башлый, зур эшчәнлек имитацияли. Бер шундый чиновникны беләм мин. Аны дусты күтәргән. Дусты бик шәп, талантлы, акыллы кеше иде. Иде дип, исән әле ул, зур урында гына эшләми инде хәзер. Ә заманында бернинди ярдәмсез, җонлы кулсыз, бары үзенең тырышлыгы, зирәклеге белән генә шактый югары менә алды ул. Бу мин әйткән чиновникны да гел үзеннән калдырмый иде, монысы карьера баскычы буенча күтәрелгәндә автомат рәвештә тегесе дә өскә үрмәләде. Тик әйткән бит Чехов, Россиядә талантлы кеше чиста гына була алмый, дигән. Нидер килеп чыккан инде анда, мин бөтен ваклыкларына кадәр белеп бетермим, кыскасы, очырдылар бу яхшы кешене постыннан. Гаҗәпләнерлек берни юк инде монда, киресенчә, аның номенклатура арасында шулай озак тоткарлануына таң калырлык. Ә теге шырт куык үз урынында калды. Хәтта тагын да югарырак постка билгеләделәр әле. Иң кызыгы, төгәлрәге, кызганычы шунда ки: элеккеге постында яхшы эшләгән өчен түгел, ә урлашып яткан өчен, ул җитәкләгән юнәлештәге эшләр бөтенләй туктап, уңышсызлыкка дучар булган өчен. Ярар, монда бик килеп чыкмады инде, янәсе, әйдә, менә монда эшләп карале, дигән сыманрак булды ул. Яңа урында да җиң сызганып, җайга салынган эшне җимерүгә керešте теге. Шуңа күрә, җәмәгать, Сөләйман пәйгамбәр юкка гына әйтмәгән инде: акылың күп булса, хәсрәт-сагышларың да артыр; әгәр дә кем дә кем белемен арттыра икән, шул кайгы-көенечләрен дә күбәйтә, дигән. Саклагыз балаларыгызны белем кебек олы хәсрәттән. Достоевский, Фолкнер, Мәһдиев, Еники китапларын яшереп куегыз, чыгарып ташласагыз, тагын да яхшырак булыр. Чеховны шундук яндырыгыз. Тукайның «Гали белән кәҗә»сен белсә бала, артыгы кирәкми. Бузова китап язган, ди. Менә шуның китабын алып бирегез балага, файдалы булыр. Музыка белән бик сак кыланырга кирәк. Классиканы, гомумән, балага тыңлатырга ярамый. Катгый тыела! Сәйдәшев, Бах, Бетховен, Чайковский, Яхиннарга бала күңелләренә үтеп керер өчен сыңар мөмкинлек тә бирергә ярамый. Үсеп килүче буынга джаз куркыныч, ул аңа үтергеч тәэсир ясый. Блюз да зарарлы, һәлакәткә илтә. Балалар Тиматины тыңларга тиеш, шул ук Бузованы. Ул вапшы маладис хатын: китаплар да яза, җырлар да чыгара, үзе шуларны җырлый да. Аңа «атказанган укытучы» исемен бирергә кирәк, күбрәк булсын иде шундыйлар. Мин боларны тик торганнан гына әйтмим, үзем кечкенәдән җыен сафсата

укып үстем. Йә Гётены, йә Гогольне, йә Әмирханны, йә булмаса бөтенләй Салих Батталны. Ә кемнәрне тыңладым мин? Әйтергә дә оят. Моцарт, Шопен, Сара Садыйкова, Илһам Шакиров башкаруындагы татар халык җырларын. Ә инде «Пинк Флойд»лар, «Кино»лар, «Сак-Сок»ларны тыңлый башлагач, бөтенләй түбән тәгәрәдем. Нәрсәгә ирештем нәтиҗәдә? Җан тынычсызлыгы, рухи эзләнүләр, үз-үзеңне өйрәнү, танып белергә тырышу, бу дөньядагы урыныңны табарга тырышу, әйләнә-тирәдә барган иҗтимагый тормышка тәнкыйди караш һәм башка шуның ише фәлсәфә-фәлән. Әйтсәң, кеше көләрлек, билләһи. Даниэла Стилны укыган булсам, «Чай Вдвоем»ны, Сабринаны тыңлаган булсам, бәлки прокурор булып китәр идем, үскәч. Яки депутат, яки полиция полковнигы. Алтын унитазга гына утырыр идем, шутка ли! Тик алай килеп чыкмады, төкердем мин тормышыма, гафу итегез купшы сүзләрем өчен. Балаларыгыз минем кебек булмасын дисәгез, – ялварып сорыйм сездән, үтенәм! Аларның киләчәген хәзер үк юкка чыгармагыз. Саша Спилбергның ваннага су урынына чипсы тутырып юынганын карыйлармы? Карасыннар, ярамый, димәгез. Китапларга килгәндә... Хәер, юк, укырга кирәкми берни дә! Сезнең балалар бәхетле тормышка лаек...

– Мин берни аңламадым, син хәзер ни сөйләдең? Кем турында булды бу? – дип куйды Хамис.

– Погода әйбәт бүген, ди, Сансыз, – дип елмайды Диләрә.

– Ә ник алай булды? – дип сорап куйды Илгизәр Зөлмәткә карап.

– Ни булды?

– Нишләп «Кызыл балан» банкротлыкка чыкты? Кадыйр үлгәнгәме?

– Әйе дә, юк та, – дип авыр сулады Зөлмәт. – Фирма бәлки әле тагын бик күп еллар шул җиләк-җимеш белән уңышлы гына эшләр иде, ләкин Кадыйрның васыятен үтәп, мин аның бөтен активларын саттым, һәрбер фирмадагы барлык акча-капиталларны әйләнештән чыгардым.

– Нигә? – диде Илгизәр.

– Әйтәм бит, Кадыйрның васыяте шундый иде.

– Ну, окей, чыгардыгыз акчаны әйләнештән, шуннан? – диде Илгизәр. – Бу бит максат түгел, нидер эшләү өчен шулкадәр күп акча кирәк булган бит инде сезгә. Нинди зур эш ул?

– Кадыйр бөтен булган байлыгын мохтаҗларга таратырга кушты: Кипишьның әнисе Хәлимә яшәгән картлар йортына, башкаларына, авыру балаларга ярдәм итүче фондларга, хосписларга, мәчет төзелешләренә, Диләрә бала тапкан роддомга, аның малае тәрбияләнгән балалар йортына һәм башкалар, һәм башкаларга.

– Балалар йортына? – диде Диләрә. – Сез ни әйттегез балалар йорты турында? Кабатлагыз әле, зинһар.

– Сезнең малаегыз тәрбияләнгән балалар йортына Кадыйр хәйрия ярдәме күрсәтергә кушты. Без анда спортзалга ремонт ясадык, туплар, фитнес өчен җиһазлар, балаларга спорт киемнәре алып бирдек.

– Ә минем улым анда түгелдер инде хәзер?

– Кабул итә алмадым мин ул баланы, ярата алмадым, дигән идегез бит әле?

– Баштагы мәлләрдә генә булды ул җүләрлек, – диде Диләрә. – Яшь чак бит, җүләр чак. Нинди коточкыч зур хата ясавымны аңлатып бирерлек кеше дә булмаган шунда ичмасам. Ике еллап чамасы узгач, улым турында торган

саен күбрәк уйлана башладым мин, аны эзләп тапмакчы булдым, тик кая ул... Әйтмәделәр роддомнан кая җибәргәннәрен... Таба алмадым мин аны.

– Ә Кадыйр тапты, – диде Зөлмәт.

– Сез беләсезме минем улымның хәзер кайда икәнен? – диде Диләрә калтыравык тавыш белән.

– Беләм.

– Кайда ул?!

– Сезнең белән бер вакытта балалар тудыру йортында кырыкның теге ягына чыккан хатын яткан. Аның да язмышы бик кызыклы, роман язарлык! Императорга сөйлисе калган да бит моны, хәзер соң инде... Кыскасы, әйбәт кенә яшәп яткан бу, ире белән ике кыз үстергәннәр. Әйтәм бит, кырык яшькә җиткәч, моңа егерме яшьлек бер егет гашыйк булган. Менә гел артыннан калмый йөргән, кем әйткәндәй, иркенләп тын алырга да җай бирмәгән бу хатынга – яратам, бетте-китте! Миңа кияүгә чык! Җыеп әйткәндә, бу хатынны гаиләсеннән аерып алып, өйләнгән бу егет моңа. Ике-өч ел чамасы балага уза алмый интеккән бу хатын, ә теге егеткә бала кирәк икән. Табибларга йөри торгач, ниһаять, авырга узган бу. Сезнең белән, Диләрә ханым, бер тирәләрдә тапкан баласын. Тик өч көннән баласы йоклап яткан җирдән кисәк кенә кычкырып куйган да үлеп тә киткән. Бу хатын кайгысыннан кая барып бәрелергә белми котырганда, палатада аның белән бергә яткан икенче бер хатын, моны тынычландырырга теләптер инде, әйткән шунда: «Әнә бит бер малайны анасы калдырып чыгып китте, шуны ал үзеңә», – дигән. Суга баткан кеше саламга да ябыша бит, бу хатын да табиблар янына барган да, бирегез ул баланы миңа, дигән, өзми дә куймый, ди. Үз дигәнен иткән бит, алган шул баланы үзенә тәки. Дөрес, роддомда чакта бирмәгәннәр, ярты еллап чамасы узгач, балалар йортыннан барып алган ул аны. Сезнең улыгыз, Диләрә ханым, Кононов Кирилл Константинович исемле. Алма алмагачтан ерак төшми ди, Россия Эчке эшләр министрлыгының Өфе юридик институтында укый, киләчәктә дөньяны җинаятьчеләрдән чистартырга хыяллана.

– Менә шулай ул! – дип куйды Галимҗан.

– Нәрсә шулай? – дип сорады Илгизәр.

– Бәләкәй чакта каз бәбкәсе саклаганда, әз генә игътибарсыз булсаң, авызыңны ачып торсаң, карга килеп бәбкәләреңне алып китә бит? Монда да шулай: татар аз гына абынса, чүт кенә ялгышса да, баласы Константин була да куя.

– Кирилл, – дип төзәтте Зөлмәт. – Константин атасының исеме. Тәрбиягә алган атасының...

– Кирилл... Улым...

## 17. Адәм булуы авыр, әрәм булуы җиңел

– Ну, банкрот «Кызыл балан!» – дип телгә килде Хамис, көтмәгәндә. – Ну, мин бит нипричом! Минем гаеп юк бит монда! Мин бит берни дә эшләмәдем!

– Берни эшләмәгән өчен дә җавап бирергә кирәк, шулай бит, Галимҗан? – диде Зөлмәт.

– Суд Галимҗанның эшен карауга күчә, аңлавымча, – диде Илгизәр. – Синең шкафка яшерелгән скелет «практикантка» дип атала идеме әле?

– Бик любвеобильный малай булып чыктың син, Буржуй! – диде Хамис. – Айдан төшкән Зөһрә турында сөйләгән идең бер сәгать селәгәйләреңне агызып, тагын нindидер практикантка килеп чыкты хәзер. Не ожидал!

– Күл астында ут торыр, ди. – Илгизәр хәйләкәр елмаеп куйды.

– Сакалына бәс кунгач, шайтан кытыклый башлый, ди бит, ир-атны, – диде Диләрә.

– Ник дәшмисең, Буржуй? – диде Хамис. – Авызыңа су каптың ыштули?

– Бәлки гаепләүче ачыклык кертер, ниһаять? – дип, Илгизәр Зөлмәткә борылды.

– Прокурор телендә «преступное бездействие, повлекшее смерть человека по неосторожности», дигән әйбер бар. 109 нчы статья, – диде Зөлмәт. – Шулай итеп, гаепләнүчеләр эскәмиясендәге өченче кеше – Гыйлемҗанов Галимҗан Гайфулла улы. 1980 елның 5 октябрендә Балтач районында туган. Өйләнгән, ике баласы бар. Мәктәптә тарих укытучысы булып эшли.

– Әйдәгез, әйдәгез, хөкем итегез татар укытучысын, оятыгыз җитсә, – диде Галимҗан. – Рәхим итегез! Мин өйрәнгән инде хәзер бер гаепсезгә суд эскәмиясендә утырырга.

– Тукта, сиңа нинди дәгъвасы булырга мөмкин? Син бит тарих укытасың? – диде Илгизәр.

– Татар теле дәресен тыйгач, аның сәгатьләрен кыскарткач, кая барыйм соң? Күчтем инде тарих укытырга, – диде Галимҗан. – Беркемгә кирәк булмаган татар теле миңа гына кирәкме әллә?

– Әйе, әйе, Император да сезне нәкъ менә шундый дип сөйләде, таныйм, – дип елмайды Зөлмәт.

– Ни дип сөйләде тагын? – диде Галимҗан ачулы тавыш белән.

– Бер сүз әйтергә ярамый аларга, үпкәләргә генә торалар, диде. Шул ук вакытта татар теле укытучылары үз миссияләрен белмиме, белеп тә башкара алмыймы, дип аптырый ул, – дип аңлатты Зөлмәт. – Ничәмә-ничә еллар буена безнең яклы законнары да бар иде, акчалары да бирелә торды, тик татар теле укыту буенча кирәкле нәтиҗәгә генә ирешеп булмады тәки, ди Император. Татар теле укытучыларын вузлардан надан итеп чыгаралармы соң, дип аптырый ул. Абсолют күпчелеге газета-журналларны да яздырып алмый бит, яңа әдәби әсәрләр белән танышып бару турында әйткән дә юк инде, ди. Татар язучыларыннан Тукай белән Җәлилдән башкаларны белмиләр дә, ди. Идеаль татар теле укытучысы мисалы итеп, ул Рәдиф Гаташны атады. Әнә бит нинди шәкертләр тәрбияләгән: Зөлфәт, Наис Гамбәр, Фәрит Гыйльмиләр, ди. Бар да татар теле укытучысыннан, мәктәптән тора, дип исәпли Император. Мәктәп бетсә, әдәбият үзеннән-үзе бетә, аннан соң инде милләт тә бетә, ди.

– Әйтер идем мин ул Императорга монда булса! – диде Галимҗан.

– Әйтегез, әйт!

– Кая булган соң ул Император татар теле укытучыларын кыйнаганда? – диде Галимҗан ачу белән. – Нишләп гаскәрен алып килмәгән безне якларга? Нигә язучыларны, журналистларны, театр артистларын, җырчыларны, ата-аналарны

җыеп, нигә протест митингы оештырмаган, нигә алар үзләренең ризасызлыгын белдермәгән? Татар теле белән килеп чыккан җәнҗаллы, хурлыклы вазгыять өчен без генә җавап тоттык. Татар теле өчен көрәштә укытучылар үзләре генә калды. Бөтен шакшыны безгә актылар, ул шовинист ата-аналардан, аларның балаларыннан ишетмәгән әшәке сүз калмады, прокуратураларда тикшерделәр безне. Җылы кабинетларда йомшак кәнәфиләрдә генә утырып, телне үстерергә тиешле акчаларны бүлешеп ятучы интеллигенцияне түгел! Мин бу хәлдән соң бер әйбергә инандым: татар татарны якламый, батыра гына. Татар башын татар ашар, дип юкка гына әйтмәгәннәр инде. Урыс ата-аналары килеп туган проблемаларда бары тик сез үзегез, татарлар гына гаепле, диделәр, мин алар белән килешәм. Булган мөмкинлекләрдән файдаланып калырга кирәк иде, балда-майда гына йөзмәскә, алма пеш, авызыма төш, дип, көтеп ятмаска иде.

– Ләкин бит Император... – дип Зөлмәт нидер кыстырмакчы иде, тик Галимҗанның кызуы җиткән иде инде, ул беркемне дә тыңламады да, ишетмәде дә, үзенекен генә сөйләде.

– Бөтен нәрсәне татар теле укытучысына өеп кую җайлы инде ул! Матбугатка язып, яңа китапларны укып бар, театрга йөр, балаларны да оештырып алып кил, сайлауларны да оештыр, тиешле нәтиҗәсен дә тәэмин ит – кыскасы дәүләтнең тузга язмаган нинди эше бар, барысын да бездән эшләтәләр. Ни генә таләп итмиләр хәзер укытучыдан, түлке җүнләп укытмасын гына! Ә сез беләсезме соң укытучының кәгазь эшеннән башын күтәрә алмаганын? Бертуктаусыз отчётлар, тестлар, укулар, аттестация – барысын да искә төшереп бетереп тә булмый хәтта! Әле тагын сез шуның өчен хезмәт хакы аласыз дип тә өстиләр. Ә минем чагыштырып карау өчен күршем бар, мәсәлән. Ул күптән түгел хокук саклау органнарында эшләп, пенсиягә чыкты. Хөкүмәт аларны шәп ашата! Нинди генә льгота-ташламалары юк! Балаларына бүләкләр, җәйге ял лагерьларына бушлай юлламалар, ипотека буенча да үз кагыйдәләре. Укытучының төшенә дә керә алмый торган әйберләр, кыскасы. Хөкүмәт укытучыга бернинди булышлык та күрсәтми, бары бушка эшләтә генә белә. Һәм, әлбәттә, таләп итә белә.

– Тулысынча килешәм Галимҗан белән, – дип, сүзгә кушылып китте Илгизәр. – Мәгариф системасын бетерүче тагын бер явызлык бар әле, ул да булса укытучыларның кул-аякларын бәйләп, аларны тулысынча хокуксыз итеп калдыру. Укучыларга бер сүз дә әйтергә ярамый бит хәзер. Ачулану түгел, тавышыңны күтәребрәк тә эндәшергә ярамый, чөнки 16-18 яшьлек әзмәвер-хулиганның нечкә психикасына тирән яра салуы бар икән укытучының. Элекке замандагы кебек почмакка бастыру, тәртип бозсаң дәрестән соң калып классны җыештыру кебек әйберләрне әйтәсе дә юк инде. Ә җәзасызлыкны тоеп алган үсмерләр хәзер бөтенләй шаштылар. Алар дәресләргә уку өчен түгел, ә укытучыдан көлү өчен, аны кимсетү өчен генә йөриләр, «батырлыкларын» видеога төшереп алып, интернетка да элеләр хәтта кайвакыт. Укытучылар боларны күрмәмешкә салыша, мәктәп директоры исә, гомумән, моның ише әйбердән уттан курыккандай курка, яшереп калырга тырыша. Имеш, мәктәпнең абруен саклыйлар.

– Карале, Штирлиц! – дип куйды Хамис. – Син родительский комитет персидәтеле кебек сөйләшеп утырасың гел, әйеме?! Әбрәкәй сандугачы син! Мин монда яшәп тә боларның берсен дә белмим, син соң каян беләсең, ә?!

– Ваемсыз булмасаң, әзрәк кенә дөньяның кая тәгәрәгәнен күзәтеп барырга теләгең булса, хәзер информация табуның бернинди авырлыгы юк – интернет тулы, – диде Илгизәр.

– Гомумән, безнең татар интеллигенциясе милләтне саклап калу, милләткә хезмәт, милли үсеш стратегиясе дип сөйли башласа, күңелем болгана башлый минем, – диде Галимҗан. – Әллә кайчан инде бер хикәя язып бастырмакчы булып йөрим шушы темага, кул җитми һаман. Менә күз алдына китерегез, бер бабай оныгы белән күл буенда йөри. Икесе дә ялан тәпи болар. Кич. Тыныч. Кызарып, кояш батып килә, тиздән төн җитәчәк, бөтен дөнья кап-караңгы булачак. Бабай оныгына карап, малай чакларын искә төшерә, коймак зурлыгындагы яссы таш эзләп таба. Оныгына: «Улым, карале!» – дип, ташны бала чагындагы кебек күл өстеннән чиерттереп җибәрә. Таш суга тия дә өскә сикерә, суга тия дә өскә сикерә. Шулай итеп, шактый еракка оча, тик барыбер ахыр чиктә су астына китә. Күл өстендә кечкенә дулкыннар күтәрелеп ярга бәрелә башлый. Кечкенә малай йөгереп килеп, бер-ике адым күлгә керә, су аның тубыгына кадәр генә җитә инде. Кечкенә учлары белән ул дулкыннарны туктатмакчы була. «Нишлисең, улым?» – дип сорый бабай. «Дулкыннарны ярга җибәрмим, анда барып бәрелгәч үләләр бит, юкка чыгалар», – ди малай. «Бәләкәй шул әле син, улым, аңлап бетермисең, – ди бабай, елмаеп. – Юкка көч сарыф итәсең, сәбәпкә каршы түгел, нәтиҗә белән көрәшәсең...»

– Брат, болар монда антисоветский, контрреволюционный пропаганда алып барырга маташалар, – диде Хамис Зөлмәткә. – Буржуй бик оста гына теманы практиканткадан татар милләте язмышына күчереп куйды, канишны, тик мине шул кыз язмышы күбрәк кызыксындыра. Буржуй ниткән ыштули аны, ә?

Хамис тагын гыргылдап көлә башлады.

– Ул практикантка күптән күктә инде, – диде Зөлмәт. – Гражданин Гыйлемҗанов, сез судка бу турыда нинди аңлатма бирә аласыз?

– Әрәмнәр булды шул, җаныкай, – диде Галимҗан. Уң як күзеннән чия төше хәтле бер күз яше агып төште.

– Кем соң ул? – дип сорады Диләрә. – Аңлавымча, сезнең мәктәпкә практикага килгән студент кыз булган?

– Әйе.

– Ни дигән сүз соң ул «преступное бездействие, повлекшее смерть человека по неосторожности»? – дип сорады Илгизәр.

– Бу нибары буш сүзләр, булмады бернинди дә преступное бездействие, – диде Галимҗан. – Киресенчә, мин аны коткарыр өчен көчемнән килгәннең барысын да эшләдем!

– Сезне тыңласаң, монда бүген әүлияләр генә җыелган, берегез дә гаепле түгел! – диде Зөлмәт. – Берсе дусларын сатып, шымчылык итәргә ризалык биргәндә, нинди кәгазьгә кул куйганын аңламаган, имеш! Икенчесенең җитәкләгән компаниясе банкрот, тик ул нипричом! Өченчесе япь-яшь кызны батырып үтергән дә, коткарыр өчен көчемнән килгәннең барысын да эшләдем, дип утыра.

– Батырып үтергән?! Галимҗан?! Дөресме бу?! – диде Диләрә.

– Бәләкәй чакта мин олыларга карый идем дә аптырый идем, – дип

сөйләп китте Галимҗан, бер ноктага төбәлеп. Бу вакытта аның күзләре ничектер пыялаланды. – Мин әйтәм, болар нишләп оекбашны шулай интегеп кияләр икән? Басып торган җирдән генә бер аягыңны күтәрәсең дә, шалт (!) тарттың куйдың бит инде оекбашны аягыңа? Юк, болар башта диванга барып утыра, бер аякларын икенчесенә куялар, аннары ах-вах килеп, оекбашларын аякларына тартып кидерә башлыйлар.

– Буржуй! Ни сөйлисең син?! Ычкындың ыштули? Сине монда яшь кызны үтерүдә гаеплиләр, ә син оекбаш турында сөйли башладың?! – диде Хамис.

– Сансыз, бүлдермә, зинһар, – диде Галимҗан. – Бераз гына сабыр ит, аңларсың... Хәзер менә үзем дә оекбашны шулай интегеп киям. Тормыш, гомумән, интегү инде ул, җәфалый икән ул дөнья, газапланырга килә икән адәм баласы бу җиһанга. Горький әйткән бит, кош очар өчен, кеше бәхетле булыр өчен туа, дип. Бер дә алай түгел икән шул, нәкъ киресенчә була икән тормышта. Мәктәптә физикадан укыдык бит инде: берни дә юктан бар булмый, бардан юкка чыкмый, бары икенче халәткә генә күчә. Кеше дә бу дөньяга килә, тегесенә китә. Шул арада ул гомерен ничек уздыра? Пычранып, гөнаһ җыеп. Сабый баланың күз яше кебек чиста дип юкка гына әйтмиләр бит. Аның күз яше генә түгел, уй-хыяллары да чиста. Тик яши-яши балачакның зәңгәр хыялларын без үзебез җиргә салып таптыйбыз, шәһвәт, хайвани теләкниятләр аркасында аларга хыянәт итәбез. Кеше җиргә бәхетле булып яшәргә дип киләдер дә ул, тик үзенең бәхетенә үзе балта чаба...

– Әйе, беләбез, – дип бүлдерде Зөлмәт. – Укыдык синең көндәлектән. Берәү бар – Иделдән ил кичергән, меңнәр бар – ник туганын белми гомер кичергән... Эшкә якынрак килик.

– Ә мин эзлим ул көндәлекне дөнья бетереп, – диде Галимҗан. – Кайларга гына куйдым икән, дим. Аннан соң, синнән чакыру хаты алгач, аңладым урлаганыңны. Алайса үзең сөйлә инде, анда бит барысы да язылган.

– Бөтен ах-вахларын, эчке кичерешләр тасвирлауны, күңел төпкелләрендә казынуларны төшереп калдырсаң, болайрак була инде, кыскасы, – диде Зөлмәт. – Галимҗан эшләгән мәктәпкә җәйге практика узарга педуниверситетта укый торган студент кыз кайта. Диана исемле. Һәм ышанасызмы-юкмы, Галимҗанга гашыйк була бу! Һәрхәлдә Галимҗан үзе көндәлегендә шулай дип язган.

– Ә ни өчен әле без ышанмаска диеш, ди? – Диләрә шулай сүзгә катышасы итте. – Хатын-кызлар әллә кемнәргә гашыйк була! Кайвакыт карап торасың берәр ир-атка, өстенә ак май ягып, юлга ташласаң, ач эт килеп иснәрлек тә түгел инде менә! Ә шуны да кемдер үлеп ярата, яши алмый аннан башка. Була ул шундый кызлар – үзләреннән күпкә олырак ирләргә исләре китә торган. Тизрәк үсәселәре киләме икән соң инде аларның? Барысының да димим, тик күбесенең бу мәхәббәт тарихы яраланган йөрәк, челпәрәмә килгән хыяллар, күз яшьләре белән тәмамлана.

– Өйләнгән башың белән, укытучы кеше, – диде Илгизәр, Галимҗанга шелтәле караш ташлап.

– Бердән, Диана үзе бертуктаусыз арттан калмый йөрде – Галимҗан Гайфуллович, Галимҗан Гайфуллович! Икенчедән, минем белән бутала башламаган булса, ул мәктәп директоры яки урам шпанасы башлыгы, Вальтер сыңары тозагына эләккән булыр иде. Директор, Хамис әйтмешли,

бик любвеобильный безнең, бер итәкне дә яныннан бушка гына үткәреп җибәрми. Тегесен әйтеп тә тормыйм инде...

– Синеңчә, димәк, Диана алар белән буталса, начаррак булыр иде? – диде Зөлмәт.

– Яхшырак булыр идемени?

– Исән калган булыр иде, – диде Зөлмәт.

– Үтермәдем мин аны, үтермәдем! Яздым бит инде барысын да көндәлектә тәфсилләп, – диде Галимҗан һәм башын иеп, учлары белән чәчләрен умырып тотты.

– Ни булган соң инде ахыр чиктә? Кешечә аңлатыгыз инде! – диде Диләрә.

– Мәхәббәт кабынган ике йөрәк арасында, – диде Зөлмәт. – Романтик очрашулар, чәчәк-кәнфитләр, тегесе-монысы. Берсендә су коенырга киткәннәр болар. Кеше-кара күрмәсен дип, пляжга төшмәгәннәр, шәһәрдән ераккарак, елганың аулаграк бер урынына барганнар. Диана йөзә белми икән. Шуңа ул суга кергәч, Галимҗанның аркасына яткан да, муенныннан ныгытып кочаклаган. Галимҗан елганың теге ярына чыгабыз, дигән. Кыз курыккан, юк, тирән урынга кермик, дигән. Галимҗан аны тыңламаган, егет икәнен күрсәтәсе килеп, киресенчә, тирән урынга йөзеп кергән. Әйдә, бер чумып алабыз, дигән ул аннары, шаяртып. Кыз бик нык курыккан, зинһар өчен, чума күрмә, дип ялварган, тик Галимҗан барыбер юри су астына төшеп киткән. Кыз куркудан кулларын җибәргән дә... шуннан соң аны беркем дә күрмәгән.

– Мин аны эзләдем, көчләрем тәмам беткәнче эзләдем! – диде Галимҗан. – Үзем батып үләрлек хәлгә җиткәч кенә, көчкә-көчкә ярга йөзеп чыктым.

– Адәм булуы авыр, әрәм булуы җиңел, – дип куйды Илгизәр.

## 18. Хөкем карары

– Шулай итеп, җәмәгать, суд утырышында гаепләнүчеләр Илгизәр Сүлтиев, Хамис Шәрәфуллин һәм Галимҗан Гыйлемҗановларның эшләре тикшерелде, – диде Зөлмәт. – Моннан егерме ел элек болар өчесе дә «булган бөтен көчемне, мөмкинлекләремне татар милләтен дөньяда таныту эшенә сарыф итәрмен!» – дип ант эчкән. Тик егерме ел узуга карамастан, берсе дә бу антны үтәр өчен бармакка бармак та сукмаган. Судья Кадыйр Ширияздaнов карары нигезендә өчесе дә кан тамызып эчкән антларын бозуда гаепле дип танылдылар.

– Ә Диләрә? – дип куйды Хамис.

Барысы да аңа аптырау катыш нәфрәт белән карап куйдылар.

– Вот ты козёл наглый! – диде Диләрә, урысчага күчеп. – Всю жизнь был такой – наглый, как танк!

– Синеңчә ул җәзасын алмаганмы әле? – диде Зөлмәт.

– Ә нинди хакы бар Кадыйрның безне хөкем итәргә? – диде Илгизәр. – Ул үзе нишләгән соң шулкадәр антны үтәр өчен?

– Ә нәрсә эшли ала иде соң ул төрмәдә? – диде Зөлмәт.

– Башкасын эшләгән бит! – диде Илгизәр. – Вальтерны үтерүне оештырган, мәсәлән. Үзе әйтте бит, әгәр син педагог икән – Монтессори бул, тегүче икән – Кристиан Диор бул, галим икәнсең – Нобель премиясен ал, шофёр икәнсең – Михаэль Шумахер кебек бул, шулай итеп татарны

бөтен дөньяга таныт, диде! Язмышыңа шулай язылгач, төрмәгә эләккәч, Аль Капоне, Пабло Эскобар булырга иде! Һичьюгы Япончик! Профессор кушаматлы бандитның бөтен дөньяга танылганын бер дә ишеткәнем юк.

– Күпертмәгез ул кадәр, – диде Зөлмәт. – Япун белән кытайны Шәмсениса түтәй белән бутамагыз. Кемдер бер гаепсезгә төрмәгә эләгеп тә, аннары да тормышының күпчелек өлеше рәшәткә артында узса да, татар җырчыларына да, язучыларына да, сәләтле балаларына да һәрвакыт булышып килде. Сез генә белмисез, чөнки ул бу турыда чат саен кычкырып йөрмәде. Ул гомере буе шушы антны йөрәгендә йөртте, аның өчен бу дөньяда бу анттан да мөһимрәк берни дә юк иде. Ә кемдер хәтта ант эчкән вакытта да аны җитдигә алмаган, күңеленә кертмәгән. Үтәү турында әйтмим дә инде. Кемдер бу антны бөтенләй хәтерләми, ә кемдер, исендә булса да, тормыш авырлыкларына сылтап үтәргә җыенмый. Беркемгә кирәк булмаган татар теле миңа ник кирәк соң ул, дип утыра. Кыскасы, монда бәхәсләшерлек урын юк, бердән. Икенчедән, туйдым мин сездән, җәмәгать, гарык булдым. Шулай итеп, суд өч гаепләнүчене дә – Сүлтиевне дә, Шәрәфуллинны да, Гыйлемҗановны да – яшьлек антларын бозуда гаепле дип таба һәм һәрберсенә кан тамызып эчкән антларын бозган өчен җәза билгели.

– Нинди җәза? – диде Диләрә куркып.

– Гражданин Сүлтиев, Илгизәр Насих улы! Сез 1999 елның 30 декабрендә майорга язып биргән гаризагыз турында Алманиядәге җитәкчеләрегезгә хәбәр итәргә тиеш. Үз теләгегез белән моны өч көн эчендә эшләмәсәгез, мин ул документны үзем аларга җибәрәм. Җаен табармын кулларына тапшырырга, шикләнмәгез. Гражданин Гыйлемҗанов, Галимҗан Гайфулла улы. Сез, иртәгә үк полициягә барып, Диана исемле студент кызны җинаятьчел саксызлык аркасында үтерүегез турында гариза язарга тиеш. Явка с повинной. Язмаган очракта сезнең көндәлекне тикшерү комитетына үзем җибәрәм. Гражданин Шәрәфуллин, Хамис Халит улы...

– Ә миңа нинди җәза ди? Ни өчен җәза? – диде Хамис. – Мин беркемне сатмадым, беркемне үтермәдем. Минем бер гаебем дә юк!

– Сезнең гаеп, кабатлап әйтәм, кан тамызып эчкән антыгызны онытуда! – диде Зөлмәт.

– Аның өчен статья юк бит! – диде Хамис. – Теләсә кайсы суд мине аклый! Чөнки мин гаепсез!

– Менә оправдать итмәсен өчен, – диде Зөлмәт елмаеп, – мин сиңа бер флешка бирәм, анда бик кызыклы мәгълүматлар җыелган. Шуларны салым инспекциясенә илтеп тапшырырсың, яме. Бармасаң, үзем илтеп бирәм.

– Нинди кызыклы мәгълүмат тагын? – диде Хамис.

– Аль Капоне исеме яңгырады күптән түгел генә, – диде Зөлмәт. – Кем ул, беләсеңме?

– Мафиозникмы әле ул?

– Әйе, Америкада «сухой закон» вакытында алкоголь сатып, сутенёрлык итеп, комарлы уеннар оештырып баеган гангстер, – диде Зөлмәт. – Шул рәвешле кергән акчаларын легальләштерү өчен ул бөтен Америка буйлап кер юу урыннары ачкан. Прачечнаяның татарчасы ничек була, Галимҗан?

– Парикмахерская чәчтараш бит, монысы керюыштыр инде, – диде Галимҗан.

– Ярар керюыш булсын ди, – диде Зөлмәт. – Монда пычрак керләреңне

алып килеп юу, бердән, бик җайлы булган, икенчедән, бик очсыз торган. Шуңа күрә америкаcreated өйләренә кер юу машиналарын сатып алып та тормаган. Ни өчен шулай очсыз? Чөнки Аль Капоне ул керюышларны акча эшләр өчен тотмаган, ә пычрак акчаларын чистарта торган схемада кулланган. Шуннан «акча юу» дигән гыйбарә кереп киткән телгә. Шулкадәр оста булган инде бу Аль Капоне, полиция бөтен кырын эшләрен белеп торса да, берничек тә тота алмаган моны, кылган җинаятьләрен дәлилли алмаганнар. Тик ахыр чиктә барыбер җаен тапканнар. Беләсеңме, нигә утыртып куйганнар аны, Хамис?

– Юк, нигә?

– Налог түләмәгән өчен. Сиңа да шул яный, 199 нчы статья, алты елга кадәр. Менә бу флешкада, – диде дә Зөлмәт, кесәсеннән нидер чыгарды. – Бу флешкада «Кызыл балан»ның бөтен «кара бухгалтерия»се җыелган. Һәрбер документта – синең имзаң. Бушка килгәннең атасы үлгәнне белми идеңме әллә син? Берни эшләмичә гомер буе директор кәнәфиендә утырып, рәхәтләнеп, бушка акча алып ятармын дип өметләнгән идеңме? Һәрнәрсә өчен кайчан да булса түләргә кирәк. Шуның белән вәссәлам, җәмәгать! Минем әйтәсе сүзем бетте.

### 19. Әнигә әйтмәгез!

– Ә юк! Тагын бер нәрсә калган икән, – диде Зөлмәт. – Мин бит сезнең һәрберегезгә Кадыйрның китабын алып килгән идем бүләккә. Хәзер алып чыгам, – диде дә Зөлмәт үз бүлмәсенә юнәлде. – Ә чын язмыш үзең язган гына! Аздан тора дәвам, аздан гына...

Илгизәр, Хамис, Галимҗан, Диләрә бер-берсенә карап каттылар.

– Сизенгән иде күңелем, – диде Галимҗан, – ахыры начар бетәсен.

Ул тагын көзгегә карады. Көзге бер мизгелгә каралып алды да, яңа күренеш ачылды: Диана белән Гоголь ниндидер затлы йортта вальс бии-бии Акгөл белән Бузова янына килеп җиттеләр, тегеләре исә дөньяларын онытып үбешеп торалар иде. Аннары фильм ахырындагы титрлар сыман астан өскә китаплар ага башлады. Беренчесенә «Фәхрине үтереп ташладылар» дип, исеме язылган иде, калганнарына бары тик авторы гына: Антон Чехов, Әмирхан Еники, Фёдор Достоевский, Уильям Фолкнер, Габдулла Тукай, Иоганн Гёте, Мөхәммәт Мәһдиев, Арво Валликиви, Михаил Булгаков, Салих Баттал...

– Кул кушырып утырсак, схлопнет безне бу официант, – диде Хамис. – Чё то надо думать, җегетләр!

– Думатьтан узган инде монда эшләр, – диде Илгизәр. – Бездән алда уйлап куйганнар...

Илгизәр тагын нидер әйтмәкче иде, ишек ачылып китте дә үз бүлмәсеннән китаплар күтәреп, Зөлмәт килеп чыкты. Йөзендә канәгать елмаю иде, ул ашыкмый гына үзе яңа гына хөкем чыгарган гаеплеләргә таба якынлашты.

Кече казан ташучан, ди. Хамис кисәк кенә сикереп торды да, котырган үгез кебек үкереп, Зөлмәтнең бугазына ташланды. Иң гаҗәпләндергәне шул булды, каршына Хамисның очып килүенә официантның бер дә исе китмәде, бала җоны да селкенмәгәндер, ул ничек елмаеп атласа, шулай дәвам итте. Сансыз килгән шәпкә Зөлмәтне бәреп екты, китаплар як-якка чәчрәп очтылар. Хамис корбанының өстенә менеп атланды, ярсу белән, котырынып, аның муенын

бар булган көченә кысты. Ул арада Галимҗан өстәлдән пиджак ярлыгын кискән пычакны алып, бөтен ярсу-ачуы белән, селтәнә-селтәнә Зөлмәтнең аякларына пычакны берничә мәртәбә кадады. Тик пычак тупас башлы иде, кайбер сукканнарда ул хәтта чалбар тукымасын да тишә алмады. Шуны аңлап алгач, Галимҗан Зөлмәтнең кулын тотып алды да беләзек тирәсеннән аның кан тамырларын кисә башлады. Официант боларга тамчы да карышмады, хәтта бер тын да чыгармады. Илгизәр исә, бер мизгел шок хәлендә утыргач, көзге каршыннан Фемида сынын күтәреп алды. Аннары идәндә әүмәкләшкән ирләр янына йөгереп килеп Фемиданы мөмкин кадәр югарырак итеп баш өстенә күтәрде һәм бар булган көчен салып статуэтка белән Зөлмәтнең башына бәрде.

Диләрә, шунда гына аңына килеп, җан ачысы белән кычкырып җибәрде. Илгизәр җәһәт кенә аның авызын каплады.

– Тссс! – диде Илгизәр, пышылдап диярлек. – Кычкырма! Җегетләр! Безгә тизрәк таярга кирәк! Тикшерегез түлке, әйберләрегез калырлык булмасын.

– Ачкычны табарга кирәк! – дип, Хамис Зөлмәтнең кесәләрен тикшерде. Шунда куен кесәсеннән бер конверт тартып чыгарды.

– Конверт ниндидер, – диде Хамис.

– Кая бир монда, ачкычны эзлә! – диде дә Илгизәр, конвертны алып ачты. Аннан кулдан язылган хат килеп чыкты. Илгизәр хатны кычкырып укый башлады:

– Фәхрине үтереп ташладылар, дияр иде Кадыйр. Ашыкмагыз, җегетләр! Сезнең беркая да ашыгасы калмады, алдагы берничә елга тормышыгыз билгеле. Мине үтерү турындагы җинаять эшен тикшерү комитетында инде тәмамлап, тегеп куйдылар, бөтен имза-пичәтләре урынында, акчасы түләнгән. 105 нче статья, пункт Ж – убийство, совершенное группой лиц по предварительному сговору. Унике елга кадәр. Сездә сорау туар инде: «Нигә кирәк булды икән Санчога үз тормышын болай корбан итү?» – диярсез. Аңламассыз шул сез, тик шулай да әйтеп карыйм. Беренчедән, миндә лейкемия таптылар, барыбер тиздән үләсе. Тик аны тапмаган булсалар да, мин барыбер бу эшкә барган булыр идем. Кадыйрның соңгы үтенечен үтәргә тиеш идем мин. Ансыз яшәү бик күңелсез иде, теге дөньяда очрашырбыз дип ышанам. Ахырда сезгә бер үтенечем бар. Минем әнием авылда берүзе генә яшәп ята. Гел теге «Калина красная» киносындагы сыман. Хәлимә исемле. Фамилиясе минеке кебек. Адрес паспортта бар. Ике юл гына булса да, хат язып салыгыз аңа, зинһар, юкка көтеп ятмасын мине. Әнигә әйтмәгез инде кыйнап үтергәнне, авыру алып китте дип языгыз. Алдан ук бик зур рәхмәт! Бәхил булыгыз. Зөлмәт.

Галимҗан көзгегә борылып карады. Кадыйр белән Зөлмәт, кулларын бер-берсенең җилкәсенә салып, бик канәгать кыяфәттә елмаеп, аңа карап торалар иде.

Ишеккә шакыдылар.

– Ачыгыз, полиция!



Лилия
Фәттахова

# ВАКЫТ КҮК ТАРАЛА ХӘЯТНЕҢ ӨННӘРЕ...

***

Минем йөрәк инде ярты гасыр
«Яратам» дип тибә.
Минем күзләр күргән һәм күрмәгән,
Мин ишеткән, хәтта ишетмәгән,
Минем куллар тоткан һәм тотмаган,
Минем күңел откан һәм отмаган
Никадәрле гүзәллек бар
Җирдә...

Ярты гасыр инде йөрәгемне
Сөю саклап килә.
Игелекне күреп һәм күрмичә,
Ирек хисен тоеп һәм үлмичә,
Ишләр белән сөхбәт кылып,
ишсезләнеп, гаҗизләнеп,
гарипләнеп, көчсезләнеп,
Исән калу бәхетеннән
көлә-көлә...

Ярты гасыр микрогаләмемдә
Падишаһым – Сөю.
Кемдер аңлар, кемдер аңламас та,
Кемдер аклар, кемдер акламас та –
Йөрәгемнең соңгы тибеше дә
«Мин яраттым» дию...

Лилия ФӘТТАХОВА `(1972) – *шагыйрә, прозаик; «Танырсыңмы?», «Карурман миләүшәсе», «Ишет мине!..» исемле китаплар авторы. Чаллыда яши.*

## Сүз көтмәгез миннән...

Сүз көтмәгез миннән,
мин үзем дә
Көтәм сүзне олпат агайлардан.
Сүзне әйтсен
кыю йөрәк белән –
Җилнең исү көчен абайлаган.
Ә минем сүз –
яшьле сүз ул бары...
Яшел сүз ул.
Ул соң кемгә кирәк?!

Авыр чакта сүзнең егәрлесе
һәм зирәге була ала терәк.
Сүз көтмәгез миннән...
Мин үзем дә
тилмерепләр көтәм акыллы сүз.
Энә сыман тишеп
сипләсен ул!
Мин җеп сыман –
иярермен сүзсез.

## Уйлар

Дүрт ягыгыз – кыйбла, димәдем лә...
Әй, уйларым, кая таралдыгыз?!
Кыйбла бутап, юл табуы кыен...
Минем җанда барыбер яралгыгыз...

Җан-нигезнең якты тәрәзәсен
Кара таплар белән тапламагыз.
Сез – минеке, мин сезнеке лә ул,
уртак йорт ул, безнең Акланыбыз.

Җыелыгыз! Дөньялыкның аның
һәр тарафы кыйбла ягы түгел.
Хаклык – аклык ягын – һич шөбһәсез
мизанына салсын гамьле күңел.

## Бу илдә

*Бу илдә табынып кына яшиләр...*
Г.Морат

Бу илдә – балбаллар илендә –
Табынып яшиләр ялганга:
Җан кыйган кылычның очында
Кан түгел, җиңүле гамь барга.

Бу илдә – балбаллар илендә –
Ялкыннар ялмамый ялганны.
Таш сыннар бастырып куйганмы
Дәрманын ирекле җаннарның?!

Бу илдә – балбаллар илендә –
Табынган саен җан абына.
Иблиснең тантана итүе! –
Очкыннан учаклар кабына...

Бу илдә – балбаллар илендә –
Өметне өзмәве бик читен.
Аллаһта – ышаныч дигән көн.
Бары шул... бербөтен... бербөтен...

***

Усаллана барабызмы?
Гаепсезнең
Бер гаепсез булуына
шигебез бар...
Кыланабыз
фал китабын ачкан сыман –
Ә бит күзләр – сукыр...

Колакта – зар...
Язмыш юлларының тузаннары
туры юлны күрсәтмичә
каплап тора.
Үзебезнең хаталарның шәүләләре
адым саен каһкаһәләп
саклап тора...

Курыкмыйбыз ялгышудан.
Бәя – катгый.
Ышанычның чит-читләре –
китек-китек.

Усаллана барабыз бит
түгелме соң?
Без соң әле
кая кадәр барып җиттек?..

## Уйлану

Киткәннәр көтәдер дигән уй килгәли...
Көтәдер безнең дә кайтасы көннәрне.
Һәм шулчак бәгырьне телгәли-телгәли
Вакыт күк тарала хәятнең өннәре.

Бүләкнең иң зуры – кул белән орынмас,
Кадере беленмәс Вакыт ул...
Иң затлы касәдән татлы сут уртлыйбыз
Һәм... йөзне чытабыз: «Ватык ул...»

Һәр җанда бу Җирне яктырак итәрлек
Ут-чыраг булуын оныттык...
Аяныч түгелме: без Җирне никадәр
Аяусыз рәвештә корыттык...

Вакытның үзен дә, камчылый-камчылый,
«Йөгенер ул безгә!» дидекме?!
И адәм затлары! Без соң бу фанины
Мәңгелек булыр дип белдекме?

«Вөҗүден күргәнче – гадәме хәерле»*
дип кемнәр озатыр кемнәрне?..
...Киткәннәр көтәдер дигән уй килгәли.
Көтәдер безнең дә кайтасы көннәрне...

*МӘСӘЛЛӘР*

## Керәле-чыгалы

Тирә-юньне тыңлап торгач бик озак,
Сул колакка дәшкән икән Уң колак:
– Мин ишеткәнне ишеттең лә кичә,
Ничек кенә түзәсең селкенмичә?!

– Үземнең дә аптыраган чак, туган,
Бу Хуҗама, белмим, нәрсәдер булган.
Ишеткәнгә төшенергә теләми дә
Чыгара да ата, хәтта иләми дә.

**P.S.** Керәле дә чыгалыга калгач хәлләр,
Кемнәр генә бер-берен соң аңлар, җәлләр?

* Булуыннан булмавы хәерлерәк мәгънәсендә.

## Акыл сату

Тәвә кошы күрше арандагы
Сарыкларның тетмәләрен тетә:
– Сарык булгач, рәхәттер ул, име?!
Бер кайгысыз гомерегез үтә.

Азык хәстәрегез Хуҗа күрә,
Ачтан үтермәсен белгәч – җиткән!
Бигрәк гамьсез яшисез сез, әстәгымә!
Бернидә дә гамегез юк читтә.

Үшән генә күшәп яткан сарыкларның
Бер йоны да селкенмәгән бу сүзләрдән,
Башын комнан алган чакта акыл саткан
Тәвәмени абруй әле, дип безләргә.

**P.S.** Акыл сатмас өчен дә шул акыл кирәк.
Шул хакта да уйлыйк әле сирәк-мирәк.

## Зоопаркта

Ике маймыл гәпләшәләр зоопаркта:
– Белмисеңме, ни кылына теге якта?

– Белмәдем дә, белмәмен дә! Пычагыма?!
Нәрсәгә ул безнең кебек корчаңгыга?


– Корчаңгы дип... без читлектә корчаңгы ла,
Чирләр үтәр үз иркеңдә торсаң гына.

– Аермасын, диген, адәм – читлегеңнән!
Ул иректә ни буласын Ходай белгән??!

**P.S.** Читлекнең шул һавасы да үзгә һава –
Бер гөнаһсыз уйларда да кинә таба.

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Рафис Сәлим

# АГЫЙДЕЛНЕҢ БУ ЯГЫНДА

ХИКӘЯ

Бертуктаусыз сөйләп торган улының сүзләрен тыңлый-тыңлый, Гыймран атын тышаулап, чирәмлеккә җибәрде. Коры-сары җыеп, ут тергезде. Күп тә үтмәде, корымлы кап-кара чәйнектә чәй кайнап та чыкты. Гыймран кружкаларга икешәр шакмак шикәр салды. Ипи кабып, шатыр-шотыр шикәр чәйнәп, чәй эчә башладылар. Малай туктамыйча сөйләде дә сөйләде... Аяк очында гына челләдә көйрәп, ялкауланып аккан инеш, малайның сүзләрен җөпләгәндәй, вак дулкыннарын ярга кага иде...

– Әти, ул шәһәрдә яшәгәндә, ышанасыңмы, юкмы – шушы төтен исенә чаклы сагындыра икән! Агачның менә шулай шарт-шорт януына чаклы сагындыра... Дөрес, кухняда газ януын күрергә була анда... Анда таш та таш, әти... Гел туйдырып бетерә икән ул таш. Йортлар – таш, тротуарлар – таш, коймаларга, эскәмияләргә тикле таш. Таштан йөри-йөри аяклар арый, ташка карый-карый күз арый. Ничек чыдый кеше шул таш арасында...

Гыймран ашамлыкларны җыеп алып, биштәргә салды, учакны сүндерде. Кесәсеннән янчык белән газета чыгарды. Газетаны пөхтәләп кенә ертты да, аңа махра сипте, йомры итеп, оста итеп төреп тә куйды. Аны төкерәге белән җайлап кына җилемләде. Авызына кергән тәмәке бөртеген җайлап кына, әллә кая кадәр төкерде дә Агыйделгә карап утыра башлады.

– Анда, әти, машиналар тавышы колакны тондырып бетерә икән... Ул безнең бу тынлыкны, әти, анда акчага сатып алыйм дисәң дә, таба алмыйсың икән. Һи-и... Кара әле, әти, бал корты...

Гыймран карашын үзенең күн итеге тирәсендә йөргән бал кортына күчерде.

– Күр әле, әти, ничек рәхәтләнеп очып йөрүен! Анда, әти, мондый бал кортларын күрә алмыйсың инде. Каян килсен шәһәргә – бал корты?!.

Гыймран тәмәкесен кабызды. Туплауга барып, сыерларны карап килде.

---

Рафис СӘЛИМ (Рафис Сәлимҗанов) (1952) – *язучы. «Елан мөгезе», «Күкеле сәгать», «Төркиләрнең бөек теле» китаплары авторы. Чаллыда яши.*

Көндезге сәгать уникеләр тирәсе иде, мондый кызуда малларда ашау кайгысы юк, лапас астында тик күшәп торалар.

...Кичке сәгать җиделәр тирәсендә атка атланган Гыймран, чыбыркысын сөйрәп, арт капкадан ишегалдына кайтып керде.

Малай, тәрәзәдән аны күреп, өйдән ашлы су алып чыкты, сызгыра-сызгыра, атка эчерә башлады. Атның маңгаендагы йолдызлы ак кашкасыннан сыйпап узды. Баскыч төбендә тәмләп кенә көйрәтеп утырган әтисе янына басып, җәйләүдә сөйләгән сүзләрен дәвам итте.

– Анда, әти, менә шушы атларга тикле сагындыра. Аптырыйм – нигә кеше китә ул шәһәргә... Анда кыш көне рәтле көрт күрә алмыйсың. Җәй көне юньле яшеллек күрә алмыйсың... Анда ашарга да сыер мае шикелле майлар юк... Безнең сөт шикелле куе да түгел анда сөт. Анда кеше безнеке шикелле сөтне үз гомерендә бер тапкыр да эчә алмый... Ә каймаклары – күпчеп беткән катык шикелле бер нәрсә шунда... Аннары анда, әти, кеше гел өйдә утыра. Ә безнең тыштан кергәнебез дә юк. Чит илләрдә киресенчә, байлар авылларда яшиләр икән хәзер. Безнең бу авыл, әти, алпавыт утары кебек бер нәрсә булып чыга инде, шулай булгач. Авылда һәр кеше – алпавыт, ә үзе шуны белми яши, әти... Анда кешенең ашаган әйбере хәзер күбрәк химия икән, бездәге шикелле свежий әйберләр юк икән анда хәзер...

Гыймран, төпчеген баскыч төбенә ташлап, озаклап итек табаны белән таптап торды. Малай чиләкләрне алып суга китте. Ул кайтып кергәндә дә әле Гыймран шул урында, чыбык белән баскыч төбенә җәелгән кызгылт комга ниләрдер сызгалап утыра иде.

– Анда, әти, безнең инеш суы шикелле суларны төшләрендә дә күргәннәре юк кешеләрнең. Анда чылтыр-чылтыр җырлап аккан суның ни икәнен белми яши кеше.

– И-и, ямьле дә соң безнең инеш буйлары! Андагы кеше мондый матурлыкны күрер өчен әллә ничә автобус, трамвай алыштырып, әллә ничә сәгатьләп бара. Ә безнең – бакча артында гына бит шундый сәйрән. Су буе тутырып казлар, бәбкәләр... Анда бит кеше мондый нәрсәләрне йә кинода, йә телевизорда гына күрә...

Малай һаман сөйләвен белде. Чиләк күтәреп, сыер саварга чыккан әнисе дә, алар янына килеп, башын селки-селки, малайның сүзләрен тыңлап торды.

– Ярар, улым, мунча булгандыр инде, – диде ул, ниһаять. – Атасы, син дә бар, булмаса...

Алар аталы-уллы икәүләп мунчага кереп киттеләр.

– И-их! – дип шатланып кычкырып куйды малай, мунча ишегеннән керүгә. – Яратам мунча исен! Төтен исе дә бар – шуңа күрә яратам... Ах... Ух!.. Яратам шушы каен себеркесе исен! – дип сөйләнде малай. – Син дә яратасыңмы, әти?

– Әллә тагын, – диде Гыймран, чүмеч белән ташка су җибәреп һәм бияләй белән бүрек киеп, ләүкәгә менеп утырды.

– Анда бит мунчага да ярты сәгать барырга кирәк, – дип сүзен дәвам итте малай. – Мунчасы да син теләгәнчә ташлы түгел бит әле аның... Кешесе дә күп... Ә монда бер мунча – бер үзеңә...

Мунчадан чыкканда малай койма буендагы кычытканнарны сыйпап китте.

– Менә шушы кычытканнарга тикле сагындым... Карлыган бакчасын да сагындым... Шушы бәрәңге бакчасына тикле... Синең шулай сагынганың бар идеме берәр вакыт, әти?

– Әллә тагын.

***

Төн. Мөдәрриснең караваты янында, икесе ике урындыкка утырып, Гыймран белән Хәмдия сөйләшә.

– Балакаем, – ди ана. – Кайта да шул, сагынам да сагынам, дип сөйләнә дә тагын чыгып китә.

Гыймран пәрдәләрне күтәреп, зәңгәрләнгән тәрәзәләргә карап алды.

– Уятырга кирәк, – диде ул.

– Улым, тор... Тор инде!

– Ә? Әү, әни?

– Тор, улым. Соңга каласың.

– Әз генә... Бераз гына йоклыйм әле, әни.

– Әтиең, бакча артыннан атны алып кайтам дип әйткән иде. Барасыңмы?

– Барам! – диде малай һәм шунда ук сикереп торып, җәһәт кенә киенде дә чыгып та йөгерде. Бераздан тәрәзәдән аның йолдыз кашканы ишегалдына алып кайтып кергәне күренде.

Яктырды. Ата белән ана Мөдәррисне инеш күперенә тикле озата килделәр.

– Әллә соң... Китмисең генәме, улым? – дип, сак кына сорап куйды ана аерылыр алдыннан. – Агыйделнең арьягында бер инәгә бер сыер... Ә барсаң берни дә юк, диләр бит!

– Авылны яратам да дисең, – дип, моңсу гына елмаеп өстәде атасы да.

– Их... Мин бик китмәс идем дә бит... Кызлар китә шул! – диде малай һәм очар кошлар кебек тезелешеп барган авылдашлары артыннан соңгы кош булып, араларына барып кушылды.

Кызларның алданрак барган берсе, иң нечкә биллесе, борылып, ата-анага бер күз салды да – юлында булды...

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең олуг юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗатта уңышлар телибез.*



Рифат
Сәлах

# ВАКЫТ АГА... КӨЗГЕ ЯҢГЫР БУЛЫП...

## Алма ява

Көзге җилдә җиргә алма ява —
Җыр явамы шулай, кем белә?
Ни кадәр моң белән тулган җирем —
Алтын белән дөньям күмелә.

Никадәр моң белән тулган сөю,
Син кайтасың икән көзләргә.
Ә мин чыккан идем сине сагынып,
Алтын алмаларны эзләргә.

Ә мин чыккан идем, бик юксынып
Алма булып пешкән чагыңны.
Син бөтенләй үзгәрмәгән икән —
Кояш кебек һаман ягымлы.

Җилфер-җилфер сары күлмәкләрең,
Бөдрә чәчең җилдә тибрәлә.
Әйтерсең лә, көзге күбәләкләр
Очып уйный синең тирәдә...

Әйтерсең лә, сагыш булмаган да,
Әрнү булмаган да шикелле.
Син һаман да яз гүзәле икән —
Битләрең дә һаман сипкелле.

Син һаман да язгы, назлы икән,
Көзләр килмәгән дә диярсең.
Күзләреңдә шаян нурлар уйный —
Әллә син дә мине сөясең?

---

Рифат СӘЛАХ (1987) – *шагыйрь; Төркия язучылар берлегенең Н.Кемаль исемендәге әдәби премиясе лауреаты. «Яшел ай», «Ак фәрештә», «Мин – хыялың синең!..» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Көзге җилдә җиргә алма ява,
Бәхет ява микән, кем белә!
Син һаман шул – һаман минем хыял,
Син мәңгегә минем күңелдә!

## Әюп пәйгамбәрнең чишмәсе

Унсигез ел кичкәч авыр хәлдә,
Сызланудан кипкәч күз яше.
Тешне кысып, бер тибүдән чыккан
Әюп пәйгамбәрнең чишмәсе.

Авырлыклар басса иңнәреңне,
Бер йотым су учлап эчәсе.
Каршы якта гел ургылып торсын
Әюп пәйгамбәрнең чишмәсе.

Дөнья агар, мәңге туктамас ул,
Исәр җилнең исәр исәсе.
Күңелеңдә һаман челтерәсен
Әюп пәйгамбәрнең чишмәсе.

Бер хәрәкәт кирәк авыр чакта,
Үкчәң белән җиргә тибәсе.
Әбелхәят хаҗәтмени, булса
Әюп пәйгамбәрнең чишмәсе?

Унсигез ел яраң сыкраса да,
Сызлансаң да күңелең төшмәсен.
Иманыңа барыбер табарсың син
Әюп пәйгамбәрнең чишмәсен.

## Көтелмәгән сөенеч

Бүген иртән чыкта коендыңмы?
Юындыңмы чишмә суында?
Ак күлмәгең җилфердиме җилдә,
Нинди шатлык синең җырыңда?

Сизәсеңме, сөенечләреңнең
Акрын гына җанга үрләвен,
Бәхетеңнең күккә ашуларын,
Сөюеңнең янып дөрләвен?

Сизәсеңме, син бөтенләй башка,
Башкачадыр күңел моңың да.
Күрәсеңме, бөтен игелекләр,
Изгелекләр ява юлыңа.

Син барасың оҗмах түрләренә,
Иңнәреңә элеп нур-канат.
Син барасың шушы юллар буйлап,
Гомереңдә, бәлки, мең кабат.

Син барасың шушы юллар буйлап,
Беренче кат, бәлки, кем белә.
Күңелеңә әнә кояш куна,
Күзләреңнән шатлык бөркелә.

Насыйп булсын сиңа һәр иртәне
Чишмә челтерәвен тыңларга.
Һәрчак атла шулай сөенә-сөенә
Изгеләрдән изге җомгага.

## Дөнья каһвәсе

***(Этюд)***

Каһвә тәэсиреннән гасаби мин,
Үрсәләнәм, янам, биртеләм.
Әллә нигә бик тиз кызып китәм,
Бер кайгырам шунда, бер көләм.

Тынгысызлык чире кагылдымы,
Күмелдеңме гамьгә, әй, адәм?
Бер мизгелгә аерылып тор син
Дөнья дигән чиксез каһвәдән.

## Вакыт ява

Яңгырчактан өскә коела да,
Вакыт тама бармак арасыннан.
Күз яшьләре белән бергә ул да
Төпкелләргә төшеп бара сыман.

Вакыт ага, кайчак кайнар судай,
Кайчак суык суын сибә өскә.
Мин туктатыр идем бу яңгырны,
Туктатуның серен сөйләгез дә.

Вакыт ага... Күзге яңгыр булып,
Вакыт ага кышын ак кар сыман.
Без барабыз нидер эзли-эзли
Тамчы белән тамчы арасыннан.

Без барабыз туктатырга теләп
Мәңге тынмас вакыт яңгырларын.
Вакыт белән бергә яшьлек китә,
Вакыт белән бергә агыла моң.

Вакыт тама, юмак булып безне
Үткәннәрнең әрнү-ярасыннан.
Вакыт ява, ә барыбер алда
Яшьлек учаклары яна сыман.

## Шагыйрь хакы

*– Безгә күпме түләрләр икән?*
*– Сметада каралмаган.*
Ишеткәннәрдән

Шагыйрьләр бит һава сулап яши,
Шигъриятнең поты бер тиен!
Халык каршысына чыгам диеп,
Танылам дип, әйдә, бер сөен!

Шагыйрь халкы ач килеш шәп яза,
Усалрак була, дәртлерәк.
Сметада берни каралмаган,
Исемең юк, үзең вак, димәк.

Ач килеш бик җырлап булмый, диеп,
Җырчыларга акча бирелә.
Ансамбль бит, күпме сикерә бит,
Түләмичә булмый биюгә.

Ә шагыйрьләр... Алар фәкыйрь була,
Алар хисле, алар кадерсез.
Ничек җырлар икән җырчы халкы
Милләтебез калса шагыйрьсез?

Ә шагыйрьләр бушка язып йөри,
Халык күңеленә юл эзләп.
Вакыт җиле күмеп китәр беркөн,
Сметаны куяр тигезләп.

## Кояш өчен

Кояш өчен көрәш бара җирдә,
Ут атыла, җаннар кыела...
Әйтерсең лә, безгә нурлар белән
Мәңге сүнмәс бәхет коела.

Кояш өчен көрәш бара җирдә,
Аһ, өзелә күпме гомерләр.
Өйләр сала кеше, гөлләр чәчә –
Гөл өстенә оча күмерләр...

Кояш өчен көрәш бара җирдә,
Җылы җитми микән кешегә?
Үз дустыннан көнли, күршесеннән,
Туганына хәтта үчегә...

Ә кешеләр ялгызлыктан гаҗиз –
Җан дусларын таба алмаган.
Оялмыйдыр алар адәмнәрдән,
Оялмыйдыр хәтта Алладан.

Кояш өчен көрәш бара җирдә:
Бер бәндәне кыра бер бәндә,
Ялгызлыкта калган күңелләргә
Җылы җитми торган бер мәлдә.

## Яшьлек

Күкрәгемдә дөрләп торасың син,
Күзләремнән нурлар коясың.
Сиңа таулар – бер калкулык кына,
Менеп җитмәс бөек кыя син.

Сиңа диңгез – бер күл кебек кенә,
Иңен-буен мең кат иңләрлек.
Бер карасаң, синдә күпме гакыл,
Бер карасаң, күпме юләрлек.

Кайчагында моңга саласың син –
Төпләренә төпсез упкынның.
Мең мәртәбә синдә ташкын булдым,
Мең мәртәбә синдә ут булдым!

Син канатлар биргән идең миңа,
Кире кайтармасам, бигайбә!
Әй син яшьлек, безнең арабызга
Мәңге китмәс өчен кил әйдә.

Әй син яшьлек! Әллә китәм дисең,
Калдырырга юкмы бер чара?
Китмә бездән, китсәң, яңадан кайт,
Башка дөньяларда булса да.

## Дүшәмбе

Бу дөньяның өермәсе белән
Бер бөртектәй килеп төшәмме?
Иртә белән кеше бураныдай –
Каршы ала безне дүшәмбе.

Ике көнгә оеп алган инсан
Бүген иртән кинәт уяна.
Әйтерсең лә кичә генә килгән
Бу өч көнлек фани дөньяга.

Уйларымны тезеп куйган чакта,
Гавам тагын боза барысын.
Кочагына дәшә дүшәмбе көн,
Ничек инде эшкә бармыйсың!

Бу дөньяның тынмас буранына
Өр-яңадан гавам чакыра.
...Әллә нигә ыгы-зыгы тансык
Бураннары тынган җаныма.

## Икенче җәйгә кадәр


Интернет киңлекләрендә
Йөгерә шундый хәбәр.
Хушлашып торыйк әле дип,
Икенче җәйгә кадәр.

Әйтерсең, җәй белән җирдән
Гүзәллек, иләм китә.
Гүяки тормыш туктала,
Көч бетә беләгеңдә.

Гүяки бөтен моң-сагыш
Тугыз ай биләр сине.
Гүяки мәңгелек күкнең
Кинәттән бетәр сере.

Гүяки өзелер җиһан
Галәмнең үзәгеннән.
Гүяки китәр чәчәкләр
Мәхәббәт үзәненнән.

Гүяки шушы бер җәйгә
Бар дөнья яме сыйган.
...Күңелдә һаман яз булса,
Җәйләр дә артык сыман.



*2006 елда Европа һәм Азия кыйтгаларындагы бер төркем төрки телле Язучылар берлекләре Төркиядә җыйналып, үзара берләшергә дигән карар кыла һәм Евразия Язучылар берлеге оештыра. Аның Генераль Рәисе итеп (төрекчә әйтсәк – башканы) Якуп Өмәруглы сайлана.*

*2012–2016 елларда бу оешма безнең Татарстан Язучылар берлеге белән дә актив хезмәттәшлек итте. Язучыларыбыз Төркиядә һәм башка төрки республикаларда үткәрелгән күп чараларда катнашты. Хәтта күренекле шагыйребез Зиннур Мансуров татар-рус-инглиз телләрендә чыккан «Тукайча татар кодексы» һәм «Тукай белән әңгәмәләр» дигән китаплары өчен Евразия Язучылар берлеге карары белән «Төрки дөньяның Ел әдибе» дип табылды.*

*Якуп Өмәруглы 1966 елда туган. Башлыча хикәяләр яза. Аның беренче китабы 1987 елда дөнья күрә. Әсәрләре Төркиядә, Казакъстанда, Кыргызстанда, Үзбәкстанда, Азәрбайҗанда, Иранда һәм Россиядә басылып чыккан.*

Якуп Өмәруглы

# УН ДОЛЛАР

хикәя

Ул очкан самолёт чыгып килгән кояш нурларында коенып, аэродромның төшү полосасына килеп керде. Кадыйр алдында таможня контролен үтү һәм такси яллап, күрше илгә барып житү бурычы тора иде. Аңа һәрвакыт таможня хезмәткәрләренең пассажирларга мөнәсәбәтендә илнең тышкы дөньядан яшерен эчке тормышы чагылган кебек тоела иде. Юлда күп йөргән кеше таможня хезмәткәрләренең үз-үзен тотышына карап, үзе очып килгән илнең сәяси һәм икътисади хәлен, халкының грамоталылыгын һәм тормыш-көнкүрешенең нинди булуын чамаларга мөмкин. Бу хакта ачыктан-ачык сөйләргә бик ярамаса да, ул һәркем өчен дә билгеле хакыйкать. Бал белән закон һәм тәртип идарә иткән, икътисад чәчәк аткан дәүләттә, бөтен нәрсәгә карата яшертен, әмма ап-ачык хөрмәт була һәм кагыйдәләр тайпылышсыз үтәлә; ә икътисад әле яңа гына үсә башлаган яки үсешеннән туктап калган илләрдә, күп сораулар элемтәләр аша гына хәл ителә, бөтенләй башка атмосфера хөкем сөрә. Моның шулай икәнлеге әле самолёт бортында чакта ук аңлашыла башлый. Самолёт очышын төгәлләүгә, пассажирлар тыгылыша башлыйлар һәм хаос килеп туа. Ни өчен соң әле берничә минут элек кенә тәрбияле һәм тәкәллефле күренгән кешеләр, икенче бер илгә очып килеп төшүгә, кинәт кенә үзгәрәләр, культуралылыкта берничә баскычка түбән төшкән кебек булалар? Сизәсез микән, аэропорт хезмәткәрләренең карашы да кайвакыт гаять салкын һәм кырыс булып күренә. Аларның аеруча игътибар белән пассажирлар агымыннан күзәтү астында булырга тиешле кешене эзләүләре сизелеп тора. Багажы булмаган, кулларына чемодан гына тоткан югары дәрәҗәдәге, авторитетлы

пассажирлар, гадәттә, тикшерү кебек формаль процедураларны тизрәк үтәргә ашыгалар.

Кадыйр паспорт контролендә озак тоткарланмады. Таможня хезмәткәре аның документында күрше ил визасын һәм эш лицензиясен күреп, үз биләмәсендәге хакимлеген күрсәтергә тырышкандай, каты итеп үз мөһерен сукты. Паспортын алгач, офицер сизмәслек итеп кенә «уф» дип сулыш алып, ул беренче ишеккә таба юнәлде. Әмма тулы иреккә кадәр әле ерак, алда такси белән тикшерү пунктына барып җитәсе бар иде. Моның өчен башта күрше ил чигендә урнашкан такси тукталышына барырга кирәк. Һәм шуннан шул ил номерлары булган таксида юлны дәвам иттерергә. Дөньяда ике ил чикләре кисешкән нокталар бихисап күп, һәм аларда яшертен генә таксиларының номерларын да алмаштырып, ике ил буйлап та йөрүче таксистлар да җитәрлек. Чит ил номеры белән йөрүче такси, әлбәттә инде, тикшерү пунктларында эшләүче полицейскиларның игътибарын үзенә тиз җәлеп итә. Мондый өстәмә «тикшерүләр» өстәмә түләүләргә, ришвәт бирүләргә мәҗбүр итә. Ришвәт бирүне Кадыйр һәрчак үзенең кешелек дәрәҗәсен төшерү дип кабул итә, ул гаиләдә дә шундый тәрбия алган, университетта да аңа шулай дип укыттылар. Эш шуңа барып җитсә, ул комач кебек кызарып чыга, йөрәге ярсып тибә башлый. Әле аэропортта чакта ук аңа үз хезмәтләрен күрсәтәбез дип, ике кеше бәйләнде. Аларга шикле караш ташлап, Кадыйр карашы белән генә күңелдә ышаныч тудыра торган һәм пөхтә кыяфәтле машина йөртүче эзли башлады. Һава аланыннан чыгу юлында очып килүчеләрне хет оҗмахның үзенә кадәр илтеп куярга тәкъдим итеп, бер көтү таксист каршы ала. Кадыйрның күзе шундый «бомбил»лардан бер читтәрәк басып торган урта яшьләрдәге бер иргә төште. Аның карашын сизеп, таксист теге ике яшь егетне кулы белән җиңелчә генә этеп, Кадыйрның кулыннан чемоданын алды да:

– Машина тегендә, киттек, – диде.

Кеше ташу белән шөгыльләнүчеләр клиентларын үзләренә җәлеп итү серләрен бик яхшы үзләштергәннәр.

– Кая барабыз? – дип сорады таксист.

– Ханҗәйләүгә, – диде Кадыйр.

– Йөз.

– Кырыкка барам.

– Төнге бәяләр шундый.

– Сез нәрсә, таң атып килә бит. Сезнең өчен кояш ике мәртәбә чыкмас, – диде Кадыйр.

– Ярар, иллегә барабыз, – дип килеште таксист.

Юл хакын ризалашкач, йөртүче пассажирын дөньяны күп күргән, Европадан монда ничек килеп эләккәне билгесез булган иске генә «Мерседес» янына алып килде. Машинасын көч-хәл белән генә кабызгач, таксист:

– Күршеләргәме? – дип сорады.

– Әйе, – диде Кадыйр.

– Минем яхшы танышларым бар, баргач, сезне шулар янына утыртырмын. – Бу таксистның тикшерү пунктындагы танышлары турында әйтүе иде.

– Яхшы. Тик алар машиналарына шул ил номерларын куйсалар, әйбәт булыр иде, – диде Кадыйр һәм уйлап куйды: «Ярдәм итәргә теләвеме бу моның, әллә алардан клиент тапкан өчен үзенә дә өлеш чыгамы?»

Бу уй таң алды томанында эреп юкка чыкты, Кадыйр төн богауларын өстеннән салып аткан дала гүзәллегенә сокланып, тәрәзәдән карап бара

башлады. Алар ике полиция пунктын җиңел генә узып киттеләр. Таксист ул пункларны ерактан ук күреп алып, катгый тон белән: «Ришвәтчеләр!» дип белдерде.

– Алар гына шундыймы? – дип сорады Кадыйр, елмаеп.

– Каян белим тагын кемнәрнең коррупционер булуын. Ә болар турында яхшы беләм, алардан күп күрдем золымны, – диде ир һәм үзенең балалары турында сөйләргә тотынды.

Ханҗәйләүдә Кадыйр икенче машинага күчеп утырды. Монысы «Мерседес»тан күпкә яхшырак, яңарак, йөртүчесе дә ышаныч тудыра торган кеше булып күренде. Юл хакын килешеп түләгәч, ул таксига кереп утырды, багажын йөртүчеләр үзләре урнаштырдылар. Тиздән алар чик буена килеп җиттеләр. Таможняда тынлык иде, гадәтләнгән тавыш, шау-шу ишетелмәде. Таксист Кадыйрны төшергәч:

– Мин машинаны күчерә торам. Теге якта очрашырбыз, – диде.

Кадыйр таможня тикшерүе урнашкан бинага керде, ул яңа иде. Буш зал буенча үтеп, паспорт контроле өстәлен эзләп тапты, яңарак кына эшкә керешкән хезмәткәрләр янына килеп басты. Аларның берсе үз янына килергә ымлады. Кадыйр аның янына барып, документын сузды. Хезмәткәр паспортның фотолы битен эзләп тапты һәм әле Кадыйрның йөзенә, әле фотога карап, аларның бер-берсенә охшашлыгын тикшерә башлады. Таможня контроле үткәндә бу, мөгаен, иң күңелгә ятышсыз процедурадыр. Кадыйрга тикшерүче бу эшне юри шулай сузадыр шикелле тоелде. Аның йөзе белән паспорттагы фоторәсем арасында аерма тапмагач, офицер документтан визалы битне эзләргә кереште. Тапкач, шулай ук ашыкмыйча гына визаны өйрәнә башлады. Кулын компьютерга сузып:

– Эш белән килдегезме? – дип сорады.

– Әйе, мин төзелеш фирмасында идарәче, – диде Кадыйр, аның болай да сораячагын аңлаганга, махсус эш урынын һәм дәрәҗәсен әйтеп.

– Димәк, начальник?

– Юк, мин урынбасар.

Шул минутта хезмәткәр Кадыйрның мәгълүматларын компьютерга төшереп, илтифатсыз гына:

– Алайса, сездән йөз доллар, – дип куйды.

– Минем бөтен документларым да тәртиптә, ни өчен бирергә тиешмен мин ул кадәр акча?

Таможня хезмәткәре, сорауны ишетмәмешкә салышып, Кадыйрның паспорт номерын язуын дәвам итте.

– Бу илдә кайчаннан бирле яшисез?

– Дүрт ел, – диде Кадыйр.

– Телне яхшы беләсез, димәк?

– Әйе, начар түгел.

Кадыйр чынлап та бу ил телен шулкадәр яхшы үзләштергән иде, хәтта аның чит илдән икәнен белмәүчеләр шушы ил кешесе дип кабул итәләр иде.

– Махсус курсларга йөрдеңме?

– Әйе, беренче ярты елны бары тик тел өйрәнүгә багышладым.

– Алайса, илле доллар бир, – диде таможня хезмәткәре, тел белгәне өчен ташлама ясагандай.

– Яхшы, тик шуны әйтегез, ни өчен мин сезгә акча бирергә тиеш? Минем документларым барысы да тәртиптә бит.

Хезмәткәр үзенә бирелгән сорауны ишетмәгән кыяфәт чыгарды. Үзе аннан:
– Эш өчен рөхсәтең бармы? – дип сорады.
– Бар.
– Лицензия үзең беләнме?
– Менә, рәхим итегез.
Барлык кәгазьләрне дә паспорт янына куйганнан соң, хезмәткәр мөһерен эзли башлады һәм башын күтәрмичә генә:
– Яхшы, егерме биш доллар бир, – диде.
Кадыйр ни көләргә, ни еларга белмичә:
– Сезгә ул акчаны ни өчен бирергә тиеш икәнен әйтегез дә, мин аны бирәм, – диде.
Хезмәткәр мөһерен тапты һәм барлык тиешле урыннарга сугып чыкты да виза кәгазен паспорт эченә тыгып, Кадыйрга сузды:
– Киттек, чәй эчәбез.
Кадыйр каршы килә алмады, хезмәткәр ишарә белән аны коридорның теге башындагы бүлмәгә дәште. Бүлмәдә алар Кадыйрның чит телне яхшы белүе, аның фирмадагы эше турында сөйләштеләр. Ул арада чәй кайнап чыкты. Хезмәткәр бер йотым гына ясады да:
– Ярар, ун доллар бир, – диде.
Кадыйр бу сүздән соң каушап калды. Ул инде тикшерүне үтте, бөтен документлары да аның үзендә. Ни өчен соң әле офицер аннан ун доллар акча сорый?
– Яхшы, мин бирәм, тик сез шулай да әйтегез, ни өчен?
Офицер Кадыйрга карап, тирән сулыш алып күрсенде дә:
– Эх, Кадыйр әфәнде, әгәр дә син бирмәсәң, әгәр дә башкалар бирмәсә, бу эшкә урнашыр өчен биргән акчаларымны ничек кайтарып алырмын соң мин?! – дип куйды.
Мондый җавaптан аптырап катып калган Кадыйр, ишеккә караш ташлап алды да, куеныннан акча янчыгын чыгарып, ун доллар санап, аның кулына сузды. Өстәлдә аның эчеп бетермәгән чәе торып калды. Таможня хезмәткәре аны ишеккә кадәр озатып, күптәнге дусты белән аерылышкан кебек хушлашып калды.
Кадыйр чикнең теге ягында аны көтеп торучы таксига барып утырды һәм юлын дәвам иттерде. Аның башында: «Әгәр дә юлда пропуск пунктында туктатып, ун доллар сорасалар, ул акчаны кем бирергә тиеш, минме, әллә таксистмы?» дигән уй тынгы бирмәде.

*Төрекчәдән* **Зарина МОСКАУ** *һәм* **Рафис КОРБАН** *тәрҗемәсе.*

# СОҢЛАГАН ПИКНИК

ХИКӘЯ

Берничә көн элек, ниһаять, яз житте. Март җепшеклеге генә түгел, ә чын яз, биек күге, назлы кояшы һәм кышкы йокыдан уянган агачларның хәтфә яфраклары белән. Мал табибы булып эшләүче Фатыйх өендәгеләргә, һава торышы яхшыргач та, табигать кочагына алып чыгарга вәгъдә бирде.

Озын кыштан соң күңел яшеллеккә һәм кошлар җырына сусаган иде. Әтиләреннән киләсе елларда табигатькә чыгасылары турында ишеткәч, барысы да зур дәрт белән әзерләнергә керештеләр. Кичтән үк кирәкле әйберләрне җыйнаштырып куйдылар. Өйдә үзгә бер җанлылык хөкем сөрде. Бигрәк тә балалар шатланды. Ничек көттеләр, ничек әзерләнделәр алар бу көнгә! Әти-әниләрен гаҗәпләндереп, мәктәптән кайтуга, гадәти булмаган бер тырышлык белән дәресләрен хәзерләргә утырдылар. Өй эшләрен, хәтта ял көненә бирелгәннәрен дә, кисәткәнне дә көтеп тормыйча башкарып куйдылар! Ял көненә билгеләнгән планнарына берни дә комачауларга тиеш түгел иде. Ә планнар бар, планнар күп! Ул планнарны кору үзе бер рәхәтлек иде! Кыш буе табигатькә чыкмыйча яшәү бик ялыктырган һәм булачак сәфәр турында уйлау алдан ук аларга зур ләззәт бирә иде: уйнаячаклар, рәхәтләнеп йөгерәчәкләр, туп тибәчәкләр бит! Атна буе үзләрен тәртипле тотарга, әти-әниләрен борчымаска һәм гадәттәге вак-төяк шуклыклар белән кәефләрен кырмаска тырыштылар. Бер сүз белән әйткәндә, бар да әйбәт барды. Көткән ял көннәре якынлашты. Табигатькә чыгу мәшәкатьләре балаларны гына түгел, әти-әниләрен дә җанландырып җибәрде. Ниһаять, зарыгып көткән шимбә иртәсе туды. Бөтен гаилә бердәм булып, иртәнге аш табынына җыйналды. Бар да әзер, биштәрләр тутырылган, әллә ничә кат тикшерелгән. Иртәнге чәйне генә эчәсе дә – юлга кузгалырга!.. Кинәт беркем дә көтмәгән телефон шалтыравы өйне яңгыратты. Барысы да ниндидер бер борчылу белән бер-берсенә караштылар. Барысы да елларга корылган планнарының җимереләсен уйлап куйдылар. Кирәк бит, шундый вакытта шалтырап торуын күр әле син ул телефонның! Фатыйх борчылган чырай белән өстәл артыннан күтәрелде һәм балаларның кырылган кәефен күрмәмешкә салышып, телефон трубкасын алды.

– Алло, тыңлыйм... Әйе, мин мал табибы... Сөйләгез.

Ул, гадәттәгечә, игътибар белән шалтыратучыны тыңлады, аннары аңа берничә сорау бирде. Балалар тын да алмыйча әтиләренең йөзен күзәттеләр. Шулкадәрле зарыгып көтеп алган пикникны кичектерергә туры килер микәнни? Бу сорауга бары тик әтиләре генә җавап бирә ала иде. Димәк, сөйләшү ни белән бетәсен көтәргә туры киләчәк. Башка чара юк. Озак көтәргә туры килмәде. Әтиләренең телефон шалтыратучыга соңгы сүзләре шундый булды:

– Яхшы, мин сезне аңладым. Хәзергә берни дә эшләмәгез, мин бераздан килеп җитәрмен.

Менә шул. Шулай гына була күрмәсен дип куркып торган нәрсә килеп чыкты. Әтиләре эше белән китеп барачак. Атна буе әзерләнеп көтеп алган табигатькә чыгу булмаячак. Барысы да тынып калды. Балалар төмсә чырай белән әтиләренә карадылар. Аларның йөзендә иртәнге шатлыкның эзе дә калмаган иде. Гаҗәп бит, бер-ике минут эчендә ничек шулай кырылырга мөмкин кешенең кәефе! Әниләренең дә йөзеннән шатлык качкан иде, ләкин ул өйдәгеләргә берни дә сиздермәскә тырышты. Аның карашы сүзсез сорау белән гаилә башлыгына төбәлде.

– Суджулар авылы башлыгы шалтырата, – диде Фатыйх, гаилә әгъзаларына мөрәҗәгать итеп. – Авылда бер гаиләдә көтелмәгән хәл килеп чыккан: сыерлары бозаулый алмый икән. Төне буе азапланган, ди, мескен хайван. Иң мөһиме – ул сыерны сатып алу өчен хуҗасы кредит алган булган, әле ярты хакын да түләргә өлгермәгән. Мескен сыер үлеп китсә... Тизрәк барып, сыерга ярдәм итәргә кирәк. Авыл башлыгы бик үтенеп, тизрәк килеп җитүемне

сорады... Без бит бүген табигатькә чыгарга тиеш... Мин сүз бирдем... – дип, Фатыйх алга таба ни әйтергә дә белмичә тынып калды.

Балалар башларын аска иеп, сүзсез калдылар.

– Ярар, зыян юктыр дип уйлыйм. Суджулар авылы ерак түгел, ун минутлык юл. Мин тиз әйләнеп кайтырга тырышырмын. Бераз соңлап булса да чыгарбыз, ярыймы? Йә, нәрсә дисез?

– Әй, әти! – диде кәефе кырылган кече улы. Ләкин ул кинәт бозау туа алмыйча үлеп китәргә мөмкин бит дип уйлады. Әтисенә әйтергә теләгән сүзен әйтмичә: – Бар, әти. Коткар бозауны, – дип куйды. Аннары: – Тизрәк кайтырга тырыш, – дип тә өстәде.

Фатыйхка улының бу сүзләреннән соң җиңел булып китте, ул аңа сөеп карады һәм битеннән үбеп алды. Аннары кызының да башыннан сыйпап куйды һәм «килештек, шулай итәрмен дә» дип, ашыгып, өйдән чыгып китте. Әле шактый еллар ипотека бурычын түлисе булган йорт каршында аның «Рено» маркалы автомашинасы тора иде. Ул аны кабызды да, мотор кызган арада багажнигын ачып, эш өчен кирәкле әйберләрен тикшерде – брезент алъяпкыч, итек, инструментлар, дару шешәләре – барысы да урынында иде. Кыршылган күн сумкада анестезия өчен кирәкле препаратлары саклана. Ул машинага утырып, рульгә тотынды да, борылып, тагын бер кат тәрәзәгә карады. Анда улы белән кызының башлары күренә иде. Ул, барысы да әйбәт булыр, дигәнне белдереп, аларга кулын изәде.

Юл кыштан соң шактый таушалган, аны кар сулары лыкырдаткан, чылбырлы тракторлар тирән чокырлар ясап бетергән. Балаларга ун минутлык юл дип ышандырса да, кырык-кырык биш минутка ук сузылырга да бик мөмкин. Их, менә хәзер дүрт көпчәге дә тарта торган «Джип» булса иде ул, дип уйлады Фатыйх һәм, күңелсезләнеп, үз хыялларыннан көлеп куйды. Шундый «Джип»ны күрер көннәр булырмы? Әле монысы өчен дә түләп бетермәгән. Аннары: «Яхшы «Джип» та алырбыз, Алла боерса!» дип, үзен тынычландырды.

Юл бер сәгатькә якын вакытны алды һәм шактый гына ялыктырды. Суджулар авылына барып җиткәндә, ул үзен нык арган итеп хис итте. Авыл башында аны башлык көтеп тора иде. Аның янында урта яшьләрдәге ир белән хатын күренә. Ире бер аягыннан икенчесенә авышып, юлдан килүче машинаны күзәтә. Сыер хуҗаларыдыр, дип уйлап куйды Фатыйх. Килеп җиткәч, ул бу ирне таныды, хәтта исемен дә искә төшерде. Хәсән – кырык яшьләр чамасындагы кеше. Әмма бөкрәйгән җилкәсенә, җилдә каралган йөзенә һәм җыерчыкларына карап, аңа алтмышны да бирергә буладыр. Янындагы хатын-кыз аның җәмәгате икән. Фатма, сөйкемле, ачык һәм ягымлы чырайлы бу хатын иреннән күпкә яшьрәк күренә иде. Ләкин хәзер аның кыяфәте нык алҗыган һәм карашы сүрән иде. Фатыйх алар белән кайда һәм кайчан танышканын хәтерләде. Узган язда Хәсән белән Фатма кызларын кияүгә бирделәр, ә җәен кече улларын шәһәргә укырга озаттылар. Танышу шул уллары белән бәйле иде. Ул елны Суджулар авылында мәктәп тәмамлаучылар арасында бары тик аларның уллары гына имтиханны югары уку йортына керергә мөмкинлек бирә торган баллга тапшыра алды. Нәкъ менә шул вакытларда Фатыйх нindидер эшләре белән бу авылга барып чыккан иде. Шунда ул Хәсәнне беренче тапкыр күрде, Фатыйхны бик зур игътибар белән күзәтүеннән, ул аның үзенә нindидер йомышы бар бугай дип уйлады.

– Сезнең миңа соравыгыз бар, ахры? – дип сорады ул аннан.

Читенсенеп һәм сүзне нидән башларга белмичә генә, ул аның янына килеп

танышканнан соң, сүзләрен бик авырлык белән сайлап кына, үзенең улы, аның мәктәптәге уңышлары, чыгарылыш имтиханнарын югары билгеләргә генә тапшыруы хакында сөйләде.

– Сезнең белән киңәшләшәсем бар иде... Бер мәсьәлә буенча... Күреп торасыз, без гади кешеләр, көчкә очын очка ялгап яшибез... Ә малайның укыйсы килә... Менә уйлыйм: булдырырбыз микән? Булыша алырбыз микән? Аны укытыр өчен кайдан акча табарбыз?..

Фатыйх шуны аңлады: бу кешенең үзе югары уку йортында белем алган берәрсеннән хуплау сүзе ишетәсе килә икән. Димәк, менә кемгә ярдәм итәргә ашыгып килгән икән ул, менә кемнең сыерына ярдәм кирәк икән. Өлгерергә иде бит. Хәсәннең йорты авыл башында ук булып чыкты. Фатыйх машинасыннан чыкты, каршылаучыларны һәм аларга ничек тә ярдәм итәргә килгән авылдашларын сәламләде. Сүзне озайтып тормыйча, ул шунда ук машинадан алып килгән әйберләрен чыгара башлады. Хәсән белән хатыны һәм авыл башлыгы аңа ничек ярдәм итәргә белмичә, тизрәк кулындагы әйберләрен, комбинезонын, итеген алырга ашыктылар. Фатыйх тагын бер тапкыр күн сумкасындагы әйберләрен барлады. Шунда ук уллары турында сорашты, аннан нинди хәбәрләр килүен белеште. Табибның аларның улларын хәтерләве һәм аның турында сорашуы Хәсәннең күңелен йомшартып җибәрде, ләкин ул бу минутта мескен сыер һәм аның туа алмый азапланган бозавы турында уйлый иде. Шуңа күрә Фатыйхның соравын җавапсыз калдырды. Аңлашыла, әлбәттә, сыер бит – аларны туендыручы. Сыер булмаса, улларын ничек укытырлар? Шул уйлар Хәсәннең бөтен тынгылыгын алып, башында утыра, үткен пычак кебек аның йөрәген сызлата иде. Йокысыз үткән төн, сөйләшә белми торган сыерның газаплanulары, иң мөһиме, аларның мескен хайванга берничек тә ярдәм итә алмаулары Хәсәнне тәмам йончытты. Хәзер аларның хатыны белән телләрендә бер генә сүз: «Алла хакы өчен, Фатыйх мирза, ярдәм итегез безгә!» – дип әйтергә генә хәлләреннән килә иде. Алар ялварып, Фатыйхка карадылар. Хәсән кинәт түзеп тора алмыйча сулкылдап куйды.

– Ул кадәр борчылма әле син, – дип куйды Фатыйх, үзе дә сизмәстән «сез»дән «сиңа» күчеп. – Хәзер барысын да коткарырбыз! Анасын да, бозавын да! – диде ул, Хәсәннең иңнәреннән кагып. Шунда ул ишегалдына җыелучыларның нинди зур өмет белән үзенә карап торуларын күрде. Тәбәнәк кенә кирпеч койма белән әйләндереп алынган бу ишегалдындагыларның олысыннан кечесенә хәтле барысы да аның ярдәм итә аласына ышанып, бар да әйбәт булып бетәсен көтәләр иде. Алар арасында Фатыйх сунарчы Фикрәт танышын да күреп алды. Ул бу авылдагы йорт хайваннарын дәвалавы белән танылган иде. Гадәттә, авыл халкы мондый очракларда аңа мөрәҗәгать итте.

– Нәрсә булды, Фикрәт ага, бу юлы сез дә ярдәм итә алмадыгызмыни? – диде ул сунарчы дустына.

Ул аның шулай сораячагын көткән, күрәсең, шунда ук җавап бирергә ашыкты:

– Тракторга бәйләп тартып алырга мәллә дип уйлаган идем, якын җибәрмәделәр бит, – диде ул.

«Уңышсыз шаяртуыдыр, ахры, бу», дип уйлады табиб.

– Моның бернинди дә файдасы булмас иде шул, – диде дә Фатыйх кызу адымнар белән абзарга юнәлде. Абзар дигәнең асылда кысан, бер якка авышкан сарай иде. Беренче карашка ук аның диңгез аръягыннан кайтарылган сыерларны асрау өчен бик уңайлы каралты булмавы күренеп тора. Эш шунда,

соңгы елларда хакимияттә авыл хуҗалыгы белән кызыксыну көчәйде. Халыкка кредитка «Гелштейн» токымлы сөт сыерлары сатып алырга тәкъдим ителде. Бу хакта ишетеп алган Хәсән шунда ук мөмкинлекне ычкындырмаска ашыкты. Ни дисәң дә, яхшы токымлы сөт сыеры, шуның өстенә кредитка бирелә! Шундый сыер асрап, бәлки әле хуҗалык эшләрен көйләп җибәреп тә булыр. Шулай итеп, аның сараенда «Гелштейн» токымлы затлы сыер барлыкка килде.

– Ничек дип дәшәргә бу чибәркәйгә? – дип сорады Фатыйх, елмаеп Хәсәннең хатыныннан. Абзар ишегеннән керергә кыенсынып торган хуҗабикә, сорауны ишеткәч тураеп басты да ирен читләренә елмаю чыгарып:

– Балалар аны Алакыз дип атыйлар, – диде.

Яны белән сайгакта ятучы сыер үз кушаматын ишеткәч, муенын борып, хатынга карады. Аның зур матур күзләре озын керфекләре аша тирән моңсулык белән багалар иде. Фатыйх шунда аның уң күзеннән яңагы буйлап эре яшь бөртеге тәгәрәп төшкәнен күрде. Фатыйх озак азап чиккән затның хәленә кереп, абзардагы кешеләрдән чыгып китүләрен сорады. Аннары ул тиз генә комбинезонын һәм итекләрен киеп алды да, «Кысанрак икән шул монда, – дип куйды. – Борылырга да урын юк. Эшләве җиңел булмас».

Ул кулына, перчатка киеп, сыерның эченә кертте, бозауның исәнме, юкмы икәнлеген белергә кирәк иде. Сыер бөтен тәне белән хәлсез генә калтыранып куйды. Аңлашылды – бозау дөрес ятмый, Фатих аның калак сөяген генә тота алды. Димәк, аны башы белән алга, чыгу юлына борырга кирәк. Асылда, тәҗрибәле ветеринар өчен ул кадәр үк катлаулы эш түгел. Сыерның ни халәттә булуыннан гына тора. Тулгак тотудан аның бөтен гәүдәсе калтырана, тирләүдән йоны юешләнеп, табигый йомшаклыгын югалткан. «Шәп түгел хәлләр», дип уйлады табиб.

– Хәсән ага, маңгаемдагы тирне сөртеп ал әле, – диде ул һәм Хәсәннең куркудан агарынган йөзен күрде. Шунда абзарга сунарчы Фикрәт килеп керде дә бая әйткән мәгънәсез тәкъдимен кабатлады:

– Ветеринар ага, нәрсә болай азапланасың, әйдә трактор белән бәйлибез дә акрын гына тартып чыгарабыз.

«Шаяртмый икән бу лабаса», дип аптырады Фатыйх. «Кирәк бит шундый вакытта!» Хәсән хатынының кулыннан сөлгене алды да Фатыйхның тирләгән маңгаеп, битен сөртеп төшерде. Аннары Фикрәт ягына карап:

– Чыгып кит әле моннан! Чыгарып җибәрегез әле шуны! – дип кычкырды.

Фикрәткә булган ачу Фатыйх белән Хәсәнгә көч керткән кебек булды. Фатыйх эшкә кереште. Сыерның еш тулгак тотуы эшләргә комачаулый иде. Аның куллары оеды, аркасы авырта башлады, иңбашлары сызларга тотынды. Күзләре яшь белән капланды. Бозауның башын артка бору кыенлашты. Бу минутларда Фатих ни өчендер Хәсәннең улы турында уйлады. Аның «Улым укырга тели» дигән сүзләре колагында яңгырагандай булды. Фатыйх башын селеккәләде һәм тагын бер тапкыр бозауны борырга талпынып карады. Инде көчләр тәмам бетте дигәндә, сыер еш калтыраудан манма тиргә батып чыкканнан соң, аның эчендә нидер селкенеп куйгандай итте. Ветеринар бозауның башы белән борылганын, якты дөньяга чыгарга әзер булуын сизде. Аның йөрәге җилкенеп куйды, иңнәрен басып торган авыр йөк төшкәндәй булды.

– Тагын бер көчәнеп кара да, икегез дә котыласыз – син дә, бозавың да! Яле, матурым! – дип, ул сыерны иркәләп, сыртыннан сыпырды. – Әйдә, Алакыз, әйдә акыллым!

Боларны күреп торган Хәсәннең тез буыннары калтырана иде. Үзенә урын таба алмыйча, ул кулындагы сөлгене әле урап тота, әле бушатып, өзеп ташларга теләгәндәй йолыккалый иде. Сарай ишеге янында торган хатынының Аллаһыга ялварып, дога укуыннан иреннәре туктаусыз дерелдәде. Алар икесе дә нык киеренкелектән суларга да куркып торалар кебек күренде. Хәсән хайванның газаплануын күрмәс өчен күзләрен чытырдатып йомды. Ул Фатыйхның:

– Йә инде, акыллым, тагын бер, менә шулай, менә шулай... Матурым!

Аның «матурым» дип әйтүе бозауның дөньяга килүе белән бер мизгелгә туры килде. Моны күреп, Хәсән тизләнеп, бозауны кочагына алды. Шунда Алакыз авырлык белән дүрт аягына торып басты. Фатыйх сыер белән абзар стенасы арасында кысылып калды. Абзардагылар моны күреп, куркуга төштеләр. Шулчак мал табибының канәгать тавышы яңгырады:

– Менә ул, менә синең бәләкәчең! Йә инде, тизрәк яла үзен!

Алакыз шул мизгелдә Фатыйхка таба борылды һәм аның күзләренә карады. Аннары зур, юеш теле белән аның йөзен, кулларын ярларга тотынды. Назланудан табибның тамагы кибеп китте. Ул хайваннан шундый назлау көтмәгән иде. Аның күзләренә кайнар яшь тулды. Түзеп тора алмыйча, ул елап җибәрде.

– Мине түгел, бозавыңны яла. Менә синең бозавың, Алакыз... Рәхмәт сиңа! Рәхмәт!

Күзләренә яшь тулудан берни дә күрмәгән Фатыйх артына борылып карады. Бу минутта елаучы ул гына түгел икән! Сыерның үзен коткаручыга шундый рәхмәте барысын да дулкынландырган: Хәсән дә балалар кебек сулкылдый, хатыны да диварга борылып, яулык чите белән күзен сөртә. Алакызның зур күзләре дә яшь белән мөлдерәмә иде.

Фатыйх шунда үзен өйдә балалары көтеп утыруын исенә төшерде, кабаланып китәргә җыена башлады. Хәсәннең хатыны күршеләрдән алган катыктан ясаган әйрән әзерләгән икән. Сусаган Фатыйх аны рәттән ике касә эчеп җибәрде, хуҗабикәгә зур рәхмәтләр әйтте. Авыл башлыгы белән Хәсән аны калырга, дастарханда утырырга кыстадылар.

Фатыйх: «Башка вакытта», – дип, ягымлы гына баш тартты.

Өйгә кайтып җиткәндә, аны балалары киткәндәге кебек үк тәрәзәдән дүрт күз белән көтеп утыралар иде. Әтиләренең машинасын күрүгә алар урамга йөгереп чыктылар да, шатлыкларыннан сикерә-сикерә, аның каршына йөгерделәр. Фатыйх колачларын киң җәеп, аларны кочаклап алды һәм күкрәгенә кысты. Балалар да әтиләренең муеннарына асылындылар, ләкин шунда ук борыннарын җыерып, кулларын ычкындырдылар.

– Фу, әти! Синнән сыер исе килә!

Әтиләрен шулай кочып, бу кадерле балакайлар каян белсеннәр ди инде моның, аны әле күптән түгел генә, алар шикелле үк, сөеп ялаган бәхетле хайванның исе икәнен! Фатыйх кадерлеләрен җайлап кына, җиргә бастырды. Учы белән аларны башларыннан сыйпап:

– Йә ничек, сез әзерме? Мин хәзер юынып кына алам да телефон тагын шалтыралаганчы кузгалабыз, – диде.

*Төрекчәдән* **Карлыгач МУКАШЕВА** *һәм* **Рафис КОРБАН** *тәрҗемәсе.*

# АНЫ МӘСКӘҮ ТАНЫГАН

## ЮНЫС САФИУЛЛИНГА – 75 ЯШЬ

Кешене яхшылап белү өчен аның белән бер пот тоз ашарга кирәк, диләр. Ягъни, бергә-бергә, утлар-сулар кичеп, катлаулы хәлләр аша үтәргә кирәк дип әйтүләре. Шулай булганда гына, аның турында төпле фикер булдырырга, тулы канлы әйбер язарга мөмкин. Менә мин дә заманыбызның зыялы, талантлы, зәвыклы улы Юныс Габдулла улы Сафиуллин турында хәл кадәренчә җыеп, бер сүз әйтергә телим. Тик шунысы бар: миңа бер пот түгел, аның белән тозны бер уч та ашарга туры килгәне юк. Шуңа күрә, ниятемдә булса да, шушы эшнең гамәленә керешүне һаман чигерә киләм. Һәр кеше – үзе бер дөнья. Иҗади шәхесләр турында сүз барганда, икеләтә җиһан. Чөнки алар әсәрләрендә үзләре икенче дөнья тудырырга сәләтле. Каләм көче белән сурәтләгәннәренә башкаларны да инандыру көченә ия. Шуның өчен булса кирәк, алар гадәттә, мин тулысы белән әсәрләремдә, диючән. Димәк, бер юл кала: миңа аның иҗатын тулаем ныклап өйрәнергә кирәк. Аның әсәрләрен берәм-берәм укып барам, сәхнәдә күргәннәрен күз алдымнан үткәрәм. Кинәт уем яктырып китә: аңа быел 18 октябрьдә җитмеш биш яшь тула икән бит. Төз буйлы, җиңел сөякле, мөлаем, җимешле эше булган каләмдәшебезгә бу уңай белән аңа лаеклы уйларымны әйтмичә һич ярамас. Шуңа күрә күңелемдә булганнарны җыеп әйтүне кичектерү һич тә мәгъкуль булмас. Бу яшькә исән-имин, иҗади хәлдә килеп җитү үзе бер күркәмлек.

Сугыш алды һәм сугыш елларында туганнар турында сүз барганда, без аларның гомер юлы башындагы авырлыклар кичерүләрен күрсәтергә күнеккән. Юныс исә, бөек җиңүебездән соң, ике ел үткәч кенә дөньяга аваз салган. Шулай да халыкның очын-очка ялгый алмыйча яшәгән вакытларын да күреп үскән. Сугышка кадәр үк армиядә командир булган әтисе Бакырчыда да югалып калмаган. Һәрхәлдә Юныс бездәй сугыш ятимнәре кебек әтисезлектән газап чикмәгән. Акъегет мәктәбендә укыган чагында ук шигырьләр яза башлавы, Марсель абыйсы кебек укытучыларының аның бу шөгыленә ихтирам белән караулары, аны концерт-спектакльләргә җәлеп итүләре үсмер өчен зур рухи ярдәм була.

Аның күңелендә ике теләк көрәшә: алга таба нинди юлдан китәргә – актёр булыргамы, әллә шагыйрьме? Сораша торгач, шуны белә: шагыйрь итеп тәрбияли торган уку йорты юк икән, артистлыкка әзерләүчесе бар. Юныс театр училищесына керү өчен Казанга килә. Сәләтле, яшенә караганда, җитди табигатьле әлеге үсмернең ниятен биредә дә хуплыйлар. Сәнгать осталары белән беррәттән аны биредә Миләүшә Маннурова һәм Вахит Хаков кебек тел-әдәбият галимнәре дә укыта. Ниһаять, аңлый: артист бер үк вакытта каләм әһеле дә була ала икән бит! Юныс та үҗәтлек белән шигырь язуын дәвам иттерә. Х.Туфан, Н.Арсланов кебек аксакаллар, инде ул вакытта әдәбиятта ныклы адымнар ясый башлаган Диләрә Зөбәерова да аның талантын күрәләр, җылы гына сүзләр әйтәләр. Ул тора-бара шигъри юморескалар да язгалый. Шагыйрь Зөлфәт нәкъ менә аның шушы юнәлештәге әйберләренә өстенлек бирә. Ничектер шулай килеп чыга, бик теләсә дә, ул аларны үзе эшләгән «Чаян» журналында урнаштыра алмый. «Ялкын» да битләреннән урын бирергә ашыкмый. Шигырь белән эш барып чыкмагач, ул иҗатын пьесалар язу юнәлешендә дәвам иттерергә карар кыла. «Ур, тура, сатирик!» дигән комедиясе бу өлкәдә беренче адымнарыннан. Ул елларда Язучылар берлегендә яшь язучылар белән эшләүче Рөстәм Мингалим бу әсәрне яратып кала, очрашкан саен: «Теге,

сәхнәдә алма бураны кузгаткан комедия кайчан дөнья күрә инде?» – дип әйтә торган була. Юк-бар әйбер хәтер төпкеленә шулай эләгеп калмый ул. Шуның белән канатланган Юныс бер-бер артлы «Дом на слом, ягъни нигез туздыручылар», «Бер үк күзләр елый да, көлә дә» дип аталган әсәрләр иҗат итә. Күрәсең, алар әле тәҗрибә туплау баскычлары гына булгандыр. Шул ук җитмешенче елларда сәнгать кешеләре арасында композитор Әгъзам Фәттах турында да, мәсәлән, мондыйрак такмак таралган иде:

*Ниһаять, билгеле булды*
*Көй язучы Әгъзам да.*
*Мәскәүдә танылу алгач,*
*Күрде үзен Казан да.*

Юныс белән дә шуңа охшаш бер вакыйга була. Сиксәненче еллар башында шагыйребез Гәрәй Рәхим РСФСР Язучылар союзында эшләде. Анда үз кешебез булгач, татар язучылары һәм шагыйрьләренә дә кайбер мәсьәләләрне хәл итүе җиңелгә килә иде. 1982 елда ул татар драматургларының яңа әсәрләре буенча Мәскәүдә фикер алышуны оештыра. Безнең авторлар әсәрләрен тәрҗемә итеп, алдан ук Г.Рәхимгә җибәрәләр, ә ул аларны укып фикер әйтү өчен башкаладагы театр тәнкыйтьчеләренә, белгечләргә тапшыра. Ю.Сафиуллинның «Әллә өйләнергә инде?» әсәре күренекле тәнкыйтьче В.Фролов кулына килеп керә. Моны белгәч, Мәскәү драматурглары да куркып тора торган әлеге белгечнең бәясен Юныс шактый дулкынланып көтә. Ләкин бер нәрсә аны тынычландыра: нәрсә генә әйтсә дә, ни генә дисә дә, бу кеше әсәрне укып, белеп әйтәчәк. Казанда кайчакта фикерне әсәр буенча алып барудан бигрәк, синең башка якларыңны истә тотып тудыралар. Шулай була да, В.Фролов әсәргә бик гадел бәя бирә. Алынган теманың, образның яңалыгына, коллизия тудыру маһирлыгына игътибар юнәлдерә. Бары тик шунда гына яшь авторның үзе белән дә таныша, колагына гына кайбер өстәмә сүзләрен дә җиткерә. Болар, әлбәттә, Юныснын күңелен күтәреп, канатландырып җибәрә. Казаннан бергә килгән коллегалары алдында да күңелле була.

Ләкин мондый каршылыклар аны иҗат кешесе буларак үҗәтләндерә генә. Әнә Мәскәү тәнкыйтьчесе аның язганнарында уңай башлангычларны да күреп алган бит. Димәк, аңарда, сәнгати яктан бәяләгәндә, нидер бар. Ул бер хакыйкатьне яхшы аңлый: иҗат кешесе, ни генә язмасын, сәнгатьнең кайсы төрендә генә пәйда булмасын, ул замандашларына нинди дә булса яңа фикерне, яңа карашны җиткерүче, тормыш хәл-әхвәлләрен образлы итеп күрүче, яшәешнең моңа кадәр күзгә ташланмаган якларын ачып күрсәтүче. Ул моны үз шәхесенең тирән күңел төпкелләрендә бөреләнгән хис-тойгыларын, уй-фикерләрен җиткереп, билгеле бер рәвешкә кертеп тормышка ашыра, шуның белән башкаларны да үзенең мәсләктәше итә торган тылсым көченә ия була. Күзгә артык ташланмыйча, эзлекле рәвештә иҗат колачыңны киңәйтүне дәвам иттерү – иң мөһиме.

Күңелне төшермичә, эзлекле рәвештә иҗат белән яшәү, үзенең мөмкинлекләренә ышану нәтиҗә бирми калмый. Юныс Габдулла улына да бәхет елмая башлый. Ниһаять, үзе эшли торган Күчмә театр әлеге дә баягы «Әллә өйләнергә инде?» комедиясен сәхнәләштерә. Исеме «күчмә» булса да, читтәрәк яшәгән халыкны театр тамашалары белән эстетик тәрбияләүгә гаять зур өлеш кертеп яшәүче труппаның әлеге спектакле киң яңгыраш ала. Мәсәлән, Мәскәүдә чыга торган «Театральная жизнь» журналы (1978, № 7) бәяләвенчә, әсәр «персонажларның характерларын тирән белеп, күзәтү осталыгы һәм сәхнә кануннарын яхшы белеп» язылган.

Бу вакытта инде Юныс Сафиуллин театр училищесын гына түгел, Мәскәүнең үзендә Сәнгать институты каршында ике еллык режиссёрлык курсларын да тәмамлап кайткан, шулар өстенә алты-җиде еллык актёр булып эшләү тәҗрибәсе дә бар. Димәк, болар аңа әсәрне язганда, сәхнәдә гәүдәләндерү хасиятләрен дә профессионалларча күз алдына китерү мөмкинлеген бирә. Бу инде аның тагын бер өстенлеге булып тора.

Театр сәнгате белгече Д.Гыймранованың «Спектакль тамашачылар тарафыннан яратып кабул ителә» дип язуы әсәр авторы күңеленә канәгатьлек бирә («Советская Татария». – 1979. – 1 апрель). Бөялеп торган су ерыла, әлеге авторга башка театрлар да игътибар итә башлый. Әлмәт театры «Менә без дә үсеп җиттек...» әсәрен сәхнәгә чыгара. Бу инде авторның үзенә дә ишарә булып кабул ителә. Ягъни менә мин иҗат иткән әсәрләр дә сәхнәгә күтәрелә башлады! Иң мөһиме – жанры буенча моңсу комедия дип билгеләнгән әлеге әсәрне дә тамашачы җылы кабул итә. Беренче пьесалар җыентыгының шушы әсәр исеме белән аталуы да, мөгаен, авторның әлеге әсәрен иҗатындагы бер мөһим баскыч итеп каравыннан килгәндер.

1981 елда Ю.Сафиуллинның тормышы һәм эшчәнлеге Г.Камал исемендәге төп театрыбыз белән бәйләнә. Шуннан соң кырык елдан артык инде ул шушы татар театр сәнгате мәркәзендәге иҗат мохитендә яши. Бирегә актёр итеп алынуы ук аның осталык мөмкинлекләренә бирелгән бәя дип уйларга кирәк. Артистның гомуми зур сәләте һәм шуның өстенә тагын нинди дә булса аңа гына хас ягы булмаса, биредәге берсеннән-берсе олы талантлар арасында тиешле урыныңны табармын, димә. Шундый сыйфатларның шактый сирәк очрый торганы – каләмле булу. Андый кешене тагын да нәтиҗәлерәк итеп файдаланырга кирәклеге дә аңлашылып тора. Шулай итәләр дә – Ю.Сафиуллинга әдәби бүлек мөдире вазифасын тапшыралар. Театрның уңышы иң әүвәл сәхнәләштерү өчен әсәрләр табудан башлана. Димәк, әлеге вазифа биредә барыннан да мөһимрәк. Дөрес, бу очракта да төп сүзне баш режиссёр әйтә. Ул, моны хәл иткәндә, шәхси иҗат амплуасын да исәпкә ала. Әмма аның өстәлендә сайлап алырлык кульязмалар булып торырга тиеш. Моны инде Ю.Сафиуллин кебек әдәби бүлек мөдирләре тәэмин итәргә бурычлы. Иҗат омтылышы белән янган шәхеснең үрнәге башка авторларга да йогынты ясамый калмый.

Ниһаять, 1981 елда талантлы һәм кыю режиссёр Дамир Сираҗиев әдәби бүлек мөдиренең үз әсәрен – «Алмазбулат»ны – академия театры сәхнәсенә күтәрә. Әниле-уллы Наилә Гәрәева белән Фәрит Бикчәнтәевнең төп рольләрне бергәләп башкарулары да матур яңалык булып кабул ителгәнлеге бүген дә хәтеремдә. Икенче куелышта исә әсәр Ф.Бикчәнтәев режиссёрлыгында туды. Тамашачы ничә еллар буена бу әсәрдән аерылырга теләмәде, күпләр аны кабат-кабат карады. Мондый бәхет классик булып кабул ителердәй әсәрләргә генә туры килә. Шулай итеп, әсәрнең сәхнә тормышы Ю.Сафиуллинны драматург буларак танытуда бер олы адым булды. Театрның аңа бер-бер артлы мөрәҗәгать итүе, һәр куелышта озын гомерле булуы автор талантының күрсәткече иде.

Аның иҗатындагы шундый мөһим әсәрләрнең иң күренеклесе – әлбәттә, «Идегәй» трагедиясе. Аның тарихыбыздагы бу затны гәүдәләндерергә алынуы үзе бер иҗади кыюлык. Бу эшкә этәргеч бирүче итеп шул ук М. Сәлимҗановны санарга кирәк. Нәкъ аның тәкъдиме буенча «Идегәй» эпосына нигезләнеп, сәхнә әсәре язуга конкурс игълан ителә. Һәр эшкә үтә җаваплы, таләпчән килүне гадәт иткән Юныс Габдулла улы әлеге халык авыз иҗаты әсәре һәм бик күп тарихи мәгълүматлар белән җентекләп таныша. Шул ук вакытта Н.Исәнбәтнең шушы эпоска нигезләнеп утызынчы елларда иҗат иткән әсәренә күз төшерергә ашыкмый. Чөнки ул аңа күпмедер тәэсир итәр дип уйлый. Ә бу очракта аның язганы бары тик үзенеке, кабатланмаган булырга тиеш.

Хәтерлим, Казан дәүләт университетында дәүләт имтихан комиссиясе рәисе булып эшләгәндә, бер елны Ю.Сафиуллинның шушы әсәренә нигезләнеп язылган диплом эше якланган иде. Шушы чарага драматург үзе дә килде. Мин шунда кызыксынган идем:

– Ни өчен театр Нәкый ага Исәнбәт әсәрен генә сәхнәләштермәде?

Юныс Габдулла улы Марсель Хәким улы белән бергәләп бу хакта нык уйланганнар икән. Моның сәбәпләре турында шактый дәлилле сөйләп бирде.

– Н.Исәнбәт, – диде ул, – үз әсәрен утызынчы елларның икенче яртысындагы рухи кысынкылык шартларында язган, эпостан килеп чыга торган төп карашларны ачып бирү мөмкинлегеннән мәхрүм булган. Туксанынчы елларның хөрлеге шартларында

һәммәсен тарихи дөреслеккә туры китереп эшләү мөмкинлегеннән файдаланмау һич тә дөрес булмас иде.

Чыннан да шулай бит. Ю.Сафиуллин тудырган әсәр рухы белән дә, сурәтләнеше белән дә халык эпосында уздырылган карашларга тулырак туры килә. Моның өчен, драматургның гына түгел, баш режиссёрның да фикер үсеше, карашларының заман рухына якын килүе кирәк булды. Бу уңай белән бер фәнни мәҗлестә М.Сәлимҗанов әйткән сүзләр хәтеремә килә:

– Халыкка ачы хакыйкатьне ярып әйтеп бирергә теләдек, – дигән иде ул. – Икенчедән, артистларыбызның осталыгын тагын да күтәрергә дигән ният тә бар иде. Гомерләр узгач, әйтсеннәр иде: Татар дәүләт академия театрында нинди титаннар эшләгән, татар тарихын сәхнә теле белән нинди итеп ачып салганнар!

Автор һәм режиссёр әсәрнең яңача куелу әһәмиятен Субра карт образын гәүдәләндерү ярдәмендә дә ачыклыйлар. Бу образга йөкләтелгән бурыч дастан кысаларыныкыннан бик күпкә арта. Билгеле булганча, әлеге карт дастанда бары тик бер генә тапкыр күренә. Ул, Туктамыш хан сараена килеп, мәҗлестә катнаша һәм Идегәйнең Котлыкыя малае икәнлеген әйтә. Бу – сюжетның кискен борылыш алган иң киеренке урыны. Биредә Субра картның Туктамышка биргән киңәше төрле уйларга этәрә. Идегәй качып киткәч, ул болай ди:

*– Ялгызы ерак китмәстер,*  
*Иделдән ерак үтмәстер.*  
*Тугыз ирне җибәр дә,*  
*Алдап-йолдап кашына ал,*  
*Кашына ал да башын ал!*

Бу сүзләр белән таныш булгач, Субра картка карата күңелдә тискәре караш туа. Чөнки укучы күз алдында әлегә кадәр Идегәйнең тик уңай сыйфатлары гына ачыла килде. Субра ни өчен аңа карата шулай рәхимсезлек кылырга өнди? Бу карт явызлык иясе буларак кабул ителә дияргә була. Ләкин моның сере тиз ачыла. Ул болай дип өсти:

*Исән-аман китсә ул,*  
*Иделдән ары үтсә ул,*  
*Шаһ Тимергә җитәчәк,*  
*Шаһ Тимерне алып килеп,*  
*Сарайны харап итәчәк.*

Вакыйгалар барышы, чыннан да, шуңа китереп чыгара да. Димәк, Субра карт алга карап фикер йөртүче булып күзаллана. Шуның белән аның дастандагы хезмәте тәмамлана. Билгеле инде, Идегәй, аның улы Норадын, бөтен вакыйгаларны хәрәкәткә китерүче образлар буларак, сюжетның катлауланганнан катлаулануын тәэмин итәләр, алар һәлак ителгәч кенә хикәяләү тукталып кала. Әсәрне сәхнә өчен яңадан язуның зарурлыгы спектакль белән танышкач аңлашыла төшә. Чөнки, еллар үткән саен, мәгълүматыбыз арта һәм ачыклана бара, шул рәвешле тарихка булган карашларыбызда гына түгел, сәхнә телендә дә үзгәреш бара. Н.Исәнбәтнең сугышка кадәрге чордагы сурәтләү ысуллары бүген тиешенчә яңгырамаска да мөмкин. Ю.Сафиуллин әсәргә заман сулышы өрүнең бик отышлы юлларын тапкан. Шул ук Субра картның прологтагы һәм финалдагы монологлары спектакльнең ватанпәрвәрлек рухын нык арттыра, тамашачыны халкыбызның гаять катлаулы көрәштән торган тарихы турында тирәнтен уйландыра. Дөреслекне яшерүнең дәүләтләрне харап итүгә китерүен әйтеп, ялганга юл бирмәскә өндәгән соңгы сүзләр тулаем әсәргә йомгак булып кабул ителә. Ягъни шул сүзләрнең яңгыравы гына да әсәрнең өр-яңа варианты иҗат ителүен аклый. Бу күренешләр халык мәнфәгате белән яшәгән җырчы-чичәннәрнең җырлары үлемсез,

мәңгелек дигән фикерне раслау өчен хезмәт итә. Субра картның 195 яшьтә булуы да шуңа ишарә. Ул Туктамышның ата-бабаларыннан да уздырып яшәгән, ханның үзеннән соң да тереклеген дәвам иттерәчәк. Җырга, халык акылына үлем юк!

Субра картны шул чорның җырчысы итеп тә, бүгенге көнебезнең аксакалы буларак та карарга мөмкин. Ул иң мөһим фикерне – халык бәхетенең ачкычы аның бердәмлегендә, алга карап эш итүендә икәнлеген җиткерергә ярдәм итә. Бу – авторның һәм театрның зур табышы. Хан булуны үзмаксат иткән Норадын, бүгенге гамәле иртәгә нинди нәтиҗә бирәсен чамаламыйча, нигездә үч һәм нәфрәт белән генә эш иткән Идегәй Алтын Урда халкының иртәгәге язмышы турында җитәрлек дәрәҗәдә уйлый алмыйдыр. Үз тирәләрендә ялманып йөргән ялагайлар белән чын, ихлас күңелле кешеләрне аера алмаулары икесен дә һәлакәткә илтә.

Яңа автор, табигый, үз элгәрләрен кабатламаска тиеш. Ләкин күпмедер күләмдә кабатламый да хәлең юк. Чөнки Н.Исәнбәт тә, Ю.Сафиуллин да бер үк дастан белән эш итәләр. Бу очракта вакыйгалар эзлеклелегендә охшашлыклар котылгысыз. Әмма шунысы куанычлы: Ю.Сафиуллин, дастанны тулаем һәм аның төп каһарманын, башка образларны да үзенчә бәяләп, яңа версия барлыкка китергән. Бу катлаулы әсәрнең барлык сюжет сызыкларын да бер җепкә тезү кыен эш. Мәсьәлә шунда, сәхнә әсәрендә тамашачының кызыксынуын тотып торырлык үзәк интрига булырга тиеш. Бу үзәк биредә бар, ул – Идегәй белән Туктамыш мөнәсәбәте. Башка барлык сызыклар шушы үзәк тирәсенә җыела. Драматург өчен иң авыры – гаять катлаулы хәл-әхвәлләрдән әлеге мөнәсәбәткә тәэсир итәрдәй тармакларны аерып алу. Безнең карашка, Ю.Сафиуллин монда шактый отышлы эш иткән. Дөресен әйткәндә, биредә Идегәй образыннан тыш, Норадын, Туктамыш образлары да сюжет оештыруда лидерлыкка дәгъва итәләр. Алай гына да түгел, драматург Яникәгә дә шушындыйрак бурычлар йөкли. Яникә әлеге версиядә, Җанбай белән берлектә, вакыйгаларның киеренкелеген, интригаларның үткенлеген тәэмин итүчеләрдән булып чыга.

Автор Норадын образын эшләүгә аеруча көч салган. Сөяк-санагы түгел, акыл-ихтыяры да ныгып җитмәгән Норадын язмышы укучының һәм тамашачының да уртак хәсрәте булып әверелә. Аның белән аралашкан күренешләрдә Идегәй дә, сугышчан һәм кыю гаскәри генә түгел, бәлки улы турында кайгыртучан, аның гамәлләрендә үзенең көрәше дәвам иттерелүен күрергә теләгән, күңеле ярату белән тулы ата буларак та тасвирлана. Нәкъ менә шул нәрсәләр фаҗигале финалның дәһшәтен көчәйтә дә.

Чыннан да, хәзерге шартларда бу әсәрнең яңгырашы шулайрак булырга тиеш тә булгандыр. Чөнки халкыбыз да урта гасырлардагы ата-бабаларыбызның нинди хәлләр кичергәнлегеннән бүген шактый хәбәрдар. Моңа кадәр яшереп киленгән тарихыбызны ачыклауда соңгы унъеллыкларда шактый алга кителде. Ю.Сафиуллин моны сизгер тойган һәм заман тамашачысы таләпләренә җавап бирерлек версия тудыра алган. Идегәйне кеше буларак аңларга мөмкин, әмма халыкның шул көннәрдәге һәм ерак киләчәк язмышын хәл итүчеләрнең берсе булган кешенең холкы, аның акланмаган гамәлләрен күрсәтү аша драматург хәзерге буыннарга да олы сабак бирә. Хәер, халык әйтмешли, борчага үч итеп, тунны утка ягу кебек ахмаклыклар безнең чорда да булгалап тора. Димәк, Идегәйләр барлыкка килсен өчен җирлек һаман да бар. Менә болар барысы Ю.Сафиуллин әсәренең кыйммәте тарихка яктылык төшерүдә генә түгел, бәлки алга таба мондый адашуларга юл куймаска кирәклеген хәзергеләрнең колагына киртләп куюда да.

Без Юныс Сафиуллин иҗатының кайбер сәхифәләрен генә күздән кичердек. Шул кадәресе дә бу иҗатчының драматургиябез үсешендә, тормышны эстетик өйрәнүдә бик җимешле һәм нәтиҗәле эш иткәнлеген күрсәтә. Бу хөрмәтлебезнең театр сәнгатебезне үстерүдә үзенең саллы өлеше бар. Аның алга таба да куанычлы табышларга юлыгып яшәвен телибез.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН**

# ХИСЧӘН ФИКЕРЛЕ ШАГЫЙРЬ

***(Рәшит Әхмәтҗанов иҗаты турында уйланулар)***

*Моңайсаң – мин булып эндәшер*
*Җирдәге иң тере тылсымнар.*

## Кереш кәлимә

Олы тарихлы татар шигърияте, саный-атап китсәң, гаҗәеп үзенчәлекле, тирән эчтәлекле мирас калдырган исемнәргә бай икән. Һәркайсы үзенә насыйп тормыш вә иҗат юлын узган. Язмыш аларга туган җиренә, милләтенә, якыннарына тугрылыкка сынауларын җибәреп кенә торган. Яңалыкка дәгъва итмәстән, исемгә чыгарылган шагыйрь әйтмешли, «Бер сәфәрдә биш кыямәт кичеп», «сагыш сихерләре ярдәмендә» исән-имин калган Х.Туфан, уртак ил азатлыгы өчен башларын бүкәнгә, күкрәкләрен дошман ядрәсе астына куйган М.Җәлил, Ф.Кәрим, А.Алиш, Г.Кутуй, аяк-куллары хәрәкәтсез калгач та, авызларына каләмнәрен кабып, туган милләтләренә изге теләкләрен әйтеп калдыра алган Ф.Яруллин, Г.Сәгыйров, Җ.Дәрзаманнар иҗатлары белән һаман да безнең арада. Шулар янына кылган гамәлләре, чор таләпләренә сизгерлеге, туган милләтенең һәр әгъзасына бәхет теләп, үз кул көче белән көнен күргән, гади ташчыдан күркәм шигъри югарылыкка күтәрелгән тагын бер шәхесне атыйсым килә. Ул – Рәшит Хәниф углы Әхмәтҗанов (1941-1995).

Үзе исән чакта ук «Хыялларым үзем белән» (1965), «Адымнар» (1969), «Ак канатлар» (1972), «Гомер чишмәсе» (1976), «Алмалы җәй» (1979), «Җан яктысы» (1980), «Йөрәк бәйрәме» (1988), «Моңлану» (1991) кебек һәркайсы төпле бәя алган җыентыклар авторы, халкына азатлык, мөстәкыйльлек, ирек таләп иткән милләт вәкилләрен оештырып, ачлык мәйданына алып чыгучыларның берсе – үзаман Рәшит Әхмәтҗанов иде. Аның янына абыйсы, күренекле артист Илдус, әдипләр Ф.Бәйрәмова, Г.Морат, Ә.Мушинскийлар килеп бастылар. Шул дәртле, өметле еллар рухын чагылдырган, әйдаманнарыбызны зурлаган, М.Җәлилнең «Моабит дәфтәре» янына урнашырлык, жанрлык хасияте буенча югары патетик поэма үрнәге «Ачлык мәйданы» шигырьләр бәйләме авторы да «ташчы» ир-егетебез Р.Әхмәтҗанов иде. *(«Ачлык мәйданы», 1993, 10000 д.)* (милләтебезнең «тыны» кысыла барган саен бу тарихи вакыйганы онытырга тырышабыз).

Иҗаты тыйнак, мәгәр түбәннән күтәрелгән чишмә суы агышын хәтерләткән Р.Әхмәтҗанов миллионлаган гаярь егет-ирләрнең гомерен өзгән, исәннәрне бәхеттән мәхрүм иткән каһәрле 1941 елда, тарих тарафыннан җәберләнгән, кимсетелгән милләтемә бер юаныч, күчтәнәч, өмет чаткысы булсын дип, Аллаһы Тәгаләбез татар шигъриятен дөнья сүз сәнгате дәрәҗәсенә күтәргән Тукайны бүләк иткән апрель аенда, бөек шәхесебез бакыйлыкка күчеп, бер көн узгач, 14 апрельдә дөньяга оран салган Р.Әхмәтҗановка шул ук елда туган күпчелек яшьтәшләреннән аермалы буларак, Тукай исемен йөрткән премия бирелмәде.

Һичсүзсез, ул аңа лаеклы иде. Бу гаделсезлеккә аның исе китмәде кебек, чөнки ул иҗаттан туктамады, мең еллык шигъри мирасыбызга таянып, иртәнге саф чык бөртекләренә манчылган шигъри тәлгәшләрен коюын белде.

Шул ук вакытта аның талантын, язганнарын күрмәделәр, «башыннан сыйпап» үсендермәделәр дип тә булмый. Үзе исән чагында ук Х.Туфан, Г.Ахунов, М.Әгъләм,

Р.Фәйзуллин, Ф.Бәйрәмова, З.Мансуров, Р.Зәйдулла һ.б. әтрафлы затларыбыз аның иҗатына һәрьяклап уңай бәяләрен биреп, хуплау сүзләрен ишеттереп калдырдылар.

Шул хәтлесе дә бар: Бөек көч сугышта катнашачак ирләрнең фаҗигале язмышын алдан сиземләп, аларның аң төпкелләренә дәвамчыларын калдыру ихтыяҗын сеңдергән. Башка милләтләр өчен җавап бирә алмыйм, татар ир-егетләре милләт алдында торган бурычларын «намус» белән үтәгәннәр. Меңәр еллык татар сүз сәнгате тарихында әдәбиятыбызга, бигрәк тә шигърияткә, бер елда бу чаклы талантлы сүз осталары килгәне юк иде һәм, хәзерге вазгыятьтән чыгып фикер йөрткәндә, киләчәктә дә мондый үсешнең пәйда булуы шикле.

Ил өстенә яуябырылган елда туган Р.Харис, Г.Рәхим, Р.Гаташ, Р.Әхмәтҗанов, Х.Бәдигый, М.Каюмовтай шагыйрьләр исемлеген Ф.Садриев, Т.Әйди, Н.Хәсәнов, Р.Хәмид, Ф.Галимуллин, Ә.Шәрипов кебек прозаиклар, драматург һәм әдәбият галимнәре, тәнкыйтьчеләр тулыландыра. Әлеге буын алтмышынчы – җитмешенче елларда әдәби процесска өермәдәй, яшеннәр яшьнәтеп, искергән өлгеләрне кире кагып килеп кереп, яңача фикерләүләре белән танылдылар.

Озак еллар дәвамында «Казан утлары»ның бүлек мөхәррире булган каләмдәшенә Р.Фәйзуллин бәя бирә: «Рәшит Әхмәтҗановның шагыйрь һәм дә зур шагыйрь икәнен кешеләргә раслыйсы юк. Әмма аның шигъриятенең үзенчәлеген, нечкәлекләрен үзебезгә аңлыйсы, күпләребезгә төшендерәсе бар әле»[1]. Укучыга тәкъдим ителә торган язмаларның да төп максаты, азмы-күпме булса да, Рәшит Әхмәтҗановның иҗатын үземә аңларга һәм башкаларга төшендерергә тырышу.

Ул «Казан утлары»нда эшләгән елларда мин Алабугада яшәсәм дә, Язучылар берлегенең идарә яисә әдәби журналыбызның редколлегия әгъзасы буларак, Казанга еш килә идем һәм әдәбиятыбызның «штабына» кагылмыйча китми идем. Мин Р.Әхмәтҗановтан нибарысы өч яшькә генә олырак булсам да, ул һәрдаим мине урындыгыннан күтәрелеп, «Тәлгат абый, хуш киләсез, чәй куеп җибәримме», дип елмаеп каршы ала торган иде. Аның риясызлыгы, ихласлыгы һәр хәрәкәтеннән, сүзеннән, күзләреннән бөркелеп торуы күңелгә сеңеп калган. Үзен күреп, очрашып аралашканчы ук, аның кешелекле лиризм, психологик нечкәлек, моң, сагыш илә өретелгән иҗаты белән таныш булганга, «үзенә ошаган шагыйрь» дигән фикердә ныгыганчы ук, иҗатына багышлап, «Бизәкләр төрлелеге» исемле мәкалә язган идем. Ул, чиратын көтеп, «Казан утлары»ның 1981 елның алтынчы санында (160–169 битләр) басылып чыкты. Кабатланмас, яшьлек хисләренә бирелмәс өчен ул язмаларыма күз дә салмадым.

2022 елда тууына 81 ел тулган асыл затыбызның мирасын өйрәнүгә багышланган ошбу язмаларым рухына бер дога булып барсын...

## Исәннәр моңы сүрелмәсен

Р.Әхмәтҗанов бөтен булмышы, табигате, җаны-тәне белән лирик рухлы шагыйрь. Аның иҗаты турында язылган барча мәкаләләрдә шуңа якын фикер уздырыла. Берничә шигырьләр җыентыгын нәшер итеп, каләмдәшләренең җылы сүзләрен ишетеп, фатихаларын алганнан соң гына, анда да әле теләмичәрәк, шулай кабул ителгән этикет буенча гына олы жанрга алына һәм төрле елларда (ул аларны күрсәтеп, теркәп бармый) дүрт поэма иҗат итә: «Язлар быел соңга калды», «Исәннәр моңы», «Аучылар кибетендә» һәм «Бишташ».

Ошбу әсәрләрендә шагыйрь үзен һәм сөекле халкын борчыган, һәрхәлдә уйландырган көнүзәк мәсьәләләрне калкытып куйса да, аның иҗатында жанрның классик таләпләренә җавап биргән поэма юк. Лирикасындагы шикелле үк, аларның

[1] Фәйзуллин Р. Күңел һәм җан сәфәре. Китапта: Рәшит Әхмәтҗанов. Моңлану – Казан.Татарстан кит.нәшр., 1991.– Б.5. «Арадашчы» вазифаларын үтәгән шагыйрь галиҗәнаплары, ягъни автор үзе.

«каһарманнары» табигать сурәтләре яисә вакыйга-хәлләрне йөрәге аша «үткәрүче», «узып баручы», «күзәтүче», «бәя бирүче».

Ирекле, сыйдырышлы композицияләре, сүз-сурәт үзенчәлекләре белән алар лиро-эпик жанрның катгый таләпләренә җавап бирмәсәләр дә, үзәкләрендә яткан проблемалары, сурәтлек сыйфатлары, һәркайсында үзенчә яңгыраш алган мелодраматизмнары белән күңелләрне иркәләп, фикер уятырдай тезмә әсәрләр.

«Язлар быел соңга калды» белән танышканда, мәҗүси фикерләү, табигать, гомумән, тышкы дөнья күренешләрен җанлы итеп күзаллаган антропоморфизм чорына килеп кергәндәй хис итәсең! Әсәрнең үзәк каһарманы җиһандагы тереклеккә «җан биргән» диңгез булып чыга. Ул «сөйләр бәлки нинди тамчы булганын», каян килеп чыкканын дигән өмет алдагы шигъри юлларда ачыкламышын таба шикелле.

*Сөйләр диңгез: без эзләгән хакыйкатьне*
*Бәлки әле иң беренче тапкандыр?*
*Тапкандыр да... Мәңге тере дулкыннары*
*Таш ярларга ябырылып ташлангандыр.*
*Һәм шуннан соң җирдә яшәү башлангандыр,*
*Башлагандыр, бәлки, барысын шушы диңгез.*

(«Язлар быел соңга калды»).

Поэмада диңгез ялгызлыкта калдырылмый: аны җирдәге тереклекне дәвам иттерүче кошлар, торналар, саба җиле, йолдызлар, таш ярлары һ.б. хәрәкәткә китерелгән «җан ияләре» тулыландыралар. Алар мәхәббәтнең үлемсез көче, яшьлекнең аңа табынуы, кешенең җирдәге урыны турындагы нисби уйлануларга алып чыгалар, юл ачалар.

Диңгез – шагыйрь иҗатында иң еш очрый торган, илһам күзәнәкләренең үзәгендә торган сурәт-җисемнәренең берсе. «Диңгез-язмыш», «Чуерташ тавыш», «Дулкыннар өстендә», «Йөгерә-йөгерә дулкыннар...» әсәрләрендә калкып чыгып, «Язлар быел соңга калды» әсәрендә тулырак чагылышын табып, шагыйрьнең эчке тавышының көйле аһәңен билгелиләр. Күрәсең, Хәзәр каганаты, Кубрат хан заманнарында диңгез буйларында яшәгән бабаларыбыздан буыннар аша килеп, аң төпкелендә сакланган моң, лирик затның хисси дөньясын иләсләндерә торгандыр.

«Язлар быел соңга калды» – тыныч тормышка, дөресрәге, табигать җисемнәренә, тереклек ияләренә гашыйклар күзе белән карый алган, хисси-медитатив дулкында иҗат ителгән романтик әсәр. Авторның хыялый дөньясы байлыгы белән сокланган хәлдә дә, бал мичкәсенә бер кашык дегет тә соралып тора. Ник дисәгез, фикер-кичерешләрне бер үзәккә җыеп торган реаль шәхес булмау, куплетларның шырпы каплары мисле берсе икенчесенә охшап, шыплап тутырылуы һәммәсе «дөрес» күпсүзлелеккә алып килә, юлларның гелән 12-12 ле иҗекләрдән генә торуы ялыктыра.

Шагыйрьнең табигать белән гармониягә, рухи һәм җисми бердәмлеккә омтылуын, илаһи мәхәббәтне олылавын хуплаган хәлдә дә, иҗат ителү ягыннан икенче – «Исәннәр моңы» поэмасына күчү теләген уята. Чөнки анысында азмы-күпме җанлы кешеләр белән дә «күрешеп» аласың!

«Исәннәр моңы» поэмасына юллама-эпиграф итеп, Туфан шигыреннән алынган «Кырда ике ак канат ята» гыйбарәсе, күңелдә өметле дә, шомлы да хисләр уятып, тизрәк поэма белән танышуга этәрә. Ул чәчмә әсәрләргә хас талгын алым белән башланып китә. Кунып чыгаргамы, ял итәргәме дигән ният белән капкага шакыган мосафирны «ап-ак чәчле» Ләйсән исемле карчык каршы ала һәм тәмле чәе, мәгънәле сүзе белән кунак итә. Сөйләшүнең үзәгендә миллионнарның гомерен өзгән, исәннәрне гаилә бәхетеннән мәхрүм иткән, һәркемнең аңа үз мөнәсәбәте булган сугыш хәсрәте тора. Ул итагатьле хуҗабикәнең язмышында да тирән эз калдырган икән. Гадәти татар

авылының чибәр кызларының берсе – Ләйсәнгә шул авылның ике булдыклы асыл егетләре, җитмәсә, әле дуслар – Басыйр белән Рәхимҗан гыйшык утында яналар. Кайсы күңеленә, җанына якынрак икәнен тәгаенли алмаган кызга сугыш үз «чишелешен» тага, аны икесеннән дә мәхрүм итә.

«Елау белән җырлау бар икән» дип, җилкәнчекләрен фронтка озаткан кичтә үк кыз төшендә аларны «күлмәкләре янып торган» килеш күреп, исән-имин кайтмаячакларын аңлый. Һәркайсы бәхеткә лаеклы фаҗигале шәхесләр. Аларның холыклары, язмышлары колхозда тракторчы булып эшләп, гаилә ләззәтен күрмичә картайган карчыкның эчке-сөйләм монологында, бигрәк тә Рәхимҗанның үлеме алдыннан язган тетрәндергеч эчтәлекле «Чук-чук сәлам безне сөйгәннәргә! Үлгәннәрдән сәлам исәннәргә!» сүзләре белән башланып киткән хатын уку һәм Басыйрның Ләйсәнгә мөрәҗәгать итеп, «Мин башымны синең өчен саклыйм» дип, атакага күтәрелмәвен искә төшерү поэма композициясенең агышын катлауландыра. Юк шул, мәхәббәткә ышыкланып кына, язмышыңны үзгәртеп булмый икән. Лирик затның бәя-нәтиҗәсе катгый, камчы шартлавы кебек яңгырый: «Шул мизгелдә мәхәббәте хөкем итте аны үлемгә». Һәм икесенә кызның мөнәсәбәтен ачыклау тирән уйланылган һәм икеләтелгән проекцияле, кискен психологик юлларга тапшырыла.

*Басыйр исән,*
*Кайсы якка*
*Борылмасын – Басыйр йөзе;*
*Аңа таба карап тора*
*Рәхимҗанның ике күзе.*

Күңелне әрнетеп, ачу, нәфрәт, сызлану хисе уятып, шул чорның бер күренеше «Аучылар кибетендә» поэмасына үтеп кереп, фабула канвасының үзәгенә куела. Өендә ачлыктан шешенеп утырган биш баласына ризык юнәтеп кайтучы Фатыйманы фашистларны символлаштырган сугыш чоры бүреләре ботарлап ташлый. Аның батырлыгы таң калдыра. Ире сугышта вафат булган тол хатын үлгәндә дә, «бәрәңгесе тулы» төенчеген кулыннан ычкындырмый. Ананың фидакарьлеген искә төшерү исәннәр колагына сеңәргә тиешле нәтиҗәгә алып килә.

*Фатыймага алтын һәйкәл кирәк –*
*Ачтан үтермәде балаларын.*

«Аучылар кибетендә» поэмасында да вакыйга-хәлләр аучыларга кораллар сата торган кибеткә кергән «алып баручы» затның юлда очраклы танышкан, «Атасыннан акыл» (каян, ничек белеп, бәяләп алган), «буй-сын, Йосыф матурлыгын» алса да, әле мәхәббәт сагышы ләззәтен татымаган, әмма «баш мие җелеген» кайнатып торган, Уралдан килгән егет булып чыга. Алар әүвәл икәүләп, диварларда эленеп торган кораллар, рәсемнәр белән танышалар. Юлдашы «ник пуля үтми торган күлмәкләр сатылмый?» дип, сатучы кызның башын катырганнан соң, кемдер улына «Машина калдырган, сарай салдырган», ә минекенең «бар мирасы – мылтык калды ике көпшәле», дип, атасын «чеметеп» алырга да онытмый. Ә картинадагы елан егетнең «уйларына шуышкандай» тоела.

Аквариумдагы, ягъни тоткынлыктагы кәрлә балыклар язмышы, сәфәрчеләргә җитди нәтиҗәләр ясарга, ягъни «үз телләрен, хәтерләрен җуйган халыклар» белән кинаяле чагыштыру, аналогия уздыру мөмкинлеген бирәләр. «Атлантиданы эзли-эзли белми кеше кая барганын» метафорасы сурәткә читтән килеп кергәндәй тоелса да, битараф калдырмый, уйландыра. Мондый «өстәмәләр», сюжет-композиция таләпләре белән санашмаган Р.Әхмәтҗановның сурәтле фикерләү үзенчәлеге «җимешләре»н тәшкил итәләр. Җыеп кына әйткәндә, «Аучылар кибетендә» бай мәгънәви сәяси эчтәлекле

әсәр. Иҗатчы киштәләрдәге кораллар, диварларда эленеп торган мамонт аулауны, бүре тотуны сурәтләгән рәсемнәрне «күрсәтү» аша теләсә кайсы сугышка, явызлыкка нәфрәт хисе тәрбияләү максатын яшерми. Бу кибеткә сәфәр кылу бернинди уңай тәэсир уята алмый. Үкенеч хисе генә йөрәкләрне әрнетеп, чеметеп ала.

Эчтәлеге белән танышканчы, «Бишташ» поэмасы сәеррәк исемле булып күренсә дә, тәнкыйтьтә басылып чыккан чорда ук югары бәяләнә. «Аучылар кибетендә» һәм «Бишташ» авторның гына түгел, гомумән, поэзиябезнең табышы саналырга лаеклылар», дип язып, Р.Фәйзуллин поэмага үзенчә аңлатма да бирә. «Бер караганда, бу поэмаларның сюжет җепләре өзелеп-өзелеп киткәндәй тоела. Алай түгел икән шул. Ул җепләр үзәк өзгеч моң белән тоташтырылганнар икән. Моң сихеренә ия булган шагыйрьнең үзенчәлеге, иҗади табышы итеп кабул итәргә кирәк моны»[2].

«Бишташ асылташлары» мәкаләсендә икенче олы шагыйребез, ачлык мәйданы эпопеясен бергә кичергән Г.Морат әүвәл әсәрне «пародоксаль поэма» дип бәяли һәм аңа үз шәрехләү – аңлатмасын бирә. «Әсәр хикмәтле сүз әйтүгә корылган... Рәшит Әхмәтҗановның фикерләү үзенчәлеген исәпкә алмаганда, әдәбият гыйлемендәге әзер кагыйдә-кануннарга гына таянып эш йөрткәндә, «Бишташ» поэмасына да таш атып була торгандыр...»[3]

Күренекле шагыйрьләр гоманын хуплаган хәлдә, шагыйрьнең тормыш юлыннан килеп чыккан бер мөһим фактны онытмасак иде. «Бишташ» поэмасы шагыйрьнең тормыш юлыннан үсеп чыга, дөресрәге, шуңа бәйле. Баулы районының Татар Кандызы авылында җиденче сыйныфны тәмамлаганнан соң, 1957-1958 елларда ул Бөгелмәдә төзүчеләр көллиятендә укый һәм 1961 елда армиягә алынганчы, адашы, атаклы төзүче, Социалистик Хезмәт Герое Р.Саттаров кул астында ташчы булып эшли. Шуңа күрә булса кирәк, университетта татар теле һәм әдәбияты укытучысы белгечлеген алып, төрле газета-журналларда эшләп, «Казан утлары»нда бүлек мөхәррире буларак та, төрле һөнәрләрне үзләштерсә дә, аның гомерлек юлдашлары, сердәшләре булып «ташлар» калалар.

Бу табигать җисемнәре төрле рәвешләр алып, аның «Кем атсын таш яраланган кошка?!», «Яшь авыр ташлар – тау астында», «Муеныма аскан ташың – тау иде», «Чуерташ тавышы», «Баштан – ташка» кебек күпсанлы шигырьләрендә автор фикерен – хыялын, кичерешләрен укучыга ирештерү чаралары буларак үстереләләр. «Ташлар» аны бөтен иҗаты буйлап «эзәрлекләп» киләләр. Шул исемдәге поэма язган шагыйрь Әдип Маликовка багышланган поэмасында каләмдәшен зурлап «Ташчы» дип атый.

Тәнкыйтьче Р.Шакирҗанов беркадәр шаяртып та булса кирәк, шагыйрь иҗатына багышланган мәкаләсен «Ташлар кеше итте» дип атый *(«Татарстан яшьләре», 1990, 24 март).*

Дөрес, кеше көнкүрешенең юлдашы – таш әдәбиятка күптәннән үтеп керә. «Бишташ» поэмасына юллама-фатиханы «Таш, батмыйча, су өстендә йөзеп йөрде» гыйбарәсе белән Кол Гали «бирә». Башка шагыйрьләр иҗатында да таш сурәте еш очрый.

*Бу таш...болгар бабам торган йортның*
*Нигезеннән купкан, күрәсең.*
*Мин абындым аңа,*
*Телсез кинәт*
*Телгә килде:*
*Нигә тибәсең?!*

Кинәт уянган таш шагыйрьнең хыял дәрьясын хәрәкәткә китерә: кеше таштан савытлар, балта ясый, өйләр сала, аңа бәя Туфанның «Талантлы син, Кеше туганым» дигән тантаналы гыйбарәсен искә төшерү аша бирелә.

[2] Фәйзуллин Р. Күңел һәм җан сәфәре. Китапта: Р. Әхмәтҗанов. Моңлану. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1991. – Б.7-8
[3] Морат Г. Җәяүле кошлар. – Казан: Тат.кит. нәшр., 2002. – Б.172.

Алдагы ташларның берсе кабер ташы булса, өченчесе вулканны айкап-чайкап, «ташны күккә аткан булган» икән. Дүртенче бүлек таудан «нәни генә тылсымлы бер ташка әйләнгән» матдәгә багышлана. Соңгы бүлектә «...Казанына таш салып, / Аш кайнаткан ананы, / күрүчеләр булганын / Белми әле балалар» дип, нәселен ач үлемнән саклап калган аналарга дан җырлана. Поэманың керешендә («Поэмага чакыру»), соңгы сүзендә («Поэма белән саубуллашу») тормыш, яшәеш үзәне – киң мәгънәсендәге мәхәббәтне олылаган, Ай, Йолдыз, Күк, Җир кебек олы җисемнәрне шигъри әйләнешкә керткән юлларның төп максаты – ташка табынган хезмәт Кешесен олылау булып чыга.

«Бишташ» поэмасын чынбарлык белән ирекле «әңгәмә» дип атарга була. Шагыйрь милләт язмышына кагылышлы мәсьәләләрне күтәрүне дә онытмый, хәтта фәлсәфи сөземтәләр – халык мәкаләләре белән «бәхәскә» керүдән дә тартынып тормый.

*«Аш белән бәр», диләр. Тыңлама!*
*Таш белән бәр – әгәр тисәләр.*
*Аш белән күп бәрдек,*
*Ә барыбер*
*Тамырыңнан сине кисәләр.*

Мин Р.Әхмәтҗановның күләмле әсәрләрен кат-кат укып, аларның хикмәтле үзенчәлекләре, сюжет төзелешләре, сурәтләү чаралары турында уйланып, бу өлкәдә үземне белгеч санап йөрсәм дә, Р.Әхмәтҗанов поэмаларына «ачкыч» таба алмыйча изаландым. Рәхмәт Ләбиб Леронга, мин айлар буе оештыра алмый интеккәнне бер җөмләгә сыйдырган. Ул үзенең бер эпиграммасында Р.Әхмәтҗановка мөрәҗәгать итеп, түбәндәгене яза: «Шигырең шәп... Поэмаң да... / Тик шундадыр аерма: / Һәр поэмаң – озын шигырь, шигырең – поэма»[4]. Барысы да көн кебек ачык: аласы да, бүләсе дә юк. Бу инде, кем әйтмешли, «шагыйрь җанын аңлыйм дисәң», төп игътибарны аның лирикасына юнәлтергә, кыйбланы шул тарафлардан эзләргә кирәклекне аңлата.

## Язмышка әверелгән шигърият

*Туган илем!*
*Мең кат тапкырланган*
*Мәхәббәтем, нурым тик сиңа!*
(«Минем өчен дөнья»).

Лирика – шигъриятнең иң өлгер һәм шәхеснең рухи дөньясына иң сизгер төре. Р.Әхмәтҗановның халкына калдырган мирасының иң зур өлешен лирик юнәлеш алып тора. Каләмдәшләре аны еш кына «моң һәм сагыш шагыйре» диләр. Аның бай рухи халәткә ия лирик герое Җир шары, Галәм борчуларын, милләт хәсрәтләрен, аерым шәхеснең шатлык-кайгысын, аерылышу-кавышу матавыкларын үз йөрәге аша уздыра.

Нечкә хисле, тормышчан нигезле лирик Р.Әхмәтҗанов тормышның ачысын-төчесен, уңай вә тискәре якларын күп татыса да, самими сабыйлыгын җуймаган, бөтен барлыгы, рухы, сурәтле фикерләү рәвеше белән лирик шагыйрь булып кала алган. Аның җыйнак күләмле, төгәл вәземле, шул ук вакытта тормышының үзе шикелле төрле эчтәлекле шигъри парчаларына халык җырларына хас җыйнаклык, төгәллек, садәлек, эчтәлекләре ягыннан кешеләрне яратудан килгән ихласлыгына хилафлык китерми, лирик геройны тар аратага куып кертми. Җыеп кына әйткәндә, шагыйрьнең туган иленә, тирәлеккә, табигатькә багышланган шигырьләрендә халык телен, яңгыраш аһәңнәрен үзенчә чагылдыруы, тышкы сүз-сурәт гадилекләре, керсезлекләре белән төрле катлам укучыларын үзләренә тартып торалар. Бу яктан ул канатлы каләме тудырган рухи дөньяның сизгер, халык язмышы турында уйланганда, иң уйчан да, иң

[4] Лерон Л. Сөяксез тел: пародияләр, эпиграммалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – Б. 151.

кыю да шагыйрьләрнең берсе. Рәшит Хәниф улы тереклекнең, тормышның кадерен белеп яшәде һәм шуны шигъри калыпка салу сәләтенә ия иде.

Иҗатының бу үзенчәлекләре аңа багышланган язмаларның исемнәрендә үк күренә: «Чәчәк җылысы» (М.Әгъләмов), «Нәни инеш, тамчы һәм зурлык» (М.Хуҗин), «Акчарлакның сагышы» (Р.Батулла), «Нечкә хисле, батыр йөрәкле» (Р.Фәйзуллин) һ.б. Ягъни аның мирасы Р.Әхмәтҗановны «Моң шагыйре» дип атарга этәрә. Үзе төзеп, тышлыгын сыйпап өлгергән, халкы язмышын, лирик каһарманның рухи дөньясын, җанына газиз табигатен чагылдырган иң тулы җыентыгын бер сүз белән «Моңлану» (1991) дип атый.

Кайсы чыганаклардан килә икән шагыйрьгә «Тормыш, тормыш, / Нинди күңелле син, / Әй, татлы да синдә моңаю» («Табам әле») кебек, бер караганда, каршылыклы, чынлыкта тормышны зурлау хисләре? Әлбәттә, мондый фикерләр, кичерешләр туган халкының холкыннан, язмышыннандыр. Тарихның гасырлар дәвамында үзен рәнҗетүенә карамастан, татар халкы моңлы, көйле, саф күңелле булып кала алды. Галимнәр фикеренчә, аның яшәешен җырдан, көйдән үзгә күз алдына да китереп булмый. Бусы – бер.

Психологлар, дин белгечләре бала тәрбиясен, «әхлак дәресләрен», яшәеш күнекмәләрен, холык-менәз үзенчәлекләрен ана карынында ук үзләштерә, ана булачак дәвамчысын догасын укып, һич югы бисмилласын әйтеп, мөмкинлеге булганча, яхшылык кылып күтәреп йөрсә, баласы тәүфыйклы вә итагатьле була, диләр. Барлык иманлы шагыйрьләр иҗатындагы шикелле, Р.Әхмәтҗановның анасына атап язган, башка мәүзугълы шигырьләрендә искә алулар махсус җыентык тупларлык. «Әнкәмне сагынганда», «Әнкәң уйлана», «Еллар буйлап», «И бала», «Әнкәмнең шәле», «Исемдә, әнкәй, исемдә» кебек шигырьләре чын мәгънәсендә бала белән ана арасындагы якынлыкның «шаһитлары». Баласын фани дөньяга ярлыкаган ана улына бәхетле, сөенечле тормыш теләсә дә, таләпчәнлек хасияте турында да онытмый.

*И бала, алтын яшьлегең*
*Бу җиргә нәрсә чәчәр?*
*Нәрсә чәчәр?.. Урмасмы*
*Бары тик көмеш чәчләр.*

(«И бала»)

Илнең «канлы көннәрендә туган» сабыйның назланасы, иркәләнәсе килүе һәм шул ук вакытта тормышка җайлашып, аның кырыс таләпләренә буйсынып, холкын чыныктыруга омтылуы нечкә психологик анализ аша бирелә.

*Ә мин әле җирдә бер нарасый:*
*Иренгә бал, күзгә нур тама.*
*Еласам да, дөнья,*
*Елама, дип,*
*Алсу алма биреп алдама.*

(«Алмагачның бары бер алмасы»).

Күкрәк сөте белән үстергән бала, балигъ булгач та, ана ярдәменә мохтаҗ «сабый» икән.

*Карлыганнан как кояр*
*Баласына бүләккә,*
*Кая аны җибәрер?*
*Солдат улы йөрәктә.*

(«Карлыган җыя ана»)

Чәчмә белән әйтелердәй ифрат гади юлларда ничаклы җылылык, ихласлык. Автор җан чисталыгын гадел яшәүдә, хакыйкатькә хыянәт итмәүдә күрә. Анасы, гомумән,

өлкән буын, халкы яшәгән төбәкләр, туган йорт, гаилә учагы – барчасы шагыйрь өчен изге табыну үзәкләре, рухи маяклар.

*Аксакаллар миңа акыл бирделәр:*
*Күңелең ак булсын һәрчак, диделәр.*
(«Аксакаллар миңа...»)

Аның туган халкына биргән бәясе дә гаҗәеп төгәл һәм Орхон-Енисей таш язмаларына «өстәп» куярлык.

*Исе китмәгән халкымның*
*Җирнең алтыннарына, –*
*Җыр төяп йөргән икән ул*
*Атына, корабына.*
(«Исе китмәгән...»)

Илһам чыганагы – туган илен ул бернинди байлык-нигъмәткә, алтын-көмешкә дә алыштырмый. Аның һәр күренешен, күзәнәген үз итсә дә, аны риторикага, югары өслүбкә күчеп мактамый.

*Үз илемә кайтып киләм*
*Яшьле күзем,*
*Көләм үзем.*
*Тамчы яшем – илемдәге*
*Үз диңгезем,*
*Үз диңгезем.*
(«Ярларыңны ташлап»).

Поэмаларына багышланган бүлектә искәртелгәнчә, диңгез – аның өчен изге төшенчә, таяныч ноктасы. Шул ук вакытта иксез-чиксез су дәрьясы, ак күбекләрен уйнаткан дулкыннар белән хозурланса да, ул анда озакка кала алмый, лирик зат авыл чишмәсенең суын сагынып, шунда ашыга.

*Киттем диңгез.*
*Киттем диңгез.*
*Авылымның чишмәсеннән*
*Су бирегез.*
*Су бирегез.*
(«Ярларыңны ташлап»).

Табигать күренешләренә мөкиббән китмәгән яисә бу табигый матурлык белән сокланмаган шагыйрь юктыр. Р.Әхмәтҗанов кебек бөтен барлыгы белән хисчән сүз остасы бигрәк тә. Аның каләменнән тулышкан яфраклар мисле өзелеп төшкән «Җил килде дә...», «Җил иде түрдем җаныма», «Куркыныч», «Мәхәббәтнең исәнлегенә» кебек күпсанлы шигырьләрендә табигать бизәкләре: җил, су, тал, имән, «телчән» ярлар, дулкыннар – рухи дөнья «кодлары», гомумиләштерү чаралары «вазифаларын» үтәүләре өстенә, лирик затның «җанлы әңгәмәдәшләре». Шигъри шәкелдә дулкыннар, ярлар арасындагы диалог, эчке сөйләм алымнары эчтәлекне тирәнрәк ачуга буйсыналар. Бәхәсләр «шаһиты» тал бушка ярсымаска «киңәшен бирә».

*Су өсте тып-тыныч.*
*Тик ярлар сөйлиләр:*
*– Дулкыннар терелер, көт, – диләр.*

*Су өсте тып-тыныч.*
*Тик ярлар сөйлиләр:*
*Тал әйтә: – Ялгызың ярсыма,*
*Берьюлы кайтырлар барсы да...*

Беренче юлларны кабатлау рәхәт моңсу халәт тудырып, табигатьне, димәк, тормышны төрле үзгәрешләрендә кабул итәргә әзерли.

Әйтелгәнчә, аның бай мирасын тар мәүзугъ киртәләре белән чикләп булмаса да, мәхәббәт һәм табигать күренешләре аша кеше кичерешләрен сурәтләгәннәре күзгә ташланып, «төркемләнеп» торалар. «Мәхәббәт дисбесеннән» шигырьләр бәйләме, «Җиде яктан җил исә», «Миләшләр», «Соклану», «Кайда ява» кебек күпсанлы шигырьләрен атап үтү дә җиткәндер. Мәхәббәт сагышын вә ләззәтен үзәккә алган шигырьләре тышкы бизәлешләре, образлар куәсе җәһәтеннән халык җырлары вәзененә якын булсалар да, көтелмәгән борылыш-чигенешләре, нәтиҗәләре белән алардан аерылып, «мин Рәшит Әхмәтҗанов каләме «җимешләре» дип, оран салып торалар. «Сөю миңа тугры булды», «Ярым китте», «Яр сөйгәннәр – менә бездәй моңлы була», «Мәхәббәткә мине биреп китеп» шигырьләре якты сагыш, үкенеч, моңсулык белән сугарылганнар. Мәгәр алар көйгә салынып, җырлап йөрүгә көйләнгән такмазалар түгел. Аларга кискен борылышлар, тирән психологизм хас.

Ай – Р.Әхмәтҗанов иҗатын бизәүче, лирик затның тирән кичерешләрен укучыга ирештерүче, хәтта кеше «мәшәкатьләрен» үзенә алучы «җанлы» образ.

*Мин сөйгәнгә сөймәде ул,*
*Үземә – үз өлешем.*
*Никтер шул Айга охшатам*
*Өлешемнең көмешен.*
(«Ай төшкән кое төбенә»).

Лирик затның бер сере дә юк, күңеле, рухы яшен яктысындагы кебек ачык. Ул тирәлек белән якыннан, иң садә хисләре белән уртаклаша.

*Күгемне ятим калдырып,*
*Коега төшкән дә Ай,*
*Янып, балкып ята суда,*
*Бер кызның алкасыдай.*
(«Ай төшкән кое төбенә»)

Алдагы юлларда әдәби образ дәрәҗәсенә күтәрелгән Ай «серләрен сөйгәненә сөйләү» нияте белән коедан «елгага күчә». Кем соң ул Айның сөйгәне дигән кызыксынуга да аңлату табыла. Айның «дөнья бетереп», суларны айкап эзләгән ратканы «кызыл гөлләр» булуы ачыклана. Су исә «мәҗнүн» Айга сагышыннан «сап-сары» шәлләр бәйләргә киңәшен бирә.

Лирик затның табигать белән «мөгамәләгә» керүе катлаулы да, серле дә. Нибары дүрт юлдан торган «Төнге элегия» – олы төшенчәләр белән «үз күреп» аралашуы, сөюгә озын-озак гомер теләве белән кыскалыкта фикри осталык таләбенә җавап биргән парча.

*Төн буе кемнәр сөйләшә? –*
*Әллә күк... Җиргә эндәшә:*
*– Мин нишләрмен синнән башка?*
*– Сөю кебек озак яшә!*
( «Төнге элегия»)

Табигать күренешләрендә кеше холкын, халәтен сиземләү җәһәтеннән, Рәшитне рус поэзиясеннән бары тик С.Есенин белән генә чагыштырып буладыр. «Кешедә» шигыреннән күренгәнчә, дөньяда адәм баласыннан да кадерле җан иясе юк.

*– Диңгезләрнең җаны бармы?*
*– Бар. Кешедә!*
*Бөтен ирек, иркенлекләр – ул кешегә.*

Бик гади, тормышны, яшәешне бизәп, ал да-гөл итеп сурәтләгән шигырь дип уйлап та өлгермисең, соңгы юлда, шулай ук җаны булса да, яшәүнең ямен, аерым кешеләр арасында гына түгел, илләр, дәүләтләр, сәяси бәйләнешләр даирәсендә дә низаглар, хәтта сугышлар китереп чыгарган, алты хәрефтән торган сүз атала: «хыянәт». Шуннан соң, тартылган җәядән ычкынган ук шикелле, кискен бәя чыгарыла: «Сәлам бирмә, кеше димә ул кешегә» («Кешедә»).

Р.Әхмәтҗанов иҗатында буш сүзле, мәгънәне гади сөйләү белән алыштырган шигырьләр юк диярлек.

*Иртән үләр күбәләккә*
*Мәңгелек биргән канат. –*
*Кайгырмый, оча... Иртәгә*
*Кояш чыга дип кабат.*
(«Иртән үләр»)

Р.Әхмәтҗановның тормышчан һәм шул ук вакытта афористик төгәл, чәнечкеле дә, уйнак та шигырьләреннән мисаллар китерә башласаң, иҗатының яртысын санап үтәргә туры килер иде. Чөнки аның күпчелек шигырьләре форма ягыннан төзек, җыйнак, матур шигъри табышларга бай. Әдәбият нәзариятендә «системалы анализ» дигән шактый популяр алым бар. Шул киң колачлы, «демократик» атамага таянып, аның лирикасын «оялап» теркәү юлына басып кына, күңелне юатырга мөмкин. Тематик һәм мәгънәви, вазгыять һәм сурәтлелек җәһәтләреннән килеп, «сызым» болайрак булырга мөмкин:


Ана – туган ил (табигать) – мәхәббәт – олыгаю (халык язмышы турында уйланулар) – туган тел – милли азатлык өчен көрәш юлына басу – дөнья барышында һәркайсыбызның тоткан урыны – җир белән күкне берләштергән мәңгелек хакыйкать, өмет, ышаныч турында уйланулар.

Традицияләр белән яңачалык арасындагы мөнәсәбәтләргә багышланган алдагы бүлектә Р.Әхмәтҗановның лирик шигырьләрен читләтеп үтеп булмас! Чөнки әле меңәр еллык тарихлы, киң колачлы, талантларга бай татар шигърияте өчен Р.Әхмәтҗанов гадәти күренешме, теләсә кая үсә алган үләнме, әллә олы сүз сәнгатендә берәүдән рөхсәт сорап тормыйча үсеп киткән талант иясеме, дигән сорауга җавап табылып бетмәде кебек. Шуңа күрә аның иҗатына сәфәрне дәвам итәрбез.

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,**
*филология фәннәре докторы.*

*(Ахыры киләсе санда.)*

# ХИКӘЯНЕҢ ДӘВАМЫ БАР




Татар әдәбиятына мең ел дисәк тә, бу вакыт аралыгы, асылда, шигъриятькә карый. Һәм ул әсәрләрнең күбесе төрки халыкларның шактые өчен уртак. Татар хикәясе (гомумиләштереп әйтсәк, чәчмә әсәрләр) яңа заман әдәбиятының үзенчәлеге, ул XIX гасыр ахырында, XX гасыр башында гына мәйданга чыга. Без хәтта аның беренче нигез ташларын куючыны да атый алабыз. Ул язучы, тарихчы, этнограф Каюм Насыйри (1825–1902). Идел буе татарлары XIX гасыр дәвамында урыс патшасына төрле мөрәҗәгатьләр, хатлар язып, үз телләрендә көндәлек матбугат булдыру хыялы белән яшиләр. Ләкин Беренче урыс инкыйлабына кадәр (1905 ел) моңа һич тә рөхсәт булмый. Газета яки журнал нәшер итү хыялына ирешә алмагач, Каюм Насыйри еллык календарьлар чыгара башлый. Шуларда үзенең кыска хикәяләрен, рус һәм төрек телләреннән тәрҗемәләрен бастыра. Әйтергә кирәк, аның әсәрләре әле дә әдәбият сөючеләрдә кызыксыну уята, ә «Әбүгалисина» дигән хикәясе балалар өчен нәни китап булып кабат-кабат нәшер ителә.

Әлбәттә, аңа кадәрге гасырларда да төрки-татарлар арасында хикәяләр язылган, нәшер ителеп тә, кульязма килеш тә халык арасына таралган. Ләкин аларда нәкъ менә шушы җирдә генә була торган вакыйгалар сурәтләнми диярлек. Әллә алар Мәскәү кенәзлегенең Казан ханлыгын яулап алганда (1552 ел), күп кенә матди һәм рухи байлыклар белән бергә юкка чыкканмы? Сакланып калган хикәяләрне яңа заманда иҗат ителгәннәр белән чагыштыру шактый кыен, аларның күбесе дини-схоластик. Ләкин арада әле дә кызыксынып укырлык хикәяләр бар. Алар, асылда, «Кәлилә вә Димнә» сюжетларына корылган. Әлеге нәзирәи хикәяләрдә авторлар хәтта эротиканы да артык кыенсынмый гына кертеп җибәрә.

Егерменче гасыр башыннан яңа татар әдәбияты кеше ышанмастай уңышка ирешә: Россия империясенең төрле шәһәрләрендә дистәләгән газета-журналлар чыга, китап нәшриятлары пәйда була, йөзләгән язучылар әдәби мәйданга чыга. Күпләргә кинәт булып тоелса да, моның, әлбәттә, алшартлары булган. Аларның беренчесе – ике гасыр арасында татар буржуазиясенең көчәюе, мал туплавы, икенчесе – татарлар арасында ныклы мәдрәсәләр системасының (ягъни мөстәкыйль татар мәгарифе!) инде гасыр дәвамында гамәлгә керүе. Гасыр башында мәдрәсәләрнең күбесендә Шиһабетдин Мәрҗани, Исмәгыйль Гаспралы кебек милләт юлбашчыларының тәэсирендә яңа ысул белән – җәдитчә укыта башлыйлар. Әлеге агым да татар әдәбиятының алга таба юнәлешенә нык йогынты ясый.

Менә инде гасырдан артык хикәя татар укучысының әдәбиятта иң яраткан жанры булып тора. Аның кыскалыгы, фикергә, сурәтләргә бай булуы биредә иң беренче шарт, билгеле. Кинаяләр, шигъриятькә хас алымнар, интрига булганда хикәянең әһәмияте, мавыктыргыч көче тагын да арта. Егерменче гасырда язылган хикәяләрнең бөтен бер панорамасын күзалдына китерер өчен үзе дә атаклы хикәяче булган Мәгъсүм Хуҗин төзеп чыгырган «Татар хикәясе антологиясе. Егерменче гасыр» (2001 ел) китабы белән

танышу да җитә. Анда йөз унсигез автор кергән. М.Хуҗин әлеге хикәяләрне өч йөздән артык авторның әсәрләре арасыннан сайлап алган. Прозаның нинди генә юнәлешендә язылган хикәяләр юк анда! Сатира да, традицион реализм да, фантасмогория дә, фәлсәфи риваять формасында язылганы да.

Шушы ук күп төрлелек XXI гасыр хикәясенә дә хас. Төрек кардәшләргә тәкъдим ителәсе әлеге антологиягә без утыз исән-сау язучының утыз хикәясен сайладык. Әлбәттә, хикәячеләр күп, ләкин китапның күләме чикле, шуңа күрә шушы жанрда аеруча танылу алган авторларның гына әсәрләрен ирештерергә мәҗбүрбез. Китапны әзерләү вакытында шуларның берсе, күренекле язучыбыз Әхәт Гаффар кинәт вафат булды. Ләкин без, кагыйдәгә хилафлык килсә дә, антологиянең эчтәлеген шул килеш калдыру дөрес булыр дигән нәтиҗәгә килдек. Мәрхүмнең рухына дога булып та барсын әлеге хезмәт.

Хәзерге татар хикәяләренең антология булып Төркиядә нәшер ителүе – татар әдәбияты өчен олы вакыйга. Әдәби багланышлардан тыш, бу әле ике тугандаш халык арасында мәдәни, иҗтимагый элемтәләрнең һаман да нык булуы турында сөйли. Яшерен-батырын түгел, аларны юкка чыгарырга теләүче көчләр дә бар. Әлеге китапны нәшер итәргә алынган «Һәҗә» нәшрияты хезмәткәрләренә, Татарстан ягыннан – шушы эшкә хәерхаһ булган иҗтимагый эшлеклеләрдән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтовка, Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зариповка ихлас рәхмәт. Рәхмәтнең иң олысы, әлбәттә, Антологиянең тәрҗемәчесе, моңарчы да уннан артык татар китабын төрек укучысына тапшырган Фатиһ Кутлуга.

Әдәби багланышларыбыз киләчәктә дә дәвам итсен, иншалла! Арабыз ерак булса да, күңелебез якын.

**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА,**
*Татарстан Язучылар берлеге рәисе.*

# ТӨРКИЯГӘ КАЗАН КҮЧТӘНӘЧЕ

Анкараның абруйлы «Һәҗә» нәшриятында «Хәзерге көн татар хикәяләре» исемле китап басылып чыгу, Төркиядә яшәгән татарлар һәм татар теленә, мәдәниятенә гашыйк төрекләр өчен гаять матур бер бүләк, тәмле күчтәнәч булып иреште. Бүгенге көндә исән-сау булган олпат әдипләребездән алып, танылып килүче яшь авторларга кадәр утыз шәхеснең берәр әсәре төрек телендә чыкты, әле быелның август аенда гына табадан төшкән китапны иң беренчеләрдән булып мин укыдым дисәм, ялгыш булмас. Ачысы да, татлысы да кергән төрле ризыклардан торган ассорти-күчтәнәч кебек, тәмләп, букеттагы һәр чәчәкне иснәгән кебек берәм-берәм укыдым ул утыз әсәрне, туган ягыбыз, халкыбыз, әдәбиятыбыз өчен горурланып, сөенеп, кайгырып укыдым. Татарстан Язучылар берлеге бик шәп проект башлаган, афәрин, дип сөендем. Авторлар Ркаил Зәйдулла тарафыннан сайлап алынса, хикәяләрен язучылар үзләре тәкъдим иткән, проект буенча әлеге әсәрләрнең рус теленә тәрҗемәләре дә бетеп килә икән инде.

Хикәяләрнең барысын да төрек теленә бер кеше – Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, татар кияве Фатиһ Кутлу тәрҗемә иткән. Әсәрләрнең бирелү тәртибе үзенчәлекле бер хронологиягә буйсынган: аларның язылу-басылу вакыты белән түгел,

ә бәлки язучыларның яшьләре искә алып төзелгән, иң өлкән язучы буларак, Рабит Батулла һәм Тәлгат Галиуллин утызлыкны «ачып» җибәрсәләр, Рөстәм Галиуллин белән Рүзәл Мөхәммәтшинның хикәяләре җыентыкны йомгаклап куйган. Һәр хикәянең азагында автор турында кыскача белешмә бирү, иҗатының кайсы әдәби бүләкләргә лаек булуын атау да бик урынлы күренә. Тукай премиясе лауреатлары гына ничә кеше кергән җыентыкка, башка әдәби премияләрне атап китү дә хәзерге татар әдәбиятының активлыгын, иҗат эшенә Татарстанда югары бәя бирелүен күрсәтеп тора.

Язучыларның яшь аермасы 1938 дән 1989 елга кадәр озын бер вакыт аралыгын үз эченә алган кебек, сайланган әсәрләрнең дә эчтәлеге, тематикасы, стиле, геройлары бер-берләреннән шактый аерылып тора: монда фаҗига да бар, уен-көлке дә, сабантуйлар, җыр-моңнар да, мәхәббәт тә... Тик шулай да күпчелек хикәяләрнең үзәгендә галиҗәнап Хәтер торуын абайлау авыр түгел: гражданнар сугышы һәм колхозлашу чорларыннан (А.Әхмәтгалиева «Әрем балы»), Сталин репрессияләре (Р.Мөхәммәдиев «Мәҗит абыйдан сәлам...»), Бөек Ватан сугышыннан (А.Хәлим «Паравыз кычкыртты», М.Галиев «Китү», В.Имамов «Яшьлек урамы», В.Нуриев «Мәһдиев һәм...», Р.Рахман «Вәриснең әтисе кайта», Ф.Яхин «Әткәй сугышны сөйли») калган моңсу, тетрәндергеч хатирәләр төрле әдәби ысуллар ярдәмендә укучыларга җиткерелә. Монда шуны искәртергә кирәк: Икенче Бөтендөнья сугышында катнашмаган Төркия өчен безнең горурлыгыбыз – Бөек Ватан сугышында казанган җиңүебез – тарих дәреслекләрендә тиешенчә аңлатылмаганга күрә, әллә ни аерым һәм зур әһәмияткә ия түгел (төрек җәмәгатьчелеге бу сугышны 1939–1945 елларында булган Бөтендөнья сугышы дип таный, шунлыктан тәрҗемәче дә берничә урында «совет-алман сугышы» (1941–1945) дип искәрмә бирергә мәҗбүр булган). Бу уңайдан төрек укучысына әлеге сугыш чорында тылдагы татар хатын-кызларының, балаларның никадәр хәсрәт һәм михнәт күрүен җыентыкта урын алган хикәяләрдәге геройларның кичерешләре аша якыннанрак аңларга мөмкинлек туар, дип өметләнергә кирәк. Кызыл яулыклы «ударник» комсомол кызлар, сугыштан соңгы татар авылларында дуңгыз фермалары белән «дан тоткан» колхозлар, агломерация сылтавы белән су астында калган авыл-салалар, нефть чыгару максатында ташландык хәлгә китерелгән уңдырышлы туфраклар, марҗаларга өйләнеп, балалары чукындырылган татар ирләре, Африка негрларына хәтле килен булып киткән кызларыбыз, наркомания баткагыннан чыга алмаган яшьләр, эчкечелектән талантын җуйган осталар, тагын безнең өчен гаять тә таныш булган, әмма төрек укучысы бер укуда ук аңлап бетерә алмаслык никадәр халәт һәм хис бар бу хикәяләрдә! Бер М.Галиевнең «Китү» хикәясенә генә никадәр драма, фаҗига сыйган, XX гасырда совет чорына хас бозыклык, динсезлек, эчкечелек, зимагурлык, сукбайлык, урыслашу, ата-анадан баш тарту кебек җәмгыяви «чирләр» белән татарларның да авыруы Нәфисә карчык язмышы аркылы әйбәт күрсәтелә. Җанга якын бу карчыкның картлар йортына «китәргә» теләмәве дә бик аңлаешлы, гомер буе «рәхәт йөзе күрмәгән», картлык көнендә ялгыз калган Нәфисә татар анасының җыелма образы булып күз алдына килеп баса. Тик әсәрнең финалы көтелмәгәнчә... белмим, төрек укучысы аны ничек кабул итәр, фәкать соңгы өмете дә сүнгәч, комсомол косынкасын элмәк итеп, үзен-үзе аскан әбинең бу эшен табигый һәм ышандырырлык дип кабул итүе авыр. Икенче бер сөйкемле татар әбисе белән Р.Зәйдулланың «Картый» хикәясендә танышабыз: урыслашып баручы оныкасына бер җәйдә Аллаһы Тәгаләне һәм ислам динен яраттыра алган карт абыстай инде җан тынычлыгы белән ахирәткә китә, бу да бер батырлык безнең өчен хәзер...

Гаиләдәге тигезсезлек, көнчелек, хатынга кул күтәрү, баланы анадан аеру, ятларга киткән сөйгән яр темаларына язылган хикәяләр (Х.Ибраһим «Арыш арасыннан йөгерүче бала», Р.Габделхакова «Яңгырдан соң», Л.Лерон «Ир хакы», Ә.Гаффар «Карачкылар»(Әхәт абый, ни кызганыч, эш барышында мәңгелеккә күчкән, урыны җәннәттә булсын!) төрек укучысының күңеленә хуш килер дип уйлыйм, чөнки бу

проблемалар төрек тормышында һаман көн кадагыннан төшми, ире тарафыннан үтерелгән хатыннарның саны бүген дә кимеми...

«Һәр авылның үз юләре була», диләр төрекләр, татарча ике хикәядә (Ф.Җамалетдинова «Кеше күңеле – кара урман», Р.Галиуллин «Дивана») акылга җиңел баш каһарманнар – гашыйк Пәттери һәм чәчәкләр белән сердәш Дивана – күңелләре белән нормаль кешеләр белән чагыштырганда, үтә нечкә хисле, чиста һәм баерак итеп сурәтләнгән. Нәкъ шундый ук хәл «кеше үтерүче» даны таралган Госманның авылдашларына миһербанлык сабагы бирү вакыйгасында да күренә (Г.Гыйльманов «Авылдаш»). Бу әсәрләрне дә төрек укучысының яратып кабул итәчәгенә шик юк.

Китапта күңел күтәрердәй, җиңелрәк укылышлы әсәрләр арасыннан Л.Зөлкарнәйнең Сабантуй темасына иҗат ителгән лирик «Хушлашу сүзе» (тәрҗемәдә «Әлвида»), Т.Галиуллинның мәктәп, укучы-укытучы темасына язылган «Кысыр хәсрәт», Ф.Садриевның «Соңгы дәрес», З.Хөсниярның үз хезмәтен җыр иткән хирургларга мәдхия рәвешендәге «Доктор Байчурин»ы, онык белән бабайның күңелле мөнәсәбәтләре тасвирланган Р.Сабырның «Гәрәшәй түбәсе», шулай ук К.Кәримовның юмористик эчтәлекле «Карурманда кара песи», З.Хәкимнең «Наркокурьер» хикәяләрен күрсәтергә була. Замана яшьләре (Р.Мөхәммәтшин «Мин дә үләрмен әле», М.Закир «Карбыз»), сәнгать әһелләре (Р.Батулла «Җаныңны ярып бир!»), экстрасенслар (М.Кәбиров «Йөрәк»), баеп та, халкына бер тамчы ярдәм итмәгән яңа татар түрәләре (Н.Гыйматдинова «Түрә»), баласын аңлы рәвештә татар мохитеннән саклап үстергән яңа татар байлары (Р.Сәгъди «Корыган алмагач»), авыл табигате өчен борчылучы шәһәр ханымнары (Ф.Сафин «Кисмәгез каеннарны») сурәтләнгән хикәяләр дә татар тарихын, халыкның көнкүрешен бик белмәгән төрек укучысы өчен, һичшиксез, бай материал бирә, җанлы тормыш вакыйгалары халкыбызның психологиясен, авыр, борчулы үткәнен һәм бик тә җиңел булмаган бүгенгесен аңлау мөмкинлеге тудыра.

Егерме еллап Татарстанда яшәп, безнең яшәешебезнең эчен-тышын яхшы таныган, инде әдәби тәрҗемә өлкәсендә шактый тәҗрибә туплаган Фатиһ Кутлуның бу яңа хезмәте, чынлап та, мактауга лаек, студент чагында «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н кочагыннан төшерми йөрүе бушка булмаган икән, көннән-көн осталыгы арта, каләме шомара бара, күз тимәсен. Монда Фатиһ әфәнденең Татарстан Язучылар берлеге өчен зур бер табыш булуын да танымый мөмкин түгел (тагын кайсы берлектә шундый оригиналь әгъза бар?!). Тәрҗемә эшендә җиңел юлдан китмичә, язучы фикерен, халык җырларын (алар җыентыкта аз түгел!) биргәндә, әдәби камиллеккә омтылышы, туган телендәге сирәк кулланыла торган сүз һәм әйтемнәрне дә кертеп җибәрүе, безнең җирлектәге агач, чәчәк, үлән исемнәренең төрекчә эквивалентларын таба алуы күренә. Әйтик, безнең яклардагы әрсез, сөйкемсез, әмма ачлыкта оныннан икмәк пешерелгән алабута Төркиядә бик таралмаган, җыентыкны укучы аның «сиркән» дип аталуын, бар чиргә дәва мәтрүшкәнең «гүвә оту (көя үләне)» икәнен инде белеп калыр. Ф.Сафинның «Кисмәгез каеннарны» әсәрен «Кисмәгез хушларны» дип бирүен күргәч, мин хәтта аптырап куйдым, чөнки каен сүзенең төрек телендә дә бар икәнен белә идем, тик сүзлеккә кереп киткәч, ул каен белән бу каенның бер түгел икәнен күрдем: баксаң, сагыну-сагыш символы каеныбызның төрекчәсе хуш икән бит, хушлашу, хуш, сау бул мәгънәсенә ни кадәр якын. Тәрҗемәченең иң уңышлы табышларыннан берсе А.Хәлимнең «Паравыз кычкыртты» әсәрендә ачык күренә: Тәнзиләне сөйгәне Газинурдан гомерлеккә аерган, ирен сугышка алып киткән паровоз, Ф.Кутлу тарафыннан «кара терән/поезд» дип тәрҗемә ителгән, төрек халык җырларында аерылышуның асыл символы булып торган кара поезд хикәядәге хис-тойгыны тагын да көчәйтеп кенә калмый, әсәрне төрек аһәңенә аеруча якынайта. Тагын гаять матур бер мисалны Л.Зөлкарнәйнең Казан сөлгесенә мактау җырлаган әсәренең тәрҗемәсеннән китерергә була: төрек телендә бит сөртә торган тастымал өчен кулланыла торган «хавлу» сүзе белән бирми Ф.Кутлу ул «җан юлдашым

сөлгене» – үзендә ниндидер сер саклаган пәшкир сүзен китерә, астөшермәдә дә бу сөлгенең үзенчәлекләрен, эшләнешен аңлата. Үзем өчен ачкан бу яңалыклар, төрекләр әйтмешли, бигрәк тә «һушыма китте». Гомумән, тәрҗемәче, астөшермәләрдә искәрмәләр биреп, төрек укучысын шактый күп тарихи-этнографик белешмәләр белән тәэмин итү юлын иркен кулланган.

Җыентыктагы кеше исемнәренең төрекчә бирелү рәвешенә аерым тукталасы килә: Төркиядә, гадәттә, татарча исемнәрне «төрекләштереп» укырга яраталар, әйтик, Габдулла Тукайны – Абдуллах Тукай дип, Гаяз Исхакыйны – Аяз Исхаки дип әйтәләр һәм язалар, әмма бу бер дә дөрес түгел кебек, минемчә. Русларның Иван Бунинын Көнбатышта Иоан Бунин дип, яки Джон Смитны русча Иван Смит дип бирми бит беркем дә?! Гарәп теленнән кергән «каты г» авазын төрек телендә әйтеп маташмау, Госманны Осман, Галине Али дип әйтү безнең очракта аеруча дөрес була алмый, мәсәлән, Тәлгат Галиуллин исемен Талат Алиуллин, Галимҗан Гыйльмановны Алимҗан Илманов дип язу бер кысага да сыймас иде (русча бозганнары гына җитмәгән, төрекчә дә бозылсынмы безнең исемнәр?!). Бу бәхәсле мәсьәләгә тирән кермичә генә, шуны әйтәсем килә: Ф.Кутлу язучыларның һәм әсәрләрдәге персонаж исемнәрен татарча калдырырга тырышкан, моның өчен аерым рәхмәт үзенә. Исем дигәннән, тагын бер проблеманы күтәрмичә булмый: безнең кайбер исемнәребезнең мәгънәләре, «төрекчәләштереп» укыганда, ямьсез якка үзгәреп китә икән бит: әйтик, хикәяләрдә очраган исемнәрдән Вәрис/Варис – варикоз, Рәзил/Рәзилә – оят, хурлык, Энгель – комачау, инвалидлыкны аңлата. Моның кебек тагын Мирумир, Октябрина түтәй, Ганс абзыйның кызы Эльза, Ирис һ.б.ларны ничек итеп бирергә белмәгән тәрҗемәче кайсын шул килеш калдырган, кайсының хәрефен үзгәрткән: Энгил, кайсысын сүзгә-сүз «аударган»: Октябрина-Әкимийә/Әкимә. Бу исемнәрнең күпчелеге К.Кәримовның «Карурманда кара песи» хикәясендә кулланылган булып, авторның максатларыннан берсе халкыбызда яңа туган балага шаккатыргыч, ә чынлыкта тузга язмаган исем тагу гадәтен чеметкәләп алу булса да, төрекчә тәрҗемәдә бу тәнкыйди караш бик үк аңлашылып бетми кала, укып-аңлап бетереп булмый торган исем-сүзләр өеменә әверелә. Җитмәсә, әсәр эчендәге «порнуха, киллер, гастарбайтер, матальщик» кебек матавыклы сүзләрнең урынсызлыгы текстны авырайта, әле ярый, тавык йомыркасы эчеп йөрүче карак песинең «батырлыклары» бу кимчелекләрне басып китә. Боларның барысын тәрҗемәченең эше бер дә җиңел булмавын аңлатыр өчен әйтеп китәм, хәер, Ф.Кутлу үзе дә китапка язган кереш сүзендә бу турыда телгә ала.

Үз хезмәтен Ф.Кутлу «Горбәтне үзләренә ватан иткән, ватан аларга горбәткә әверелгән Төркияле татарларга» багышлаган. «Горбәт» сүзен «туган илдән еракта калу, читтә йөрү» дип аңласак, Акчуралар, Исхакыйлар, Куратлар һәм башка бөекләребез генә түгел, Төркиягә күченеп китәргә мәҗбүр булган ни кадәр гади татар кешесенең шунда яңа ватан табуын, ничәмә-ничә буын үстерүен, телен, милли кемлеген сакларга тырышып яшәвен искә алыйк. Җитмәсә, бүген горбәткә чыгучылар, тугандаш Төркиягә килеп сыенучы татарларның саны бермә-бер артты, ахыры хәерле булсын. Төсле бизәкләрдән торган мозаика кебек, укучысын үзенә җәлеп итеп торган «Хәзерге татар хикәяләре» китабы – татар әдәбиятының кечкенә генә бер парчасы, горбәттәге милләттәшләребезгә дә бер юаныч, сәлам, Казан күчтәнәче булып ирешсен. Бу төр проектларның дәвамы күп булсын, татар әдәбияты үссен, баесын, чит илләрдә, башка телләрдә дә танытылсын, укылсын, таралсын иде дигән теләктә калам.

**Әлфинә СИБГАТУЛЛИНА.**




*«Безнең юл» журналының актив авторлары: Кави Нәҗми, Фатих Сәйфи-Казанлы, Гомәр Гали, Мәхмүт Макъсуд, Нигъмәт Хәким, Шәриф Камал, Һади Такташ һ.б. 1926 ел.*



*«Казан утлары»нда Өлкәннәр көне. Алгы рәттә (сулдан уңга): Вакыйф Нуриев, Мансур Вәлиев, Рәдиф Гаташ, Рашат Низамиев, Рәфикъ Юныс, Камил Кәримов, Флёра Сабирова; арткы рәттә: Лилия Вагыйзова, Айсылу Имамиева, Ландыш Әбүдәрова, Рөстәм Галиуллин, Элеонора Җамалиева, Лилия Гатауллина, Фәнил Гыйләҗев. 2020 ел.*



*Зөфәр Рәмиев белән Резеда Ганиева. Бу айда әдәбият галиме, профессор Резеда Ганиевага 90 яшь тулган булыр иде.*



*Зөфәр Фәтхетдинов (1940–2019) – хокук белгече, язучы.*



*Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев һәм мәдәният министры Зилә Вәлиева (бу айда Зилә Рәхимҗан кызы 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтә) Татарстан Язучылар берлегенә килгәч. М.Шәймиев янында Илфак Ибраһимов (ул вакытта Язучылар берлеге рәисе) белән Нәбирә Гыйматдинова. 2009 ел.*

# XVI ГАСЫРНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫ – XVIII ЙӨЗНЕҢ УРТАСЫНДА ИДЕЛ-УРАЛ ТӨБӘГЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕ

## 5. Тарикатьләр

Ханлык чорындагы рәсми ислам институтлары, мәчет һәм мәдрәсәләр җимерелгәч һәм дәүләтнең, һәм аксөякләрнең матди ярдәме тукталгач, мөселманнарның рухи тормышында суфилар мөһим роль уйный башлый. Дини практика, нигездә, шәхси характерда булып, гаиләгә күчә. Җәмгыятьтә хөкем сөргән пессимизм рухы, көчләп чукындырудан курку, халыкта таралган төрле сүзләр, кайгы-борчулар күп булу, башка сәбәпләр белән суфиларның халык арасында йогынтысы арта.

Бу гасырларда Урта Идел төбәгендә Нәкышбәндия тарикате өстенлек иткән. «Башка тарикатьләрдән аермалы буларак, нәкышбәндиләр һөнәр белүне, үз икмәгеңне эшләп табуны пропагандалаганнар. Зикер әйтү формасы тавышсыз, тыныч (зикр-и һафи) булганга, һәр төрле эшне башкарганда, күңелне Аллаһ хозурында тоту өчен өзлексез зикер әйтү бурычы ансатрак үтәлгән. Нәкышбәндияләрнең традицион классик киемнәре ак чалма, ап-ак өс киеме, сары аяк кием, билгә кушак бәйләү булган», дип ассызыклый профессор Ә.Сибгатуллина (*Сибгатуллина Ә. Татар әдәбияты һәм суфичылык // Суфизм в Поволжье: история и специфика. (Материалы круглого стола, организованного Центром Исламской культуры «Иман»). Казань, 2000. 93 б.).*

Суфи шагыйрьләр иҗатында югары әхлак сыйфатлары, аерым кешенең Аллага якынаюы, индивидуализмга корылган дини хисләр турында сөйләнә. Әмма XVII гасырда суфи шагыйрь Мәүла Колый беренче булып мөселман җәмгыятен уятырлык, аны активлыкка, берләшүгә өндәгән фикерләрне дә яңгырата.

«Мәүла Колый» шагыйрьнең тәхәллүсе булып, аның чын исеме турында әдәбият галимнәре арасында төрле фикерләр әйтелде. Шунысы тәгаен билгеле: ул Казан тирәсендәге авылларның берсендә туып үскән. Мәүла Колыйның остазы Мамай мулла Казанда имам булып торган, ул да – Нәкышбәндия тарикате тарафдары, Болгар шәһәрлеге хәрабәләре янында Бәләм Хуҗа һәм башка шәехләр хөрмәтенә астана төзеткән.

Шагыйрь бер хикмәтендә үзенең остазы (пир) Мәхмүд Әгъзам (1464–1542) нәселеннән дип искә ала. Мәхмүд Әгъзамның Сәмәрканд каласыннан булуын, ә мөридләренең бик күп төбәкләрдән, шул исәптән Болгар һәм Казаннан икәнлеген ассызыклый. Күренекле сәясәтче һәм рухани Мәхмүд Әгъзам үзенең хезмәтләрендә Нәкышбәндия тарикатенең сәяси линиясен тасвирлап, тарикат җитәкчесенең илбашына начарлык теләмәвен һәм шәригать кануннары буенча яшәргә тиешлеген билгели *(Идиатуллина Г. Развитие татарской общественной мысли в XVIII в. // Восстание под предводительством Батырши и общественно-культурная ситуация*

---

*Ахыры. Башы 8, 9 нчы саннарда.*

*в татарском обществе в XVIII в. Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2007. С. 21).*

Н.П. Рычков 1760 еллар азагында Биләр шәһәрлеге тирәсендә җәй көннәрендә төркем-төркем «башкортлар» һәм мөселманнар җыелуын һәм борынгы таш хәрабәләрдә гыйбадәт кылуларын күзәтә (*Рычков П.И. Журнал или дневные записки путешествия капитана Рычкова по разным провинциям Российского государства 1769 и 1770 году. СПб., 1770. С. 5).*

Мәүла Колый 1678 елда бер төркем Казан өязе ясаклы татарлары белән Биләр шәһәрлеге калдыклары янына күченеп килгән һәм шунда авыл җәмгыяте оештырып, иген игеп яши башлаган. Күрәсең, Биләр шәһәрлегенә әрвахлар рухларына гыйбадәт кылырга килү үзенә күрә бер хәрәкәт төсен ала башлагач, 1699 елда патша хакимияте аларны куып тарата *(Дәүләтшин К. Мәүла Колый // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда / [төз. Р.Ф.Рахмани]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 241-266 б.).*

Шагыйрь үзенең «Береккәннәр сыйфаты» исемле поэмасында ир белән хатын арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне һәм аларның кыен хәлдән котылуларын тасвирлаганнан соң, дин кардәшләренә мөрәҗәгать итеп, тормыш кыенлыкларын җиңәр өчен берләшергә, бердәм булырга кирәк, дигән яңа шигарь ташлый:

*Акыллы адәм берләшеп берлек кыла,*
*Хак рәхмәте берлектә якын була.*
*Кил, йә, мөэмин, берләшеп кыл һәр эшне,*
*Хакның рәхмәтенә ирешә ул кеше.*
*Берләшкәннәр сыйфатын әйттем сезгә,*
*Берләшкән эш иминдер сезгә-безгә.*
*Хак рәхмәте берлектә хасил була,*
*Берләшеп гыйбадәт кылган рәхмәтле була.*

*(Мәүла Колый поэмалары: «Береккәннәр сыйфаты» «Хәләл нәфәка эстәгәннәр сыйфаты» / төз. Мәрданов Р.Ф. Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2008. 51 б.).*

Татарларның рухи башкалалары да булган Биләр, Болгар шәһәрлекләре, күрәсең, шул заман укымышлылары тарафыннан мөстәкыйльлеген югалтканнан соң таркалган җәмгыятьне берләштерерлек символлар итеп күзалланган. Мәүла Колыйның Биләр тирәсендә фикерле кешеләр белән бергәләп урнашуын, шунда халыкның тартылуын – әлеге күзаллауның бер чагылышы дип карарга кирәк. Батыршаның 1755 елда төзелгән «Тәхризнамә» исемле халыкка өндәмәсендә исә Идел-Урал төбәгендә яшәгән дин кардәшләре «Болгари мөселманнар» дип атала (*Тәхризнамә (Батыршаның халыкка өндәмәсе) // Восстание под предводительством Батырши и общественно-культурная ситуация в татарском обществе в XVIII в. Казань, 2007. 199 б.)*. Батырша русларны «Шәһремез мәгъмүр Болгарны хараб» кылуда гаепли *(Шунда ук. 203 б.).* А.Франк бик төгәл язганча, Батырша җитәкчелегендәге баш күтәрү болгарчылыкка сәяси төсмер бирә.

1755 елда Батырша «ислам кылычын күтәреп» (*Тәхризнамә (Батыршаның халыкка өндәмәсе) // Восстание под предводительством Батырши и общественно-культурная ситуация в татарском обществе в XVIII в. Казань, 2007. 204 б.),* мөселманнарны самодержавие-чиркәү хакимиятеннән, рус чиновникларының башбаштаклыгыннан һәм ришвәтчелегеннән, чукындырудан якларга өнди. Батырша самодержавиенең салымнар җыю белән генә канәгатьләнмичә, мөселманнарның эчке эшләренә кысылмау турындагы вәгъдәсен үтәмәвен, мөселманнарны көчләп чукындыру кампаниясе ассимиляцияләүгә хезмәт итүен ачык күрә. Ислам динен яклау баш күтәрүчеләрнең байрагына әверелергә, күтәрелеш бик зур җирләрне – Урта Идел, Урал буен һәм Көнбатыш Себерне иңләп алырга тиеш була. Хакимият Батыршаның мөселман этник

төркемнәрен берләштереп, бик зур территорияне хөкүмәт контроленнән чыгарачагын яхшы аңлый.

1755 елгы Батырша җитәкчелегендәге кузгалыш тиз бастырылса да, Россия сәясииҗтимагый тормышындагы бу яңа күренеш – көньяк-көнчыгыш чик буе өлкәләрендә исламны яклау идеологиясе астында руханилар җитәкчелегендә татар, башкорт, казакъларны берләштереп, корал тотып дәүләткә каршы чыгу, мөселман дәүләте төзү омтылышы империя хакимиятен хафага төшерә.

…Һиндстанда, Бабур заманында Мәвараэннәһердән килгән Нәкышбәндия тарикатенең бер тармагы буларак, Әхмәд Фарук Сирхинди (1563-1624) нигез салган Мөҗәддидия тарикате киң тарала. Сирхиндинең фикерләре Коръәнгә һәм Сөннәгә нигезләнә. Бу гыйлемне Бохарага XVII гасыр азагында шәех Хәбибуллаһ Бохари алып кайта (1699-1700 елда вафат). Хәбибуллаһ шәех, Урта Азиядән килеп, беркадәр вакыт Казанда яшәгән һәм күп кенә трактатлар язган мәшһүр Суфи Аллаһиярның (1720 елда вафат) да мөршиде була. Урта Азиядә укыган татар егетләре, Мөҗәддидия тарикате суфилары буларак, XVIII гасырда туган илләрендә актив рәвештә Сирхинди фикерләрен тарата башлыйлар. Шул рәвешле, чит илләр белән дини һәм мәдәни элемтәләр көчәя башлагач, XVIII йөздә Урта Идел буенда Нәкышбәндия тарикатенең яңа бер тармагы популярлаша.

## 6. «Болгар мөселман җәмгыяте» концепциясе

XVII–XVIII гасырлар дәвамында төбәктә яшәгән суфилар «Болгар мөселман җәмгыяте» концепциясен формалаштыралар. Алда язылачак XVII йөзнең икенче яртысында Юныс бине Иванай ахун биргән фәтвада «Болгар җире» турында сүз бара.

Болгар мирасы һәм Болгардан килгән ислам традициясе турында мәгълүмат моның белән чикләнмичә, ул бүгенге көндә сакланып калган берничә шәҗәрәдә теркәлгән. Бу шәҗәрә хуҗаларының нәсел башлары болгарларга барып тоташа.

Болгар турында тарихи хәтернең тагын бер әһәмиятле һәм тәэсирле матди чагылышы һәм чыганагы булып, Болгар шәһәрлегендә сакланып калган биналарның хәрабәләре, төрбәләр, мәчет манаралары һ.б. торган. Алар Алтын Урда чорында төзелгән булсалар да, мөселманнар фикеренчә, Болгар рухи мирасының дәвамчанлыгын гәүдәләндергәннәр. Шуңа күрә XVII гасырда шул төрбәләрдә һәм мөселман зиратында җирләнгән әрвахларга дога кылу өчен килгәннәр.

Болгар шәһәрлеге тирәсендә мөселманнарның дини активлыгы хакимиятне дә борчый. 1712 еллар тирәсендә биредә Успен православие монастыре оештыру һәм аңа җир бүлеп бирү шушы ислам дини активлыгын киметү һәм мөселманнарны биздерү өчен эшләнгәне шик тудырмый. 1722 елның май аенда Идел буйлап Казанга таба йөзеп килүче Пётр I Болгар хәрабәләрен карарга туктагач, биредә әрвахларга дога кылырга килгән мөселманнар төркемнәренә юлыга.

Болгарчылык идеяләре таралышының тагын бер мисалы *Морад мулла, төгәлрәк әйтсәк, аның Кама аръягында халык арасында таралган кулъязмалары белән бәйле.* Мулла Морад – хәзерге Самара губернасының Гали авылында туып, шунда яшәгән дин һәм җәмәгать эшлеклесе Морадбакый Ишали улы; ул якынча 1735-1740 елларда дөньяга килгән һәм XVIII гасыр ахыры – XIX йөз башында вафат булган *(Мәрданов Р. Кем ул Морад мулла? // Безнең мирас. 2015. №3. 33-34 б.*).

Мулла Морад *дин кардәшләрен Болгар шәһәрлегенә мәчет салырга һәм Болгарны торгызырга өнди. Биредә сүз Урта Идел буендагы Болгар дәүләтен торгызу түгел, ә рухи һәм дини Болгарны торгызу турында бара (Валиуллин И. Мурад мулла (XVIII в.) // Татарские интеллектуалы. Исторические портреты. Казань: Изд-во «Магариф», 2005. С.9-10).*

Мулла Морад фикерләре йогынтысында 1769 елда Уфа өязенең өч мең мөселманы

Болгар шәһәрлегенә барып, күмәк гыйбадәт кылу уздыралар. Шуннан соң мулла кулга алынып, Оренбург губернасы җитәкчелеге каршына китерелә. 1771 елны аңа карата башланган мәхкәмә тикшерүе Санкт-Петербургка күчерелә. Екатерина II Сенатка мулла Морадны – гаепсез, әмма акылына зыян килгән дип игълан итәргә боера һәм туган иленә кайтарып җибәрә.

1773–1775 елларда Е.Пугачёв җитәкчелегендә баш күтәрү башлангач, мулла Морад яклы мөселманнар восстаниегә кушылып китәләр *(Франк Аллен Дж. Күрс. хезмәт. 64-65 б).*

«Болгар мөселман җәмгыяте» концепциясенең төп нигезләмәләре Хисаметдин бине Шәрәфетдин Болгари-Мөслиминең «Тәварихы Болгария» (Болгар тарихы) хезмәтендә бәян ителә. Ш.Мәрҗани «Мөстафад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр) исемле хезмәтендә бу китапны кискен тәнкыйтьли, анда язылган тарихи фактларның чынбарлыкка туры килмәвен раслый, язылу вакытын 1785 елдан соң дигән фараз әйтә, М.Госманов XVIII–XIX гасырлар чигендә язылган дип төгәлләштерә. Тел галиме В.Хаков исә, текстның тел үзенчәлекләрен өйрәнеп, аның башы һәм ахыры – XVI яки XVII гасырда, калган өлешләре соңрак чорда язылган дигән фикер белдерә.

1993 елда Ә.Хәйри тарафыннан әзерләп нәшер ителгән Р.Фәхреддиннең ««Болгар вә Казан төрекләре» әсәренә кушымта» исемле кульязмасында бу хакта кызыклы һәм игътибарга лаеклы түбәндәге фаразлар әйтелә. 1) «Китап Тәфтазани (1353 елда Гөлстанда вафат булган әдип) хозурында укып кайтучы бер галим тарафыннан язылган да, нөсхәсе сирәк очрый торган, көч куймый гына килгән мал дип белеп, икенче бер җилкуар адәм ия булган һәм китапны теләгәнчә үзгәрткән яки бозган». 2) «Китап тарихчы булмаган кеше тарафыннан төзелгән булу сәбәпле, ул күзенә төшкән һәрбер язуны, картлар вә хатын-кызлар арасында таралган һәрбер хәбәрне нәтиҗә ясамыйча, хөкем чыгармыйча теркәгән». 3) «Китап бер генә кеше әсәре түгел, арттырылып вә кушылып язылган җыентык. Шул бер адәм китап рәвешенә китереп күчергән генә». 4) «Китапны язучы Бохара, Сәмәркандларда йөргән вә тәкиййәләрендә гомер сөргән мөридләрдән ишеткән сүзләрен иләми вә җилгәрми язып барган. Соңыннан бу мәмләкәткә кайтып, төрле җирләрдә тәбарәк вә фатихачы, ягъни Коръән укучы булып йөргән дә ахырында Болгарда күрше булып торган вә шундагы күршеләрдән ишеткән сүзләрен һәммәсен дә язган» *(Фәхреддин Р. Казан вә Болгар төрекләре. 59 б.*).

Соңгы берничә дистә елда татар тарихчылары, Мөслиминең болгарчылык концепциясен этник нигезгә күчереп, бик нык тәнкыйть иттеләр. Аллен Франк һәм М.Кемпер исә суфи Мөслими язган әсәрдә этник болгарчылык түгел, ә дини болгарчылык хакында сүз бара дип, аларны төзәтте.

Болгарчылык концепциясенең нигезен легендар характердагы тарих тәшкил итә. Имеш, Болгарда Айдар хан идарә иткән заманда Мөхәммәд пәйгамбәрнең өч сәхабәсе – Габдрахман бине Зөбәер, Зөбәер бине Җәгъдә һәм Талха бине Госман – шәһәргә килеп, үзләрен табиб дип күрсәтеп, кешеләрне дәвалап йөриләр. Айдар ханның кызы Туйбикә паралич авыруы белән чирли башлагач, ханның күз алдында могҗиза белән каен үстереп, дәвалап, кызны терелтәләр. Ислам диненең көченә ышанып, хан мөселманлыкка чыга. Сәхабәләр Болгарда өч ел дәвамында халыкка Корьәнне, дин һәм шәригать кануннарын өйрәтә һәм Җәмигъ мәчете төзетеп, анда җәмәгать намазларын укыта. Халыкны ныклап ислам диненә күндергәч, ике сәхабә кире Мәдинә шәһәренә кайтып китә, Зөбәер бине Җәгъдә исә, хан кызы Туйбикәгә өйләнеп, Болгарда яшәп кала. 25 ел гомер итеп, Болгарда вафат була *(Франк Аллен Дж. Күрс. хезмәт. 143-144 б.)*.

Мөслими хезмәтендә сәхабәләрдә белем алган һәм төрбәләре шәһри Болгарда булган 33 ир-ат (*Шунда ук. 144-145 б.*), каберләре билгесез сәхабәләрдән Коръән өйрәнгән һәм исемнәре сакланып калган 19 хатын-кыз (*Шунда ук. 148 б.*) табигыйннар

(табигыйннар заманасы Мөхәммәд пәйгамбәр вафатыннан соң (һиҗри буенча 11 ел) башланып, һиҗри 180 елда тәмамлана, аларның мирасы ислам хокукы формалашуда мөһим этапны тәшкил иткән, чөнки сүзләре Коръән, Сөннәт һәм сәхабәләрдән соң дүртенче урында торган) атала.

«Болгар өлкәләрендәге табигыйннар турында фасыл» дигән бүлектә Болгар каласына, сәхабәләр янына килеп белем алган табигыйннар исемнәре һәм алар килгән төбәкләр саналып чыгыла: «Башкорт» дигән кабиләдән, «Өфе Иделеннән», Агыйдел, Дим суы, Ак суы, Кичү суы, Чушым суы, Шушма суы, Казан суы, Чирмешән суы, Минзәлә елгасы, Туйма елгасы буйларыннан, Зөя тамагыннан һ.б.

Аннан соңгы бүлектә Болгардан чыккан табигыйннар язган хезмәтләр, аларның кайберләренең Сәмәркандка һәм Багдадка китүләре, шунда исламга хезмәт итүләре шәрехләнә.

«Болгарда изге шәехләр һәм бөек әүлияләр турындагы фасыл»да Урта Идел төбәгендә яшәгән Хуҗа Әхмәд Ясәвидән һәм башка күренекле шәехләрдә белем алган шәхесләрнең исемнәре атала, каберләренең Идел-Урал һәм Себер төбәгендә икәнлеге хәбәр ителә.

Аксак Тимер, Болгарны һәм Кашанны җимергәч (Мәрҗани бу факт тарихи чыганаклар белән расланмый дип каршы төшә. – *И.З.*), Мәскәүгә таба яуга кузгала, ләкин Владимир каласын җимергәч, киңәшчесе булган Мир Тимер хәзрәт күргән төш нигезендә (төшенә Хызыр галәйһиссәлам кереп, «Аллаһтан сиңа Мәскәү йортын дингә өндәргә әмер юк», дигән сүз әйтә), октябрь азагында Сәмәркандка кайтырга чыга һәм кышны (ике ай) гаскәре белән Яңа Казан каласында һәм тирә-як авылларда уздыра. Туктап торган вакытында Аксак Тимер һәм Мир Тимер хәзрәт табигыйннарның каберләрен зиярәт итеп йөриләр. Якын төрбәләргә үзләре баралар, ерактагыларына (мәсәлән, Зәй тамагына) Яңа Казаннан торып зиярәт кылалар. Китапта Аксак Тимер яки Мир Тимер хәзрәт зиярәт кылган табигыйннар исемнәре китерелә. Аларның да саны берничә дистә.

Шулай итеп, күпсанлы табигыйннар каберләре Идел-Урал төбәгендә ислам диненең Болгар каласыннан, бирегә килгән өч сәхабәдән таралганын раслый, шул рәвешле аның борынгылыгын дәлилли, Идел-Урал төбәгендәге ислам тарихын Мөхәммәд пәйгамбәр заманына кадәр олыгайта, аның дәрәҗәсен югары күтәрә, башка борынгы ислам мәдәнияте төбәкләре белән тиңдәш итә. Бу каберлекләрнең саклануы, шуларның бер өлешен дөньякүләм танылган хәрби җитәкче һәм дәүләт эшлеклесе Аксак Тимернең зиярәт итүе Идел-Урал төбәгендә ислам диненең Болгардан таралу тарихына чынбарлык төсмерләре өсти.

Р.Фәхреддин Хисаметдин бине Шәрәфетдин Болгари-Мөслиминең «Тәварихы Болгария» хезмәтендә табигыйннар хакында төгәл мәгълүматлар язылуны түбәндәгечә фаразлый: «Болгар шәһәре җимерелгәннән соң һәм әһле исламның хөкүмәт мәркәзе Казанга күчкәннән соң да, Болгар зиярәтчеләре белән тулы вә олуг бер мөселманнар җыела торган урын булып дәвам иткән. Хаҗилар өчен рәсми юл күрсәтүчеләр булган кебек, Болгарга зиярәт кылырга килүчеләргә ярдәмләшү өчен арадашчылар булган. Арадашлык итүчеләр зиярәт өчен килүчеләрне үзләренең хосусый дәфтәрләренә язып барганнар. Кайсы өлкәдән килүләре, ир яки хатынмы икәнен – һәммәсен тәфсилләп язу гадәт булган. Бу хәл русларның Казанны басып алуларына вә Болгарда булган борынгы һәйкәлләрне җимерүләренә, ислам халкын аннан куып, русларны урнаштыруларына кадәр дәвам иткән. Зиярәт кылучы ирләр вә хатыннарның исемнәре язылган дәфтәрләрдән күренгәнчә, соңыннан алар сәхабәләрдән дин өйрәнергә килүче иярчен ирләр вә хатын-кызлар булып шөһрәт тапканнар. Сәхабәләрнең Болгарда олуг галимнәрнең каберләре булу турында хәбәре вә шуның кебек риваятьләрнең күбесе Болгарда булган күршеләр вә зиярәт кылдырып йөрүче арадашчылар тарафыннан халыкны җәлеп итәр өчен уйлап чыгарылган нәрсәләр булып, халык арасында таралган». *(Фәхреддин Р. Казан вә Болгар төрекләре. 60 б.).*

Күренекле галим М.Әхмәтҗанов хәзерге Минзәлә районы Калморза авылы янындагы ике изгеләр каберендә XVII гасыр ахырында вафат булган татар морзалары күмелгәнлекне язып чыккан иде *(Ахметзянов М. Письменные источники по истории суфизма у татарского народа // Суфизм в Поволжье: история и специфика. (Материалы круглого стола, организованного Центром исламской культуры «Иман»). Казань, 2000. С. 7).*

Яшь тарихчы И.Ф.Шәфиков бүгенге Зәй районы җирлегендәге табигыйннар исемнәре шул каберләр янындагы авыллар, авылларга нигез салган кешеләр исемнәре яки янәшәдә агучы елга атамасы булган дигән кызыклы фараз әйтә *(Легенда о сахабах в Булгаре: конструирование прошлого или продукт народного творчества?* (*https://milliard.tatar/news/legenda-o-saxabax-v-bulgare-konstruirovanie-proslogo-ili-produkt-narodnogo-tvorcestva-1351, карау датасы – 15.03.2022*).

Күрәбез, суфилар төрле төбәкләрдә изгеләр каберлекләре «булдырып», алар янына якын-тирә авыллардан килеп, даими рәвештә гыйбадәт кылуны тәэмин иткәннәр, шулай гади халыкның дини активлыгын арттырганнар. Һәр төбәктә табигыйннар каберләре «барлыкка килгәч», күп вакыт һәм беркадәр матди чыгымнар сораган гамәл: Болгар хәрабәләренә барып, андагы табигыйннар каберләрен зиярәт кылу ихтыяҗы кими.

Шул рәвешле, Идел-Урал төбәгендә Нәкышбәндия тарикате суфилары динне Мөхәммәд пәйгамбәр сәхабәләреннән кабул итү фикерен үзәккә куеп, мөселманнарның дини болгарчылык үзаңын формалаштыралар.

## 7. XVIII гасыр уртасында Идел-Урал төбәге мөселманнарының дини ихтыяҗлары

Ш.Мәрҗани Идел-Чулман төбәгендә XVI гасырның икенче яртысыннан башлап формалашкан дини вазгыятьне түбәндәге сүзләр белән тасвирлый: «Казан Россия составына кергәч, мөселманнарның дин һәм дөнья эшләренә комачаулык һәм кысынкылыклар булмый. Татар арасында туган дәгъва һәм низагларны, мәеттән калган малны бүлү һәм васыятьләрне үз меллалары һәм олылары җиренә җиткереп хәл кылалар. Теләгән җиргә һәм теләгән рәвештә мәчет, мәктәп һәм мәдрәсәләр бина кылганнар. Кемне ихтыяр итсәләр, әгәр риза булса, имам иткәннәр. Имамнарны кире кагуга да мәхәллә һәм авыл халкы мөстәкыйль булган. Балаларга исем бирү, өйләнү, мәетләрне күмүдә һәркем үз ихтыярында булып, моңа беркем дә булса читтән катнашмаган, ягъни Россия дәүләте бу эшләргә һичнинди каршылык кылмаган» *(Мәрҗани Ш. Курс. хезмәт. 200 б.*)

Ш.Мәрҗанинең бу фикеренә 1767 елда язылган Идел-Урал төбәге мөселманнарының гаризалары шактый төгәллек кертә.

Мөселманнарга дини ихтыяҗлары турында мәгълүматны хөкүмәткә җиткерү мөмкинлеге Екатерина II тарафыннан «мәгърифәтле монархиянең» яңа кануннар җыелмасын төзү өчен чакыртылган Уложенная Комиссия (1767-1768) депутатларга биргән наказларда теркәлә. Мәскәүгә килгән 572 депутат арасында 29 мөселман (24 татар, 3 башкорт, 2 бохарлы), 2 керәшен татары була.

Әйтергә кирәк, мөселман депутатлары наказларының күбесе икътисади эчтәлекле: алар икътисади чикләүләрне юкка чыгаруны, татар морзаларына дворян хокукларын бирүне сорыйлар.

Дин тоту өлкәсендә гозерләре дини тормыш алып бару өчен уңай шартлар булдыруны сораудан гыйбарәт була:

• көчләп чукындыруны туктату;

• христиан динен кабул иткән кавемдәшләрен рус авылларына күчерү яки аерым урнаштыру;

• ислам динен һәм мөселманнарның дини хисләрен кимсетүчеләргә каршы махсус канун кабул итү;

• Мәккәгә хаҗ кылырга бару һәм кайтуга рөхсәт, бу ерак сәфәр өчен паспортлар бирү;

• мәчетләр төзүдәге чикләүләрне юкка чыгару, һәр авылда гыйбадәтханә, шул исәптән, таш биналысын да, төзергә рөхсәт итү;

• рус хакимияте билгеләп куйган башкорт старшиналарының шәригать мәхкәмәсе карарларына кысылуларын туктату;

• шәригать мәхкәмәсен руханилар карамагында калдыру;

• ахуннарны шәригать мәхкәмәләренә сайлап кую;

• мөселман руханиларының аерымланган статусларын билгеләү һәм аларны салымнардан азат итү;

• һәр мәчеткә өчәр кеше: мулла, мөәзин һәм мөҗәвир (каравылчы) билгеләү һәм аларны башка һәр төрле эшләрдән азат итү.

## 8. Йомгак

XVII йөз – XVIII гасырның урталарына кадәр дини дәвамчанлыкны тәэмин иткән һәм югалтканны кире кайтару өчен җирлек әзерләгән түбәндәге институтларны күрсәтергә мөмкин: авылларда дини йолаларны башкаручы абызлар, мәчеттә руханилар вәгазьләве һәм җәмәгать намазларына җыелу, Госманлы дәүләтеннән һәм Урта Азиядән алып кайтылган, нигездә, төрки телдәге дини хезмәтләр һәм суфи әдәбият, чит илләрдәге мәдрәсәләр, шунда укып кайткан голәмә-суфилар һәм алар ачкан уку йортлары.

XVII гасыр ахырыннан башлап күзәтелгән чукындыру кампанияләре абызларның, суфиларның, ахуннарның дини активлыгы артуга, авыл мөселман җәмгыятьләренең берләшүләренә һәм йомылып яшәүләренә зур йогынты ясый.

Безнең уебызча, XVII–XVIII гасырларда ахуннар Казан ханлыгы заманында булган сәед белән кала һәм сала мөселман мәхәлләләре руханилары арасында булган урта идарә институтын гәүдәләндергәннәр. Дәүләтчелек юкка чыгу шартларында дин әһелләре арасында горизонталь элемтәләр тагын да ныгыган, бу мөнәсәбәтне көйләүдә беренче планга гыйлем дәрәҗәсе чыккан. Чөнки имамнар да, гади халык та – төрле дини мәсьәләләрдә яисә мирас бүлү карарларыннан риза булмаганда, башка низаглы очракларда үз сүзен әйтерлек – гыйлемле, төбәк мөселманнары тарафыннан хөрмәт ителгән һәм абруйлы шәхескә мохтаҗ булганнар.

Шундый шәхесләр табылган, акрынлап, аларны чит илләрдә укып кайткан гыйлемле кешеләр алыштырган. Бер үк вакытта, мәдрәсә ачып, мондый шәхесләр төбәк өчен мәхәллә руханилары әзерли башлаганнар. Ислам традициясе буенча, мәхәллә руханиларын авыл халкы билгеләсә, ахуннарны руханилар сайлап куйган. Рус хакимиятенең кызыксынуы булмау һәм татар аксөякләренең авылларда йогынтылары бик йомшак булу шартларында, дини тормышны оештыру буенча барлык вәкаләтләр ахуннар кулында туплана барган. Алар, әлбәттә, руханилар өстеннән махсус күзәтчелек итмәгәннәр, ләкин муллаларның үз арасында чыккан төрле дини һәм башка мәсьәләләрне, шулай ук мәхәллә белән имам арасында бәхәсләрне караганнар, чыгарган карарлары үтәү өчен мәҗбүри саналган. Авыл халкы үзе сайларга җыенган дин әһеленең белем дәрәҗәсен билгели алмау сәбәпле, бу вазифаны да ахун башкарган яисә үз мәдрәсәсендә укучы бер шәкертне тәкъдим иткән. Ш.Мәрҗани һәм Р.Фәхреддин хезмәтләрендә исемнәре теркәлгән, чит җирләрдә яки Сәгыйть бистәсендә укып кайтып, мөдәррислек итүче ахуннар нәкъ менә төбәк дини административ һәм шәригать мәхкәмәсе җитәкчеләренә әверелгән дип уйлыйбыз.

XVII гасыр уртасында беренчеләрдән булып Мәвараэннәһердә дини белем эстәп

кайкан Юныс бине Иванай ахун «Болгар җире ун өлештән тора, халкына да шәригать кушуы буенча гошер (җыелган уңыштан салым. – **И.З.**) бирү тиеш» дип фәтва биргән. Фәтвада сүз салымны мәхәллә руханиларына тапшыру турында барган (*Мәрҗани Ш. Күрс. хезмәт. 233-234 б.; Фәхреддин Ризаэддин. Күрс. хезмәт. 40-41 б.).* Юныс бине Иванай ахун бер төбәктә дини идарә белән шөгыльләнсә дә, аның фәтвасы Урта Идел буеның барлык мөселманнарына таралган. Бу яктан караганда, ул Россия төбәкләре өчен фәтва бирүче мөфти сыйфатында чыгыш ясаган.

Дини активлыкның көчәюе XVII йөз ахыры – XVIII гасыр башында Көньяк Уралга күченгән татар имамнарының, хакимият күзәтүе йомшак булудан файдаланып, автоном дини үзидарә оештыруларында да ачык күренә. Көньяк Уралны 10 өлешкә бүлеп, шулар өстеннән күзәтчелек итүче һәм авыл имамнары тарафыннан сайланган Казан ягыннан килгән 10 ахун-голәмә дин әһелләреннән имтихан алу, авылларга, авыл җәмгыяте белән килештереп, имамнар билгеләү белән дә шөгыльләнгәннәр**.**

Без Урта Идел буенда оеша башлаган дини үзидарә моделе күпләп татарлар күченеп килгән Көньяк Урал төбәгенә шуннан «күчереп алынган» дип уйлыйбыз. Авыл җәмгыятьләре, әле мәдрәсәләр системасы булмау сәбәпле, җәмәгать намазына җитәкчелек итү һәм дини ритуаллар башкару өчен белемле һәм тәкъва имам сорап, төбәк ахунына мөрәҗәгать иткән. Ахуннар күчмә һәм ярым күчмә тормыш алып баручы башкорт җәмгыятьләренә дә үз кешеләрен урнаштырганнар дип уйларга нигез бар. Чөнки күчмә тормыш рәвеше руханилар әзерләүдә зур кыенлыклар тудырган. Идел төбәгеннән килгән абызны, имамны билгеләү, күченеп килүчеләр һәм башкорт вотчинниклары бергә яшәгән авылларда ике төркемнең дә дин кардәшләре булуын ассызыклап, үзара яхшы мөнәсәбәтләр урнаштырырга мөмкинлек биргән. Нәкъ менә шушы үзара килешеп яшәү тәртибе күченеп килгән ясаклы татарларга һәм башка халыкларга башкорт сословиесенә язылырга уңай шартлар тудырган. Башкорт авылларына билгеләнгән муллалар мәҗүси динендәге башка этник төркемнәрне дә вәгазьләү белән шөгыльләнгәннәр.

Руханиларның һәм мөселманнарның дини активлыгы арту патша хөкүмәтенең христианлаштыру сәясәтен көчәйтүенә бәйле булган. Шул сәбәпле, мөселман авылларында эчке мобилизация көчәйгән дип уйларга нигез бар.

Идел-Урал төбәгендә яшәүче православие динендә булмаган йомышлы һәм ясаклыларны чукындыру турында патшаның 1681 ел 16 май указына каршы баш күтәрүне мөселман руханиларының «изге сугыш» дип игълан итүе исламның халыкны оештырырлык, бер йодрык итеп туплярлык көч булуын, дин әһелләренең исә мөселман җәмгыятьләре өчен җаваплылыкны үзләренә алуларын күрсәтә. Хакимияткә каршы дини хокукларны яклап, кораллы чыгыш 1681-1683 елларда җиңү белән тәмамлана. Шушы вакыттан дини көнитешне оештыруда яңа этап башлана.

Хакимиятнең 1740–1764 елларда массакүләм чукындыру сәясәте дә мөселманнар тарафыннан көчле каршылыкка очрый һәм имамнарның да, мәхәллә әгъзаларының да активлашуына китерә. Бу елларда, мәҗүсиләрдән аермалы буларак, күпчелек очракта авылларда берничә генә кешенең (гаилә) дин алыштыруы, бу шәхесләрнең бәлагә тарып яки гомерлек рекрут хезмәтеннән калу өчен генә бу адымга барганлыгын раслап тора.

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре докторы*

# БАБАЛАР ҖИРЕНӘ ТАРТЫЛУ

Әнием ягыннан да, әтием ягыннан да ата-бабаларым Казан ягыннан. Ике бабам да, әбиләрем дә Әстерхан губернасына әле 1917 елгы инкыйлабка хәтле үк килгәннәр.

Авылыбызга нигез әтиемнең атасы Гыйләҗетдин бабам һәм тагын Казан ягыннан килгән биш кеше тарафыннан 1917 елның көзендә, әле Вакытлы хөкүмәт идарә иткән вакытта салынган. Икенче елның язында аларга Урта Идел буйларыннан күченгән татарлар кушылган. Алар авыл кору өчен Идел тамагының иң матур урыннарының берсен сайлаганнар. Дәүләтчелегебезнең мең еллык тарихын гәүдәләндергән бу тирәләрнең гүзәллеге хакында 1072–1074 елларда атаклы болгар әдибе Мәхмүт Кашгари язып калдырган.

*Идел суы ага торыр,*
*Кыя төбен кага торыр.*

Әгәр дә халкыбызны ике шәхеснең исеме белән генә күрсәтергә кирәк булса, мин Габдулла Тукай һәм Илһам Шакиров исемнәрен атар идем. Тукай исеме буенча беркем дә бәхәсләшеп тормас дип уйлыйм, шулай ук Шакировка да каршы килүче булмас. «Иске кара урман» һәм «Ак калфак» җырларын җырлаганда, аның тавышының матурлыгы һәм көче таң калдыра, аңа карап сихерләнәсең. Күңелдә ихтыярсыз ата-бабалар җиренә, аның җырларына һәм йолаларына тартыла башлыйсың.

Музыкаль сәләтләре әллә ни зур булмаса да, әтием «Сарман» җырын үзенә бер соклану белән ярата торган иде. Олыгайгач, мин үзем дә бу җырны яратып җырлый башладым. Бөтен мәҗлесләрдә дә җырламыйча калмый идем. Ә Тукайның «Туган тел»ен мин үзем өчен җырлыйм. Мин аны бер дә туктамыйча җырларга әзер, аның һәр сүзе күңелнең әллә нинди яшерен кылларын тибрәтергә сәләтле. Бу күңелдә үз балаңны мең тапкыр кочып сөйсәң дә, аз булган кебек халәт тудыра.

Авылыбыз тарихы буенча материаллар туплаганда, мин Гөлчирә Касыйм кызы Туйбактина белән таныштым. Аның әтисе Касыйм Шаһиҗиһан улы Әстерхан мөселман хәрби-революцион комиссариаты рәисе булган. Мирза Сәгыйтовтан кызы Әминәгә мирас булып калган буш яткан җирләрдә безнең Яңа Болгар авылын салуда якташларына нәкъ менә шушы кеше ярдәм иткән.

Гөлчирә Касыйм кызы вафат булганнан соң, аның атасы турында җыйган барлык материаллар, фотолар минем кулга күчте. Ул фотоларның берсе 1911 елда Әстерханда төшереп алынган. Шул елны безнең шәһәргә Габдулла Тукай килгән. Ул биредәге татар зыялылары белән очрашкан. Фотода шул очрашу сурәтләнгән. Алар арасында «Идел» газетасы редакторы Сәгыйть Рәмиев, артист Зәйни Солтанов, Касыйм Туйбактин һәм башка күренекле шәхесләр бар. Мин ул фотоны тирән хөрмәт белән кулга алам. Бәлки әле ул фотоны Тукай да үз кулларында тоткандыр! Менә шулай мин «Туган тел»нең авторы белән очраштым!

Язмышымның икенче зур бүләген мин 1992 елда алдым. 18-23 майда өлкәдә Черноярский районының Ташлы Яр авылында яшәгән татар шагыйрәсе Газизә Сәмитованы искә алуга багышланган татар мәдәнияте көннәре узды. Татарстаннан



*Тукай Әстерханда. Басып торучылар (сулдан уңга): Абдрахман Әбүбәкеров – укытучы, Әбдрәхим Басыйров – «Идел» газетасы хезмәткәре, Шәһид Гайфетдинов – укытучы, Әбүбәкер Вәлиев – укытучы, Зөлкарнәй Байкин – укытучы. Утырганнар: Касыйм Туйбактин – укытучы, Зәйни Солтанов – артист, Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Сафи Биккин – приказчик, Давыт Мәхмүтов, Әҗәрхан Мәхмүтова – аның хатыны, Фатыйма Динникаева. Идәндә утыралар – Зәйни Солтановның энесе, Басыйр Абдуллин, Әбдрәхим Динникаев, Туктар Динникаев – аптекарь.*

мәдәният хезмәткәрләренең зур төркеме килгән иде. Аларның бер төркеме безнең авылга килде. 21 майда без кунакларны Икрянин районы чигендә каршы алдык. Автобуска кердек. Анда мин озын гына ябык гәүдәле, башына түбәтәй кигән, тәрәзәдән карап утыручы бер иргә игътибар иттем һәм Алабугадан килгән таныш профессорым Леонид Шәйсолтан улы Арсланов янына килеп, аның белән сүз башладым. Шунда «Идел» газетасының редакторы Әлфия Дәүләтова колагыма пышылдап кына: «Шамил абый, биредә Илһам Шакиров та бар!» – диде. Башка килгән беренче уй: «Булмас ла!» иде. Шуннан «Нишләп булмасын! Нишләп соң әле мин аны танымадым?!» дип уйладым.

Без Бертюль балык заводына килдек. Кунакларны һәм без – каршы алучыларны цехлар буенча йөрттеләр һәм яшь мәрсин балыкларын үстерү циклларын күрсәттеләр. Мин Илһам Шакировның төркемнән аерылып йөрергә тырышканына игътибар иттем. Аның янына килергә батырчылыгым җитмәсә дә, мин аны күз уңыннан югалтмаска, гел аның артындарак йөрергә тырыштым. Үзе белән янәшә туры килүдән файдаланып, ул миннән мәрсин балыкларының үзенчәлекләре хакында сорады. Мин аңа җавап бирдем. Без шулай итеп сөйләшеп киттек. Авыл кешеләречә тыйнак, тыныч һәм үзен-үзе тотышында бернинди дә мактанчыклык күренми иде. «Хәтеремдә әле, клубыгыз искерәк кенә агач бинада иде», – диде ул. Минем дә исемә төште. Минем әле малай чак иде. Язгы ташу вакыты, артистлар елганы аккан бозлар аша кичәргә батырчылык итмәделәр. Башка чара юк, зал шыгрым тулы, бар да артистларны көтә. Тамашачылар хәтта бусагага утырганнар, күп кеше өйләреннән урындык күтәреп килгән. Безнең егетләр елганы кичәр өчен бозлар арасына такталар салып, артистларны авыл ягына чыгарга чакырдылар. Ләкин берсе дә елганы болай кичәргә батырчылык итмәде. Бары тик Илһам Шакиров белән баянчысы Рөстәм Вәлиев кенә риза булды. Илһамны иптәшләре чыкмаска үгетли башлады. Ләкин ул: «Кешеләр көтә бит!» – дип, авыл ягына чыкты. Кунакларның бик сирәге генә мондый батырлыкка барырга мөмкин иде. Авыл бүгенгә хәтле Илһам Шакировның бу батырлыгын һәм аның берүзе сәгатьтән артык җырлавын хәтерли әле.

Безнең әңгәмә дәвам итте.

– Илһам абый, сезнең абыегыз да әйбәт җырлый дип әйтәләр, – дидем мин.



*Илһам Шакиров. 1992 ел.*

– Әйе, – диде ул. – Шофёр булып эшли. Махсус музыкаль белеме юк. Без барлыгы биш туган.

Аннары ул безнең авыл турында сорашты. Мин туган якны өйрәнүче буларак, аңа авылыбыз тарихы турында сөйләдем. Аңа әбиемнең – әтиемнең әнисенең Казан губернасының Әхмәт өязендәге Әхмәт авылыннан булуы хакында әйттем. Илһам абый кызыксынып китте.

– Бу авыл бүген Сарман районына карый, Сарманнан өч чакрым гына ераклыкта, – диде ул. – Мин үзем дә шул тирәләрдә туганмын!

Шунда минем зиһенем ачылып китте! Менә каян килә икән ул минем «Сарман» җырына мәхәббәтем! Сарман – минем ата-бабаларымның туган җирендә икән бит! Бу тартылуны генетик хәтер белән генә аңлатырга мөмкиндер. Аеруча Илһам Шакировның ата-бабалары белән минекеләр бер тирәдә яшәгәннәр.

Без кунакларны табигатькә алып чыктык. Мондагы тәмле сыйлар белән кунак иттек: мәрсин балыгыннан уха пешердек, кара уылдык белән сыйладык.

Сабан туйларында була торган кайбер уеннарны искә төшердек. Биергә дип уйлагач, баянчыбызның каядыр китеп юкка чыкканын абайладык. Шунда мин үзем белгән «Әтнә» көен уйный башладым һәм Илһам абый беренчеләрдән булып биергә чыкты. Аны биетү минем хәтта хыялыма да кереп карамаган иде.

Кичке якта без Илһам Шакировны һәм тагын берничә кунагыбызны авылыбызның абруйлы кешесе Айшәхан Мәҗитова янына алып бардык. Ул авылга 1917 елда, әле алты яшьлек бала вакытында әтисе Әбүбәкер белән килгән булган. Аның өендә һәркайда чисталык, җыйнаклык, күпләгән чигелгән тастымаллар, чаршау-чыбылдыклар, келәмнәр. Өйдә безгә бала чагыбыздан таныш «Зингер» тегү машинасы, сандык, йөрми торган борынгы дивар сәгате, шәмаил һәм көчле тавышлы будильник – әбекәйнең яшьлек хатирәләрен яңартып тора.

– Илһам, балам, саулыгың ничек? – дип сорады әби, гадәттәге кунак кергәч укыла торган догадан соң.

Ул безгә, аның күз алдында үсеп зур булган кешеләргә дә шулай мөрәҗәгать итә. Илһам абыйның җавабы да шулай ук бик гади генә булды.

Кич белән кунаклар һәм авыл үзешчәннәре катнашында концерт булды. Илһам абый үз чыгышын икенче каттагы бүлмәсендә утырып көтте. Мин хөрмәт йөзеннән булса да чыгыш ясаучыларны тыңлый алмадым, Илһам абыйны бүлмәсендә ялгыз утыртып калдыру итагатьсезлек булыр иде. Ул миннән:

– Мин җырлаганда да шушында утырырсыңмы? – дип сорап куйды. «Мин сезнең чыгышыгыз вакыты җиткәнне көтеп утырам», дип әйтүе миңа уңайсыз иде. Залда җырлаучыларны икенче каттан гына тыңлап утыру, әлбәттә, бигүк әйбәт түгел, ләкин андый артистлар бездә күпләгән, ә менә Илһам Шакировка аларның берсе дә җитми. Тукай белән Шакировны алыштырырдай шәхесләрнең киләчәктә тагын тууы бик шикле. Минем, бәйләнгән кебек, Илһам артыннан тагылып йөрүем әнә шул аңа булган чиксез хөрмәтем һәм аның зурлыгын аңлаудан иде.

Шунда мин, түзмичә, әйтеп куйдым:



*Кунаклар белән Яңа Болгар мәктәбендә очрашу. 1992 ел.*

– Илһам абый, «Сарман»ны җырларсыз әле?!

Ул минем хисләрне аңлады бугай, кулына кәгазь кисәге алып, җыр исемен һәм минем исем-фамилиямне язып куйды. Мин: «Мөмкин булса, «Туган тел»не дә», – дип өстәдем.

– Ярар, «Туган тел»не дә җырлармын, – дип килеште Шакиров.

«Сарман» җыры игълан ителгәч, ул аны: «Шамил Корбангали улы соравы буенча җырлыйм. Ул да чыгышы белән шул яклардан икән. Мин үзем дә шул яклардан», – диде. Соңыннан ул концертта катнашкан барлык җырчыларны сәхнәгә чакырып чыгарды һәм алар белән бергәләп «Туган тел» җыры белән концертны тәмамлады.

Куплет арасында баян уйнаган арада Илһам җырның икенче строфасын телдән кабатлап, тамашачыларны да аягүрә бастырды һәм барысы да Илһамга кушылып җырлый башлады. Берни белән дә чагыштырып булмый торган рухи күтәренкелек белән һәм йөзләрен күзләрендә җемелдәгән яшьләренә чылатып, яше-карты «Туган тел»не җырлап, кичә тәмамланды.

Барысы да Илһам Шакировка кушылып җырлауларыннан канәгать иде. Менә шундый матур, тәэсирле булып истә калды ул очрашу.

**Шамил СИРАҖЕТДИНОВ,**
*Әстерхан шәһәре.*

*1992 елгы фотоларны*
**Мидхәт ШАКИРҖАНОВ** *төшергән.*

*Гали Хуҗиның туууына – 110 ел*

# БҮГЕН ДӘ УЙЛАНЫП УКЫРЛЫК



1930 елларда каләм тибрәтә башлап, әдәбиятыбыз мәйданында үз урынын алган үзенчәлекле каләм иясе, фронтовик шагыйрь Гали Хуҗиның (1912–1966) тууына – 110 ел. Эзләнеп укысаң, аның әсәрләре әле бүген дә дулкынландыра, уйландыра.

«Әдипләребез» дип исемләнгән библиографик белешмәлектә бирелгән мәгълүматларга караганда, булачак шагыйрь 1912 елның 17 октябрендә Татарстанның Апас районы Карамасар авылында тимерче гаиләсендә туа. Авылда җидееллык мәктәпне тәмамлый, аннары Казанга килеп, авыл хуҗалыгы институтының хәзерлек курсларында укый. Курсларны тәмамлагач, институтка кабул ителә, ләкин авырып китүе сәбәпле, укуын ташларга мәҗбүр була. 1932–1941 елларда башта «Кызылармеец» газетасында әдәби хезмәткәр, соңыннан «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасы редакциясендә җаваплы секретарь һәм редактор урынбасары, 1941–1942 елларда ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетында пропаганда буенча секретарь вазифаларын башкара. 1937–1941 елларда, төп эшеннән аерылмыйча, Казан дәүләт педагогика институтының кичке бүлегендә укый.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Гали Хуҗига, күзе начар күргәнлектән, хәрби хезмәттән азат итә торган бронь бирелә. Ләкин ил язмышы хәл ителгән бер вакытта шагыйрь читтән генә күзәтеп тора алмый, комсомолның Татарстан өлкә комитетында эшләп йөргән җиреннән, үзе теләп, фронтка китә. Сугышның ахырына кадәр Беренче Украина фронтында татар телендә нәшер ителә торган «Ватан намусы өчен» газетасының җаваплы сәркатибе эшен алып бара. Аңа алгы сызыкта да еш булырга туры килә. Ут эчендә курку белмәс милләттәшләребез белән очраша, аларның батырлыклары турында мәкаләләр бастырып чыгара. Фронттагы сугышчан хезмәтләре өчен үзе дә Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә.

Еллар үткәч, фронтовик шагыйрь Мөхәммәт Садри Гали Хуҗиның тууына 60 ел тулуга багышланган мәкаләсендә болай дип искә алачак: «Днепр буйларыннан Берлинга кадәр сузылган сугыш юлларын бергә үттек. Ул һәрвакыт җыйнак, сабыр булуы белән бергә, һәркем күңеленә ачкыч тапты. Аның сугышка кадәр яшьләр газетасында эшләп алган тәҗрибәсе фронт газетасына бәя биреп бетергесез зур ярдәм итте. Ул газетага беренче хәбәрләрен, шигырьләрен җибәргән солдатларда, сержантларда өметле каләм ияләрен сиземләде. Андыйларны командование аша редакциягә чакыртты, иҗади эшкә канатландырды» *(«Социалистик Татарстан», 1972 ел, 12 октябрь).*

Сугыштан соң да Гали Хуҗи журналистлык хезмәтен дәвам иттерә: «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасының үз хәбәрчесе, аннары «Яшь сталинчы» («Татарстан яшьләре») газетасының редакторы булып эшли. 1954–1962 елларда ул Татарстан Язучылар союзы каршындагы яшь язучылар белән эшләү бюросына җитәкчелек итә. 1963 елдан гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул профессиональ язучы сыйфатында әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә.

Гали Хуҗиның шигырьләре көндәлек матбугатта утызынчы елларның беренче яртысында күренә башлый. «Шатлык» дигән беренче шигъри җыентыгы 1936 елда басылып чыга. Утыз биш еллык иҗат дәверендә Гали Хуҗи дүрт дистәдән артык поэма, баллада һәм шигъри цикллар иҗат итә. Һәм алар ул кичеп үткән чорның шигъри елъязмасы булып бәяләнергә хаклы.

Шагыйрь үзенең 54 нче туган көнен каршылар алдыннан, 1966 елның 13 октябрендә вафат була.

Сайтыбызга урнаштырылган радиотапшыруда укучыларыбыз игътибарына Гали Хуҗига кагылышлы уникаль язмалар тәкъдим ителә. Ул шагыйрьнең үз тавышы белән ачылып китә. Тарихы болай. 1960 елда шагыйрь Татарстан радиосына килеп, үзенең «Идел хикәясе» дигән поэмасыннан бер өзек укый. Ул шул чакта бер тапкыр эфирда яңгырый да байтак вакыт онытылып тора. 1972 елда радио мөхәррире, шагыйрь Әхмәт Рәшит арабыздан вакытсыз бакыйлыкка күчкән каләмдәшләре истәлегенә багышланган тапшыру әзерли. Һәм менә шунда 12 ел буе архивта тузанланып яткан әлеге язма янә хәрәкәткә килеп ала. Хәер, шуннан соң радио тапшырулар әзерләгәндә, аңа мөрәҗәгать итүче булмаган. Сәбәбе аңлашыла: әсәрнең шул заман идеологик таләпләренә туры китереп, коммунистлар партиясенә, Ленинга дан җырлаган урыннары шактый. Ә инде 1990 еллар башыннан андый тематика матбугатта үзенең актуальлеген югалтты. Ләкин бу язма, әсәрнең үзеннән, эчтәлегеннән бигрәк, безгә тарихи истәлек буларак кадерле. Ул – шагыйрьнең үз тавышы сакланып калган бердәнбер аудиодокумент.

Аннары тыңлаучыларны тагын бер гаҗәеп кызыклы язма көтә. Сез бөек композиторыбыз Салих Сәйдәшевнең Гали Хуҗи шигыренә язган «Халисә» дигән мәшһүр җырын ишетерсез. Заманында халык тарафыннан яратып кабул ителеп, туйларда, бәйрәм мәҗлесләрендә телдән төшмәгән әлеге җыр профессиональ башкаручылар репертуарында да ныклы урын алган. Ул вакытта бит әле, җырларны хосусыйлаштыруны белгән кеше дә юк, безнең көннәрдәге кебек, аерым җырчылар «бу җыр – минеке, монысы – синеке» дип, тавыш кубармыйлар. «Ай Ходаем, бу җырны башкалар җырласа, мине уздырыр», – дип курку юк. Бер үк әсәрнең берничә җырчы репертуарында булуы гадәти хәл. Иҗат дөньясында киң күңеллелек хакимлек итә. Шуңа күрә дә Татарстан радиосы фондында «Халисә» җыры Хәдичә Гыйниятова, Рәшит Ваһапов, Фагыйлә Тимерова, Усман Әлмиев, Вафирә Гыйззәтуллина язмаларында саклана. Әле быел гына яшь җырчыбыз Рөстәм Егоров та шушы үлемсез әсәрне башкарып, безнең эфирыбызны бизәде. Кыскасы, хәзер сез әлеге атап үтелгән җырчыларның барысын да ишетерсез. Һәм тагын шунысы кызыклы: моны сез үзегез дә сизми-тоймый калмассыз, дип уйлыйбыз, башкаручыларның һәрберсе җырның хасиятен, эчтәлеген, моңын үзенчә ачып биргән, аны үзенә генә хас бормалар-мелизмнар белән бизәгән. Нәтиҗәдә милли музыкаль сәнгатебезнең йөзек кашлары булып торырдай яңа язмалар барлыкка килгән.

Бу QR-код аша сайтыбызга кереп, җырны башкарган олпат җырчыларыбызга, аның көен иҗат иткән Салих Сәйдәшевка һәм шагыйрь Гали Хуҗига рәхмәт әйтеп, якты рухларын искә алып тыңларсыз.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

# СӘЯХӘТЧЕ ЧЕБЕННӘР

ЮМОРИСТИК ХИКӘЯ

Табигать кочагына сыенып утырган бер авылда Чыжбетдин, Пыжбикә, Мәхәббәтнур һәм Җидекүз кушаматлы чебеннәр яши иде.

Җиңел автомобиль эченә эләгеп, ихтыяри-мәҗбүри рәвештә шәһәргә сәяхәткә кузгалырга туры килде аларга. Чокыр-чакырлы кыр юлыннан асфальт трассага чыкканчы башларын бәрә-бәрә аңнарын югалтыр чиккә җиттеләр, машинага ник кереп кунаклаган көннәренә төштеләр, бичаралар. Асфальт юлда тирбәлеп бара башлагач кына хәл кайтты үзләренә.

Иң элек Мәхәббәтнур маҗаралары башланды. Ул машинада утырып барган гүзәл туташка үлепләр гашыйк булды. Шул гыйшкын аңлатыр өчен, шашынып, кызның яңа өлгергән шалкан кеби тыгыз вә йомры күкрәкләренә, агач эшкәртү станогында шомартып ясалган нәкышлы өстәл аяклары сыман төз вә матур ботларына кунды. Әмма дә ләкин, газетаны игътибар белән укып барган туташыбыз мәсьәләнең асылын аңламады, газетаны уртага бөкләп, уңайлы мизгелдә Мәхәббәтнурның сыртына кундырды.

– Эх, ошбу дөньяда чебен мәхәббәтен аңлар кеше тумаган икән әле, – дип, авыр көрсенде дә җан тәслим кылды, бахыр.

Бар нәрсәдән хәбәрдар, үтә дә кызыксынучан холыклы Җидекүз иптәше Мәхәббәтнурның гүзәл туташ аякларына сыланып, соңгы сулышын алуына көнләшеп тә куйды хәтта.

– Язмышлардан узмыш юк шул, туганкай, – дип, үзалдына сөйләнеп куйды Җидекүз.

Чебеннәр үз кардәшләрен югалтуны тиз онытты. Чыжбетдин белән Пыжбикә, бәласеннән башаяк дигәндәй, аулаграк почмакка посып, йокыга талды. Җидекүз машинаның ачык тәрәзәсеннән муенын сузып, дөньяны хозур кылып бармак булды. Бу гамәленә үкенде үкенүен, тик соң иде шул: җил Җидекүзне йолкып алып, арттагы машина пыяласына китереп бәрде. Җидекүз гомеренең соңгы мизгелләрендә Мәхәббәтнур кебек хыялланып алу түгел, үз телендә ләхәүләсен укырга да өлгермәде. Чыпылт иткән сәер тавышка уянып киткән Пыжбикә арттагы машина тәрәзәсенә береккән Җидекүзне күрде.

– Юл йөрү кагыйдәләрен үтәмәү шулай фаҗигале тәмамлана лабаса, – дип, Пыжбикә үзенең ирексездән саркып чыккан күз яшьләрен ефәк канатлары белән сөртеп алды.

Ниһаять, сәяхәтчеләр шәһәргә килеп җитте. Чыжбетдин белән Пыжбикә башта, төтенле-газлы һаваны, транспорт тавышын күтәрә алмыйча авырып ятты.

«Никләр генә эләктек шушы машинага? Саф һавалы авылыбызга тизрәкләр генә кайтып китсәк иде», – дип, беравыздан уфтандылар. Җан иясе кайда да ияләшә дигәндәй, берничә көннән дусларыбызга хәл кереп, кала урамнарын урап кайтырга

ниятләделәр. Туганнан бирле татар авылында гомер кичергәнлектән, урысчасын да такы-токы гына белгән Пыжбикә диварлардагы инглиз телендәге игъланнарны күреп, балавыз сыгарга ук тотынды.

– Дөньяның чигенә барып эләккәнбез, кире кайтулар булмас, ахры!

Чыжбетдин дә шылтыр җибәргән иде бу ят-сәер күренешләрдән, шулай да сиздермәскә тырышты.

– Ярар, шыңшыма әле. Әнә сыраханәгә кереп чыгыйк, күңелләрең күтәрелеп китәр.

И-и-и, сыйландылар да соң. Һәр чокырдан берәр йотым эчә торгач, шартлар чиккә җиттеләр. Пыжбикә: «Булды, эчеп үләм бугай», – дип, урамга алданрак чыгып китте. Шунда ук аңа бер шәһәр чебене килеп бәйләнде.

– СПИД белән хәлләр ничек? Әйдә, мәхәббәт уены уйнап алабыз, – диде текә чебен, очып куна-кунышка.

Пыжбикә әллә үзенең авылча беркатлылыгы белән, әллә азрак исереп китүеннән, ят чебеннең тел төбен аңлап җиткермәде.

– Рәхмәт, спирт кирәкми. Әле генә сыраханәдән чыктым.

– Спирт димим мин, СПИД дим. Шундый-шундый йогышлы авыру, ягъни мәсәлән, – дип аңлаткандай итте ят чебен.

– Ә-ә, безнең авылда ишеткән-күргән нәрсә түгел, – диде Пыжбикә.

Тик җөмләсен тәмамлап бетерергә дә өлгермәде, ят чебен аны диварга кысып та куйды.

Чыжбетдин ыңгыраша-ыңгыраша сыраханәдән сөйрәлеп килеп чыкканда, Пыжбикә сулкылдый-сулкылдый елап утыра иде.

– Эх, син, Чыжбетдин! Мине ялгызымны калдырып, ни гомер сыраханәдән чыга алмыйча йөрисең. Бер авылда яшәп, бер мәртәбә кочаклаганың да булмады. Шәһәргә аяк басарга өлгермәдек, инде бәйләнделәр дә үземә. СПИДны белмим, коронавирус йоктырмаган булса ярый инде шәһәр мөртәте, – дип өзгәләнде Пыжбикә.

Чыжбетдиннең үзенең дә хәле хәл иде шул.

– Монда дөнья бөтенләй башкача икән, – дип сөйли башлады ул. – Сыраханәдә үзем генә калгач, яныма шәһәрнең чебен кызы сыенды. «Ике мең сум бирсәң, мин – синеке», – ди. Авылдан ялгыш кына килеп эләктем шәһәргә, акчам юк, дим. Акча булган очракта да, авыл халкы синең кебек кәнтәйләргә акча туздырмас, утын-печән хәстәрләргә тотар иде, дим. Шунда кыска итәкле чебенкәй текә чебеннәргә ым какты. Бишәү ябырылды өстемә. Үзем дә куркып калмадым, эшләп үскән тирес чебене бит мин. Шәһәрнең капкорсак чебеннәрен идәнгә бәреп ектым, үземә дә эләкте, кәнишне.

– Булган беткән. Калган гомеребезне бергә үткәрербез, Пыжбикәм.

Пыжбикә шатлыгыннан очынып куйды.

Чыжбетдин белән Пыжбикә кочаклашып, күңелләрендәге әрнүләрне бушатты. Чәчен тарап утырган Су анасы фонтанында битләрен-кулларын юдылар һәм таныш җиңел машинаның авылга кайтасын көтеп тормыйча, җәяүләп, сәфәр чыгарга карар кылдылар. Агай-энеләр һәм апа-сеңелләр, олы юлда саграк йөрегез, безнең Чыжбетдин белән Пыжбикәне таптап уза күрмәгез...

**Дамир БӘДРИЕВ**

# Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## МӘСКӘҮДӘ ТАТАРСТАН РЕПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТЕ КӨННӘРЕ

Мәскәүдә Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәре Г.Тукай һәм М.Җәлил һәйкәлләренә чәчәкләр салу белән башланды. Чәчәк салуда ТР Премьер-министры урынбасары – ТРның Мәскәүдәге тулы вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин катнашты. Ул көннәрдә Россия дәүләт балалар китапханәсендә Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллинны искә алу кичәсе, балалар әдәбиятын пропагандалау мәсьәләләренә багышланган «түгәрәк өстәл», Әсәдуллаев йортында Казаннан килгән язучылар белән очрашулар булды. Бу чараларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, язучылар Равил Фәйзуллин, Газинур Морат, Рүзәл Мөхәммәтшин, Рифат Җамал, Ленар Шәех, Вера Хәмидуллина, Йолдыз Шәрәпова, Алёна Кәримова һ.б. катнашты.

Россия башкаласында Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәре Мәскәү Халыкара музыка йортында зур тантана – сәнгать осталарының гала-концерты белән тәмамланды. Анда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады. Ул шулай ук бер төркем милләттәшләребезгә Дәүләт бүләкләре тапшырды.

## РӘШИТ ВАҺАПОВКА ҺӘЙКӘЛ

Казанда Татар дәүләт филармониясе янындагы бакчада ТАССРның халык артисты Рәшит Ваһаповка һәйкәл (авторы – Андрей Ковальчук, архитекторы – Герман Бакулин) ачылды. Аны ачу тантанасында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, Түбән Новгород өлкәсе губернаторы урынбасары Олег Беркович, җырчының бертуган абыйсының оныгы Рәүф Ваһапов, җырчылар, язучылар, галимнәр, музыка сәнгате белгечләре, мәдәният әһелләре катнашты.

## ХАЛЫКАРА ШИГЫРЬ ФЕСТИВАЛЕ

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла Дагыстанда XX гасырның олуг әдибе Рәсүл Гамзатов истәлегенә багышланган традицион «Ак торналар» халыкара шигырь фестивалендә булып кайтты. Ул кумык шагыйре Әнвәр Аҗиевның музей-йортында әдәби очрашуда да катнашты.

## СӘМӘЙ ТАТАРЛАРЫНА СӘФӘР

Татарстан делегациясе Казакъстан Республикасының Сәмәй шәһәрендә эш сәфәрендә булды. Аның кысаларында «Иртыш буе татарлары: тарих һәм хәзерге заман» дип исемләнгән Халыкара фәнни-гамәли төбәк тарихын өйрәнү конференциясе, I Иртыш буе Халыкара Сабан туе үтте. ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразиев һәм башка мөхтәрәм кунаклар бөек татар шагыйре Габдулла Тукай һәйкәленә чәчәкләр салды. Һәйкәл 2016 елда, шагыйрьнең тууына 130 ел тулу уңаеннан ачылды. Татарстан кунаклары шулай ук Сәмәй шәһәренең Татар сәнгать мәктәбенең яңа бинасында булдылар. Мәктәп быел үзенең 30 еллыгын билгеләп үтә. Әлеге чараларда Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының Татар төбәкләрен өйрәнүчеләр белән эшләү комитеты җитәкчесе, профессор Альберт Борһанов, Казакъстан Республикасы Абай өлкәсе акимы Нурлан Уранхаев, аның урынбасары Шалкар Байбеков, «Иртыш моңнары» татар халык җыр һәм бию ансамбле җитәкчесе Габделхак Ахунҗанов, язучылар Фәүзия Бәйрәмова, Равилә Мурат-Шәйдуллина, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин, галимнәр Илһам Гомәров, Дамир Исхаков, Азат Ахунов һ.б.лар катнашты. I Иртыш буе Халыкара Сабан туеның абсолют батыры булып Казакъстан Республикасы көрәшчесе Эскархан Осканов калды. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров җиңүчегә төп бүләк – квадрацикл тапшырды.

## ИСТӘЛЕК ТАКТАСЫН АЧУ

Казанда Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин яшәгән йортта (Толстой урамы, 16А) шагыйрь истәлегенә мемориаль такта (авторы – Тимофей Тюрин) ачылды. Аны ачу тантанасына ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов, ТР Дәүләт Советы депутатлары, язучы-

лар, галимнәр, Республика балалар китапханәсе вәкилләре, шагыйрьнең иҗатын яратучылар килгән иде. Тантанада Минтимер Шәймиев, Фәрит Мөхәммәтшин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ, Роберт Миңнуллинның хатыны Клара ханым чыгыш ясады.

### РАЗИЛ ВӘЛИЕВКӘ 75 ЯШЬ

Казанда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт, М.Җәлил исемендәге Республика премияләре лауреаты, Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, «Дуслык» ордены иясе, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе Разил Вәлиевкә 75 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә (сценарий авторы Илсөяр Иксанова, режиссёры Илдар Хәйруллин) булды. Анда ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин юбилярга ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев котлавын, ТР Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хатын тапшырды. Бәйрәмдарны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ, якташлары исеменнән Түбән Кама муниципаль районы башлыгы һәм шәһәр мэры Рамил Муллин (Түбән Камадан «Нардуган» бию ансамбле белән) котладылар. Казакъстан Республикасы «Туран» университеты профессоры Гриф Хәйруллин видеокотлау җибәрде. Кичәдә зал тулы халык Разил Вәлиевнең җырларын (аларны Венера Ганиева, Филүс Каһиров, Рамил Миндияр, Илүсә Хуҗина, Эльмира Кәлимуллина, Рөстәм Насыйбуллин, Илгиз Мөхетдинов, Илнар Ялалов, Алмаз Хөсәенов, Чулпан Юсупова, Ильвина, Татьяна Ефремова җырлады), шигырьләрен (Г.Камал театры артистлары Фәнис Җиһанша, Фәннүр Мөхәммәтҗанов, Ришат Әхмәдуллин, Илнур Закиров, К.Тинчурин театры артисты Ирек Хафизов укыды) тыңлап хозурланды. Юбилярның якташы Алмаз Хәмзин белән бергә башкарган туган авылы Ташлык турындагы җыр да кичәгә ямь өстәде. Туфан Миңнуллин белән Марсель Галиевнең Р.Вәлиев турындагы шаян истәлекләре язылган видеоязма да тамашачы күңелендәге хатирәләрне яңартты. Кич буена сәхнәдә Рәсим Ильясов җитәкчелегендә «Казан нуры» оркестры уйнады.

### АЛИШНЫ ИСКӘ АЛУ

Абдулла Алишның туган көнендә Казанда каһарман әдип исемен йөрткән 20 нче гимназиядә (монда ишегалдында Алишның бюсты тора, музее эшли) тантаналы митинг булды. Анда катнашучыларны гимназия директоры, шагыйрә Рәхимә Арсланова сәламләде. Митингта Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рифат Җамал, Алиш премиясе лауреатлары исеменнән шагыйрь, прозаик Галимҗан Гыйльманов, каһарман әдипнең туганы Фаина Алишева, гимназия укучылары чыгыш ясады. Абдулла Алишны туган ягы – Спас районы Көек авылында, Болгарда да искә алдылар. Искә алу чараларында А.Алиш премиясе лауреатлары Рафис Корбан, Равил Рахмани, Йолдыз Шәрәпова, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, педагог Рәхимә Арсланова, Алишның туганнары катнашты.

### КЕСӘ КИТАБЫНЫҢ УНБИШЕНЧЕСЕ

«ТАТМЕДИА» бинасындагы конференцияләр залында язучы Рафис Корбанның «Тәүбә көне» китабын (анда авторның шул исемдәге һәм «Бер уч туфрак» повестьлары кергән) тәкъдим итү булды. Бу – «ТАТМЕДИА» АҖ ярдәме белән «Казан утлары» журналы китапханәсеннән» сериясендә чыгарылган унбишенче китап. Яңа китап бәйрәмендә «ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры Шамил Садыйков, басманың мөхәррире, «Казан утлары» журналының җаваплы сәркатибе Ландыш Әбүдәрова, язучылар Галимҗан Гыйльманов, Рәдиф Сәгъди, Юныс Сафиуллин, авторның авылдашы, галим Роберт Шакиров, тарихчы Рөстәм Гайнетдинов, Биектау Үзәк китапханәсе мөдире Лилия Хәмидуллина, Татарстанның халык артисты Азат Тимершәех һ.б. чыгыш ясады. Бәйрәмне шагыйрә, прозаик Шәмсия Җиһангирова алып барды.

### ЯЗУЧЫЛАР МИРАСХАНӘДӘ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы ТР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма мирас үзәгендә узды. Каләм ияләрен институт директоры, ТФАның мөхбир-әгъзасы Ким Миңнуллин сәламләде. Мирасханә җитәкчесе Илһам Гомәров татар халкының язма мирасын туплау һәм саклау турында сөйләде. Язучы, галимә Гәүһәрия Хәсәнова этисе, Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиевнең шәхси архивын Язма мирас үзәгенә тапшырды. Утырышта шагыйрә, прозаик, галимә Рифә Рахман белән шагыйрә Лилия Гыйбадуллина М.Җәлил исемендәге Республика премиясенә тәкъдим ителде.

2022 елның 16 сентябрендә 76 нчы яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, популяр җырлар авторы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Илсур Гайнетдин улы Хөснетдинов** вафат булды.

Мәрхүмнең җәсәде Арча районы Сикертән авылы зиратында җирләнде.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: Литературный конкурс «Майдан – для батыров!»:*
*повесть А.АХМЕТГАЛИЕВОЙ «Фазыл-Файзулхан»; роман Р.САБЫРА «Чисто татарское убийство», рассказ Р.САЛИМА «На этом берегу...»;*
*стихи А.СУФИЯНОВА, Л.ФАТТАХОВОЙ, Р.САЛАХА.*
*«Литература родственных народов»: рассказы Я.УМАРОГЛЫ в переводе с турецкого языка З.МОСКАУ, К.МУКАШЕВОЙ, Р.КУРБАНА.*
*«Юбилеи»: статья Ф.ГАЛИМУЛЛИНА к 75 летию Ю.Сафиуллина.*
*«Литературная критика»: статья Т.ГАЛИУЛЛИНА.*
*«Татарская литература - в переводе: статьи Р.ЗАЙДУЛЛЫ, А.СИБГАТУЛЛИНОЙ.*
*«1100 лет со дня принятия Ислама в Поволжье»: статья И.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«Память»: статья Ш.СИРАЗУТДИНОВА.*
*«Бесценные голоса»: статья к 110 -летию Г.ХУЖИ. Рубрику ведет Н.АКМАЛ.*
*«Сенной базар»: юмористический рассказ Д.БАДРИЕВА.*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: Памятник Сююмбике в Касимове. Фото А.АРАХАМИЯ.*

# IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: Literary competition «Maidan is for batyrs!»:*
*story by A.AKHMETGALIEVA «We will come, he will not come»; novel R.SABYR «Purely Tatar murder», story by R.SALIMA «On this bank of the Agidel»;*
*poems by A.SUFIYANOV, L.FATTAKHOVA, R.SALAKH.*
*«Literature of kindred peoples»: stories by Y.UMAROGLY translated from Turkish by Z.MOSKAU, K.MUKASHEVA, R.KURBAN.*
*«Anniversaries»: article by F.GALIMULLIN on the 75th anniversary of Y.Safiullin.*
*«Literary criticism»: article by T.GALIULLIN.*
*«Tatar literature in translation: articles by R.ZAYDULLA, A.SIBGATUllINA.*
*«1100 years since the adoption of Islam in the Volga region»: article by I.ZAGIDULLIN.*
*«Memory»: article by Sh.SIRAZUTDINOV.*
*«Priceless Voices»: article dedicated to the 110th anniversary of G.KHUZHI. The rubric is led by N.AKMAL.*
*«Hay Bazaar»: humorous story by D.BADRIEV.*
*From the photo archive of the magazine.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our cover: Monument to Syuyumbike in Kasimov. Photo by A.ARAKHAMIA.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Касыйм шәһәрендә Сөембикә-ханбикәгә куелган һәйкәл. *А.Арахамия фотосы.*